КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Иңнәремдә көн талпынып куйды… *Шигырьләр*. ....3
Факил САФИН. Бәхетлеләр үз илендә яши… *Шигырьләр*. ....34
Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Буа. *Роман*. ....38
Энҗе ХӨСӘЕНОВА. Мин сиңа ошарга тырышмам. *Шигырьләр*. ....108
Ләйсән НИЗАМОВА. Тиле. *Хикәя*. ....112
Илдар КЫЯМОВ. Мин – бары тик гади кеше генә... *Шигырьләр*. ....121
Рафига УСМАНОВА. Ярлыкану бәхете. *Повесть*. ....124

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Остаз. *Документаль повесть*. ....8

«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Вакыйф НУРИЕВ. Кыска юлның дәвамы яки мәңгелек сер. ....145

«КАЗАН УТЛАРЫ» – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМДА

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. «Казан утлары» – татарның «визит карточкасы». ....148

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Равил РАХМАНИ. Чын шагыйрь... Һаман да шагыйрь! ....151

*Юбилейга барышлый:* фотоархив. ....158

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Чикләрне тоташтыручы. ....160
Юлай ШАМИЛОГЛЫ. Минем тормыш тарихым. ....162

ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

Бакый УРМАНЧЕ хатирәләре *(Зөфәр Мөхәммәтшинның кереш сүзе белән)*. ....169

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Алтын Урда дәүләтендә ислам мәдәнияте. ....178
*Газиз тавышлар:* Безнең көннәрне дә язган әдип *(Галимҗан Ибраһимовның туууына – 135 ел)*. ....186
Мәңге тузмый торган «башмак» *(«Башмагым» музыкаль комедиясе премьерасына – 80 ел)*. Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара. ....187

XI БӨТЕНРОССИЯ ТАТАР АВЫЛЛАРЫ ЭШМӘКӘРЛӘРЕ ҖЫЕНЫН КАРШЫЛАП

Ландыш НӘСЫЙХОВА. Нәфис затның көчле җилкәсе... ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....159
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*№ 3 (1193) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**

*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 25.02.2022, график буенча 25.02.2022, басылып чыгу вакыты 02.03.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-0551. Тираж 9104.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

12+

© «Казан утлары», 2022 ел

Şigriət
Шигърият



Лилия
Гыйбадуллина

# ИҢНӘРЕМДӘ КӨН ТАЛПЫНЫП КУЙДЫ...

## Кош юлы[1]

Көн кагынып куйды. Иңнәреннән
Ап-ак карлар очты, карлар очты.
Тыпырчынып куйды вакыт җиле
Һәм кыбырсып куйды канат очы.

Офык аръягында таң тибенә,
Иңсәләргә иңә көн сулышы.
Вакыт җилен җилпеп үтсен икән
Каурый-канатлары очар кошның!..

Үтсен лә ул киләчәккә таба,
Тапсын ла ул анда кунар урын.
Иңнәрендә – иртәгәсе көннәр,
Карашында – үткәннәрдән корым.

Вакыт җиле җилпи. Гомер җитми.
Киткәннәргә һәр мизгеле тансык,
Көткәннәргә һәр мизгеле артык.
Бара кошлар Дөнья йөген тартып.

Канат йөзләреннән вакыт ага,
Һәм туфракка тама тир ачысы,
Сукмакларны сискәндереп куя
Көмеш моңнар тулы һәр тамчысы.

Очар кошлар юлы күктәме соң?
Очар кошлар юлы биектәме?
Кош икәнен беркөн онытыр ул,
Тел очыннан китәр ирек тәме.

[1] Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Шигырь» номинациясендә «Шоңкар» тәхәллүсле автор тарафыннан язылып, 2 урынны алган әсәр.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА (1987) – *шагыйрә; «Белла» халыкара әдәби премия лауреаты. «Мин бәхетне күрәм!..», «Тынлык кайтавазы», «Кайту» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Үткәннәре – тансык, көткән – артык…
Борылыр да эзләренә карап
Зыңлап куяр җирдә һәр дүрт тараф,
Сызлап куяр иңнәрендә канат.

Юллар такыр. Юллар себерелгән –
Канат кара юллар сөременнән.
Күкләр ерак, күкләр чиксез биек –
Күнегелгән инде, күнегелгән...

Мәгәр зыңлап тора дөнья моңы,
Изрәп ята юллар – өмет тулы.
Кошлар юлы – фәкать күк иркендә.
Иңнәремдә Көн кагынып куйды.

* * * [2]

Көн коела уйчан тәрәзләргә,
Көн урала бишек япмасына.
Тынмас дигән җырлар тына берчак,
Сынмас дигән корыч гамьнәр сына.
Төн каера сагыш казыкларын,
Төн аера учлам йолдызларны,
Төн тырнагын үтеп, көнгә керә,
Көнгә керә үткән вакыт зары.
Көн сарыла ишек яңагына,
Көн сарыла идән сайгагына,
Бишек челтәренә чуклар тезә,
Нарасыйлар баса аягына,
Тыпыр-тыпыр китә дөнья буйлап.
Дөнья уйлы, буйдан-буйга юллар.
Шул юлларга талир тәңкә чөя
Без үстергән кызлар, безнең уллар.
Өр-яңадан давы куба җирнең,
Чор үзәген тырный тынгысызлык.
Әйдә, күңел, эндәшмичә торыйк,
Көн җылысын тойыйк,
Җирне тыңлыйк.
Сөйләшмичә торыйк, азга гына
Иркен сулап куйсын таулар өне.
Үткәннәрнең кайтавазы иңсен,
Безнең сүзләр бик еракта инде:
Мәңге яшим, мәңге сөям, дигән,
Мәңге тоям, дигән, җилләр тынын,
Назларымда мең тибрәтәм, дигән,
Юлдашларның күңелләре кылын…
Төн каера сагыш казыкларын,
Төн аера янәш йолдызларны.
Таң күзенә чык-яшьләрен тезә
Парын табалмаган йолдыз зары.

[2] Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Шигырь» номинациясендә «Нәүрүзбәк» тәхәллүсле автор тарафыннан язылып, 1 урынны алган әсәр.

Көн сарыла тәрәз өрлегенә,
Көн сарыла ишек яңагына,
Җирдә юллар ята. Шул юллардан
Гомер-гомер еллар бара гына.
Гомер эзләрендә – көмеш чыклар,
Төн карасы тамган йолдыз зары,
Көн яктысы манган корыч гамьнәр,
Әллә ниләр, әллә ниләр тагы...
Ул эзләрне әле абайламас
Безнең уллар, без үстергән кызлар.
Аларны да көн яктысы сөяр,
Аларны да төн карасы сынар.
Казык йолдызларым кубып төшәр,
Тәрәзләрдән китәр көн яктысы.
Сайгакларны, ишек яңакларын,
Бишек бавын килә, их, саклыйсы...
Сарыласы килә хәтер булып,
Тере булып, җылы сагыш булып.
Уянасы килә улларымның
Сулык-сулык йөрәгенә кунып.
Уеласы килә кызым чигәр
Сөлгеләрнең бизәк өлгесенә,
Алар җирдә яшәп өлгерсенгә,
Алар җирдә сөеп өлгерсенгә,
Чөеп өлгерсенгә оланнарын
Тупырдатып, мәңге калыр булып,
Тәпи китеп, юлга җиткәннәрен
Карап калсалар да аерылып.
Аерыласы килми көн күзеннән,
Өзеләсе килми сагышлардан.
Йолдызлардан тамган көмеш чыклар
Безнең гомерләргә багышланган!..
Хәтер җебен сузып кичәгемә,
Җылы сагыш салып кичләремә,
Корыч гамьнәр корып кичәремә,
Көн сагыла тәрәз читләренә,
Көн ябыла бишек челтәренә…

## Ак күбәләк

Мин сагынган йортның чаршаулары зәңгәр,
Зәңгәр бизәкләрдән көн агыла талгын.
Утсыз тәрәзләргә, төнге пәрдәләргә
Борылам да карыйм, борылам да тагын...

Кашагага сонган орчык төсле менә
Кыбырсый да күңел, ашкына да тына.
Тәрәз төбендәге сулган яраннарга
Канатлары таплы ак күбәләк куна.

Ул адашкан, ахры. Утсыз тәрәзләрнең
Яктысы да соры, сулышы да салкын.

Шушы тәрәзләрдән шушы дөньялыкка
Ак күбәләк төсле балачагым бакты.

Сизгер сайгаклардан вакыт уза сыкрап,
Өстәлдә өч касә – кул җылысын җуйган.
Үзен-үзе кочып, кабат кырлач көтә
Сәке түрендәге иске сырган юрган.

Йортның ишегенә тотка куйган кешем –
Каенлыкта ташка чүкеп уйган исем.
Бабам кочагына сыенырга ымсып,
Җанда сызлап торган үксез сөю хисе…

Мичтә тәгәрәткән кайнар көлчә исе,
Әкиятле кичләр, кәгазь-каләм исе.
Әбкәм күзләрендә туган туфрак төсе,
Җан ярасы төсле, күз карасы төсле.

Еллар арты еллар, гомер арты гомер
Шартлап ава җиргә, кара туфрак кочып.
Вакыт күзен төртеп, нидер көтә төсле
Кашагада калган иске җитез орчык.

Зәңгәр чаршаулардан чор агыла талгын,
Шушы үксез йортка әйләнәм дә кайтам.
Салкын тәрәз төбе. Сулган яран гөле.
Канатлары таплы ак күбәләк ята.

* * *

...Җыерчыклы җылы кулларына
Елышкан күк иде пычкы сабы.
Әйдүк, кызым, диеп ымлады ул,
Иярдем мин – тугыз яшьлек сабый.

Ике яклы кул пычкысы белән
Ипләп кенә икәү агач кистек.
Дөнья түп-түгәрәк сыман иде,
Түп-түгәрәк үзе, үзе китек…

Сөйләшмәдек. Агач пышылдады.
Ишетмәдек – сабый белән карый.
Дөньялыкка тын җылысын бөркеп,
Өстебездә көзге кояш карый.

И сөйләде мыжык зарын агач,
Тирәбездә көмеш тожыр очты.
Бүрәнәнең зарын тыңлап кына
Кисә бирде ике яклы пычкы.

«Сөйләр сүзең көмеш булса мәгәр,
Дәшми торуларың – алтын, балам...»
Әбкәй алдан атлый, мин артыннан
Чыбык-чабык җыеп, тыңлап барам.

Моржалардан күтәрелде төтен,
Дөньялыкка эңгер-меңгер инде.
Сүз сөйләүче күп тә, тыңлаучы аз.
Тыңлыйк әле бераз, дисәм инде…

* * *

Кучкарында шырпы торыр иде,
Чыра телер иде балта белән…
Гомерем буе туңам. Гомерем буе
Мин шул җылы йорттан кайтып киләм.

Йолдызларга багар өчен генә
Мин дөньяга чыккан идем кебек.

Йолдызлары бозлы икән, әбкәм,
Учларымда бетте алар эреп.

Мин кемнәрнең эзләренә басам,
Минем эздән кемнәр дөнья даулый,
Гасыр тузанында ауный-ауный,
Кемнәр таңда йолдызларны аулый?..

Юллар ерак икән, дөнья фани,
Кырлач кергән төннәр озак икән.
Йолдызларын күрдем, юллар үрдем,
Кайтыйм дисәм, яшәү – тозак икән.

Йолдызлары учларымда эри,
Күкрәгемдә дөрли дөнья өне.
Төшләремдә күреп уянам мин
Ап-ак бусагалы ятим өйне.
Мин ул йортка гомерем буе кайтам,
Гомерем буе туңам, салкын монда.
Чыра телеп калдыргандыр әбкәм
Һәм шырпысы бардыр кучкарында…

## Җәйге яңгыр

Болыннардан күксел күкрәү узган,
Соңгы тамчы тетри өрәңгедә.
Кичкырынлап яуган яңгырдан соң
Җәйләүләрдән күккә күтәрелә
Җир сулышы, җир җылысы, тыны.
Яшим дисең икән – яшә генә,
Бу – тормышның иң самими җыры.
Яңгырдан соң, җәйге яңгырдан соң,
Ерганаклар һәм чиләкләр тулып,
Изрәп ята әле бая гына
Күктә йөзгән ак канатлы болыт.
Яшим дисәң, яшә иркен сулап.
Һавасы соң – юкә балы сыман!..
Кипкән икмәк тотып, күрше карчык
Көтү каршыларга әнә чыга.
«Тәчтәй-тәчтәй» диеп, сөеп кенә
Бөдрә йөнтәс сарыкларын сыйлар.
Буразналы учларында җирнең
Һәр сабые язмышына сый бар...
Тугайлардан күксел күкрәү узган,
Ялгыш эндәшсәң дә, өзелер сыман
Өрәңгедә калган өркәк тамчы.
Юкка юкса, дуамал җил тынган.
Җир сыйлана синең сулышыңа,
Җир сөенә синең сулышыңа.
Яңгыр булып, ак болытлар ява,
Җир сыена синең булмышыңа!..
Табаннары белән тойсыннар дип,
Чылаткандыр инде чүәкләрен,
Кыз-кыркынның кер бавында калган
Шәльяулыгын, зәңгәр күлмәкләрен.
Кибәргә дип элгән ак керләрен
Җәйге яңгыр юри чайкап куйган,
Гөл үстергән уңган киленнәрнең
Гөлләренә ак бөреләр уйган...
Күкрәүләре белән узып киткән
Җиләк исле җәйге җылы явым.
Җир сыена сиңа, туфрак көтә
Яңгыр булып кайтуыңны тагын…

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы*



Нәбирә Гыйматдинова

# ОСТАЗ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

Малай туды, малай! Әйдә, малкай, тоякларыңнан ут чәчрәтеп юырт инде син. Сәгытдин хуҗаң бишенче тапкыр әти. Бишенче, димәктән... Өченчесе белән дүртенчесен сабый чагында ук күкләр алды шу-ул... «Нәсел җебе шулай киселерме икән?» – дип, и, өзелде үзәк, и, сызлады бәгырь. Шөкер, беренчеләре – улы белән кызы матур гына үсеп килә. Менә үзләренә энекәш тә кайтачак.

Авыл уракка төшкән кич иде. Шатлыгы кыр-басуларга сыймаган ирнең арбасына «бәби өлеше» – яңа гына суктырган бодай тутырдылар (шыпырт кына келәтеңә бушат, туган!) Юл чокыр-чакырлы, тәгәрмәчләр, дүрт читлегә әйләнгәндәй, җирне кырып-сыдырып тәгәри, әмма Сәгытдин, дилбегәсен еш-еш кагып, атын куалавын белә. Бу хәбәре белән тизрәк өйдәгеләрне сөендерәсе!

...Иртән әтисе Шәйхетдин карт капкасын ачса – әз генә аркан аумый. Урам буйлап сибелгән бодай, сап-сары эз салып, алар турына табан сузылган. Йа Ходаем, башыңны өтермәндә черетерлек хәл! Былтыр гына Сталин үлде. Теге шомлы елларның кайтавазы әле дә тынмаган, әле дә халыкның йөрәгенә үрләгән курку кимемәгән. Бер уч бодай өчен бичара кыз-катыннарны хөкем иткән чорларны яхшы хәтерли бабагыз! Ә монда бер уч кынамы соң, монда язгы ташу! Бөртек аккан, бөртек! Куанычыннан җан-фәрманга атын чаптырган Сәгытдин, күрәмсең, чуртым да сизмәгән.

Җитез карт, кеше-кара күргәнче дип, себерке белән бөтен урамны себерә. Бәласеннән баш-аяк! (Эз яшерелгәч, тирән уйга чумар дәү әти... Эчтән

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА (1956) – *Татарстанның халык язучысы; «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Икебезгә дә авыр», «Үзем генә беләм» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

исә шик кимерер. Оныгына биш яше тулгач, «тормыш арбасы» турында фәлсәфә куертыр, ләкин малай аның ярты кәлимәсен колагына элмәс.)

...Ызбага мичтә пешкән ипи исе кебек татлы ис – бәби исе таралган. Матча ыргагына аскан бишектә Фәрит исемле бөтерчек йоклый. Шук-шаян оныклар алмаш-тилмәш бишекне тирбәткәндә әйләндереп капламасын дип, читтән генә дәү әти күзәтә. Бәләкәчнең алты яшьлек абыйсы Әнәснең күзе ут яна: энекәше зурайгач, икәү качышлы уйнарлар...

Ә алдагысы, тәрәзә уеп карасаң да, күренмәс. Чиратка тезелгән еллар исәп-хисап йомгагын тәгәрәткәндә, анда менәниләр чорналыр: «Фәрит Шәйхетдинов. Көрәш буенча Татарстан һәм Россия чемпионы, шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә үткәрелгән турнирның 1977 елгы чемпионы, унбиш мәртәбә Сабантуйларның абсолют батыры».

Әмма Яшел Үзән районының Караужа авылы малаена җиңел генә бирелмәс дан-дәрәҗә. «Җир тырмашып» дигән сүзләрне үзгәртеп әйтсәк: «Мәйдан тырмашып яуланыр алар».

«Баш тренер. Баш хөкемдар. Татарстанның Сумо көрәше президенты» вазифалары Сәгытдин улына дөрес һәм гадел булганы өчен йөкләнер.

Тик йомгакта ак җепләр белән бергә карасы да буталыр. Сынауларны тауга биргәннәр – күтәрмәгән, аннан соң кешегә биргәннәр – күтәргән, ди, борынгылар. Күтәрә Фәрит Шәйхетдинов...

## 1. «Ала да бәрә, ала да бәрә»

«Мин үземне өч яшемнән бирле хәтерлим. Тәнем кояшта каралып беткәнгә күрә кушаматым «Кара малай» иде. Әти: «Тышың кара, эчең ак булсын, улым», – дияр иде. Биш тулганда, сөннәтче бабайны чакырдылар, ычкынмасын дип, әни башымнан, Шәйхетдин дәү әти аягымнан тоткан иде. Безнең чор балалары компьютер зәхмәте белән чирләмәде, без дөньяны табигать аша танып белдек. Тау итәгенә урнашкан Караужа гөлләр иле белән тиңләрлек дәрәҗәдә матур, таудан өстәрәк – алмагач, чия, карлыган бакчасы, Петьялка елгасы үзе бер могҗиза, ул Илләткә, Илләт Иделгә, Идел Каспий диңгезенә коя иде. Елгабызның аръягында яшелчә совхозының кәбестә, чөгендер, кишер, кыяр, помидор ише нигъмәтләре без – бала-чаганың күзен кыздырып торыр иде. Авыл тугыз урамнан гыйбарәт. Безнең оч малайлары иң көчлесе, иң усалы, безне беркем җиңә алмый, бездән шөллиләр иде. Бер-беребез белән бәргәләшсәк тә, тиз дуслаша идек анысы. Сугышып йөрергә вакыт та юк, авыл баласының эше муеннан, һәр йортта терлек-туар, кош-корт... Апрель азагында ук иллеләп йомыркадан каз-үрдәк бәбкәләре борын төртә; аларны тилгән-мазардан мин саклыйм; боларга тагын җил тидерергә дә ярамаган нәзберек күркәләр өстәлә. Сыерларны ашату нужаның да нужасы: кышкы печән запаслары чәйнәлгән, сарайда кызгандырып, «мөгезлеләр» мөгри. Сусыл яшел үләннәрне алар төшендә күрә. Әмма язгы ташуларда бөтен җирне су баса һәм күперләрнең икесе дә җимерелеп, хуҗалык көтүенә юл бикләнә. Май аенда, ничарадан бичара, сыерларны бау белән бәйләп, болынга илтә идек. Көтүчеләр яллагач, эшебез җиңеләйде, дисәм, малларның кайтышына нәрсәдер әзерләргә кирәк. Тау битендәге люцерна менә дигән азык та бит... Шуны урак белән урганда,

агрономга эләксәң – харап! Ул куа, ә без җил белән узышып элдертәбез, аяк киемнәре төшеп калса да борылмыйбыз. Кукуруз басуыннан кача-поса җыйган чүп үләннәре кипкәч сәнәк белән очыртырлык кына кала. Холкым шундый иде: таш авырлыгындагы чи үлән көлтәсен малайларга күтәртәм, ә үземә берсеннән дә булыштыртмыйм. Әллә көчемне күрсәтәсем килә, әллә артык үҗәт идем, йөгемне бавыннан тешем белән каптырып иңбашыма куям. Әле бит минеке бүтәннәрдән өч тапкыр авыррак! «Рейслар»ым да күбрәк. Дуслар әбәт ашаганда, кукуруз басуын тагын бер әйләнәм.

Кышның үзенә икенче төрле мәшәкате: кар көрәү, тирес түгү, су ташу. Соңгысы бигрәкләр дә үзәккә үтте, чөнки авылдагы сиртмәле коеларның суы кими һәм без Әнәс абыем белән зәмһәрир суыкмы ул, кар-буранмы, чанага флягалар утыртып, ике чакрымдагы «Хаҗи мулла» чишмәсенә барабыз, төпсез чиләккә ташыйбызмыни, су тиз бетә, чөнки безнең гаиләдән тыш мунчада өч күршебез юына иде.

Дәрес әзерләү юк иде. Мин өйдә: «Дәресеңне карадыңмы?» – дигән сорау ишетмәдем дә. Яхшы укыдым, көндәлектә гел «дүртле» һәм «бишле» билгеләре генә, шуңа күрә әниләрнең күңеле тыныч иде.

Уйнарга да өлгердек без. Көрәш белән мавыгу әнә шул уеннан башланды бугай. Мәгъсүм Галиуллин (күршебезнең адашы) илленче елда туган, миннән олырак иде. Аның дүрт ел армиядә хезмәт иткән Госман абыйсы Казанда самбо түгәрәгендә шөгыльләнгән. Елларда авылга кайткач: «Болай да тегеләй», – дип, йодрыкларын болгап, энесенә күнекмәләр күрсәтә икән. Мәгъсүм уйнаганда, капылт кына билдән «буып»: «Туктагыз әле, көрәшик әле», – дип, безне җиргә ата да бәрә, ата да бәрә. Күрше малайлары яшьти Солтан белән кече Мәгъсүм: «Авырттырдың», – дип үкерепләр елап, әниләренә әләкли. Китә талаш, китә ызгыш! Олы Мәгъсүмне эт итеп сүгәләр. Минем дә тәнем авырта, тик мин тешемне кысып түзә идем. Әгәр алар кебек «тренер»дан зарлансам, әти: «Әле син үзеңне яклый алмыйсыңмыни?!» – дип, колак төбенә кундырачак иде. Мин шыңшымагач, олы Мәгъсүм көрәш ысулларын күбрәк миңа өйрәтте. Тукылган киләм кебек ямь-яшел чирәмгә туптай тәгәрим генә. Ошады көрәш! Аңарда нindидер тарту көче бар иде.

Безнең Карауҗада ни сәбәпледер 1971 елларга кадәр Сабан туйларын оештырмадылар. Шуңа күрә безнекеләр тирә-күрше авылларга йөрде. Рафаэль, Тәлгать, Хәйдәр, Госман абыйлар көрәшкәндә, мин сабый күңелләшүе белән көнләшә идем. «Вәт алар кебек кулыңа сөлгене йомарлап тотарга иде дә көндәшләреңне бер-бер артлы җиргә сыларга иде!» – дип хыялланулар истә. Баш батыр калу уемда да юк, ул әле буй җитмәслек биеклектә! Әнә, Карауҗаның данлыклы абыйлары да аңа ирешмәгән.

Мәгъсүм белән күнекмәләрне туктатмадык. Ничек тәвәккәлләдем икән: 1967 елның җәендә Уразлы Сабан туена бардым. Миңа унөч яшь. Мәгъсүм берничә малайны бәрде. Мәйдан тирәли халык, кемгәдер сызгыралар, кемнедер, «әйдә дә әйдә!» дип куәтлиләр. Мин дә батырайдым: кеше күзендә беренче бил алышу, беренче чирканчык... Кызулык белән бер-бер артлы алты малайны аркасына яткырдым. Призы «шәп» иде: дистә йомырка! Шуларны майкама төйнәп очтым авылга!

– Дәү әни, миңа бүләк бирделәр! – дип кычкыра-кычкыра өйгә керсәм –

йомыркалар сытылып иzелгән, майкам буялган. Йомырка малмыни, аның каравы Карауҗада дәрәҗәм артты. «Ишеттегезме, Сәгытдиннең теге кара малае Сабантуйда көрәшеп откан, ди!»

Наил исемле малай миннән бер сыйныф алдарак укый, «Пионер» дигән велосипеды аның иң кадерле «техникасы», ул аңа теләсә кемне атландырмый иде. Гаҗәп бит, Наил минем көрәшкәнемне караган икән, хәзер урамда әллә кайдан балкып:

– Фәрит, әйдә, дуслашабыз, мә велосипедымны, йөр рәхәтләнеп, – дип юмартлана иде.

Йомырка белән «бәхилләткән» Сабан туеннан соң нигәдер бүтән мәйданнарга атлыкмадым. Мөгаен, көрәш дип дәртләндергән кешем булмагандыр. Ләкин күнегүләрдән бизмәдем, һәрдаим кабатладым. Кышкы суыкларда бәрәңге бакчасында кар шыкырдап туңгач, аяк батмый. Шунда яшьти Мәгъсүм белән бер-беребезнең кабыргасын «саныйбыз». Хәйләгә дә өйрәнәбез: көндәшең үзенә таба тарткан вакытта уң аягың белән атлап аны астан төртеп җибәрәсең. Бу безнең үзебезчә отработка санала иде. Тугызынчы сыйныфта тракторчы һөнәренә укыдык. Кышкы салкыннарда дәрес үткәрмиләр, миңа «мәйдан» бушый, парта-өстәлләрне эттерәм дә, малайларны кыздырам:

– Әйдәгез, көрәшәбез!

Каяндыр күңелгә штанга «җене» оялады. Гер күтәрү белән мавыктым. Авылда секцияләр юк, үзбелдегем белән кайнаштырам. Үземә үзем тренер, кыскасы.

## 2. «Һы, куркасыңмыни?»

Бүген чыгарылыш кичәсе. Бүген мәктәп белән саубуллашалар. Моңсу да, күңелле дә. Моңсу – син оясыннан очкан кош хәлендә, кая кунарсың? – Билгесез. Күңелле – син буй җиткергән егет, син – мөстәкыйль! Иртән үк Әнәс абыйсы кулмәк үтүкли. Фәрит белән Сабан туена җыеналар. Кичәгә кадәр Биектау районының Брикетный бистәсен өч тапкыр урарга була. Фәритне үгетләргә кирәкми дә: бара! Аның гер күтәрергә исәбе. Ничә ел йомры тимерләр белән беләкләрен шәбәйтте, инде нәтиҗәсен күрәсе иде.

Гер тирәсендә таза-таза ир-егетләр таптана иде. Боларның йодрыклары да үгез башы хәтле. Берәүсе: «Әй», – дип кул селтәр, әзмәверләр арасына кысылмас иде, тик Фәрит ниятеннән чигенмәде, ике потлы герләрне егерме тугыз тапкыр һавага «чөйде» егет. Аңа өченче урын тәгаенләнде. Кәеф шәп, күңел җырлый, абыйлы-энеле салмак адымнар белән мәйданга юнәлделәр. Ә анда пар бөркетеп, яшьләр көрәшә иде.

Әнәс абыйсы җиңелчә генә энекәшенең иңбашыннан какты:

– Син дә чык!

Фәрит кашын җыерып, аңа текәлде. Шаярта дисәң, кыяфәте җитди.

– Көлдермә инде, абый. Нинди көрәшү, ди. Чын көрәшчеләр ел буе умыртып ит ашап, каймак эчеп, көч туплый. Алар яхшы тренерлар белән дә шөгыльләнә. Мин гер күтәрергә килгән идем, шул җитәр.

– Һы, куркасыңмыни?

– Мин куркаммы? Минме?! Юкны сөйләмә инде, абый.

Моңарчы сүнимме, кабыныйммы дип пыскыган көрәш дәрте кисәк кенә дөрләп кабынды. Гүя күкләр аңа эндәшә иде: «Тырыш, билеңне бирмә-ә!» Алты көндәшен еккач, хөкемдар аны туктатты:

– Шәйхетдинов, ял ит!

Нинди ял ди, ул тамчы да армады, киресенчә, беләкләренә баһадирлар көче иңгәндәй тоелды. Сөлге тансыклаган уч төбе кызышты. Сагындырган көрәш, сагындырган!

Ә бит авыл клубы каршындагы маҗарадан соң нәрсә дигән иде? Армиягә чакырулы Госман: «Кая әле, көрәшеп карыйк», – дигәч, Фәрит аны ике тапкыр күтәреп җиргә бастырды. Ә шунда Госман шаярып, кисәк кенә егетне ташка тондырды. Ике атна сызланды Фәрит. Диагнозы куркыныч: тәненең ите кабыргасыннан купкан иде. «Бүтән гомеремдә дә көрәшмим», – дип тәүбә иткән иде ул. Тукран тәүбәсе икән лә!

...Ул тагын өчәүне чирәмгә сузып салды. Хәзер дәү-дәү абыйлар белән көч сынашасы. Алар сигезәү, майлы сарык ите ашаганнар, ахрысы, һәммәсе дә симез, кояшта битләре ялтырый. Фәриттән ике тапкыр авыррак болар. Мәйдан кырыенда абыйсы кулы белән ишарәли. «Хуп, олылар белән ярышма», янәсе. Ярыша! Дүртесен әүмәкләтте Фәрит. Менә юан гына берәү мыш-мыш сулап, егетнең каршысына басты. Гәрчә көрәш уты дөрләгән саен дөрләп канатландырса да, егет акыл белән уйлап өлгерде: «Бу абзый белән бәйләнмәскә кирәк. Чаманы чамаларга!»

– Абый, бүген безнең чыгарылыш кичәсе, – диде ул. – Син мине имгәтмичә ипләп кенә ек инде, зинһар.

Ярышлар тәмамлангач, хөкемдарның тавышы яңгырады:

– Яшьләр арасында Шәйхетдинов Фәритне батыр дип игълан итәбез!

Зур мәйданнарда тәүге тапкыр җиңү тәмен татыган туганын абыйсы аркасыннан шапылдатты:

– Мин сиңа ышанган идем, энем. Маладис!

Вәт хәйләкәр төлке! Килеш-килбәте сата ич: иртән үк хәйлә капчыгы теккән. Тәки кулга сөлге тоттыртты! Юкка гына Фәрит аны эчке тренерым дип атамый икән.

Ачуланмады егет, кайчандыр бер аның тарафыннан шундый кыю адым ясалырга тиеш бит инде.

– Сиңа рәхмәт, абый. Их! – Фәритнең күзе очкынланды. – Их, баш батыр булып калсаң иде ул, ә?!

Абыйсы аңардан да ныграк шатланган иде. Кемнең энесе? – Әнәс энесе! Дан-шөһрәт җиле аңа да әз-мәз кагыла.

– Ул көннәрне дә күрергә язсын, энем!

«Ә-әмин, – дияр фәрештәләр, – ә-әмин!»

Бүген ул Сабан туе батыры сыйфатында тар урамнарны киң итеп, күкрәк киереп (масаеп түгел!) Карауҗага кайтыр. Сыйныфташлары: «Ничек көрәштең?» – дип сораса, тыйнак кына: «Ярыйсы гына»,– дияр.

Ә дусты Зөфәр Хәнәфиев белән сөйләшкәндә, сүзгә саранланмады Фәрит, чөнки дусты да көрәш белән эрләнгән, көрәш белән тукылган җан иде. Институтка да бергә җыеналар. Фәрит авыл хуҗалыгына дигәч, Зөфәр кырт өзде:

– Юк, без синең белән педагогия институтының физик тәрбия факультетына документлар тапшырабыз!

Тапшыралар да бит, анда бер урынга җиде кеше. Конкурс! Кая инде ул авыл баласына сират күпереннән узулар.

Ул елда аңа студент бәхете тәтемәде. Билеттагы унөченче санны абитуриентлар тискәре сан дип өнәми иде, ә егет моңа борчылмады: әтисе вафат, өйдә ике кечкенә сеңел, акча ягы такыр, эшләр, әнисенә булышыр. Фәрит тимер-бетон эшләнмәләр заводына урнашты. Ә эчпошыргыч кичләрдә нишләргә икән дип аптырамады ул: «Динамо» спорт сараена штанга секциясенә язылды. Авылда ватык трактор тәгәрмәче катокларын ташып, штангалар укмаштырса, биредә аның бөтен шартын китереп ясалган чып-чыны иде.

Фәрит ялт-йолт як-ягына каранды. Залда бер ир-ат кайнаша иде, аңардан:

– Моны кузгатырга ярыймы? – диде.

Тегесе көлемсерәде:

– Йөз дә биш килолы ул, аударып аягыңны чәрдәкләмәсәң – давай!

Аягыңны чәрдәкләмәсәң, имеш. Әйдә, күр! Егет эһ тә итмичә штанганы баш очына күтәргән генә иде, күзе шарланган ир тренерга йөгерде:

– Тизрәк килегез, тизрәк! Баһадир табылды!

Зөфәр аның бу мавыгуын өнәмәде бугай, бер күрешкәндә:

– Безнең институтның спорт залында тренер Валерий Арсланов грек-рим көрәшенә өйрәтә, – диде һәм, тел чарлаган оста лектормыни, тыр-тыр лекция укырга кереште. – Беләсеңме, бу көрәшнең ватаны – Греция. Ну, малай, бик борынгы көрәш, сиңа әйтим. Кара-каршы алышасың инде. Татарча көрәштәге кебек, аларда рөхсәт ителгән алымнар гына кулланалар, малай. Тигезлеген югалттырып, көндәшеңне сырты белән, һоп, келәмгә кысасың! Хәрәмләшү, аяк чалу яки дә аяктан тарту тыела. Вакыты кыска, тиз тәмамлана. Озаклап сугышып, кәҗә маеңны чыгармыйсың, һе-һе! Плюсларын әйтимме? Җитезлегеңне, көчеңне арттыра. Сине үзебезгә чакырам! Икәү күңеллерәк, малай.

– Юк, Зөфәр, кыстама!

Фәрит бу тәкъдимгә ризалашмагач, дусты җенләнеп:

– Алайса мин институтны ташлыйм, – диде.

Менә сиңа ультиматум!

Вакыт-вакыт Зөфәр кайнар баштан тәртәгә тибеп вата-җимерә иде.

– Акылсызланма! Исәр генә үзе атланган ботакны кисә. – Егет дустын әрләде. – Ярар, киләм! Вәгъдә!

Факультет тренеры Арсланов исә коры гына сөйләште:

– Кайдан? Исемең кем? Ничә яшь?

– Карауҗадан. Фәрит. 1954 елгы.

Тренер әдәп саклап маташмады:

– Миндә шөгыльләнергә соңардың, яшең узган, хуш, – диде.

Һе, унсигез яшьтә картайганмы ул?! Әкият!

«Зөфәр дустым хакына алыгыз», дип мескенләнеп тезләнсенме инде киребеткән алдына? Иелгән башны кылыч кисми, диләр, дөрес, кисми, ә горурлыгыңны кыеп кына төшерә.

Зөфәр кырмавык кебек чат ябышты:

– Шулай диме? Хуш, диме? Ә син бирешмә, киләсе елда барыбер сезгә укырга киләм, диген. Аңла, зинһар, миңа синең белән әзерләнергә җайлы.

Синең белән күнегүләр дә икенчерәк. Ике тинтәк кушылса – яу була, ике ипле кеше кушылса – тау була, ди. Без синең белән биек-биек таулар өярбез, малай!

Моның хәтле ялваруларга таш та эрер иде, валлаһи!

Икенче тапкыр баруында кырыс тренер йомшарган иде.

– Нәрсә, тагын килдеңме, Шәйхетдинов? Үҗәт икән үзең. Ярый, төркемгә кушыл. Карап карыйк, кемнәрнең корбаны булырсың икән...

Баксаң, «корбаннар» аның үзендә үк икән. Ярты айлык күнегүләрдән соң тренер аңа берсе – ике, берсе өч ел мускул үстергән егетләрне каршы куйды. Икесен дә бәрде Фәрит. Үзебезчә, татарча! Чөнки балачакта өйрәнгән алымнар онытылмаган. Зал биһуш иде. Остазның күзе маңгаена атылды. Күрде: Шәйхетдинов уңышлы алымнар кулланды. Ләкин секциянең кыйбласы грек-рим көрәше, ә тренер аның фанаты иде. Мөгаен, ул Фәритне үз ягына табан борыр. Борса нишләтәсең, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз диләр, аңа да көрәшнең әллә ничә төрен өйрәнү комачауламас иде. Сменадан туры тренировкаларга ашыкты ул. Көрәш өермәсе җиле-давылы белән аны үзенә бөтереп алган иде.

### 3. «Син мине дөрес ектың»

Тормышымда үзгәреш: мин студент! Уку һәм көрәш агылый белән тагылый кебек гел бергә. Казанның «Химстрой» оешмасы спорт залында Гайнетдин Мөхәммәдиев көрәш секциясе ачкан дип ишеттем. Монысы чиста татар көрәше, милли көрәш! Без – авыл малайлары (егетләре димәкче идем) шунда ияләштек. Зөфәр белән еш аралашабыз. Безгә аңлатуы кыен бер сәерлек хас: беркайчан да парлашып көч сынашмыйбыз. Ник? Нигә? – җавапсыз табышмак. Үзебез шул кадәр якын дуслар. Сабан туйларында мин – аны, ул мине егарга җөрьәт итми.

– Мине ек, – ди Зөфәр.

– Юк, син мине ек, – дим.

Берсендә тренерыбыз:

– Яшьләр арасында Россия чемпионатына икегезне сайладым, сез – дуслар, – диде. – Бүтән кеше алмыйм.

Үтер, чын-чынлап көрәшеп булмый! Әлеге дә баягы: «Син ек та, син ек». Сәгать телләре текелди: җиңүчесе юк! Вакытны суздык-суздык та егерме ике белән егерме икегә тәмамладык.

– Килегез әле бире, – диде Валерий Әхмәтович һәм җилкәбездән каптырып, маңгайларыбызны чәкештерде дә артыбызга типте. – Артистлар!

Нәтиҗәдә без чемпионаттан мәхрүм калдык. Үкенмәдек, безгә дуслык кадерлерәк иде. (Гомер узар, туннар тузар, дигәндәй, бүген Валерий Арсланов Мәскәүдә яши. Минем аңа хөрмәтем зур, Казанга килсә, үзем каршылыйм. Ул минем өемдә – иң кадерле кунак.)

Зөфәрнең җиңүләре – минем дә җиңү, Зөфәрнең уңышлары – минем дә уңышым, дустым өчен чиксез шатлана идем. 1973 елдагы Мәмдәл Сабан туенда ул баш батыр булды. Ә икенче елда миңа бәхет елмайды: теге хыялым тәки канат ярды бит. Миңа башта өчне җиңәсе. Беренче көндәшне аудардым, өченчесе Ринат исемле таныш егет, оста көрәшче. Аны да аттым. Ул шундыйрак кызык кеше:

– Әйдә, тагын кабатлыйбыз, – ди.

– Ринат, – мәйтәм, – булды бит инде, әле минем алда өченче белән алыш-биреш.

Ринат борылды да:

– Әнә кара, сиңа нинди пәһлеван чыгып килә, әйдә соң, шуның белән чилән, – дип көлде.

Чын мәгәр, пәһлеван! Таза гәүдәле, киң җилкәле, эре-эре атлаганда, аяк астында җир тетри, диярсең. Ят кеше, безнең як ир-атларына охшамаган. Ахырдан әйттеләр: институттан соң «Бишнә» совхозында бер ел эшләгән, егерме дүрт яшьтә икән. Шундый көчле үзе, тиреңне куптарыр. Билдән умырып тотты. Тыпырчына-тыпырчына ычкындым моңардан. Әзме-күпме тәҗрибә бар. Ул тагын умырта, тик мин күтәреп, җир белән тигезләргә ирек бирмим. Зөфәр кычкыра:

– Ике аяк арасына кер!

Шулай тарткалашканда, аскарак төштем дә пәһлеванны күтәреп тә бәрдем.

Алда уналты батыр арасында ярыш. Әле генә миннән оттырган мужигым да исемлектә. Зөфәргә әләкте ул. Икәү җир җимертеп көрәштеләр, минем дус җиңдерми, әйләндереп кенә сала моны.

Берсендә тукталышта торам, яныма машина туктады.

– Утыр, Фәрит, – ди хуҗасы. Теге пәһлеван! Югалып калдым, киң җилкәле кеше кырыена ничек сыярмын, мәйтәм. (Ул безгә киләчәктә үзенең кем икәнен белгертер: югары постлар биләр, министр кәнәфиендә утырыр, районнар җитәкләр, халыкта зур шәхес булып танылыр.)

Ике дистә елдан соң без аның белән трибунадан көрәш карадык. Хәтерен ташка уйган: таныды. Тану гынамы, Мәмдәл Сабан туендагы хәлләрне онытмаган!

– Син мине дөрес ектың, Фәрит, ну, теге малай алдады, – ди. Зөфәр турында әйтә.

«Алдамады», дисәм, трибуна ишеләчәк иде. Хәвеф-хәтәрдән уен-көлке белән котылдым:

– Сезнең кебек баһадирны хәйләләмичә генә ничек җиңәсең, – дидем.

Мәмдәл мине – егерме яшьлек егетне баш батыр исеме белән бүләкләде. Әни – сизгер, улының дус-ишләре белән кайтасын белеп, мул итеп табын әзерләгән иде. Тәкә чалынды. Ишегалдында казан астык, хуш ис белән борынны кытыклап, быгыр-быгыр шулпа кайный, авылның олысы-кечесе безнең йортка агыла. Карауҗада бәйрәм! Сәгытдиннең кара малае – герой! Әти генә юк. Кырык биш яше дә тулмаган әти җир куенында. Их, түбәсе күккә тияр иде. Миңа: «Үз гомереңдә ничә тәкә боты кимердең?» – дип шаярталар. Утызлап! Әмма мин аларның берсен дә качып ашамадым: авылдашларны, дус-ишләрне, туган-тумачаны сыйлау җан рәхәте иде.

Берсендә көрәш чемпионы Азат Ногмановның абыйсы миңа:

– Әйдәле, минем энекәш белән көрәшеп кара, – диде.

Азат – медицина институты студенты, бик гыйлемле егет. Кулында революциягә хәтле басылган сирәк китаплар. Анда спортчыларга нинәрсә ашарга, нинди витаминнар эчәргә – тәфсилләп язылган. Ул чишенү бүлмәсендә безгә туклану кагыйдәләрен аңлата. Ә безнең ашау ягы әллә

ни түгел: такы-токы гына. Тренировка вакытында ук мин аны әйләндереп аттым. Шуннан соң Азат минем хакта төпченгән: «Бу егет кем? Шулай көчлеме ул?»

Икенче елда Татарстан беренчелегенә үткәрелгән бәйгедә без тагын очраштык һәм үзара ничьяга килештек. Мин кемгәдер оттырып, дүртенче, ә Ногманов беренче урынны алды. Ходай 1976 нчы елда безне өченче мәртәбә маңгайга маңгай терәтте. Шунысы кызык: көндәшенең биленнән тотсам – ике кат футболка кигән! Моның хикмәте шунда: футболканың берсе күтәрелә дә, икенчесеннән сөлге шуа.

– Сал, брат, – дим.

Тыңлады көндәш. Икенчесе астында өченчесе дә бар икән! Мин чемпионны җиңел генә келәмгә аудардым. Берәр эчкерлерәк бәндә чемпион башы белән егерме ике яшьлек гап-гади егеттән җиңелгәч, чыраен сытып эндәшмәс тә иде, киң күңелле Азатның, киресенчә, миңа карата хөрмәте генә арткан.

Миңа тәүлек бик кыска тоела, вакыт җитми иде. Уку, секцияләр, ялларда – авыл. Карауҗада Госман Хөсәенов малайларны татарча көрәшергә илһамландырды, мин инде Казаннан кайтканда, иң беренче клубка сугылам, кино күрсәтелмәгән кичләрдә урындыкларны почмакка өеп, мата җәябез, сәхнә шулай ук – безнеке, малайлар кызып китсә – аннан аска мәтәлүләре дә ихтимал. Ул чорларда мәктәп балалары өчен секция оештырган авыллар сирәк иде, «Яшь ленинчы» газетасы призына ярышлар башлангач кына, боз кузгалды.

Клубның тагын бер тарту көче – анда яшьләр күңел ача, көләләр, шаяралар, сыздырып уйнаган гармун көенә очып-очып, кызлар бии. Гармун дигәннән, миңа – алтынчы сыйныф баласына эти бозау суеп саткан акчага гармун юнәтте. Без күрше малае белән мунчада шуны шыгырдата идек, соңрак Әнәс абый баян бүләк итте. Әмма «ничауа» гына сиптерсәм дә, кеше алдында уйнарга кыенсына идем. Ә кыз-кыркын гармунчыга мөкиббән, гармунчы авылда «кыйммәтле тауар». Тик минем кызлар белән чөкердәшергә вакытым юк, аннары бер авыз пешкәч, нечкәбилләр гайрәтне чигермәсә дә, әллә ни кызыктырмый иде. Мәктәптә укыганда, Фирая исемле чибәркәйгә гашыйк идем. Фирая Мәскәүдә туганнарында яшәп укыды, җәйләрен авылда әниләрендә иде. Кыз фәрештәдән яралган төсле – кая ул иреннән үбү яки кочу, бармагына да кагылмыйсың, җан ярата да, күз соклана. Фирая безнең институтка укырга керде. Янәшәдә генә, кул сузымында гына, ләкин сирәк очрашабыз, чөнки әлеге дә баягы мин «эш кешесе», ягъни «көрәш» дип, күз-баш тонган. Атнага өч тапкыр үзебезнең спортзал, Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында Татарстан җыелма командасы тренеры Сәлахетдинов Мәгаз абый кул астында күнекмәләр чарлау үзәккә үткән, бигрәк тә күсе төсле сәгатьләремне кимергән юл! «Юлның ни катнашы?» – диярсез. Тулай торакта урын бирелмәгәч, башта Телевышкада – апаларда, аннары җәһәннәм читендәге Северный бистәсендә – Әнәс абыйларда тордым. Институтка дүртәр транспорт белән барасы. Әнинең сеңлесе Фәния апа студентлар ашханәсендә эшли иде, кем беләндер мине Губкин урамындагы тулай торакка урнаштыру турында сөйләшкән. Комендант хатын кулымдагы кәгазь кисәгенә акаеп:

– Йөриләр инде монда блат белән! – дип мыгырдагач, хурландым. Без

– авыл малайлары, нахаллыкка өйрәнмәгән, кешенең соңгы телем ипиенә ымсынган шикелле тоелды да, борылдым да киттем. Фираямы? Табигый ки, кыз баланың ир куенына сыенасы, бала табасы килә, башка егетне сайлады Фирая. Аерылуларны авыр кичердем, әни дә сизде: «Берәр нәрсә булдымы әллә, улым?» – диде. Безнең буын яшереп яратты, хисләрен җилгә чәчми иде, ничек әнигә: «Кызым кияүгә чыкты!» – дип зарланасың, ди.

Ә Җир шары синең аһ-зарыңа карамый, күчәрендә әйләнә, мин дә әйләндем: институтны тәмамладым, диплом кесәдә. Ул заманнарда яшь белгечләрне мәҗбүри төрле җирләргә тараталар иде, миңа: «Син сәләтле көрәшче, Казанда эшкә билгелибез», – дисәләр дә, баш туган якка каерды. Әни ялгыз, әни! Җәке мәктәбе директоры Зиннур Маликович үзенә әйдәкләде. Мин аңа бер шартымны җиткердем. Әтинең апасының малае Илдарлар өйләребез өйгә терәлгән күршеләребез иде. Туганым уку алдынгысы, математика фәненнән республика олимпиадаларында беренче урыннарны шапылдата гына, ул кимендә фән докторы дәрәҗәсенә ирешәчәк иде, әмма институттан соң аспирантурага калмады, әнисе авыргач, Карауҗада укытты. (Сүз уңаенда, Илдар җәмгысе утыз ел мәктәп директоры камытын «киде», бүген дә исән-имин генә мәктәптә эшли.)

– Зиннур абый, Илдарны да чакырсагыз, мин риза, – дидем.

Физкультура укытучы буларак, планда каралган «раз-два»лар, гимнастика, йөгерү, туп тибүләр белән генә чикләнсәм, дөньям тараер иде. Киңлек-иркенлек – мәйданнарда ул!

Җәкедә ир балалар әзрәк, ә безнең авылда алар чутсыз иде, шуңа күрә, түгәрәкләр алырга кушмасалар да, Карауҗада көрәш секциясе ачып җибәрдем. Үзем тренер. Чаткы күрше Чүриле, Күлбаш, Каратмән авылларына хәтле чәчрәде һәм нәтиҗәсе дә озак көттермәде: шәкертләрем Яшел Үзән, Аккош күле Сабан туйларында бил алышты.

1977 ел аеруча истә. «Социалистик Татарстан» (бүген «Ватаным Татарстан») газетасының ил каһарманы Муса Җәлил истәлегенә багышланган турнирларында катнашу өчен (үз авырлыгындагы Җәке һәм Карауҗа егетләреннән Яшел Үзән җыелма командасы туплап) гариза илттем. Ул Казан шәһәрендә узды һәм анда Татарстан төбәкләреннән йөздән артык, шәп-шәп көрәшчеләрнең ике дистәгә якын төркеме җыйналды. 77 нче елларда Раббани Гайфуллин, Михаил Чернов, Михаил Минеев кебек баһадирлар мәйдан арысланнары иде бит. Минекеләр шөлләмәде, шундый көчле командалар арасында җиңеп чыктык. Мактанмыйм, факт буларак кына әйтәм, мин чемпион титулына ия булдым. Уңыштан борын чөелмәде, алда әле маңгай тиреңне тамызып яуланачак призлар, исемнәр көтә: мин үзем нигез салган көрәш мәктәбендәге йөзәрләгән малайларны милли көрәш рухы сеңдереп тәрбияләргә тиеш идем. Әзерләндем. Җиңемне терсәккә кадәр сызгандым. Туган авылым Карауҗага күчендем.

### 4. «Бүтән мәйданга чыкмыйсың!»

Беркөнне Фәритнең дөньясын кара пәрдә томалады. Әнисе үлде. Ничә яшьтә дә балага әни кирәк, әни! Бүгеннән ул дөм ятим, бүгеннән газиз кешесе белән бәйләгән үтә күренмәле җеп өзелде...

Егет атналар буе авызына тәгам капмады. Моңарчы әллә ни игътибар ителмәгән гаилә тарихының битләре «җанланды».

Күрше Җәке авылы кызы мөгаллимә Зәйтүнәне Сәгытдин урлый. Әтиәнисе: «Кызның яры кырыктыр, ише чыкса – юлыктыр», – димәгән шул, алар Карауҗа малаен тиңсенмәгән. «Йөз грамм Сталин аракысы» үз эшен эшләгән, сугышта ирләрнең байтагы «шайтан суы»н чөмерергә гадәтләнгән. Шәйхетдиннең фронтовик малаен да кызмача килеш күргәлиләр, имеш. Гайбәт – кемгәдер тәмләп чәйнәргә азык. Уңган, тырыш йортка куна асылкош Зәйтүнә. Өй тулы халык: каенана-каената, каенсеңел, апалар. Шәйхетдиновларның матчасына да «кара пичәтле» хатлар кыстырылган: Сәгытдиннең Гарәфетдин белән Минһаҗ абыйлары сугышның беренче көннәрендә үк һәлак булган. Уналты яшьлек Сәгытдин дә фронтка киткән. Атасы Шәйхетдин аны Юдино стансасыннан озатканда:

– Соңгы малаемны алып китәсең бит! – дип елый-елый поезд артыннан чапкан. (Ходайның рәхмәте, яраланган улы бер елдан әйләнеп тә кайта.)

Май аенда гына Оркыя исемле кызга өйләнгән мәйдан батыры көрәшче Минһаҗның яшь хатыны җиде ел ирен көтә. Аның күз яшьләре каената белән каенаның бәгырен тишкәндер, күрәсең. «Үз ояңны кор, кызым», – дип, туйлар туйлап, киленне Солтан дигән егеткә ярәшә алар. «Туган апаңа өйләнмисеңме, улым?» – дип, Сәгытдиннең кылларын чиртеп карыйлар, ә егетнең нәкъ менә Зәйтүнәне күзләгән чагы!

Оркыя апа икенче (Минһаждан кызы туа) иреннән алты бала таба. Мәрхүмә үлгәнче күкрәкчәсендә Минһаҗның бәләкәй генә фотосын саклый. (Соңра тузмаган-таушалмаган сурәт әманәт рәвешендә Фәриткә килеп ирешер һәм Фәрит аны зурайтып, әтисенең сеңлесенә тапшырыр.)

Әби-бабай юкка гына хафаланган икән: кызлары кияүдән уңды. Ир аркасы – кала аркасы, Зәйтүнәсенә җил дә тидертмәде Сәгытдин. Оста дөнья көтте, ат җигеп эшләде, авылда абруе зур иде. Яшь гаилә ишәйгән саен ишәйде: бала – өй нуры, әгәр икесен күкләр алмаса, җидәү бергә укмашып үсәрләр иде. Әтиләре кырысрак кебек иде, ул кичләрен сөт ташый, әгәр кайтышына капканы ачып өлгермәсәң – буран туздырыр, шуңа аны ишегалдында әле Әнәс, әле Фәрит сагалар иде.

Әниләре йомшак күңелле, мәрхәмәтле җан иде. Мәктәптә башлангыч сыйныф балаларын хәреф танырга, язарга, укырга өйрәткән кичәге мөгаллимә унбиш ел кибеттә сату итте. Сатучы... Рухына ят эш! Мәктәп аның стихиясе иде. Үлчәүдә хәрәмләшмәгән, кеше тиеннәренә кул сузмаган кибетчене Карауҗалар ярата иде. Алтмыш беренче елда аңа Казанда катлаулы операция ясадылар. Табиблар: «Ел саен тикшерел», – дисә дә, үзе турында кайгыртырга җае юк: кибет, мал-туар, кош-корт, балалар һәм паралич сугып зәгыйфьләнгән кулсыз-аяксыз каенананы багу... Менә илле өч яшендә гүр иясе...

«Бирешмәскә!» – Күңел ятлаган шигарь төссезләнмәс, Алла бирсә. Фәритнең рух баганасы нык иде: ул мәктәп белән хушлашып, Осиново бистәсендәге «Майский» совхозына төзелешкә эшкә урнашты, Анда бәләкәй генә спорт залында һәр кич күнегүләр ясап, берничә егет белән япан кырда көч сынашты. Җир аның өчен кабартылган йомшак түшәк иде. Көрәш магнит сыман үзенә тарта, аңардан ычкынуы мөмкин хәл түгел,

һәм ычкынасы да килми иде. Яшел Үзәндәге бәйгеләрдә катнашты. Анда, нигездә, үзенең элеккеге шәкертләре иде.

Петровский бистәсендә нинди яңалыклар икән? Элек андагы Сабан туйларында җиңгән ир-атлар абсолют батырга тиңләнә иде. Ару-талу юк, таң атканчы көрәшәләр. Халык умарта кучедәй гөжли. Күңелле һәм кызык! Тимер-бетон эшләнмәләр заводы директоры Гайфетдин Шәйхиев аны да шунда алып барды. Көндәшләрен рәттән аркасына салган Фәрит Шәйхетдинов хәзер Әнвәр Гыйләҗев исемле егет белән соңгы ноктаны куярга тиеш иде. Үз көчен чамалый иде Сәгытдин улы: отачак! Тик менә директор бөтенләй башка план корган иде.

– Бик үтенәм синнән, Фәрит, – диде Гайфетдин Шәйхиев. – Изгелегеңне мәңге онытмабыз. Син монда беренче ел гына, Әнвәр инде биш-алты ел маташтыра. Бир инде син аңа балларыңны.

И дөньясы, дөньясы! Җиңелгәннәргә дә җиңдем дигән дан кирәк. Кеше шуңардан канәгатьме икән? Әлбәттә, бирде Фәрит. Рәхәтен күрсеннәр!

Бер генә тапкыр егет юмартланырга теләмәде. Анысы күптән инде, 80 нче еллар азагында Чаллыда Муса Җәлил призына көрәш бәйгесендә ул шулай ук көндәшләрен чөйде генә. Азактан Дахис дигән егет белән көч сынаштылар.

Фәритнең – ике, ә Дахиснең – ноль. Көрәш тәмамланырга утыз-кырык секунд!

– Мин Чаллының спорт мастеры, хурлыкка калдырма, балларыңны бир, – дип теләнгән Дахиска: «Ал!» диясе килми иде. Ул мәйданнан чыгып китте дә:

– Имгәндем, – дип, үзен көрәштән алдыртты.

Беркөнне Казанның Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында көрәш оештырдылар.

– Җаны булган кеше анда көрәшәчәк инде.

Кара, Әнәс абыйсы ничек йөрәкне җилкендерә!

– Миндә җан бар, абый! Киттек! – диде Фәрит, бу шаяртуны чынга борып. Кагыйдәләр үзгәргән, «сиксән биш кило авырлыктагылар белән «сиксәннәр» көрәшә (ул «сиксән»), әмма артка чигенү юк, алга, бары тик алга!

Мәйдан тирәсен чебен төсле халык сырган, әйтерсең, бөтен республикадан җыелганнар. Көрәшчеләр – оһо-һо, күбеккә баткан ярсу атлар кебек финишка ыргылырга әзер. Аларның кайсы гына аның беләгенә чыдар икән? Мәйдан башта дистәләгән-дистәләгән көрәшче сыйдырса да, азактан берсен генә дан мөнбәренә менгезә шул. Егет берәм-берәм көндәшләрен урды: иң азактан Максим исемле керәшен егете белән икәү калдылар. Фәрит җидедән берсен генә оттырды. Бу ярышның җитәкчеләре пошаманга төште. Ничек инде Шәйхетдиновны баш батыр итәсең, ди! Әле танылмаган да җүнләп, горур, баш иярга яратмый, диләр тагы. Монда мактап, матбугатка мәкалә язасы, фоторәсемен бастырасы! Хөкемдар әфәнделәр кеше язмышы белән уйныйбыз дип уйламады, Фәритне чакырып:

– Бүтән мәйданга чыкмыйсың! – диделәр. Гүя аның башына чүкеч белән суктылар. Нигә чыкмый? Нигә?! Ул бернинди хата ясамады!

Әмма егет бәхәсләшмәде. Бәгырь каткан, җан бозланган иде. Әлеге

гаделсезлектән гарьләнгән Әнәс абыйсының гына күзеннән мөлдер-мөлдер яшь тамды.

– Кайгырма, абый, – диде Фәрит. – Без мондый нәрсәләргә күнегергә тиеш. Хөсетлеләр, көнчеләр, егылып, борынын канатсын дип, аяк чалучылар һәр өлкәдә очрый. Спортта да шул хәл, абый. Ике очракны сөйлимме, абый? 1976 елда мин җитмеш килограмм авырлыкта Татарстан беренчелегенә көрәшкәндә, бөтенесен дә чиста салдым. Соңгы көндәшем Нәҗметдин Җәләлетдинов иде. Миннән тугыз яшькә олырак. Сиздем, Мәгаз абыйларның аңа мөнәсәбәте бүтәнчә, күбрәк аның ягына авышалар. Нәҗметдин шундый кеше: көрәшкәндә, билен эләктертми, кача, боргалана-сыргалана, җиргә тезләнә. Хөкемдар «җиңүче» дип, минем кулны күтәргән генә иде, трибунадан грек-рим көрәше тренеры Шәрәфетдинов Рафаэль атыла-бәрелә төште дә:

– Мин – баш хөкемдар, өстенлекне Җәләлетдиновка бирәм, – диде.

Халык Шәрәфетдиновның бу гамәлен хупламады: аяк типте, кычкырды, сызгырды. Бүген дә гаделсезлекне күрде кеше, абый, күрде. Икенчесендә...

– Беләм. Теге Уфадагы тамашамы? – Әнәс абыйсы әзрәк язылды. – Синең һәр адымың исәптә, энем. Институт тәмамлаган елың иде. Сиңа егерме ике яшь.

– Әйе, егерме ике иде. Баш тренер Гайнетдин абый Мөхәммәдиев, әйдәгез, Канашев Виссарион белән икегезне РСФСР беренчелегенә ярышка Уфага алып барам, ди. Ике башкорт малаен келәмгә түндердем. Ә Әсәдуллин дигәне, аю кебек, таза. Харап, Виссарион шул егеткә оттырды. «Фәрит, бир миңа баллыңны!» – дип ялынгач, мин аның белән көрәшкән төсле генә кыландым, ул миңа караганда җиңүче данына мохтаҗрак дип уйладым.

– Кызгандыңмы, энем?

– Ә син нишләр идең, абый?

Әнәс абыйсы бу сорауны өнәмәгәндәй:

– Синең кебек эшләр идем, малай, – диде. – Йә, дәвам ит!

– Инде балл белән генә канәгатьләнми Канашев: «Син Әсәдуллинны от, яме?» – ди. Баш шөрепләре бушамаган шул: хикмәт шунда ки, әгәр мин башкорт малаена оттырсам, Виссарионга чемпион исеме тәтемәячәк! Ә миңа үз ихтыярым белән баллардан колак каккач, алай да, болай да өченче урын эләгә хәзер.

Арттагы рәттә Әсәдуллин дусларына: «Всё нормально, Канашевны бәргәнне монысын (ягъни мине) ботыннан гына тотып атам», – дип мактана. Алдан кычкырган күкенең башы ярылган, диләрме әле, абый? Мактанчык белән без егерме биш минут көрәштек. Мине чәнти бармагы белән этсә дә, аңа беренчелекне бирәчәкләр иде. Чүгәләштердем дә келәмгә сыладым Әсәдуллинны! Юк, җиңүгә санамады хөкемдар. Икенче юлысында зәһәр көч белән җиргә селтәдем моны. Виссарионга бәйрәм. Ул – чемпион. Мине җилкәсендә күтәреп, мәйдан әйләнмәсенме! Шул-лай, абый. Борыннарны салындырмыйк әле без. Спортның чуртым да файдасы юк, ташла, диләр миңа. Мин файда эзләмим, просто көрәштән башка яшәүнең мәгънәсен тапмыйм. Ә Максим – әйбәт малай ул.

Парк юлыннан:

– Итле кайнар пәрәмәчләр, кәбестә пирожкилары, – дип кычкыра-кычкыра, арбасын тәгәрәтеп бер хатын килә иде. Газета битенә төргән кулёкка пәрәмәч тутырткан Әнәс абыйсы:

– Сыйлан, энем, – диде. – Алдагы көрәшләрдә җиңәр өчен көч җый!

...Ә кич белән Казан кунакханәсе бүлмәсенең ишеген шакыдылар. Бусагада Максим! Кочагында тәм-том: торт, кәнфитләр.

– Миңа ачу тотма, Фәрит. – Егет башын түбән игән иде. – Мин гаепсез, Фәрит.

– «Ачу тоту – тау кебек, йотып куйгач бал кебек», – дигән мәкальне ишеткәнсеңдер, дус. Әйдә, уз, күчтәнәчләрең белән чәй эчәрбез, – диде бүлмә хуҗасы. Көндезге мәхшәр йөрәктән сызылган иде инде. Хуш, бәхетләре шул хәрамнән генә тора икән, Фәрит түгел, алар кызганыч. Бөтен мәйданнардан да сөрә алмаслар анысы, дөреслек авызларын яптырыр. Өметләнмәсеннәр дә, Фәрит бирешмәячәк!

«Егет булса – мут булсын, ике күзе ут булсын», имеш. Фәрит мут түгел иде. Гәрчә кыз-кыркын аңа кызыкса да, йөрәге ачкыч белән бикләнгән егет яр сайларга ашыкмады. Көрәш, и, бу көрәш белән аң-зиһен томаланган бугай!

...Ә Аллаһы Тәгалә адәм баласын парлы-парлы яраткан, Фәриткә дә өйләнәсе-көйләнәсе иде. Утыз яшь! Вакыт, бик вакыт. Әнә Кукмара кызы Рушанияне очраткач, әлеге уй кош сыман күңелгә оялады. Кыз үзе җан җылымлы, үзе тыйнак, үзе акыллы иде. Аны Әнәс абыйсы да ошаткан: «Кулдан ычкындырма», – ди. Рушаниянең дә күңелендә сөю былбыллары сайрый икән. Ул кыенсынып кына:

– Туган авылым Чәбиягә Сабан туена кайтасыңмы? Әниләр белән дә танышыр идең, – диде.

Йомшак май җиле кебек колакны иркәләгән кодрәтле сүз бит син, Сабан туе! Кайта белгеле, кайта!

Олы юлдагы автобус тукталышыннан Чәбиягә дүрт чакрым тәпилисе иде. Бәйрәмгә соңарабыз дип, и йөгерде алар, и йөгерде. Килеп җиткәч кенә Фәритнең борыныннан шаулап кан акты. Ул барыбер көрәшәчәк иде. Көрәште һәм бүген-иртәгә әби-бабай дип эндәшәчәк йортка тәкә күтәреп керде.

Иртәгә Сабан туе район үзәгендә – Кукмарада, диләр. «Көрәш басуы»ннан уңышларны җыясы да җыясы икән. Кичәге пар сүрелмәгән иде әле, сигез көндәш печән покосы кебек сузылды да ятты, сузылды да ятты. Удмуртиядән Зайцев Анатолий исемле кунак та бар иде. Татарча сүз тәмен белеп, өздереп сөйләшә егет. Авырлыгы йөз килограмм. Сиксән белән чикләнгән Фәрит аны җиңәсенә ышана иде.

– Туган, – диде Зайцев, беләктән кысып. – Балларыңны бирмәссеңме икән, туган? Мин бүтән Кукмарага килмәс идем, туган.

Фәрит: «Ярар» дип, баш какты. Куян малае, йөрәгеңә үтеп, ягымлы итеп, татарча үтенгәндә, ничек аңа «юк» дисең инде, ә?!

## 5. Мәңге терелмәслек «көрәш чире»

«Өйләнешкәч тә, Рушания белән Залесный бистәсендә бер хуҗаның фатирында яшәдек. Хатынымның туганнан туганы совхоз директоры урынбасары Рәфкат абыйның өч малае, олысына унөч яшь. «Фәрит абый,

көрәш секциясе ачып, безне өйрәт», – дип бәйләнде генә бит үсмер. Миндә андый теләк әллә кайчан борынлаган иде инде. Күкрәгемдә көрәш аты тибенә, мәгәр артымнан тайларым-шәкертләрем ялын туздырып чапмаса, ни кызыгы! Тәҗрибәм зур, Карауҗадагы Көрәш мәктәбендә йөзләгән малайлар һәм егетләр спортка тартылган иде. Совхоз директоры Равил Сабитов: «Клубта бер бүлмәне бушатабыз, шунда оештырасыңмы? Бездә штатта исәпләнерсең», – дигәч, биш куллап ризалаштым. Кәеф шәп, бүлмәләрне юып-чистартып, идәнгә мата җәйдем, сиксән сантиметр калынлыктагы диварны бораулап-тишеп, турник әтмәлләдем, штангасын да китерттем, эре хәрефләр белән язып, «Көрәшче анты»н кадакладым. Башка тренер-остазлар белән чагыштырганда, миннән ун тапкыр артыграк җаваплылык сорала иде. Чөнки балалар белән эшләүнең бик четерекле яклары бар. Грек-рим көрәшеннән башладым, аңардан татар көрәшенә күчүе җиңел. Алтмышлап баланың һәркайсын күз уңында тотасы, алар терекөмеш кебек, гел хәрәкәттә. Осиново бистәсе малае белән озак кына күнегүләр ясадык. Аның штангага күз төшергәләп алуын күреп кисәттем:

– Кагылма! Сиңа иртәрәк әле.

Ярты гына секундка артыма борылган идем, көчәнә-көчәнә күтәреп маташа! Беләкләре сыек бит, тимер белән маңгаена чәкеде. Кан сиптерә генә! Бистәдә хастаханә юк, бәхетемә, аптечка тартмасы хутлаган идем, сугыш кырындагы яралыны бәйләгән кебек бинт белән кат-кат уратып бәйләгәч тә өенә җибәрмәдем, автобус белән Телевышкадагы травпунктка киттек. Әйтәм бит, мин балалар өчен унлата җаваплы идем. Бүтән секциягә йөрмәс дисәм, бер айдан авызын ерып килмәсенме малаебыз!

Безнең дан таралды: ишек ябылмый, болыт кебек агыла балалар. Җәмгысе – алты төркем! Көненә алты мәртәбә «сугышабыз», минем һәр минутым – санаулы. Ул елларда безнең бистәдә генә сыер көтүе өчәү иде, секциядәге малайлар хезмәтнең рәхәтен дә, михнәтен дә тоеп үсте, иркәләнеп ятмады, шуңа күрә алар талантлы да иде. Урамнан ук кызышып әзерләнеп керәләр, Фәрит Сәгытдинович, күнегүләрсез генә сразу көрәшәбез, янәсе.

«Грек-рим»нан ярышларга Волжск шәһәренә бара идек, анда гел призлы урыннар яуладык. Бер төбәкнең тренеры миннән:

– Ничә ел шөгыльләнәсез? – диде.

– Ел ярым, – мәйтәм.

Ышанмады. Шуннан соң минекеләрне тинтерәткән.

– Ничә ел?

Җавап шул ук:

– Ел ярым.

«Ялганлыйсыз», – дип, малайларны борып-борып чеметә икән бу.

Көрәшче спортның башка төрләрен дә үз итәргә тиеш. Минем аппетит уянды: совхоз гаражлары артындагы агачлык уртасында футбол капкасы, хоккей тартмачыгы бастырдым, кышлыкка су сибеп, боз катыра идем. Якшәмбе кичләрендә хулиган үсмерләр шунда җыела да яңа яуган карны таптый, ә син яңадан мәйданчыкны көрисең. Атна саен! «Синең бандитларың!» – дип, әле кемдер төрттерә. Юк, минекеләр шәләй-вәләйләр төркемендә катнашмады, аннан соң бетте баш: тренердан рәхим-шәфкать көтмә!

Диңгез елга ярына сыямы? – Сыймый, яры бәләкәй. Без дә клуб бүлмәсенә генә сыймый идек. Дүрт ел тарлыкта-кысанлыкта җәфалангач, балалар бакчасын бирделәр. Совхоз директоры чираттагы ялда, без тизрәк күчәргә дип өметләнәбез, әмма баш инженер көрәшнең «к» хәрефен дә аңламый иде. Ул күзен алартып:

– Ну ведь, Фарит, там бандиты собираться будут, – дигәч, мин ярсыдым:

– Какие бандиты, Пётр Андреевич?! То, что на улице ребята гуляют, это же наши-ваши дети!

Яңа өебездә иркенәйдек. Озын коридорда теннис өстәле, көрәш һәм тренажёр заллары, сауна, заманча җиһазлар – Казаннар көнләшерлек! Яшел Үзәннән, Раифадан элеккеге укучыларым да безгә тартылды. Көрәш буенча спорт мастеры Рамил Төхвәтуллин, Татарстан чемпионы Ленар Гайнуллин, Татарстан һәм Россия чемпионы, Бөтендөнья абсолют чемпионы Фирдүс Зәйнуллин кебек шәкертләрем миндә чыныкты. Унбишләп спорт мастеры әзерләдем мин. Залесный бистәсендәге көнем төнгә ялганган хезмәтемнең җимешләре бихисап. Тик үзем белән бергә туган горурлык, мескенгә сабышмау, хакыйкатькә күз йоммау, ялагайланмау кайбер кара эчле бәндәләрнең эченә тия иде. Хуп, алар юлыма күпме генә бүрәнә тәгәрәтмәсен – абынмам, ә менә шәкертләремне рәнҗеткәндә, нәфрәттән кан кайнады. Барысы да хәтердә, шуның икесенә генә тукталам.

Ундүрт яшьлек үсмерләр арасында Казан кубогына ярыш игълан ителгәч, без дә – унике кеше, көч сынашырга киттек. Минекеләр юка трикодан гына, авыл малайлары бит, спорт киемнәренә кытлык чаклар. Унике команда: «Буревестник», «Динамо», «Рубин»нар. Ике бәләкәй төркемгә бүлделәр. Алтышар-алтышар көрәшче. Безгә иң көчле «Рубин» төркеме эләкте. Минекеләр гайрәтле, боларны дөңгелдәтә генә! Хөкемдарлар чыш та пыш: «Шалишь, Шәйхетдинов, без сине очындырмабыз!»

Нәтиҗәдә хаксыз рәвештә безне икенче урынга чигерделәр. Еллар узгач, Сергей Сергачев исемле егет «тишелде»: «Тренер Диләр Хәлилов хөкемдарларны сиңа каршы котыртты». (Алты ел элек Диләр абый ул чактагы «фетнә»се өчен миннән гафу үтенде.) Минем гадәт инде: заманында кем минем тәгәрмәчкә таяк тыккан – үчекмим, аларга бүген изгелегем белән түлим.

Чишенү бүлмәсенә керсәм, малайларым хор белән кычкырып елый. Гаделсезлектән елый!

– Сез нәрсә, егетләр, сез бит авыл малайлары, алар – шәһәрнеке. Сөртегез күз яшьләрегезне! Хәзер «өченче» урын өчен көрәшәчәкбез, – дидем. Ә үземнең йөрәкне шатыр-шотыр кара мәче тырный иде.

Туксанынчы еллар башында (1993 ел дип хәтерлим) Татарстан беренчелегенә көрәш булачак, дип игълан ителгәч, без бик шатландык. Катнашабыз! Ярышлар авыл хуҗалыгы институтының «Ферма-1» залында узачак, ул да, без дә шәһәр читендә. Бер троллейбустан икенчесенә күчеп утыра-утыра (бөкеләр җитмәсә) билгеләнгән сәгатькә ничәдер минут соңардык дисәм, әле көрәшчеләрне үлчәүдә үлчиләр генә иде. Оештыручылар киресенә катты: кертмиләр. Баш хөкемдар Әсхат абый Шәйхетдинов та минем кемлегемне белә. Институтта миннән бер курс

алдарак укыган Ришат үлчи һәм шунысы мәзәк: мин аны көрәш алымнарына өйрәткән идем. Ул да яклап дәшми.

– Сез нишлисез? – мәйтәм. – Әле вакыт бар, үлчисез генә бит! Мине кире борыгыз, командамны кертегез.

Егетләр (аларга унсигез яшь!) хурланды, бер ишеләре шуннан соң көрәштән бизде. Беләсезме, яшьләр мондый тискәре күренешләрне лакмус кәгазе кебек үзенә сеңдерә дә: «Киләчәктә дә кадерсез булырмын», – дип, яраткан шөгыленә кул селти. Аның шунысы куркыныч.

Үземә килгәндә, мин беркемне дә дошман күрмәдем. «Дошманнарның үз ташы белән үз башына ат», – дигән әйтемне өнәмим. Минеке: «Ташка аш белән ат». Һәм никадәр генә каным кайнаса да, бугазларына ябышмадым.

Институттан соң мәктәптә эшләгәндә, Казаннан берәү килеп әллә ничә мәртәбә газеталарга мактап язды. Күрәсең ул, бу егет авылда калыр, зур көрәш диңгезендә йөзмәс, көймәсе комга батар дигәндер, ә минем күңелдәге корабым океаннар иңләрлек иде. Республика ярышларында һәрдаим катнаша башлагач, бу хәбәрче (хөкемдар да иде) җелегемне суырды. Исемемне бозып әйтү дисеңме яки үзгәртү дисеңме – ниләр генә кыландырмады. Берсендә дүрт көндәшемне оттым. Хөкемдарның йөзе кара янды. Алар яклаган егет: «Билбау бәйләсәләр, мин яхшы көрәшәм», – дигәч: «Әһә, – дигәннәр, – Шәйхетдинов оттырачак, давай, аның да билен бәйлик!» Ә билбау көрәше миңа элек-электән таныш, мин аны яшьтән үк өйрәнгән идем. Алдым да сыдырдым көндәшне! Хөкемдар авызын ачып калды. Шунда ул сыек кына, дәртсез генә тавыш белән:

– Җиңде Шәйхетдинов әллә кем, – диде.

Исем юк, «әллә кем!» Аңа нәрсәгә кирәк иде икән мондый көнләшүләр? Өлкән яшьтә инде ул бүген. Аңа үч сакламыйм, килсә, якты йөз белән каршы алам.

Сындырырга көчләре җитмәгәч, көрәштәге аз санлы ул хөсетле адәмнәр тынды. Мин кешеләргә кирәк идем. Югары Ослан районы безнең бистәдән кырык кына чакрым. Беркөнне Вахитов авылыннан колхоз рәисе Ринат абый Гатин шалтыратты:

– Фәрит энем, өч ел мәктәп салдырам. Проекты шул килеш ята. Документларын эшләп бетерәсе иде. Зинһар, алын, син булдырасың аны, – ди.

Төзелеш һәм көрәш... Янәшә куярлык түгел. Нишлисең, олы кеше ялвара, гозерен кире каксаң – уңайсыз. Көндез мәктәп мәшәкате белән әвәрә киләм, кич – күнегүләр. Кунак ашы – кара-каршы, дигәндәй, минем дә шартым шарт! Ринат Гомәр улын төбәкара көрәш ярышлары уздырырга күндердем. Оештыру миннән, приз-бүләкләргә акча – рәистән! Сигезләп районнан көрәшчеләр чакырдык. Шуннан соң көрәш белән чирләде Югары Ослан! Минем теләк – терелмәсен бер үк!

Сигез айда документлар әзерләнеп, мәктәп төзелеше өчен акча алынды, инде беренче катның дивары да өелде. Өйгә кайтсам, хатыным:

– Битенең яртысы янган берәү сине эзли, – ди. – Биектаудан, – ди. – Глава моңа: «Тиз генә миңа Фәритне табыгыз», – дип боерган икән, – ди.

Биектауда яңа гына Җәүдәт Миңнәхмәтовны хакимият башлыгы итеп сайлаганнар иде. Ул көрәш ярышларының вип-тамашачысы. Түрәнең нинди йомышы төште икән?

– Фәрит, сиңа район спорт комитетын тапшырам, – ди Миңнәхмәтов.

Аның җитәкчесе Әнәс белән без яхшы ук танышлар идек.

– Рәхмәт, Җәүдәт Мидхәтович! Кеше урынына килмим мин, – дим.

– Нинди кеше урыны? Әнәс больничныйда, эшләргә теләге юк. Без аны көчләп тотмыйбыз.

– Башта гаиләм белән киңәшим әле, – дим.

– Һи, кем инде хатыны белән киңәшә? – ди Миңнәхмәтов.

Залесныйда миссиям үтәлде. Әти-әниләрдән ишеткән: «Урамнарда җинаятьчел төркемнәр котырынган дәвердә сез безнең балаларны канат астыгызга җыеп, афәтләрдән саклadыгыз», – дигән рәхмәт сүзләре иң зур бүләк иде. Тик Ринат абыйдан уңайсыз. «И энем, мине ташладың!» димәсме икән?

Ул хастаханәдә дәвалана иде:

– Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, – диде. – Син бездә төзелә торган мәктәпнең вакытлы директоры идең, булдырдың, ярдәмең өчен рәхмәтнең рәхмәте, энем.

«Ордым-бәрдем, чыгып чаптым» түгел, секциядәге балаларның язмышын хәл итмәсәм, тынычлап йокламаячак идем. Остаз эстафетасын шәкертем Илдарга тапшырдым. Кызганыч, миндәге җаваплылык аңа күчмәде: ничәдер айдан секция таркалды. Югыйсә бистәдәге көрәш иң югары ноктасына җиткән иде. Дусларым Равил Яруллин, Рүзәл Хәйруллиннар белән биш ел рәттән бистәдәге күл буенда үзебезнең Сабан туебызны үткәрдек. Шәкертләрем көрәйде, аларга стимул кирәк иде. Беренче чиратта, мин аның шул ягын уйладым. Кыйммәтле призлар – суыткычлар юнәттек. Көннәрдән бер көнне бөтен хезмәтеңне пыран-заран китерсеннәр инде?! Моңа ничек кайгырганымны бер Алла гына белгәндер.

Биектауга аяк баскан көнем 1996 елның декабрь ае иде. Яңа себерке яхшы себерә, диләр, районндагы спортның торышын анализлагач, шаккаттым: мин себерергә тиеш чүп кая соң? Мәктәпләрнекеннән тыш үзәктә бер генә спорт залы да юк! Юкның – тамагы тук дип, кул кушырып утырсаң да була. Сиңа хәтле кайгыртмаганнар, яшәгәннәр янәсе. Көрәшне кайда һәм ничек кузгатырга дип, баш ватам. Миңнәхмәтов:

– Караштыр, бина тапсаң – синеке, – ди.

«Октябрь» кинотеатрына сугылдым.

– Әнә подвал, шунда көрәшегез, – ди, йөзе чытык директор.

– Татар көрәшен юеш базга типкәләмә әле син, агай!

Хакимнең икътисад буенча урынбасары Равил Рәхмәтуллин төпле кеше иде.

– Фәрит, – диде ул, – кичә кызым киноga киткән иде, озаклагач барсам, япа-ялгызы ниндидер фильм карап утыра. Ни хаҗәтемә безгә ул кеше йөрмәгән кинотеатр?

Район башлыгы ике сөйләттермәде: «Миннән рөхсәт, ал», – диде. Тимерне кызуында сугыйм, мәйтәм, бригада яллап, зал идәнен тигезләттем. Көрәш өчен менә дигән иркен мәйдан! Келәмнәр – дефицит, аптырамадык, анысын Мәскәүдән машина белән кайтарттык. Инде тренер «тудырасы», чөнки көндез чыра яндырып эзләсәң дә, Биектауда аны табалмыйсың, ә элек бил алышкан егетләр кайсы кая таралышкан. (Без аларны яңадан барлап, үзебезгә тарттык.) Ниһаять, аң төпкеленнән бер исем калыкты:

Ринат Гиламов! Ул салгалый, диләр. Гайбәттән гарык мин. «Тәрбияләрбез», – дидем. Шәп тренер, техникасы әйбәт. Без аның белән көрәш секциясе оештырып җибәрдек. Зур итеп яккан учакның очкыны ерак-еракларга чәчри, авыллар уянды, дистәләгән ноктада көрәш җанланды. Бинаны өр-яңадан төзекләндереп, эчен-тышын яңарттык. Аны ачканда, ул чактагы Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев белән финанс министры Рөстәм Миңнеханов та тантанага килде. Кунакларны каршылаганда, ничектер мин иң беренче Рөстәм Нургалиевичка кулымны суздым. Ул:

– Фәрит, башта Президент белән исәнләшәләр, – диде.

– Гафу итегез, Минтимер Шәрипович, – мәйтәм. Илбашы:

– Ничего, Фәрит, – дип елмаеп, җилкәмнән какты.

Минем гадәт: көрәш залыннан егетләр китмичә, өйгә кайтмый идем. Кайчакта Ринатны алыштырам. Аның уңышлары турында газетада мәкалә бастырганнар иде, Апас хакимияте башлыгы Азат Хәнифәтуллин шаккатып, баш чайкый икән.

– Кара син, бу бит безнең якташ малай! Кара син, ничек яхшы эшли икән. Немедленно үзебезгә кайтарыгыз!

– Фәрит абый, нишлим? Җәйгә коттедж төзеттерәм, ди глава. – Гиламов бармагын угалады. Уңайсызлана егет. Фәрит абыйсы: «Без сине эшле-ашлы иттек, рәхмәтең шушымы?» дип оялтыр, ди бугай. – Сез ни әйтсәгез, шулай булыр, Фәрит абый.

Ничек кеше тормышына тыкшынасың! Миңа андый вәкаләт бирелмәгән. Эчтән сызам. Тернәкләндек дигәндә генә, тренерсыз калулар, ай-һай, авыр. Алар – алтын бәясе.

– Хәерле юл, Ринат, – дидем. – Ярдәм кирәксә, тартынма, шалтырат.

«Аптыраган-җөдәгән, артын мичкә терәгән», – ди халык, миңа алай озак аптырарга ярамый иде: Гиламовка алмашка спорт мастеры Данис Сәлахетдиновны чакырдык. (Ринат – бүген Апаста бердәнбер тренер. Хакимият башлыгы белән сөйләшкәндә: «Тырыш егет. Аңа мактаулы исем бирергә вакыт, әйдәгез, мин Казаннан булышам», – дидем. Хәзер ул «Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре».)

Җәүдәт Миңнәхмәтовтан соң Биектау районын Рәшит Шәяхмәтов җитәкләде. Өченче хаким Нәгыйм Сәгъдиев белән дә аңлашып эшләдек. Әмма аппарат җитәкчесе белән женнәребез килешмәде, ахрысы: төрле программаларда катнашуым, сукыр тиен сорамыйча дәүләт хисабыннан биниһая зур спорт комплексы төзергә йөрүем, хәтта ки балалар һәм яшүсмерләр өчен Көрәш мәктәбе оештыруым ошамады. Бигрәк тә ул минем мөстәкыйльлекне өнәмәде. Кимчелекме бу, хатамы: «Фәлән Фәләнович, бүген моны үткәрәм, иртәгә фәлән әйбер планлаштырам», – дип, түрәләргә отчёт бирергә яратмый идем. Район уч төбендә: кайда нәрсә булган – барысы да күренә. Нигә һәр иртә аларның ишеге төбендә таптанырга?! Проблема туса, киңәшәсең анысы.

Җиденче тоем белән тоя идем: миңа монда дөнья тарайды. Башымда: «Киңрәк колачлап, зур эшләр майтарасы, көрәшкә якынаясы иде», дигән уйлар бөтерелә иде. Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдиновка турыдан ярдым.

– Аңладым, Фәрит абый, – диде ул. Үтенечемне җилгә очырмады,

рәхмәт аңа, туган көнем белән котлаганда, күңелле хәбәре белән сөендерде:

– Фәрит абый, Казанда көрәш сарае төзиләр. Әйдәле, икәү барып карыйк, – диде.

Директоры Айрат Гайнетдинов яшь кенә егет: «Урынбасар кирәк», – дигәч, Хәлил миңа ымлады.

Бер акыл иясе: «Артыгыздан күперләрне яндырмагыз», – дигән. Шуннан кире чыкмагаең, имеш. Мин дә яндырмадым.

– Китәм, – дидем Сәгъдиевкә.

– Юк, каласың, – диде ул.

– Мин бит Миңнәхмәтов кешесе, – дидем, аларның мөнәсәбәтләренә төрттереп. – Мин усал, сез миннән дә усалрак. Йә сугышып бетәрбез.

– Әйтсәң – әйтәсең инде син, – дип көлде ул. Тәки җиңелмәдем. Хаким дә үзсүзле иде, эштән азат итүен сорап язган беренче гаризамны ертты: «Китмисең, бергә эшлибез». Икенче гаризамны да ерткалап, чүплек савытына ташлады: «Бергә эшлибез, Шәйхетдинов». Өченчесендә кул куйды һәм башкарма комитет рәисенә боерды:

– Фәритне тоталмадык инде, хөрмәтләп озатыгыз!

Унөч ел гомер Биектауда үтте. Йөгеңне ат кебек җигелеп тарттың, артыңнан тау хәтле хезмәтең өелеп калды, диләр. Район уңды кебек: чираттагы хакимият башлыгы Рөстәм Кәлимуллин көрәш җанатары иде. «Кире кил», – диде ул миңа. «Рәхмәт», – дидем. Ул читтән көрәшчеләр ияләштереп, үзенекеләргә кырын карап, бик нык ялгышты. Биектау данын үз егетләрең белән күтәр, көрәш тавының иң биек түбәсенә җиңү байрагын алардан кадат! Мин сыкранмыйча кем сыкрансын: бу төбәктә көрәш уты кабынсын дип, шырпы сызган кешеләрнең берсе идем бит.

«Ак Барс» көрәш сарае директоры урынбасары вазифасына 2009 елның 4 декабрендә керештем. Менә ичмасам масштаб! Ял көннәрендә дә Россия яки Татарстан күләмендә уздырылган спорт турнирлары, чемпионатлар, бәйгеләр... Бу тоташ ел әйләнәсендә! (Бөтенесен дә санап укучыны ялыктырмыйм.) Без төрле оешмалардан кунаклар да каршыладык. «Ак Барс» көрәш сарае искиткеч объект: спорт заллары, фитнес-клуб, бассейн... Кызыксына кеше. Иренмибез, күрсәтәбез.

Бездә яңалык өстенә яңалык: борынгы «Сумо көрәше»н үзләштердек. Ул да көрәшнең бер төре, японнарда аны яугирләр сәнгате дип атыйлар. Мәйданчыктагы ике ир-ат бер-берсен сызык кырыена кысрыклап чыгара яисә табаныннан тыш гәүдәсенең кайсыдыр өлеше белән җиргә орындыра. Шул рәвешле җиңүче ачыклана. «Сумо»гыз татарга ниемә инде?» – дип бәйләнде кайберәүләр. Хәлил Шәйхетдинов әйтмешли: «Кемгә комачаулый ул? Матур көрәш. Унике айда өч Аурупа чемпионы әзерләгез әле сез!»

Узган елда (2021) «Прорыв года» номинациясендә билгеләнүебез танылуда беренче адым иде.

Яшәгән саен уйландыра: нишләп балачагымнан ук көрәш дөньясына чумдым икән? Кул-аяк исән, акыл камил, нигә бүтән өлкәләргә кызыкмадым? Татар баласының канындамы әллә ул көрәш? Әнә тарих сөйли: Әбү Хәмид әл-Гарнати (1131 ел) халык бәйрәме Сабан туе һәм көрәшче пәһлеваннар

турында язып калдыра. Без Рушания белән өч малай үстердек. Болгавыр 1985-96 еллар иде. «Бистәдә имансызлар яшереп кенә, наркотик тарата, башта яшь-җилкенчәккә тәмен татыта, ә инде тегеләр «кәнфитсез» күңелсезләнгәч, акчага сата», – дигән шомлы хәбәрләр колакка чалына, шуңа күрә миңа шәкертләрем белән улларымны урам йогынтысыннан саклар өчен уяулыкны югалтмаска кирәк иде. Иртән малайларымның тәпи басканын да, яңа гына аякланганын да, үзем белән ияртеп, секциягә китә идем. Миннән күрмәк улларым да көрәш белән мавыкты. Олысы – Фәнис бәләкәйдән үк «грек-рим» тарафдары, үзеннән олыракларны җиңә иде. Ләкин табиблар умыртка баганасындагы үзгәрешләрдән соң көрәш белән саубуллашырга кушты. Ул – хокук белгече. Аның каравы улы Тимерхан ирекле көрәш секциясендә шөгыльләнә.

Уртанчыбыз Фәнил 2005 елда Чаллыда яшьләр арасында Россия беренчелегенә оештырылган ярышта алтын медаль белән бүләкләнде. Татарча көрәш буенча Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә узган Муса Җәлил исемендәге турнирларда ике ел рәттән чемпион исемен яулады. Бөтенроссия бәйгеләрендә дә ул җиңүчеләр рәтендә. Сигез яшьлек малае Сәйдәш тә ирекле көрәш ярата. Ә төпчегебез Фәннүр – Россиянең атказанган тренеры Вакыйф Дәүләтшин шәкерте.

Улларым һәм оныкларым миннән күрмәк, дисәм, үземнең көрәш белән чирләвем, аңа фанатизм дәрәҗәсендәге мәхәббәтем кайдан икән соң? Әнинең этисе – Туктый кушаматлы Габдрахман бабай сөйләвенчә, аның бабасы Хәлиулла озын буйлы көрәшче булган. Аны иң азактан гына чыгарганнар, чөнки йөз егерме килограммлы гәүдәсе белән ир-егетләрне имгәтер дип курыкканнар. 1820 елгы Хәлиулла сиксән биш яшендә үлә. Ул чор өчен озын гомер! 1902 елдагы мәгълүматларны карадым: Россия империясендә ир-атның уртача яше – утыз ике ел.

Шушы бабай мирас итеп, миңа көрәш таягын ташлап калдырганмы? Әллә моның төбе-тамыры бик тирәндәме? Нәсел шәҗәрәбезне төзегәндә, 1570–1620 елларда туган Ирсәй, Ишем, Сәфәр атлы көрәшчеләрнең атасы Күк исемле икәнен ачыкладым. Димәк, мин Күк баба токымыннан, димәк, мин аның туруны!

Менә кайдан ук килә икән миндәге мәңге терелмәслек көрәш чире.

## 6. Әрнүләр һәм югалтулар

«Әй, кара малай! Атаң Сәгытдинне әйтәм, урам буйлата бодай сипкән кана. Син тугач шатландым, вә ләкин борчуда да идем, кара малай. Тормыш арба ул, гомер буе шуңарга ни тапканыңны төйисең. Түгелгән бөртекләр нәмәгә ишарәдер. Синең өлешең дип салынган ризык ла. Ни тапканыңны югалтырсыңмы икән, җә? Тормыш арба дим, арба, кара малай! Һи, тыңламый, ташбаш.

Биш яшьлек Фәрит чынлап та аны тыңламады, су коенырга йөгерде. Дәү этисе әллә нәрсәләр сөйли шунда».

Әй, Шәйхетдин картлач! Әгәр бүген көрәшче оныгың белән гәпләшсәң – шаять ул сүзләреңнең мәгънәсенә төшенер иде. Кайгырма, нәсел дәвамчысының арбасы төзек, алтмыш сигез елда анда ниләр генә төялмәде! Ул нинди генә кыен чакларда да өмет белән яшәде. Дүрт туганы – абыйсы,

апасы, ике сеңлесе, дүрт йолдыз төсле караңгы төннәрен яктыртты. Аеруча Әнәс абыйсының киң җилкәсенә таянды егет. Ул бит аны: «Куркасыңмыни?» дип үчекләп, мәйданга этәргән иде. Кулы җиңел, ә! Шуннан соң көрәш буасы ерылды да инде.

Йә, язмышына ник рәхмәт укымаска, ди? Бер тапкыр сөю газаплары кичергәч, Аллаһы Тәгалә Фәриткә: «Гаилә корып, уллар үстерегез, Тимерхан, Сәйдәш, Мәрьям, Мәликә, Мәдинә исемнәре куштырган оныкларыгызга куанып яшәгез», – дип, ярын-парын, Кукмара гүзәлен юллады. Рушания – өйдәге учак, аңардан туңган бәгырьләрне эретерлек җылы бөркелә.

И-и, яши-яши арбага шыбыр-шыбыр югалтулар белән әрнүләрнең яңалары да тулды. Билдәшләре, шәкертләре, дуслары...

Виссарион, Виссарион... Уфада ничек Фәритне күтәреп, мәйдан әйләнгән иде, ә! Ничек шатланган иде ул чемпион титулына! Канашев аның хөрмәтнең дә хөрмәтенә лаек билдәше иде. Бөек көрәшче иде Виссарион! Күпмедер еллардан соң егет Башкортстанда яулаган медальне Фәритнең муенына такты:

– Бу синеке, Фәрит! Синең аркада мин җиңгән идем. Рәхмәт сиңа!

Алар чын ахириләр иде. Фәрит Шәйхетдинов беркайчан да көндәшләреннән көнләшмәде, аларның һәркайсы белән дус иде. Шулай икәү сөйләшеп торганда, кемдер:

– О Виссарион, сәлам! Тиздән сиңа алтмыш яшь тулачак, гөрләтеп юбилееңны уздырабыз, – диде. Канашев нәрсәдер сизенгәндәй:

– Ашыкма әле, анда кадәр яшисе бар, – диде. Яшәп җитешмәде, ничәдер айдан соң йөрәге тибүдән туктады...

Залесный бистәсендә Илшат Гарифуллин дигән унөч яшьлек малай яшен ташы иде. Маршрут автобусы белән Йошкар-Оланың Тарьял бистәсендәге көрәш ярышларына җыенганда, ул:

– Фәрит абый, мин дә барам, – диде. Тренерның берүзенә егермеләп бала, Илшатның исә тәртип ягы аксый, юлданиләр генә кыланмас дип шикләндерә иде. Шәкертләренең әти-әнисе һәм укытучылары белән элемтәсен өзмәгән остаз мәктәптән белеште: малайны укудан азат итмиләр. Менә бу ичмасам сәбәп иде. Ә Илшат күршедә генә яши, капканы ачар хәл юк, күзен тасрайтып ул тора!

– Фәрит абый, мине дә ал! Ал инде, Фәрит абый!

Секциядәге һәрбер баланың холык-фигылен яхшы өйрәнгән һәм ситуациягә карап, кайсы төймәсенә басарга икәнен чамалаган Сәгытдин улы психолог та иде.

– Ярар, Илшат, – диде Остаз. – Мин сине команданың капитаны итеп билгелим.

– Чынмы, Фәрит абый?!

– Чын, чын Илшат. Капитан – тәртип саклаучы ул, яме?

Тәртипсез тәртиплеләрне тәртиптә тота! Көл дә, ела да! Үзендә җаваплылык тойса – үзгәрәчәк, диде Фәрит. Ялгышмады: үсмер шул хәтле җитдиләнде ки, яшен яшьнәмәде, күк күкрәмәде, әле ярышта икенче урынны да алды. Ул секциядә Остазның уң кулы булачак, ә киләчәктә һичшиксез талантлы көрәшче дигән исем белән танылачак иде.

Йа Аллаһым, әллә язмыш уңышларын күпсенде, әллә шәкертен фаҗигагә юлыктырып, Остазын сынамакчы иде. Әйтерсең, ул камчысы белән йөрәккә үк сыдырды: бер атнадан велосипед белән юлны аркылы чыккан малайны машина бәрдерде. Табиблар аның гомерен саклады, әмма... аягын кистеләр. Моңа кайсы ир заты түзсен! Фәрит тә түзмәде...

– Син бигрәк йомшак кеше икән, Фәрит абый, – диде сәерсенгән адашы.

Егет үзеннән дә йөрәккә тау-тау әрнүләр өстисен белми иде әле. Ул аның бер үк һава сулаган, бер үк чишмә сулары эчкән үз баласыдай газиз авылдашы иде. Ике адаш: олысы Фәрит Шәйхетдинов, кечесе – Фәрит Бикмуллин. Карауҗада яшәгәндә үк, спорт белән чыныктырган укучысын зур мәйданнарда күрергә өметләнде Остаз. (Өметләнде дигәннән, ул кул астындагы барлык шәкертләренә дә шундый өмет баглый, чөнки алар бөтенесе дә талантлы иде.) Бистәдә адашы белән күршеләр, йортлары урам аша гына иде. Егет – мәйдан батыры, аңа тиңнәр юк! Тик җиңүләр тамак чылату белән аралаша: утыз көн айнык, утыз көн салмыш. Күрәләтә авылдашыңны упкынга тәгәрәтәсеңме: Остаз аның тән сакчысына әйләнде. Кече Фәрит вахта белән эшли, аларның автобусы аккурат иртәнге алтыда олы Фәритләр кырыеннан үтә иде, Сәгытдин улы сакта, барып, «объект»ы Бикмуллинны уята, киендерә һәм автобуска утыртып җибәрә иде. Берсендә ул әче таңнан китте. Сизенү!

– Каядыр баш төзәтергә чапты, – диде хатыны, еламсырап.

Фәрит аның кайтканын урамдагы су колонкасы янында көтте. Кайта, апын-төпен атлап кайта!

– Кил әле, кил, – диде олы Фәрит.

– О, авылдаш абый, ни хәлләрдә? – Егетнең теле көрмәкләнде.

– Минем хәлләр яхшы, синекен дә яхшыртабыз хәзер, – дип, Остаз җилкәсеннән бөгеп, аны салкын су белән коендырды. Чыдар әмәл калмаган иде. – Эчмә, эчмә! Илерткән дә аракы, тилерткән дә аракы. Әнә Арчадагы Габделхак нишләде?! Үлде! Аракы үтерде көрәшче Габделхакны! Син дә үләсең бит, энем!

– Куркытмәле, адаш абый! Мин үлмим. Ант, бүтән авызга да капмыйм, ант! Антымны бозсам – җир йотсын! Айныдым мин, агызма инде башыма су!

Аны автобуска өлгертеп, тынычланып, секциягә – балалар янына ашыкты Фәрит. Төшке әбәдкә кайтып барганда, Настя түтәй очрап:

– Синең дустың ләх исерек, бакчагыз кырыенда йоклый, – диде.

– Кем беләндер бутыйсың син, Настя түтәй. Ул эштә, үзем каравыллап озаттым.

– Һы, эштә сиңа! Бар, кара!

Әйе, иртән генә җирен-күген тоташтырып, ант иткән адашы койма буенда ауный иде. Күтәреп, өенә илтте олы Фәрит. Эссе мунчада себерке белән чабып айнытты ул аны.

– Бүтән эчмим, ант, Фәрит абый. Бездә чыгышы белән Башкортстаннан Азамат исемле егет эшли. «Өй салырлык акча җыйгач, туган якка китәм», – ди. Көрәшче малай. Без аның белән обедларда ун-унбиш минут «бәргәләшеп» алабыз. Язмышы турында җебен җепкә китереп сөйләде. Гыйбрәт дисәң дә гыйбрәт! Төнлә урамда аңа өч бандит бәйләнә. Тәмәке

сорап, ә ул тартмый, көрәшче чөнки. Тегеләрнең берсе пычак белән кадарга дип селтәнгәндә, бу аны әйләндереп кенә каплый. Башы ярыла бандитның. Азамат качмый, Ашыгыч ярдәм чакырта. Ну кеше имгәттең дип, судка бирәләр инде. Юкса тегеләрдә гаеп, пычак белән ташлангач, Азамат үз-үзен яклаган.

Судка хәтле вакытлыча тоту изоляторында көрәшнең бүтән төре белән шөгыльләнгән ул: көчсезләрне яклаган. Тынчу камерада кырыклап ир-ат икән. Монда бугайлар азынган, яңа кеше пәйда булгач тотыналар бәйләнергә. Мыскыллау, кыерсыту, кыйнау, бәвел эчертү боларны ләззәтләндерә икән. Ул беркайчан да башлап сугышмаган, мәгәр үзенә кагылсалар, әҗәтен йодрык тутырып кайтарган. Егет дәҗҗалның дәҗҗалы белән бәрелешкән. Лидерларын тукмагач, әшнәләре бик тиз шомайган икән.

Суд арты суд... Дүрт ел төрмә. Изолятордан аны Киров төрмәсенә озаталар.

Төрмә – ял йорты түгел, анда кеше – читлектәге кош. Җаның кысылып, төшенкелек биләсә – яшәүнең кызыгы бетәчәк. Азамат – көрәшче, ә көрәшче формасын югалтса, гәүдәсе сәлперәя. Аннан соң нинди мәйдан, ди! Хыялыңны җиде кат җир астына күм! Ә аңа мөмкинлекләр гел чыгып торган. Акыл белән файдалан гына. Әлбәттә, кыек атлаганын сизсәләр, башыннан сыйпамаслар иде. Аның эшен җиренә җиткереп эшләгәнен белгәннәр, шуңа иминлек хезмәте инженеры вазифасына кулайрак, дигәннәр. Цехларда тикшергән, кимчелекләрне язган, башлыкларына аңлаткан һәм үзе дә токарь цехында егетләргә үтә дә яшерен хәрби бурыч куйган. Штанга ясарга! Тимерләрнең буен, иңен, авырлыгын үзе үлчәп-сызып күрсәткән. Аңа бүлмә сыман аерым куыш биргәннәр, шунда егет тирләп-пешеп, штанга күтәргән дә, тикшерсәләр тапмаслык җиргә торбалар астына яшергән. Үзеңә теләгән изгелекне бүтәннәргә дә телә: иректә чакта бер Әлмәт егете дә штанга белән дуслашкан икән, яшереп кенә, аны да бүлмәсенә алып кергән. Көрәш белән мавыккан егет – аның өчен табыш, аңа тагын берничә малай өстәлеп, ухылдый-вахылдый ишегалдында сөлге белән тартышканнар.

Мәйданчыктагы турник аумасын гына: «Беләктәге кан тамырлары бүлтәйгәнче тартылдым»,– ди Азамат. Янгын сүндерүчеләрнең су кисмәге дә күзенә чалынган. Зу-ур, иңе-буе җиде-сигез метр чамасы, ди. Территориядә әрле-бирле сакчылар йөренә, әгәр каптырсалар – ничәдер тәүлеккә ялгыз камера! Йөзү көрәшчегә тәҗел кирәк, монысын да җайлаган егет: сакчылар киткән арада сусаклагыч капкачын сыза гына ачык калдырып (яктылык төшсен!) йөзгән дә йөзгән! Менә ичмасам яшьләргә үрнәк бу Азамат. Бетәшмәгән егет, дөньясына кул селтәмәгән, иеме, адаш абый?

– Сиңа да үрнәк ул, энем.

– Эчмим дидем бит инде! Ант!

Сүзләр бер үк, ә гамәлләр икенче иде. Ничек кенә тырышмасын, коткара алмады шул. Ярты елдан утлы елан чагып, япь-яшь егетне гүргә тыкты. Үкенечле үлем! Хәмергә сатылган гомер! Югыйсә авылдашының ал да гөл: көрәшә, эшли, гаиләле, әгәр инде ниндидер фаҗигаләр кичерсә – кайгысын юа, дияр идең. Ә монда... Их!

Мәмдәл Сабантуйларында икәүләшеп мәйдан шаулаткан якын дусты

Зөфәр Хәнәфиевны дә хәмер харап итте. Милли көрәш йолдызы иде ул, яшьтән үк спорт күгендә балкыды, киләчәктә, мөгаен, үзе дә Остаз статусына ия булып, шәкертләренә көрәш серләрен төшендерер иде. Өстеңә дан ява, сиңа сокланалар, сине мактыйлар, халык арасында шөһрәт казанасың, ләкин боларны күтәрергә ихтыяр көчең җитми. Аның шунысы куркыныч та. Зөфәр моның бер мисалы иде.

Фәритне яшең узган дип киреләнгән тренер белән таныштырган дусты икенче елда Казан төзелеш институтына керде. Башлы! Берьюлы өч-дүрт югары уку йортында укырлык. Шәхси тормышы да көйләнгән кебек. Марҗа Татьянага өйләнде, кызлары туды. Югары Осланда төзелеш прорабы иде, ә Фәритнең бу вакытта колхоз рәисе Ринат Гатинның үтенечен тыңлап, мәктәп төзү мәшәкатьләре белән йөргән чагы. Елы да хәтердә: 1996 ның җәе. Югарыосланлылар Сабан туена әзерләнә. Зөфәр дә кытыкланган, ул:

– Фәрит, син барасыңмы? – дип сорады. – Әгәр батыр калдыртсаң, мин дә көрәшер идем.

Аксый! Әллә кайчан аягын бәргән иде, һаман хастаханәдә тикшерелмәгән.

Үгетлә, орыш, тиргә яки бәргәләп ат – файдасыз. Кермәсә дә керми икән адәм баласына! Инде көрәшәм, ди. Дәрт бар, ә дәрман юк бит инде. Шушы авырткан аягы белән ничек бил алышмакчы икән, ә?

– Хуп, көрәшерсең, Зөфәр!

Дустының көрәш дәртен сүндерергә базмады ул.

Кыр бәйрәменә Казаннан да көрәшчеләр җыелды. Зөфәрнең күзләре сагышлы иде. Ул колхоз айгырлары кебек мәйданда сикергәләгән ир-егетләргә карап торды-торды да авыр гына сулап:

– Чыкмам, ахры, – диде. – Ни... син нит әле, мине үзәккә төшер әле.

– Эчүеңне ташла, зинһар, ташла! – Фәрит йөз дә беренче тапкыр дустына ялварды. – Басылмый ул аракы белән чир. Никләр генә яраңны дәваламыйсың?! Ахырдан үкенерсең, Зөфәр. Ярар, иртәгә үзем табибка илтәм сине.

Зөфәр үпкәләде:

– Син инде тагы. Бала-чагамыни мин? Үзем барам, дим бит. Төшер әле үзәккә!

Шул ук елның декабрь аенда егетнең аягын кистеләр. Яра чиләнеп-бозылып, гангрена башланган иде.

Сәгытдин улы эше ни тыгыз чакта да дустының хәл-әхвәлен белешергә вакыт тапты. Соңгы баруында Зөфәр инде караватында селкенмичә ята иде, дустының тавышын ишеткәч, күзен тутырып-тутырып, аңа карады. Сырхауның туганы:

– Ике тәүлек күзен ачмаган иде, бүген сезгә ачты, – дип шаккатты.

Сүзсез генә бәхилләшкән икән. Иртәгәсен җанны айкаган коточкыч хәбәр: «Зөфәр китте...»

Ләгънәт яугыры шайтан суы әнә шулай татарның тагын бер талантлы көрәшче баласын мәйданнан алып ыргытты.

Ир-ат таш бәгырьле, еламый, диләр. Елый, тик күрсәтми, Фәрит тә күрсәтмәде, күз яшьләре туп-туры йөрәгенә тамып, боз-сөңгегә әверелде...

...Йа, бу исемнәрнең кайсысын тормыш арбасыннан коеп калдырасың? Алар – аның әрнүләре, аның югалтулары. Ул шәкертләре һәм дуслары

белән данын да, дәрәҗәсен дә бүлешер иде. Барысына да үзенең хәләл көче белән иреште, беркайчан да көрәшче исемен тапламады. Көрәшче... Ә бәлки, Фәрит Шәйхетдиновка тренер роле кадерлерәктер? Әйе, кадерлерәк! Әнә ничә тукталыш: авыл мәктәбе, Залесный бистәсе, «Ак Барс»та тугыз ел – Татарстан, җиде ел Россия җыелма командасы баш тренеры. Ул шәкертләренең уңышларына сөенде, алдыртып китмәсәләр – көенде. Яшьләрне өйрәтүдән тәм тапты Остаз. Бүген аның бөркетләре уенынчынын бергә кушып:

– Син мәйданга чыксаң, котыбыз оча, чөнки син безне кыса идең, Фәрит абый, – диләр.

Юк, егетләр, ул кысмады, ул сездән таләп итте! Мәйдан җебегәннәр өчен түгел. Баш хөкемдар вазифасы намуска бәйле иде. «Гадел бул, һәркемгә тигез кара».

Яшь чакларда гаделсезлек күсәге белән шактый кыйналган Сәгытдин улының көрәшчеләрне «сөйкемсез» яисә «сөйкемле сөяк»кә аермавын беләләр, шуңа күрә аның тирәсендә «фәләнне якла» дип, беркем дә ышкылып йөрмәде. Шәйхетдинов сатылмаячак! Кайчандыр аны чеметкәләгән Мәгаз абый Сәхабетдинов унсигез ел шушы көрәшне җитәкләде (мәрхүм инде, урынын җәннәттән әйләсен Аллаһы Тәгалә!). Аның турында: «Объектив түгел», – диләр иде. Әмма ул ялгыш та Фәриткә: «Моны җиңүче калдыр», – дип әйтмәде. Ә кайбер түрә-мазар өйрәтеп маташса яисә акны кара, дип исбатласа, Фәрит усал гына:

– Ә сезнең кайсыгызның мәйданда сыбызгы сызгыртып торганыгыз бар? Анда бит бөтенләй башка төрле уйлыйсың, җиңел түгел анда! – диде.

Әйе, көрәш дөньясында яшәве җиңел түгел. Сәгытдин улы таштан яралмаган, Сәгытдин улы – адәм баласы. «Моның хәтле йөк ниемә кирәк?» – дияргә дә, читкәрәк китеп басаргадыр, бәлки? Залесный бистәсендә шәхси Көрәш клубы ачам, дигән хыялны нишләтәсең?


Бер кичне хатыны белән төнге урамда һава сулаганда, ерактан ук аны озын буйлы ир-ат сәламләде:

– Исәнме, Фәрит Сәгытдинович?! Мин сезнең яхшылыгыгызны мәңге онытмыйм, сезгә барысы өчен дә зур рәхмәт. Тормышым әйбәт, өч бала әтисе мин. Олысына унсигез яшь!

Александр-Саша! Остаз белән шәкерт кочаклашып күрештеләр. Хәтерли Фәрит: бәләкәй малайның әтисе башта әнисен үтерә, аннары үзе асылына. Саша әбисендә үсте. Ятим баланы урам баткагы суырып, бик тиз юлдан яздырырга мөмкин, шуңа күрә Остаз аны көрәш белән мавыктырып усал җилләрдән ышыклаган иде. Әнә бүген егет ихлас күңелдән рәхмәт укый! Ә андыйлар бер Саша гынамы? Андыйлар йөзәрләгән-йөзәрләгән! Ә ул читкә китеп басмакчы... Әле үзе көрәш чиреннән дә терелмәгән.

«Терелмәс тә! Безнең көрәшчеләр токымы шундый!»

Чү, әллә бу гасыр диварлары аша саркыган Күк баба тавышымы?!



Факил
Сафин

# БӘХЕТЛЕЛӘР ҮЗ ИЛЕНДӘ ЯШИ...

## И хатын-кыз!

Бар табыну – Сезгә, хатын-кызлар!
Кыю булабызмы, кырысмы, –
Җиргә туган, ир-ат-булган өчен
Без мәңгегә Сезгә бурычлы!

Сез бирәсез галәм кояшы күк
Яктылыкны безнең җаннарга.
Өйрәтәсез тормыш матурлыгын,
Яшәү гүзәллеген аңларга.

Бәйрәм белән бәйрәм арасында
Гөлләр генә үсми юлларга.
Сикәлтәләр булса, аумас өчен
Сузылабыз Сезнең кулларга.

Ир йөрәге – күккә талпыныр кош,
Хатыннарда йөрәк – янарга!
Җир шарында шатлык, хәсрәт күпме –
Барысы да сыя аңарга.

Без гайрәтле фәкать Сезнең алда.
Гамәлләрнең гадел бизмәне
Хатын-кызлар! Горур, чая ярлар
Сез тормышның уңмас бизәге.

Бар табыну Сезгә – хатын-кызлар!
Кыю булабызмы, кырысмы, –
Мәхәббәтле гомер биргән өчен
Без мәңгегә Сезгә бурычлы!

Факил САФИН (1954) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г.Исхакый, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр иясе. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Саташып露аткан таң» роман-трилогиясе, «Биек тауның башларында», «Галәм күзе» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

***

Ярый әле кодрәт чикле,
Акыл саташыр иде:
Әллә кемнәр айны җиргә
Сөйрәп маташыр иде.

Ә мин менә күлгә кереп,
Айны чүмечкә җыям.
Алтын айның яктысыннан,
Синең сыныңны коям.

Сокланып карап торабыз,
Чирек ай күлдә йөзә.
Ярый җирдә мәхәббәт бар,
Ул куәт бирә безгә!

## Ераклык

Син мине чакыргансыңдыр... –
Була сагынган чаклар.
Аккош каурыйлары белән
Язгансың сәлам хатлар.

Хисләреңне җырга салып,
Чакыргансың җыр аша.
Сагышлы һәм якты моңнар
Җаннан җанга тоташа.

Нәүмиз калган чакларыңда,
Ялгызлыкта, аулакта,
Син мине чакыргансыңдыр,
Исемемне кабатлап.

Кыр казлары киткән яктан
Килгән җырларны таныйм.
Болыт аккош каурые күк –
Күземне ала алмыйм.

Син мине чакыргансыңдыр,
Җил исә сезнең яктан.
Кайтыр юлларым буталган,
Син – якын да, ерак та...

## Бәхетлеләр

Бәхетлеләр вакыт санамыйлар.
Көн сизелми, кайнар төн кыска.
Мәхәббәтле һәрбер үлән җирдә,
Якын туган – һәрбер кырмыска.

Бәхетлеләр ялгышларны тоймый,
Боз өстендә дөрли учаклар.
Күңел түре – тәлгәш-тәлгәш йолдыз,
Җылы җилләр сыйган кочакка.

Бәхетлеләр зәңгәр күктә йөзә,
Ару белми дәртле канатлар.
«Ялгышасың!..» дигән чакта кемдер,
«Юк!» дигәнне ирен кабатлар.

Бәхетлеләр яз илендә яши,
Кар-буранлы кышка керсә дә,
Ачылмаслык ишек, капкалар юк,
Алтын ачкычлары кесәдә...

## Гөрләвекләр

Язгы сулар ага, ярлар көлеп кала,
Кояш нурын эчә гөрләвек.
Тамчылары тере, күзен кыса бөре,
Гаҗәп тә соң яшәү серләре!

Шәфәкъ алсулана, офык балкып яна,
Гөрләп-шаулап ага кар суы.
Су өстендә чаткы, ай йолдызын тапты! –
Тылсымлы мәл – язның ташуы.

Гөрләвекләр акты, ярга учак яктым,
Төнне куып бии ялкыннар.
Мәхәббәттән шашкан, йолдызларга ашкан
Язларым бит шундый якыннар...

Үтте гомер, дисәм... Яшь бөреләр күрсәм,
И яктыра күңел түрләре:
Җырлап-уйнап ага, килеп җанга кага
Кояш нурын эчкән гөрләвек.

## Хәтер болыны

ТРИПТИХ

**1**

Тагын килдем. Мин ят монда...
Ни эзлим, нигә киләм?..
Күк гөмбәзе – зәңгәр чатыр,
Җир өсте – яшел түбәм.

Болын иле. Төрлелектән
Ак көнем зеңләп тора.
Офыкка бары шушыннан
Үтәчәгеңне юрап,

Басып торам җил каршында.
Синең сулышың кебек
Кайнар. Кайнарлыгы аның,
Дулкын сыман бөркелеп,

Йөзгә бәрә. Бөтерелә,
Чайпала болын – көймә.
Моңнар килә... Кайчандыр без –
Бергәләп откан көйләр.

Кабат-кабат үреләмен
Синең килер ягыңа.
Ерактан яулык болгыйсың...
Сагындыра... Сагынам...

**2**

Гүләп тора тере болын,
Ә каршымда – силуэт.
Тирә-ягым дөрләп яна,
Хәтер бит ул – синең ут!

Гөлләр кача кайнарлыктан,
Йөгерешә яшь үлән.
Күк гөмбәзе – зәңгәр сукмак,
Җир өсте – яшел түбәм.

Тәгәрим. Хәтер утыннан
Исән чыгалмам, беләм.
Офык ягына кузгалган
Салмак болытны күрәм.

Син дә үтәрсең шул якка,
Эзеңә сыенырмын.
Гөл яныннан дәшми генә
Үтүе кыендыр ул...

**3**

Ә син дәшмә!.. Җилләр сөйләр,
Барысын алар белә.
Гөлләр кибәр кайнарлыктан,
Саргаер яшел үлән.

Сөю безгә читтән карап,
Шашынып, үксеп көләр.
Офык яклап моң агыла,
Мин белмәгән ят көйләр...

Мин – ак кылган. И йөгерәм,
Кул сузымы барасы.
Ни җибәрми, ни тота соң,
Ник торам мин чарасыз?..

Җилләр – хыял, ә мин кылган,
Җилләргә башны салам:
Моңнар агылган тарафка
Көмеш чык ярып барам.

Ят күрепме – болын дөрли,
Тыналмый тоташ гүдән...
Күк гөмбәзе – яшел чатыр,
Җир өсте – зәңгәр түбәм...

Фирдүс Гыймалтдинов

# БУА

РОМАН

***

Поезд составы, мең төрле газап үтеп, ниһаять, Мәскәүгә килеп туктады. Григорий Афанасьев кирәк-яраклары, документлар салынган чемоданын җәһәт кенә кулына алды да перронга ашыкты. 1942 елның февраль ае иде. Урамда шыксыз, вокзалда халык ташкыны, биредә күбесенчә хәрбиләр, ләкин гади кешеләр дә җитәрлек, араларында эшсез кул кушырып, уңлы-суллы сугылып йөрүчеләр дә бар. Вагоннан чыгып, саф һавада ул бераз аңышмый торды. Аны яшь, көр тавыш айнытып җибәрде:

– Иптәш дәүләт иминлеге майоры! Исәнмесез!

Аңа таба лейтенант формасындагы егет ашыга иде.

– Лейтенант Соколов! Иптәш дәүләт иминлеге майоры, миңа сезне озатып куярга әмер бирелде, – диде теге егет, Афанасьевның кулыннан чемоданын алып.

Алар, вокзалдан чыгып, юл читендә торган җиңел машинага утырдылар.

– Сезне башта кунакханәгәме? – дип сорады Соколов, юлдан күзен алмыйча.

– Юк, өлгерермен. Башта Үзе янына.

– Яхшы, иптәш дәүләт иминлеге майоры!

Һөнәри тоемлавы бу юлы да ялгышмады – вокзалдан ук Нафталий Френкель кабинетына килеп, ул дөрес эшләгән, биредә аны инде зарыгып диярлек көтәләр. Кабул итү бүлмәсеннән туры кабинетка озаттылар. Афанасьев башта Френкель, аннары бүлмәдәге тагын бер генерал белән исәнләште.

– Сез әлегә таныш түгел бит, – диде Нафталий Френкель, нигәдер өстәл янына утырырга ашыкмыйча. – Гвоздевский Фёдор Алексеевич. Ул минем урынбасарым, Байкал-Амур магистрале төзелешен җитәкләүче кеше. Ә бу – Афанасьев Григорий Давыдович. Без аны әле генә көнбатыш фронтындагы саклану ныгытмалары төзелешеннән чакыртып алдык. Икегез дә уңган, булган кешеләр. Партия һәм иптәш Сталин сезгә яңа эштә зур өметләр баглый.

Афанасьев тормышында үзгәреш булачагын кичекмәстән Мәскәүгә

---

*Ахыры. Башы 1, 2 нче саннарда.*

чакыру алгач та сизенгән иде. Димәк, яңа эш... Гвоздевскийга аның хакында, күрәсең, мәгълүм. Ләкин кызыксынуы зур булса да, вакытыннан алда сораулар биреп, җитәкчеләрнең кәефен кырырга ярамый.

Френкель кул сәгатенә күз салды.

– Вакыт җиткән, безне Лаврентий Павлович көтә.

Алар, өчәүләшеп, Лаврентий Берия кабинетына юнәлделәр. Алар кергәндә Берия аягүрә баскан килеш телефон төрепкәсен кысып тотып тора иде. Ул ишектәгеләрне кулы белән ымлап кына сәламләде дә бик зур дикъкать белән кемнедер тыңлавын дәвам итте. Аннан соң: «Аңладым, иптәш Сталин», – дип, төрепкәне куйды.

– Утырыгыз, иптәшләр, – диде ул, үзе дә киң өстәле янында урын алып. Әйтерсең, бүлмәдәгеләр белән әле күптән түгел генә күрешкәннәр, ул һәркайсын да шәхсән белә. Афанасьевны күргәне бар анысы, ләкин җәелеп утырып гәпләшкәннәре юк. Хәер, Григорий Давыдович бу бүлмәдәге тәртипләрдән бик яхшы хәбәрдар...

Берия өстәл тартмасыннан бер документ тартып чыгарды.

– Иптәшләр, 1942 елның 15 февралендә Дәүләт Оборона Комитеты бик мөһим, гадәттән тыш яшерен карар чыгарды. Сез, биредә утыручылар, – ул каршындагы өчлекне түгәрәк пыялалы күзлеге аша барлап чыкты, – барыгыз да дәүләт сере белән эшләүче кешеләр, шуңа курыкмыйча сөйләшәбез. Карарның нөсхәсе сезгә җиткерелер, мин аны тәфсилләп укып тормыйм. Ике сүздә генә төп мәгънәсен аңлатам. Быелның 23 гыйнварындагы карар нигезендә безнең Эчке эшләр буенча Халык Комиссариаты Ульяновскидан Сталинградка кадәр тимер юл төзелешен башлады. Аны иптәш Фёдор Алексеевич Гвоздевский җитәкли. Без иптәш генералны махсус рәвештә Байкал-Амур магистрале төзелешеннән күчердек, бүген ул безгә биредә кирәк. Кайберләрегезгә мәгълүм булганча, БАМ төзелеше әлегә туктатылды, аның хәзерге шартларда әһәмияте кимеде, дип әйтик. 15 февраль карары исә ТАССРдагы Зөя станциясеннән Ульяновскига кадәр тимер юл төзелешен күздә тота. Нәтиҗәдә, Идел яры буйлап Зөядән Сталинградка кадәр хәрби тимер юл – рокада сузылырга тиеш. Җәмгысе мең чакрымга диярлек ара. Безгә моның өчен 1942 елның азагына кадәр вакыт бирелә. – Берия, графиныннан су салып, тамагын чылатып алды. – Фашистларны туктатасы бар, ә моның өчен ышанычлы транспорт чарасы бик тә кирәк.

Берия, теге документны өстәл тартмасына кире салып, кулына ниндидер папка алды. Афанасьевның эче «жу» итеп китте. Бу – аның шәхси эше иде.

– Григорий Давыдович Афанасьев, – дип укыды Берия, аннан янә түгәрәк пыялалары аша майорга караш ташлады. Бер мизгел текәлеп торгач, игътибарын кире шәхси эшкә юнәлтте. – Сез, иптәш майор, үзегезне безнең уртак эшкә чын күңелдән бирелгән тугры кеше итеп күрсәттегез. Бүген көнбатыш фронтында башкарган хезмәтегезне дә күрәбез, ул зур дәрәҗәдә сезнең шәхси сыйфатлар бәрабәренә дә ирешелде. Сезнең кебек кеше безгә бүген үтә дә җаваплы участокта кирәк. Ничек уйлыйсыз, булдыра алырсызмы? Сүз япа-ялан басуда барысын да юктан оештыру турында бара.

Афанасьев урыныннан сикереп торды.

– Партиянең, иптәш Сталинның һәм сезнең ышанычны һичшиксез аклаячакмын, иптәш Эчке Эшләр буенча Халык Комиссары!

– Утырыгыз, Григорий Давыдович, утырыгыз. Акларга туры киләчәк, чөнки, бердән, төзелеш безнең комиссариатка йөкләнә, икенчедән, Дәүләт Оборона Комитеты карарларын вакытында үтәү иптәш Берия өстендә.

Берия, урыныннан торып, күрше өстәлдәге карта янына килде, башкаларны да үзе янына чакырды.

– Барлык төзелеш эшләре өчен дә җаваплы кеше итеп Нафталий Аронович Френкель билгеләнә. Сораулар, мөрәҗәгатьләр, гозерләр – барысы да аның аша. Зөя – Ульян тимер юлы участогы өчен НКВДның Тимер юллар төзелеше буенча Баш лагерь идарәсе составында Идел буе төзәтү-хезмәт лагере идарәсе оештырыла. Волжлаг. Иптәш Афанасьев, сез аның җитәкчесе итеп билгеләнәсез. – Берия каләме белән картага төртеп күрсәтте. – Урнашу урыны – Казан шәһәре. Башлангыч пункттан ерак түгел Зөя бистәсе бар. Аны тоткыннарны кабул итү базасы буларак кулланырсыз. Анда иске чиркәүләр күп, барак урынына шуларны файдаланырга мөмкин. Григорий Давыдович, сезгә сак хезмәте белән әллә ни чиләнәсе булмый – лагерь контингенты чикләнгән булачак, күбрәк Идел буе немесләрен җибәрергә планлаштырабыз. Фронт сызыгы иптәш Гвоздевский участогына артык якын, анда немесләрне куллану куркыныч. Һәм, әлбәттә, җирле халыктан хезмәткәрләр җыярга туры киләчәк. Урындагы хакимиятләр белән тыгыз элемтәдә эшләгез. Дәүләт Оборона Комитеты карары белән өркетә аласыз. Аңлашылдымы, иптәшләр?

– Иптәш Берия, рөхсәтме? – дип, паровоз гүләве төсле тавыш белән аваз салды Гвоздевский.

– Әйе, иптәш Гвоздевский.

– Рельсларны кайдан алырбыз? Промышленность бөтен көчен фронтка җикте, без бүген рельс чыгаруны туктаттык диярлек...

Берия уйга калды.

– Нинди тәкъдимнәр бар?

– Әгәр рөхсәт икән, – Гвоздевский янә сүзгә кушылды. – Мин Байкал-Амур магистраленең бер өлешен сүтеп, рельс белән шпалларын бирегә китертергә тәкъдим итәм.

– Шәп тәкъдим, иптәш Гвоздевский! – Бериянең йөзендә бер генә мускул да кымшанмады, ләкин тавышында ниндидер шатлык хисе бар иде. – Тик бу фикерне башта Дәүләт Оборона Комитеты аша үткәрергә кирәк.

Кинәт өстәлдәге телефон шалтырады. Берия тиз генә барып, төрепкәне алды да, бүлмәдәгеләргә сөйләшү тәмам булуын ымлап, кабинеттан чыгарга кушты.

Бу очрашудан соң Григорий Афанасьевка әле бик озак Нафталий Френкель бүлмәсендә булырга туры килде. Френкель аңа эшнең нечкәлекләрен аңлатты, аерым күрсәтмәләр бирде, тиешле документларны тапшырды. Аннан чыкканда, вакыт инде кичкә авышкан, караңгы төшә башлаган иде. Юлдан килгән Афанасьев шунда гына никадәрле арганлыгын тойды. Куллары авыр чемоданын да күтәрер хәлдә түгел, көне буе авызына берничә стакан судан башка берни капканы булмады. Афанасьев НКВД бинасында урнашкан ашханәгә юл алды.

Ашханәдән тиз генә капкалап чыкканда, янәдән паровоз гүләвенә охшаш тавыш ишетелде:

– Григорий Давыдович, бирегә килегез! – Фойедагы кәнәфиләрнең берсендә Гвоздевский елмаеп утыра иде.

– Әлбәттә, иптәш генерал, мин хәзер...

– Безгә бик авыр йөк салдылар, Григорий Давыдович, – диде Гвоздевский, Афанасьев янәшәсенә утыргач та. – Бер мең чакрым ара, бер ел да вакытыбыз юк. Әйтте диярсең, әле бирелгән кадәр срогын да кысачаклар. Кулыбызда проект түгел, юл үтәсе җирләрнең рәтле-юньле карталары да юк.

– Аңлыйм, иптәш генерал...

– Безгә проект һәм төзелеш эшләрен берьюлы алып барырга туры киләчәк. Башкача чара юк. Шуңа да, проект ясаучылар килгәч, аларны да, эшчеләрне дә трасса буйлап сузыгыз. Мин шулай эшләргә уйлыйм. Кайбер таләпләрдән тайпылырга мөмкин: бетон юк икән, агач белән алмаштырырга була, зуррак көчәнешле кабельләрне кечерәге белән. Сугыш мәңге бармас, аннан соң тиешле нормативлар буенча төзәтербез. Ә хәзер безгә поездлар йөри алырлык юл кирәк. Борчылмагыз, Григорий Давыдович, проектчыларның шәпләрен бирәм, алар сезне авыр хәлгә куймас.

– Рәхмәт, иптәш генерал!

– Аннан соң, таякның авыр башы барыбер миндә, сездә ике йөз чакрым булса, миндә сигез йөз, – дип гөлдерәтеп көлде Гвоздевский.

Алар аерылышканда аралашып, очрашып торырга сүз куештылар. Гвоздевский берәр көнне үзенә кунакка да чакырды, бу юлы илле граммга вакыт җитмәде, ләкин, һичшиксез, бер чәкешеп салырга кирәклеген искәртте. Лейтенант Соколов Афанасьевны кунакханәгә илтеп куйганда, урамда кара төн иде инде...

Казанга килгәч тә, Григорий Афанасьев киң колачлы эшчәнлек җәелдереп җибәрде. Казанда идарәгә бүлеп бирелгән бинаны тәртипкә китерде, җитәкчелек составын раслады, аларның вазифаларын билгеләде. Төзелеш, режим хезмәте, материаллар, азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итү – боларның барысын да алдан уйлап документларда теркисе, еллык планга кертәсе бар иде.

Икенче яктан төзелештә эшлисе тоткыннарны да урнаштыру турында уйларга кирәк. Афанасьевның көне Казан белән Зөя бистәсе арасында уза иде. Бистәдә мөмкинлекләр шактый, биредә тоткыннарны урнаштырырга чиркәү һәм монастырь биналары җитәрлек. Нәтиҗәдә Зөядә аерым лагерь пункты барлыкка килде. Төзелешне кирәк-яраклар белән тәэмин итәргә тиешле үзәк база да шунда ук урнашты. Озак та үтми, лагерь пунктына Карелиядәге Сорока төзәтү-хезмәт лагереннан махсус контингент килде. Үзе чисталык яраткан Афанасьев, пычракка баткан, бетләгән тоткыннарны күреп, җирәнүен яшермәде. Лагерь пункты начальнигы Бронислав Кацнельсонга кичекмәстән мунча оештырып, баракларга урнаштырганчы тоткыннарны юындырырга кушты. Афанасьевны бер генә нәрсә шатландыра – Сороклагтан килгән тоткыннарның тимер юл төзелеше тәҗрибәсе бар.

Март башында гаилә әгъзалары белән бергә проект эшләре белгечләре дә бирегә күченергә кереште. Беренче партияне Афанасьев үзе каршылады. Аңа озын буйлы ябык гәүдәле кеше исәнләшергә дип, кулын сузды.

– Николай Иванович Маккавеев, экспедиция начальнигы, – диде ул.

– Майор Афанасьев.

Маккавеевның шәхси эше белән танышырга да өлгерде Афанасьев. Геологиядә шактый башлы белгеч, фәнни хезмәтләре дә бар. Сугышка да үз теләге белән киткән. Ләкин нәкъ менә шул фән аркасында зыян күрә дә инде Маккавеев. Ленинградка кандидатлык диссертациясе якларга кайтып килү өчен бер көнлек ял ала, әмма вакытында кире килеп җитә алмый. Тимер юлларны бомбага тоту аркасында тоткарлык килеп чыкты дип акланса да, аны барыбер кулга алалар. Озак тотмый җибәрәләр, әлбәттә, ләкин биографиясендә бу вакыйга барыбер кара тап булып кала. Күптән түгел исә бер төркем галимнәр хәрбиләрне Маккавеевның объектлар төзелешендә файдалырак булачагына инандыра. Фронттан чакыртып алалар. Һәм менә ул биредә.

– Безнең әлегә беренче төркем генә килеп җитте, төп хезмәткәрләр март азакларына көтелә, – диде Маккавеев.

– Без сезне Кочемирово бистәсенә урнаштырырбыз, – диде Афанасьев. Йорт саен кешеләргә фатирга керергә туры килер. Матди-техник база ничегрәк?

– 11 ЗИС-5 һәм 4 ГАЗ-АА автомобильләре бар, ләкин әлегә аларның барысы да килеп җитмәгән, – диде Маккавеев.

– Мондый юлларда машина белән әллә ни ерак китә алмассың, – диде Афанасьев.

– Машиналары бер хәл аның, иптәш майор, һөнәри җиһазлар юклыгы куркыта. Бораулау техникасы бөтенләй дә юк...

– Көтәргә вакытыбыз калмады, иптәш Маккавеев, кичекмәстән эшкә керешергә кирәк.

– Аңлыйм, иптәш майор. Безгә беренче шәпкә атлар кирәк булыр, сез дөрес әйтәсез, юллар юк. Икенчедән, көрәкләр ярап куяр иде – күп урыннарда кар ята, аны чистартып җиргә кадәр төшәсе бар...

– Көрәге табылыр ла...

– Һәм палаткалар...

– Палаткаларыгыз да юкмы?

– Утызлап комплект кына, ә безгә бөтен трасса буйлап таралып эшлисе...

Афанасьев проект экспедициясен барлык кирәк-ярак белән мөмкин кадәр күләмдә тәэмин итәргә боерды. Икенче көнне алар бергәләп, самолётта тимер юл үтәргә тиешле трассаны карап чыктылар. Урыны белән кар астында ятучы басуларга, урманнарга карап, Маккавеев үзенең карталарында нидер сыза, төзәтә, үзе генә аңлаган телдә пышылдап куя.

Афанасьев Маккавеев белән бергә самолётка утырган белгечләрнең йөзләрен күзәтте. Аларда нык киеренкелек сизелә. Проект әзерләүчеләр вакытның бик кысан икәнлеген, бөтенләй дә юклыгын яхшы беләләр. Бурычны үтәп чыкмаган очракта ни көтәсен дә чамалыйлар.

Самолёт белән кире Казанга кайткач, алар Маккавеев белән Волжлаг идарәсе бинасына юнәлделәр. Кабинетка кереп, чәй эчеп җибәргәч, Маккавеев бераз ачылып китте кебек.

– Бик катлаулы эш көтә безне, иптәш майор, – диде ул, маңгаена бәреп чыккан тирне сөртеп.

– Бер генә дә шигем юк...

– Безнең әле проект та юк, җирләр өйрәнелмәгән, карталар да аннан-моннан гына сызылган. Моңа, гадәттә, берничә еллап вакыт кирәк.

– Безнең максат кышка кергәнче тимер юлны сафка бастыру. Боерыклар тирәсендә сафсата кору урынсыз да, мәгънәсез дә, Николай Иванович.

– Аңлыйм, иптәш майор, бик яхшы аңлыйм... – Маккавеев өстәлдә яткан блокнотына күз салды. Самолётта очкан вакытта ул анда әледән-әле ниндидер мәгълүматлар теркәп барды. – Хәзерге вакытта безнең экспедициянең төп өлеше Рязань өлкәсендә саклану ныгытмалары төзелешендә. Аларга бирегә килү турында боерык җиткерелде, март азакларына барысы да монда булыр дип уйлыйм. Йөзгә якын кеше. Башлыча каядыр урнаштырырга кирәк, белгечләр арасында гаиләләрен алып килүчеләр дә бар.

– Тору урыны Кочемирово авылында булыр. Экспедиция штабын Зөя станциясендә урнаштырырга тәкъдим итәм.

– Анысы яхшы. Ләкин, минемчә, бераздан безгә Буа шәһәренә барып, экспедициянең үзәген шунда оештыру дөресрәк булыр. Ник дигәндә, Буа шактый зур шәһәр, безнең трассаның уртарак җирендә дә тора.

– Буада кирәкле биналар табып куярга әмер бирермен, – диде Афанасьев, үзе дә өстәлдәге кәгазьгә әлеге мәсьәләне теркәп куйды.

– Рәхмәт. Безнең һөнәри инструментлар белән зур проблема, ә алардан башка эш бармаячак. Җирле хакимияткә мөрәҗәгать итеп, алардан ярдәм сорый алабызмы? Казан бит университетлы шәһәр, биредә кайбер җиһазлар табарга мөмкин дип уйлыйм...

– Обком белән бусын да сөйләшербез.

– Григорий Давыдович, мин сезгә күпме контингент бүленгәнен белмим, миңа анысы кирәк тә түгел. Ләкин белеп торыгыз – шактый зур күләмдәге эш көтелә. Грунтны чыгарасы урыннар күп, поезд трассасы тигез булырга тиеш. Зөя, Гөбенә, Бәрле елгалары аша күперләр салу шактый көчне алачак. Кечкенә чокыр-чакырлар аркылы да махсус корылмалар төзисе...

– Кешеләр җитәрлек булачак, сез безгә проект документларын тизрәк әзерләп бирегез. Вакыт кысанлыгын үзегез дә искәрттегез, шуңа күрә проектлаштыруны һәм төзелешне берьюлы алып барырга туры киләчәк. Сезнең экспедиция вәкилләрен дә, төзүчеләрне дә бөтен трасса буйлап бүлеп чыгачакбыз.

– Берьюлы бөтен трассаны төзүгә керешәбезме?

– Нәкъ шулай.

Маккавеев бераз гына уйга калды.

– Яхшы, бу мөмкин эш. Мин экспедицияне җиде өлешкә бүләрмен. Күперләрне, чокырлар аша кичүләрне ахыргы этапка калдырабыз, алар игътибар белән өйрәнүне таләп итә. Без әлегә елгаларның язгы ташуда үзләрен ничек тотуын белмибез.

– Килештек, Николай Иванович! – Сөйләшү тәмам булуына ишарәләп, Афанасьев урыныннан торды. Аның белән саубуллашып, Маккавеев чыгып китте.

Юллар юк, трасса катлаулы урыннардан да уза, ләкин бирedә бер отышлы як та бар – поезд юлына Зөя елгасы бик якын урнашкан. Афанасьев өчен бу уйланырлык, төн йокламаслык детальгә әверелде. Самолёт белән трассаны

карап чыкканның икенче көнендә ул үзе янына ТАССРның обком секретаре Илья Михайлович Ильинны чакыртып алды. Төзелеш эшләренә җирле хакимият тарафыннан ярдәм күрсәтү бурычы нәкъ менә аңа йөкләнгән иде.

Исәнләшкәч тә, Афанасьев турыдан эшкә күчте.

– Илья Михайлович, Зөя елгасында навигация кайчан башлана?

– Навигация? – Ильин гаҗәпләнүен яшермәде. – Балыкчы көймәләре йөзсә генә инде анда. Зур теплоходларның кергәнен хәтерләмим...

– Шулай укмыни?... Миңа елга шактый тирән кебек тоелды.

– Язгы ташуда шулай инде ул, аннан соң саега.

– Пристань начальнигын чакырта аласызмы?

Ильин каушап калды, аннан соң, күз карашы белән генә рөхсәт сорап, Афанасьевның өстәлендәге телефонга үрелде. Егерме минуттан шабыр тиргә баткан Казан пристане начальнигы алар каршында басып тора иде.

– Зур пароходлар белән Зөягә кергән юк... – диде ул, дөресен әйтүенә чын күңелдән үкенүен яшермичә.

– Зур пароходлар кирәкми. Мөмкин кадәр киң төпле нинди судноларыгыз бар?

– Бар инде алар... – Пристань начальнигы кызарып-бүртенеп чыкты. – «Ветлуга», мәсәлән, «Дирижабль», «Иокоганчик»...

– Беттеме?

– Тагын берничәне оештырырга мөмкиндер...

– Алайса, – диде Ильин пристань начальнигына, – бозлар киткәч, Зөянең фарватерын катерда тикшереп, кораблар хәрәкәте өчен юнәлешне билгеләгез.

– Илья Михайлович дөрес әйтә, безнең вакыт бик тар. Зөя елгасы мөмкинлекләрен анда су күләме кимегәнче кулланып калырга кирәк.

– Елгаларны да кирегә борасыз, Григорий Давыдович, – дип тел шартлатты Ильин, пристань начальнигы калтыранган аякларында чыгып киткәч тә.

– Борырсың монда, Илья Михайлович... – Бераз уйга калып торгач, Афанасьев янә аңга килгән төсле булды. – Сезгә дә үтенечем зур, иптәш Ильин. Верховный Совет Президиумының 13 февраль карарын хәтерлисездер. Анда хәрби чорда шәһәр халкын мобилизацияләү турында сүз бара.

– Әйе, уналты яшьтән 55 яшькә кадәргеләрне...

– Нәкъ шулай. Безнең төзелеш очрагында да аны кулланырга туры киләчәк. Үзебезнең көчләр белән генә ерып чыгарлык түгел. Шулай ук якын-тирә авылларда яшәүчеләрне.

– Аңлыйм... – Ильинның йөзе каралды. – Ләкин кайдан табып бетерәсе соң ул эшче кулларны? Яшьләрне фронтка озаттык, калганнары барысы да хезмәттә. Хәзер менә чәчү башланырга тора, аннан соң печән өсте, урагы да килеп төртеләчәк. Заводлар стахановларча эшли, социалистик ярышта катнашып, бер-берсен уздырырга маташа, уздырмасаң, анда да – бетте баш.

– Мин дә сезне аңлыйм, Илья Михайлович. Ләкин шуның өчен сугыш чоры инде бу. Квоталар билгеләгез. Фәлән завод фәлән кеше җибәрергә тиеш, фәлән колхоз фәләнне. Теләсә нишләгез, тик бу эшне оештыру сезнең өстә.

Ильин бу сүзләрдә янау да, ялвару да ишетте. Афанасьевка җиңел

түгеллеген ул да бик яхшы белә. Икенче яктан, обкомга өелгән тау кадәре бурычлар да баса, хәтта махорка үстереп тапшыруның да планы бар. Ләкин икенче якта Дәүләт Оборона Комитеты карары, погоннар...

– Трасса үтә торган районнарны җыеп, аларга кеше исәбе буенча катгый бурычлар куегыз. – Афанасьев Ильинга өстәлендәге документны сузды. – Менә биредә минем исәп буенча кирәк булган кешеләр саны.

Ильин документка күз төшерде. Кама Тамагы районыннан 150 кеше, Апастан 300! Бу саннарны күргәч, аңа эсселе-суыклы булып китте. Ничек итеп, әлеге планнарны үтисе, озакламый чәчүгә чыгасы бар бит! Ул якларда яшәүчеләрне болай да авыр эш белән интектерделәр – фашистлар килеп җитә калса дип, Идел ярыннан ерак түгел оборона корылмалары төзелде. Бары тик 1942 ел башында гына, дошманның бирегә үк килеп җитүе шикле булуы аңлашылгач, ул төзелешне туктаттылар. Һәм менә хәзер яңасы... Тик Ильин дәшмәде, майорның каядыр җыенуын аңлап, саубуллашып чыгып китте.

Афанасьев исә Зөя бистәсенә юл алды. Аны лагерь пункты начальнигы Бронислав Кацнельсон каршылады, озакламый сак комиссары Сергей Шерстнёв та килеп кушылды. Алар лагерь пункты конторасына керделәр.

– Мобилизацияләнгән немеcләрнең беренче партиясе бүген килеп җитәргә тиеш иде бит, кайда соң алар? – диде Афанасьев, сәгатенә күз салып.

– Бераз соңаралар, иптәш дәүләт иминлеге майоры, станциядән җәяүләп алып киләбез, транспорт юк. Юллар да җебеп бара.

– Аңлашылды, – диде Афанасьев, кечкенә генә тәрәзә аша урамга карап. – Аларны моннан йөртеп эшләтеп булмаячак. Сороклаг контингентын биредә тоту ягын карарга кирәк, ә немесләрне трасса буйлап таратырга. Конвойлар әзерләгез.

– Минем штат буенча 370 кеше җитми, аларны тиешле күрсәткечкә җиткерү мөмкинлеге бармы? – дип сорады Шерстнёв.

Афанасьев усал күзләрен сак комиссарына төбәде. Шаяртамы бу, әллә чынлап та штатны тулыландыруга ышанамы?

– Иптәш Шерстнев, нинди күрсәткеч турында сөйлисең син?! Сугыш бара, аңлыйсыңмы?! Монда булган кадәрле штыклар биргәннәренә рәхмәт әйт. Конвойны исәпләп, дөрес итеп бүлергә кирәк, һәрбер участокта махсус контингент күләменә карап билгеләгез. Ләкин артык штатлар тотыру турында сүз дә юк!

– Аңладым, иптәш дәүләт иминлеге комиссары...

– Махсус контингентны да, конвойны да азык-төлек белән тәэмин итүне дә онытмагыз, безгә сау-сәламәт кешеләр кирәк.

– Төнгә кайда?

– Әлегә палаткаларда. Аннан соң якын-тирә авылларда аерым биналар табарга туры килер. Һәрхәлдә, немесләрне җирле халык белән бутарга ярамый. Тоткыннар да аерым яшәргә һәм эшләргә тиеш. – Афанасьев тәрәзәгә күз салды. Анда тездән пычракка баткан, алҗыган немесләр төркеме күренде. Бу – әле генә совет гражданнары – Идел буе немесләре иде. Ул, фуражкасын алып, урыннан торды. – Килеп җиттеләр, киттек әйдә.

Немесләрнең кыяфәте мескеннең аргы ягы иде. Март кояшы инде яхшы гына кыздыра, ә алар барысы да кышкы киемнәрдән. Киез итекләре лычма суга баткан. Афанасьев беренче төркемне сүзсез генә күздән кичерде.

– Башта санитар эшкәртү үткәрергә кирәк, – диде Афанасьев. – Тоткыннарны юындырыгыз. Яңа киемнәр бармы?

– Тәэмин итү бүлеге һәр көнне иртәгә китерәбез дип әйтә, без көн саен сорыйбыз, – диде лагерь пункты начальнигы Кацнельсон.

– Юындырганнан соң авырулар бармы-юкмы икәнлеген ачыкларга. Чирлеләрне – лазаретка. Анысын оештырдыгызмы?

– Оештырдык, әлегә дарулар гына юк. Бинтлар да җибәрә алмыйлар...

– Синең «юк»тан башка сүзең бармы? – Лагерь пункты начальнигы җавапларыннан Афанасьевның ачуы купты. – Ник миңа килмисең?! Бергә хәл итәр идек!

Лагерь пункты начальнигы дәшмәде. Афанасьев та аның гаебе юклыгын яхшы белә. Матди тәэмин итү системасы бөтенләй эшләми. Аларның да үз аңлатмасы – бар кирәк-ярак фронтка озатылып бара.

Нимесләрне мунчаны хәтерләткән бер бинага кертеп, салкынча су белән юындырдылар, табиблар аннан-моннан караштыргалады. Араларында унлап авыру табылды, аларны лазаретка алып киттеләр. Башлыча, югары температура, эч китүенә зарлана иде чирлеләр.

Төп контингентны исә борынгы чиркәүгә алып киттеләр. Аның тәресен бәреп төшерә алмаганнар, мылтыктан гына атканнар, күрәсең – ул бер якка чалшаеп калган. Манарасы биек булгач, менеп җитмәгәннәр, тәре шулай бер якка ауган килеш тырпаеп калган.

Чиркәүнең тәрәзәләре такталар белән кадакланган. Сөрелгән нимесләр, бер-бер артлы тезелешеп, болдырдан күтәрелеп, караңгы бина эченә кереп югала тордылар.

Кинәт бер төркемдә шау-шу, гауга чыкты. Афанасьев шунда таба ашыкты, аңа башкалар да, берничә коралллы солдат та иярде.

– Ни булды, ник шаулашасыз?! – дип кычкырды Григорий Давыдович, килә-килешкә билендәге кобурадан револьверын чыгарып.

Шаулашкан төркем аларга таба борылып тынып калды.

– Нидән гауга чыгарасыз?! – дип кабатлады Афанасьев, үзенә таба төбәлгән нәфрәт тулы күзләргә курыкмыйча туры карап.

Төркем арасыннан бер нимес чыкты. Гомер урталарына җиткән нимес иде бу. Аягында, күпләрдән аермалы буларак, күн аяк киеме, өстендә кайчандыр шактый ыспай булган пәлтә. Күзлеге укымышлылык турында сөйли, күрәсең...

– Гражданин начальник, безне үлемгә хөкем итүнең сәбәбе нидә? – диде ул, пычранган күзлек пыялалары аша зәңгәр күзләре белән тыныч кына Афанасьевка текәлеп.

– Үлемгә хөкем иттек дип, кем әйтте?!

– Аңлашыла бит инде, – нимес чиркәүгә ымлады. – Мондый урынга ябып куйганнан соң акрынлап тезеп бастырып атып бетерәчәксез безне.

Нимеснең тыныч кына әйтелгән бу сүзләреннән Афанасьев имәнеп китте.

– Исемегез ничек? – дип сорады ул, каушап калуы бераз кимегәч.

– Давид Сайбель.

Афанасьев төркемдә торган башка нимесләргә мөрәҗәгать итте:

– Давидның фикере белән килешүчеләр бармы?!

Берьюлы унбишләп кеше алга атлады.

– Сезгә дә, калганнарга да беренче һәм соңгы мәртәбә аңлатам! – Афанасьев тавышын барысы да ишетелерлек итеп күтәрде. – Сезне атмыйлар да, сез тоткын да түгел! Сез – хезмәт армиясе! Бүген урнашкан бина вакытлыча гына, озакламый барыгызны да эш участокларына юнәлтәчәкбез. Сезгә хезмәт хакы түләү дә каралган, шәхси йомышларны үтәү өчен ирекле сәгатьләр дә алырга мөмкин! Мин үзем сезгә вәгъдә итәм – торак та, ашарга ризык та булачак! Барысы да аңлашылдымы?

Немесләр арасыннан берәү дә берни әйтмәде. Аннан соң, акрынлап борылып, башларын игән көе чиркәүгә таба киттеләр.

– Гражданин начальник, – диде Давид, урыныннан кузгалмый гына. – Мин 1927 елдан бирле коммунист, безнең арада минем кебекләр шактый. Партия билетларын нишләтәсе?

– Билетлар үзегездә калсын, сез коммунист булудан туктамыйсыз...

Давид, аякларын көч-хәл белән өстерәп, иптәшләре артыннан юнәлде.

– Иптәш майор, бәлки, гауга чыгаручыларны карцерга ябаргадыр? Башкаларга сабак булыр иде, – дип тәкъдим итте сак комиссары Шерстнёв.

Афанасьев Давидның бөкресе чыккан аркасын карашы белән озатып бетергәнче җавап кайтармады. Менә тормышы ике өлешкә бүленгән бәндә. Ул, бәлки, укытучы йә табиб булгандыр. Өендә китаплардан киштәләр сыгылып торгандыр. Хәзер туган җиреннән куылган, мескен хәлдәге кеше. Киләчәге бармы аның? Юктыр, мөгаен. Тик аның да яшисе килә, ул да җылы сүзгә мохтаҗ. Барысына да сүзен кайдан табып бетерәсе? Дәүләт машинасы сөйләшеп тормый, аның тукталырга да вакыты юк. Ул үзенә эләккән кешеләрне вак-төяк чүп-чар шикелле әйләндереп, тузан бөртегенә әверелдерә. Шул тузаннардан илнең җиңүләре, җитәкчеләрнең исәп-хисаплары калкып чыга. Ләкин тузан бөртегенең дә Кеше булып каласы килә...

– Беркемгә дә тимәгез, иптәш Шерстнёв. Безгә алар белән эшлисе дә бар бит. Шуңа күрә карцер турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Афанасьев өчен бу чорда көннәре төнгә ялганды. Көндезләрен әле Зөя бистәсендә, әле проект ясаучылар янында, әле обком һәм райкомнар вәкилләре белән очрашуларда булса, төннәрен идарәсеннән чыкмый кәгазь эшләре белән шөгыльләнә. Ул аерым боерыклар белән төзелеш, лагерь мәсьәләләре буенча урынбасарларын билгеләде, материаллар белән тәэмин итү, элемтә, бухгалтерия һәм башка шундый бүлекләрне оештырды. Аларның җитәкчелегенә үзе шикелле үк НКВД вәкилләре куелды. Хәрбиләр кичекмәстән эшкә кереште.

Моның белән беррәттән Зөя бистәсендәге лагерь пунктында төзелешнең үзәк базасы булдырылды, йөкләрнең төп өлеше шушында китерелеп, трасса буйлап таратылырга тиеш иде. Ульян шәһәрендә аерым пункт барлыкка килде, аның үз базасы бар. Төзелештә эшләүчеләрне ашатыр өчен яшелчә үстерү өчен басулар бүлеп бирелде.

Акрынлап, эшләр бер җайга керде кебек. Трассаны алты өлешкә бүлделәр. Алты бүлекчә булачак поезд юлының алты кисемтәсе өчен җаваплы. Сөрелгән немесләрне шул бүлекчәләргә озатырга керештеләр. Транспорт юк, булганы да язгы пычракта батып кала, шуңа башлыча җәяүләп барырга туры килде.

Афанасьев ышандырып әйткән булса да, немесләргә бар җирдә дә рәтле торак табылмады. Табылганнары түбәсе ага торган, тәрәзәсез, ярым ташландык биналар иде. Аларны төнлә йоклардык хәлгә кертү сөрелгәннәрнең үзләренең җилкәсенә төште. Матди тәэмин итү системасы да җайга салынмады, эшчеләрнең бер кисәк ипісез утырган вакытлары шактый булды. Салкын бараклар, пычрак җир, язгы тотрыксыз һава, ачлы-туклы тормыш үзенекен итте – лазаретлар авыру немесләр белән тулды. Дарулар юк. Чирләп үлүчеләр күбәйде. Аларны төзелә торган трассадан ерак түгел җирләп бардылар.

Аякта басып тора алганнарын исә япа-ялан басуда кешене изә торган авыр хезмәт көтә. 1942 елның 17 апрелендә Григорий Афанасьев боерыгы белән эш көне тәртибе гамәлгә кертелде. Иртәнге дүрттә йокыдан торасы, бишкә кадәр юынып тамак ялгыйсы. Алтыда эш башланып, кичке җидедә генә тәмамлана. Аннан соң кичке аш, тугызда контингент урын өстендә булырга тиеш. Көндез әбәт ашау өчен бер сәгать вакыт бирелә.

Зөя станциясе белән Ульян шәһәрен тоташтырган тимер юл участогы әнә шулай башланып китте. Иделнең уң як ярында урнашкан районнарга ул күп газап һәм михнәтләр алып килде. Шактый халыкны өстән төшкән әмер буенча немесләр һәм лагерь тоткыннары белән бергә трассага җибәрделәр. Трассага якын авылларга чит-ят кешеләр кереп тулды. Тимер юлның үзен таш гасырдан калган эш кораллары белән күтәрделәр – агач тачкалар, бүкәннән эшләнгән ком тыгызлау җайланмалары, көрәк, кирка...

Кайвакыт бу тирәдә яшәүчеләрнең ишекләрен төзелештән качып киткән немесләр кага иде. Кемнәрдер аларны күрү белән куып җибәрә, кайберләре кулына бераз булса да икмәк тоттырып, бусагадан озатырга ашыга. Качкыннар ерак китә алмый – бу тирәдә яшеренеп ятарлык таулар да, караңгы урманнар да юк диярлек. Аларны НКВД солдатлары тотып алып кайтып, ныклап дөмбәсли дә кире эш урынына куып китерә.

Кайбер участокларда, буш биналар булмау сәбәпле, немесләрне авылларда гади халык өйләрендә урнаштырырга туры килде. Немесләр арасында да төрле кешеләр бар – әле анда, әле монда урлашу, хәтта җирле хатын-кызларны көчләү очраклары турында да имеш-мимешләр таралды.

Григорий Афанасьев, боларның барысын да тыңлап, үзенчә хәл итү чараларын табарга маташты. Ләкин күтәрә алмаслык йөк булып өелгән авырлыкларны җиңеп чыгарлык түгел кебек иде... Шуңа да карамастан, бурычны үтисе бар. Һәм ул берсеннән-берсе кырыс, кешене сыга торган әмерләр чыгара торды.

Григорий Афанасьев бу якларның үз колагы өчен сәер яңгыраган атамалы торак пунктлары белән якыннан танышып чыкты. Кызык төбәк иде бу. Монда кул сузымы ераклыкта рус, татар, чуваш, мари авыллары урнашкан. Татарлар чувашча, чувашлар татарча сиптереп сөйләшә, ләкин русчаны көч-хәл белән әвәли. Татарларның да ике төрлесе барлыгын белде – бер ишләре мишәр дип йөртелә, алары татарлар арасында да үзләрен ничектер өстенрәк тоталар. Шерстнёв аларның бер-берсеннән аермасын Афанасьевка бик гади аңлатты:

– Иптәш дәүләт иминлеге майоры, мишәрләр – татарларның яһүдләре ул, – диде ул, Афанасьевның да яһүд булуын әллә белмичә, әллә белмәгән кыяфәт чыгарып. Афанасьев кайтарып дәшмәде.

Кешеләре белән дә, табигате белән дә бай төбәк булып чыкты Татарстан

– Чувашия – Ульян яклары. Сулары да мулдан, ә су паровоз өчен гаять кирәкле чимал. Идел яры буенда төзелеш өчен таш карьерлары ачылды. Тәтешнең Тархан урманнары күперләр төзелешенә яраклы иде. Дөрес, шул ук Тәтештә Афанасьевка җирле хакимият белән тавышка да керергә туры килде. Юллар җимерек, күперләр менә-менә ишеләм дип тора. Тәтеш башкарма комитетына Афанасьев үзе барып, тәртип урнаштырырга мәҗбүр булды. Шуннан соң гына киңәшмә җыеп, район белән Волжлаг, килешеп, юлларны төзәтү турында карар чыгарды.

Май уртасында Афанасьевка бу якларга янә барырга туры килде. Бу юлы Тәтештән арырак урнашкан Буага. Биредәге алтынчы бүлекчә Ивашевка авылында иде. Үзе белән бергә төзелеш буенча урынбасары өлкән лейтенант Сергей Киселёвны да алды.

– Алтынчы бүлекчә буенча җаваплылык сезгә йөкләнгән иде, иптәш өлкән лейтенант, – диде Афанасьев Буага килеп җитәрәк.

– Әйе, иптәш дәүләт иминлеге майоры... – Киселёвның кәефе юк, бүлекчәдәге хәлләрне ул яхшы белә. Андагы күрсәткечләр Волжлагны артка сөйриләр.

– Хәзер менә урынга барып, сәбәпләрен дә аңларбыз.

Автомобиль, Буаның читеннән генә үтеп, сулга борылды.

– Безне кая алып барасың, Алексей? – дип гаҗәпләнде Афанасьев.

– Иптәш майор, Ивашевкага, алтынчы бүлекчә шунда урнашкан бит.

– Соң, тимер юл Буаның бөтенләй икенче ягында түгелме соң?! – Афанасьевның күз алдына капылт итеп трасса картасы килеп басты.

– Без Ивашевканы хезмәткәрләрне һәм контингентны урнаштырыр өчен биналар булганга сайладык.

Киселёвның кәефе тәмам кырылды.

– Буаның үзендә беткәнме?!

– Анда проект экспедициясе белән дүртенче бүлекчә...

Афанасьев уйга калды. Аннан капылт кына башына килгән фикердән, әйтерсең, аңга килде.

– Алтынчы бүлекчәне күчерергә кирәк! Бер урында таптанып ятмасыннар. Минемчә, Ульян өлкәсендәге Каролинское бистәсе менә дигән урын, көньяктан килүче трасса белән тоташу өлешендә проблемалар бар, шунда җибәрербез.

Алтынчы бүлекчә башлыгы Пётр Борисов аларны колач җәеп каршыласа да, борчылуыннан куллары калтырануны җиңә алмады. Афанасьев та коры гына сөйләште. Күпчелек күрсәткечләр буенча планның яртысы да тулмаган иде. Майор күзеннән бер генә җитешсезлек тә ычкынмады. Ул хәтта бүлекчәдәге сәүдә алачыгына кереп, биредә махорка юклыгын да ачыклады. Соңыннан Борисовны һәм Кисилёвны шактый киеренке сөйләшү көтте. Афанасьев икесе турында да ни уйлаганын йөзләренә бәреп әйтте. Аннан, кызуны киметеп, алтынчы бүлекчәне көткән үзгәрешләрне яңгыратты.

Ивашевкадан соң проект экспедициясенә дә сугылдылар. Аларга да Афанасьевның сораулары күп иде. Ләкин белгечләр белән өстәл кыйнап сөйләшү мөмкин түгел, шуңа майор биредә үзен күпмедер дәрәҗәдә тынычрак тотты. Тик бер нәрсә бәхәссез – проектлаштыруның да, төзелешнең дә темплары аны бер дә канәгатьләндерми.

Соңыннан майор Буаның райком секретаре Шакир Әхтәмов янына юл тотты. Аның белән еш очрашалар, әлеге җитәкченең киң күңелле, хезмәт сөючән кеше икәнлеген яхшы белә.

Әхтәмов урынында булып чыкты. Майорны күргәч тә, йөзе яктырып китте, ул шунда ук табын әзерләргә кушып, Афанасьевны кабинетына чакырды.

– Хәлләрегез ничек, Шакир Әхмәтҗанович? – Афанасьев киеренке көннән соң, ниһаять, елмаерга көч тапты.

– Ничек дип әйтим, Григорий Давыдович? Фронттагы белән чагыштырып булмый, бирегә, шөкер, сугыш килеп җитмәде. Ләкин монда да җиңел түгел. Эшче куллар бетеп бара, аның өстенә планны да арттыралар.

– Аңлыйм, хәзер барысы да фронтка җибәрелә: кешеләр дә, азык-төлек тә...

– Атлар да нык кимеде, – дип көрсенде Шакир Әхтәмов. – Колхозлар инде оныттык дигәндә, үгез җигеп йөрүгә әйләнеп кайтты. Әле яхшы камытларын саклаганнар, юкса, аларны ясап, күпме вакыт үтәр иде...

– Камыт шул бер камыттыр бит инде ул? – Афанасьев чын күңелдән гаҗәпләнде.

Майорның шундый гади генә нәрсәне дә белмәвеннән Әхтәмов ирексездән көлеп җибәрде:

– Бер түгел шул, Григорий Давыдович. Әйдәгез, бераз капкалап алыйк, – диде ул, кунакны арткы бүлмәдәге табынга чакырып. –Үгезнең, аттан аермалы буларак, мөгезләре бар, шуңа үгез камыты ике өлештән тора, кидерткәч кенә, бер-берсенә ныгытып куялар. Әйдәгез, иптәш Сталин исәнлеге өчен!

Аягүрә берне тотып куйгач, ашарга утырдылар.

– Монда нинди йомышлар белән?

– Алтынчы бүлекчәне Ульян өлкәсенә күчерәбез. Шуңа әзерлек эшләрен тикшерәм.

– Без аларга Ивашевкадан биналар биргән идек... – дип, исенә төшерде Әхтәмов.

– Әйе, анысы өчен рәхмәт, ләкин аларны бирүдә тоту зур ялгышлык. Сезнең гаеп юк, без баштан ук ул бүлекчәне башка урынга урнаштырырга ниятләгән идек... – Афанасьев бер мәлгә дәшми торды. Аннан Әхтәмовка гафу үтенгән сыман мөрәҗәгать итте. – Төзелеш эшләре бик зурдан кубачак, без сездән тагын атлар да, кешеләр дә сораячакбыз, әзер торыгыз.

– Аңлыйм... – Әхтәмов җитдиләнде. – Безнең халык эштән курыкмый. Саклану ныгытмаларын төзүдә дә сынатмадылар, япь-яшь кызлар күпме кирәк, шуның кадәр көч түкте. Кияүгә дә чыкмаган чәчтәпиләр урман кисүчеләргә әйләнеп беттеләр инде...

– Сугыш әйләндерә... Ярый, Шакир Әхмәтҗанович, озаклап сөйләшеп торырга вакытым юк, кузгалыйм.

Афанасьевны озата чыккан Әхтәмов башында мең төрле уй кайный иде. Биналарын бирде, кешеләрен урнаштырды, ләкин бу газапның башы гына булган икән. Чәчүгә төшәсе, ә аңа төзелеш өчен атлар да, кешеләр дә табасы. Кайдан алырга?! Янә шул колхозлар хисабына көчәнергә генә кала...

Җәй башында Казанга НКВДның тимер юллар төзелеше буенча Баш

лагерь идарәсе җитәкчесе урынбасары Степан Тополин килде. Григорий Афанасьев аны вокзалда каршылады.

Көн эссе иде, Тополин, маңгай тирләрен кульяулыгы белән сөртә-сөртә, вагоннан төште. Афанасьев җәһәт кенә аның чемоданын эләктереп алды. Алар исәнләштеләр. Тополин як-ягына каранды.

Казан вокзалы составлар белән шыгрым тулы, хәрәкәт тә тукталмый. Көнчыгышка таба вагоннар агыла. Кайберләрендә кешеләр, йөк вагоннарында станоклар күренә. Көнчыгыштан килүчеләрендә солдатлар очрый, яңа туплар, яңа техника абайлана. Вокзалның үзендә халык мыжлап тора.

– Бигрәк тыгыз икән сездә, – диде Тополин, машинага утыргач та.

– Казан аша составлар күп үтә, Степан Александрович, эвакуацияләнгәннәр дә бик күп. Завод-завод күчеп утырдылар.

– Йә, сөйләп җибәр, үзегездә ни хәлләр?

– Ничек дип, Степан Александрович, кулдан килгәнен эшлибез инде...

– Мин сезгә юлга чыкканчы Нафталий Аронович белән очраштым, – диде Тополин, үзенең җитәкчесе Френкельны искә алганда кинәт җитдиләнеп. – Сез башлаган рокаданы төзеп чыгу мәсьәләсендә шактый гына шикләр бар, срогына үтәп чыга алырсызмы, дип борчылалар.

– Үтибез, Степан Александрович.

Тополин Афанасьевка бораулап карады.

– Үтисең, әлбәттә, Григорий Давыдович, үтәмичә кая барасың?! Үлчәүнең бер ягында рокада, икенче ягында синең баш та минем баш! – Тополин маңгаен кулъяулыгы белән сыпырды. – 6 июньгә партия конференциясе җыегыз, барлык җитәкчеләр дә килсен. Анда барысын да уртага салып сөйләшәчәкбез. Ничек бар, шулай әйтсеннәр, чирен яшергәннең азагы ничек икәнлеген үзең беләсең... Иртәгә синең белән трасса буйлап чыгып китәбез. Минем урындагы хәлләрне үз күзем белән күрәсем килә. Бишенче июньгә Казанга кайтып җитәрлек итеп маршрут төзе.

– Яхшы, иптәш Тополин!

Алар берничә көн дәвамында трассадагы эшләр белән таныштылар, Куйбышев өлкәсенә кадәр үк барып җиттеләр.

Бер участокта туган җирләреннән сөрелгән немесләр очрады. Тополин, таш өеме башына ук менеп, аларга карап торды. Аннан соң аны Афанасьев белән бергә көтеп торган җитәкчеләр янына төште.

– Ник алар сырган чалбар белән итек кигәннәр? – Тополин черт итеп төкереп куйды. – Июнь башланды лабаса!

– Башка киемнәре юк...

– Ничек булмасын?! Складта барысы да өелеп ята бит! Кем матди тәэмин итү өчен җаваплы?

– Файтелевич белән Шац...

Тополин башын иеп басып торган ике бәндәгә борылды:

– Нәрсә бу, иптәшләр?! Эшчеләрне мыскыл итүме?! Юк, алай гына да түгел, җинаять бу! Моның өчен кырыс җәза бирелергә тиеш. – Тополин янә немесләргә күз ташлады. Берсенең башында колакчынлы бүрек, тир шыбырдап ага. – Әйдә, иртәгә үзегезне шулай киендереп чыгарабыз. Икенче көнне үк аяктан егыласыз бит!

Колакчынлы бүрекле немес траншея төбеннән менгәндә, кулындагы тачкасын тотып кала алмады, мәтәлеп китте, тачкага төялгән җир кире ишелеп төште.

– Трапларны да ясамагансыз бит! Тар гына тактадан ничек менсен ди ул, әлбәттә, егыла! – Тополин кулын селтәде. – Кайда яшиләр болар?

– Әлегә якындагы авылларга урнаштырдык.

Тополинның йөзе кызарынып-бүртеп чыкты.

– Сез нәрсә, бөтенләй башсызмы?! Нигә аларны гади халык янына җибәрәсез?!

– Соң, алар бит хөкем ителгән түгел, сөрелгән генә...

– Сөрелгән шул ук хөкем ителгән белән бер инде ул! Авыллардагы халыкка нәрсә генә сөйләмәсләр дип уйлыйсыз?! Кичекмәстән немесләрне гади кешеләрдән аерырга, сак хезмәтен көчәйтергә! Ничә дезертирлык очрагы теркәлде?

– Бу бүлекчәдә немесләр арасыннан икәү, хөкем ителгәннәр арасыннан өчәү...

– Менә, күрдегезме?! Бик кирәк, ди, аларга синең тимер юлың! Сакны көчәйтергә!

– Иптәш Тополин, – дип эндәште сак комиссары Сергей Шерстнёв. – Кызганычка, дезертирлык очраклары барлык участокларда да күзәтелә. Моны туктатыр өчен җәзаны кырыслатырга кирәк дип саныйм. Берәрсен тотып атсаң...

– Атарга ук кирәкмәс, – дип бүлдерде аны Тополин. – Ләкин җәза кирәк, дөрес әйтәсез, иптәш комиссар. Прокуратура белән суд органнарына мөрәҗәгать итегез. Җәзасын бирергә, барысына да ул хакта игълан итәргә кирәк. Белеп торсыннар!

Икенче бер участокта Тополин төзелешкә китерелгән җирле халыкны күзәтте. Ак яулыклы хатын-кызлар, картлар, мәктәп яшендәге балалар эшли иде биредә. Кызганыч манзара иде бу. Кәйлә тотып, җир каезлаучы хатын-кыз – бик сәер күренеш. Тачка белән шул җирне траншея төбеннән өскә ташучы малай да – сәер.

– Сугыш, егетләр, – дип сузды Тополин әллә үзенә, әллә янәшәдәгеләргә. – Күрсәтегез миңа, нинди ризык ашатасыз боларга?

Аны кыр кухнясына чакырдылар. Зур казанда кәбестә ашы пешеп утыра иде.

– Шулпасы бигрәк кысыр, ит юкмыни? – дип сорады ул ашчы хатыннан, кайнар ашны бер кашык авыз иткәч тә.

– Юк шул, безгә китермиләр...

Тополин янәшәсендәге төркемгә борылды:

– Тоткыннарны да, сөрелгәннәрне дә, ирекле эшчеләрне дә яхшы, туклыклы итеп ашатырга кирәк. Алайса, ач кешедән нәрсә таләп итәсе?! Ачлыктан авырулар тарала. Суны кайдан аласыз?

– Өч көнгә бер әнә теге мичкә белән якындагы авылдан китерәләр, – диде, оялып кына, ашчы хатын.

– Өч көнгә бер?! Монда лазарет оештырмакчы булдыгызмы әллә?! Су чиста һәм көн саен китерелергә тиеш!

– Су белән тәэмин итү авыррак шул, – дип акланды Афанасьев. – Ашатуга

килгәндә, без бирегә күптән түгел генә килдек бит, әлегә азык-төлек базасын оештырып кына ятабыз. Үзебезнең яшелчә үстерү мәйданнары, терлекчелек фермалары бар...

Тополин, кайсы гына участокка бармасын, Афанасьевка болай да яхшы таныш, теңкәсенә тигән проблемаларны яңабаштан ачып салды. Бер нәрсә күңелен шатландырды – күпме генә проблема булмасын, төзелешнең инде нәтиҗәләре күренә, кайбер урында траншеялар әзер диярлек, икенчесендә тимер юл полотносы күтәртелгән, ә Зөя станциясенә якынрак өлештә хәтта рельслар да салынган. Тополин яңа юлны хәзердән үк йөкләр ташуда файдаланырга кушты. «Ярар», – диде Афанасьев, эченнән генә елмаеп. Алар инде күптән бу мөмкинлекне файдаланалар иде...

Казанда Волжлаг сәяси бүлегенең беренче партия конференциясе башланып китте. Анда рокада төзелешенең төрле бүлекчәләреннән барлыгы 83 делегат сайланган иде. Ике көн дәвамында алар барлык булган проблемаларны, каршылыкларны уртага салып сөйләштеләр. Мәскәү ашыктыра, вакыт кысан, фронттан яман хәбәрләр килеп тора. Шуңа күрә сөйләшү үтә дә ачык, ирләрчә кырыс килеп чыкты.

Башта доклад белән төзелеш башлыгы, майор Григорий Афанасьев чыгыш ясады. Аннан соң фикер алышуга күчтеләр.

– Иптәшләр, – диде икенче бүлекчә начальнигы Иосиф Савицкий. – План буенча билгеләнгән эшләрнең уңышы безнең ни дәрәҗәдә кирәкле ресурслар белән тәэмин ителүгә бәйле. Гөбенә белән Бәрле елгалары аша күпер сала башларга кирәк – кулыбызда проект юк. Җир эшләре буенча акрын барабыз. Бу иң кирәкле әйберләр булмауга да бәйле. Бездә хәзер дә аягына итек киеп эшләүчеләр бар. Шушы кызуда киез итек белән нәрсә эшләп булсын?! Бу да җитештерүчәнлеккә суга. Кемдер сырган чалбар киеп йөрергә мәҗбүр. Әгәр тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителеш булмаса, нәтиҗә дә булмаячак. Экскаваторлар хакында. Төзелеш начальнигы үзенең чыгышында бөтен трассага алты экскаватор бүленеп бирелүен әйтте. Шуның икесе безнең бүлекчәгә эләкте. Кабул иттек, барысы да әйбәт кебек. Ләкин бераздан бер өлеш запас частьләрен салдырып, Зөядәге техниканы төзекләндерү өчен алып киттеләр. Нәтиҗәдә безнең экскаваторларыбыз эшли алмый.

Бишенче бүлекчә начальнигы Григорий Москович чыгышында кимчелекләрне урап үтәргә тырышса да, тоз-борыч өстәми калмады. Төзелештә эшләүчеләрне ашату тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган, транспорт юк, Куйбышевның Партия Обкомы җибәрергә тиешле 2500 кешенең сиксәне генә килгән. Ашату мәсьәләсендә Афанасьев аны берничә мәртәбә бүлдереп, Московичның үзен үк булдыксызлыкта гаепләсә дә, тегесе туктамады. Азактан гына, мондый җыелышлардагы гадәт буенча, Москович та хәрбиләрчә «булдырырбыз» дип тәмамлады. Тагын берничә кеше чыгышларында бер-бер артлы охшаш проблемаларны ачып салдылар. Нимесләр контингенты арасында көнлек планны 400 процентка арттырып үтәүчеләр дә барлыгы мәгълүм булды. Проект документациясенең эшләнеп бетмәве зур тоткарлыкка китергән.

Белоглазовның чыгышы бигрәк тә хисләргә бай иде:

– Биредә доклад ясаганда, төзелеш начальнигы Дәүләт Оборона

Комитеты карарының февраль аенда ук кабул ителүен әйтеп китте, ә без эшкә апрельдә генә керештек. Идарә аппаратының бу җитди бурычны үтәр өчен әзерләнергә җитәрлек вакыты бар иде. Чынында нәрсә? Кадрлар белән тәэмин итү котчыккыч хәлдә. Советлар Союзында тулып яткан тәҗрибәле тимер юл төзүчеләрне алдан ук табарга мөмкин иде. Ә безгә архитекторлар, механиклар килә – алар мондый төзелешне моңарчы күргән кешеләр түгел. Транспортны әзерләмәдек. Төзүчеләр, тачкаларны күтәреп, унбишәр чакрым барырга мәҗбүр булган очраклар бар. Әгәр план 70-80 процентка үтәлә икән – бары тик ай ахырында көне-төне эшләү бәрабәренә генә. Ай буе тик ятабыз да килеп терәлгәч, эшкә ябышабыз. Хезмәтне оештыру рәвеше Пётр Беренче заманыннан ерак китмәгән. Тачка – бердәнбер механизация чарасы. Эш бары тик кешеләр җилкәсендә генә бара.

Белоглазовтан соң сүз алган Фёдор Резчиков кинәт төзелештә эшләүче немесләргә ябырылды:

– Безнең колоннада, мәсәлән, Кондра фамилияле бәндә бар, – диде ул, күзендә усал очкыннар уйнатып. – Ул бер киңәшмәдә «Тоткыннардан нинди төзүчеләр чыксын инде», – дип әйтеп салмасынмы?! Ярый ла бу очракта бүлекчә начальнигы башка намуслы хезмәткәрләр белән бергә теге Кондраның авызын вакытында томалады. Минемчә, ул фрицларга карата бүлекчә начальникларының хокуклары киңрәк булырга тиеш. 2 тәүлек урынына 20 тәүлек карцер чәпәсә, башкалар да уйланыр иде.

Зал, моны ишеткәч, үзара сөйләшеп, гүләп алды, конференцияне алып баручы Григорий Мурашов, каләме белән буш бокалны чыңгылдатып, тынычлыкка өндәде. Белоглазов дәвам итте:

– Санитар хәл турында берничә сүз әйтәсем килә. Санитар бүлек, мөгаен, бүген бик канәгатьтер – ул безне медперсонал белән күпме теләсәң шулкадәр күләмдә тәэмин итә. Тик барысы да чиле-пешлеләр, араларында ник бер рәтле табиб булсын! Бездә дарулардан хәтта аспирин да юк. Инструментны әйтмим дә. Бинт кисеп, яраны бәйләү өчен җирле халыктан кайчылар алып торырга мәҗбүрбез. Казанга киләбез – бинтларны да, кайчыларны да сезгә җибәрдек, диләр. Җибәрмәгез, зинһар өчен, алар безгә килеп җитми, килгәндә, үзебез алып китәрбез! Тәэмин итүчеләрнең берәрсе килгән чакта аңа безнең шартларда кичекмәстән операция ясыйсы иде, шуннан безгә ни җитмәгәнен белер иде! – дип ачынып сөйләде ул.

Өченче бүлекчә эшләгән участок Татарстанның Кама Тамагы һәм Апас районнары биләмәләренә карый иде. Бүлекчә начальнигы Баранов җирле халыкның тырышлыгын ассызыклады.

Сүз сак комиссары Сергей Шерстнёвка җитте. Ул май аенда 107 немес һәм 12 тоткынның дезертирлык кылуын хәбәр итте. Күбесе тотылып кире кайтарылган, һәм аларның берсе дә бүгенге көнгә кадәр бернинди дә җәзага тартылмаган. Шерстнёв качып китүчеләрнең күплеген ике нәрсә белән аңлатты. Бердән, немесләр якын-тирә авыллардагы гади халык йортларына фатирга урнаштырылган. Башлыча төнлә качалар да икән немесләр.

– Шуңа күрә төп бурыч – тиешле режим һәм ышанычлы изоляция тәэмин итү, – диде Шерстнёв, тамагын кырып. Күп тәмәке тартудан аның бугазында һаман да ниндидер төер тора иде. – Моның өчен аларны авыллардан чыгарып, аерым пунктларга тупларга кирәк. Фатирга

кергән нимесләр җирле халык белән дә аралаша бит. Алар кешеләрнең әйберләрен, ризыкларын, киемнәрен урлый, аннан да хәтәррәк очраклар бар. Дезертирлыкның тагын бер сәбәбе – сакчылар җитмәү.

Төзелеш җитәкчелегендә хатын-кызлар да бар иде. Өченче бүлекчәдән иптәш Громова трибунага менгәч, тимер юл салуның күңелсез манзарасы тагын берничә аянычлы төсмер белән «баетылды»:

– Безнең төзелештә гади халык арасыннан җәлеп ителгәннәрнең 40 проценты – хатын-кызлар, күпчелеге эвакуацияләнгән кешеләр, кызылармиячеләрнең хатыннары, балалары да бар. Балалар арасында сукбайлык мәсьәләсе аеруча кискен тора, – диде ул, әлеге проблемага чын күңелдән борчылуын яшермичә. – Колонналарда балаларны ашатырга хакыбыз юк, алар ач калалар. Иптәш Афанасьев белән сәяси бүлектән балалар өчен махсус шартлар тудыруны үтенәбез. Җитештерүчәнлеккә кагылышлы проблемалар да бар. Минем мобилизацияләнгән җирле халык турында әйтәсем килә, биредә менә партиянең Обком секретаре дә бар, – Громова Ильинга күз салды. – Безгә Апас районыннан – 300, Кама Тамагыннан 150 кеше җибәрергә тиеш иделәр. Апаслар башта эшкә бик кызу керешкән кебек булды да, алар җибәргән 250 кешенең унберен кире кайтарырга туры килде. Чөнки исемлеккә яше уналтыга тулмаган балаларны һәм инвалидларны да керткәннәр. Эш шунда тукталып калды. Кама Тамагы бөтенләй дә 50 кешене генә оештыра алды. Бусы татар районнары турында. Чувашия районнарына килсәк, әгәр хәлләр болай дәвам итсә, тиешле күләмдә эшчеләр мобилизацияләнмәсә, без куелган бурычны бөтенләй дә үтәп чыга алмаячакбыз...

Чыгыш ясаучыларны күбрәк тыңлаган саен Афанасьевның кәефе ныграк кырыла барды. Анысы юк, монысы юк... Җитмәсә, Степан Тополинның да йөзе караңгыланганнан-караңгылана бара, аңа биредә бәян ителгән хәлләр бер дә ошамаганлыгы аермачык булып тоемлана. Кемдер тягач, кемдер шпал, кемдер йөк машинасы, кемдер агитбригада, гәҗитләр таләп итә. Боларны җыеп, Нафталий Френкель каршысына утыртасы иде. Сөйләп карасыннар иде аңа. Өстәл сугып, барысын да куып таратасы да бит, Партия җыелышы, алай кыланырга ярамый. Гражданнар сугышын үткән майор түзде. Шушы кешеләр белән аңа зур төзелешне ерып чыгасы. Йә йөкләнгән бурычны үти, йә... Афанасьев биленә беркетелгән кобурадагы revolьверын капшап куйды. Аннан кулындагы сәгатенә күз салды.

– Вакыт соң, тәмамлагыз, – диде ул, пышылдап, янәшәсендәге Мурашовка.

– Иптәшләр, бүгенгә җитәр! – диде майорны бер сүздән аңлап Мурашов. – Иптәшләр, иртәгә иртән дәвам итәчәкбез, бүгенгә тәнәфес игълан ителә.

Җыелыш залыннан чыккач, Григорий Афанасьев, тимер юллар төзелеше Баш идарәсе начальнигы урынбасары Степан Тополинны һәм партиянең Татарстан Обкомы секретаре Илья Ильинны үзенең кабинетына дәште.

– Бик кызу бара сөйләшү, – диде Тополин, урындыкка утырып, тәмәкесен тартып җибәргәч. – Ачыктан-ачык сөйләшү... – Тополин тәмәке төтененең һавага очып китүен күзәтеп тынып калды. Аннан кинәт җан кергән төсле булды. – Нәрсә, Григорий Давыдович, шушылай коры килеш кенә йокларга озатмакчы буласыңмы?

– Сез нәрсә инде, иптәш Тополин, – дип, Афанасьев шкаф ишеген ачарга юнәлгән иде дә, аны Ильин туктатты.

– Степан Александрович, Григорий Давыдович, рөхсәт итсәгез, бүген үзем сыйлыйм. Минем табыннар корылган, машина көтеп тора. Киттек безгә.

– Менә бу тәкъдим ичмасам! – Тополин, тәмәкесен сүндереп, урыныннан торды.

Обком дачасында аларны чыннан да көтәләр иде. Мунчалар ягылган, себеркеләр пешерелгән. Мунча кергәнче, бакча уртасындагы җәйге верандада корылган табын янына утырдылар. Өстәл төрле ризык белән сынып төшәрдәй итеп тутырылган. Табынга килгәч тә, беренче чәркәне иптәш Сталин исәнлеге өчен басып эчтеләр. Бераз тамак ялгагач, сөйләшү җайлабрак китте. Ләкин ул барыбер партия конференциясендә салынган сукмактан чыга алмады.

– Төзелеш эшләре яхшы да бара, начар да, – диде Тополин. – Без синең белән, иптәш Афанасьев, төрле участокларда булып кайттык, күп нәрсәләрне күрдек. Хәтерлисеңме, ялгышмасам, өченче бүлекчәдә булды бу хәл. Автотранспорт юк. Аңа җаваплы кешене чакырдык, сөйләшәбез. Ык та мык. Катырак әйтеп тә ташлаганмындыр. Әмма файдасы тиде – карыйм – бер сәгать тә үтмәде, сигез машина килеп туктады. Димәк, автомобильләр бар, оештыру сәләте генә юк.

– Төзелештә тимер юл салуның ни икәнен дә белмәүчеләр шактый, – диде Афанасьев, калҗадан соң майга буялган бармакларын ап-ак салфеткага сөртә-сөртә. – Кешеләр әзерлексез, анысы да чабудан тарта, иптәш Тополин.

– Кешеләр нинди бар, шундый инде... – Тополин киерелеп куйды. – Хәзер башкаларын табу мөмкин түгел. Яхшылары, әнә, фронтта... Анда халкыбыз кан түккәндә, мондагылар тир түгәргә теләми. Иптәш Ильин, Обком секретаре буларак, сезгә җирле халыкны күбрәк мобилизицияләргә кирәк. Ике кулы, ике аягы булган теләсә кемнең файдасы тиячәк.

– Мобилизацияләр идек тә, бездә дә картлар белән хатын-кызлар гына калды, – диде Ильин, көрсенеп.

– Мондый вакытта бер кеше өч кеше урынына эшләргә тиеш. – Тополин чираттагы чәркәдән соң табынны тәмам җыелышның дәвамына әйләндереп куйды. – Оборона Комитеты безгә план куйды – аны ничек тә үтисе. Юкса, илебез дә, үзебез дә бетәбез. Нимес хәшәрәте басып алачак...

– Нимесләр дигәннән, – дип сүз катты уйчан Ильин. – Минемчә, хәзер төзелештә эшләүче нимесләргә карата мөнәсәбәт бер дә дөрес түгел. Мондагылар бит нимес-фашистлар түгел, аларны безгә каршы мылтык күтәреп килгәннәр белән бер рәткә куярга ярамый. Алар безнең совет җирендә яшәп көн күргән кешеләр, араларында коммунистлар да бар. Ә күп урында мин аларны кимсетү, мыскыллауны күрәм, ул фактларны Обкомга җиткереп торучылар да бар.

– Иптәш Ильин, сез ялгыша күрмәгез тагын, – дип җитдиләнде Тополин. – Кеше сиңа күзеңә карап, бер нәрсәне әйтергә, ә эченнән бөтенләй икенче нәрсәне уйларга мөмкин. Бүрене күпме генә ашатсаң да, ул урманга карый. Болар белән дә шул ук хәл. Әйе, эленке-салынкы эшләп йөргән була, ләкин уйлары кайда икән аның? Ул да безнең бугазны чәйнәп өзәргә әзер түгел

дип, кем әйтә ала? Менә, мисал өчен, Зөя, Гөбенә елгалары аша салына торган барлык күперләр дә агачтан ясала. Аларга кинәт ут капса? Яндырып җибәрү берни тормый бит. Шуңа күрә аларны күз астында тотарга кирәк.

– Аңлыйм, ләкин бу очракта эш турында сүз бара. Минемчә, аларның күңелен күтәрсәк, дөрес оештырсак, җитештерүчәнлек үсә төшәр иде, – Ильин кызарып ук чыкты, куллары калтырана башлады.

– Сез безгә җирле халыктан эшчеләр бирегез. Эвакуацияләнгәннәр арасыннан сайлап алырга кирәк. Килешәм, тоткыннарны гади халык өйләренә урнаштыру ялгышлык, аны төзәтербез. Ләкин моны да обком ярдәменнән башка эшләп булмый – бараклар вакытлыча гына төзелсә дә, аңа материал кирәк.

– Материалларны да хәлдән килгәнчә оештырырбыз, кешеләрне дә җибәрербез, Степан Александрович, эш кенә барсын.

Янә берәрне күтәреп куйдылар.

– Григорий Давыдович, сиңа да сораулар шактый. Эшне оештыру, беренче чиратта, синең җилкәдә, – Тополинның сүзләреннән Афанасьев куырылып төште. – Без партия кушканны гына эшләргә өйрәнгән, менә иртәгә кәгазь җибәрерләр дә, анда барысы да ничек тиеш шулай язылган булыр дип яшәдек. Ләкин хәзер башка замана. Сугыш шартларында яшибез. Хәер, кайберәүләр моны аңлап бетерми бугай. Маклаков бүлекчәсен генә алыйк. Маклаков киенгән, минсиңайтим! Ефәк ак күлмәк, чалбары ялт иткән, аягында лак белән буялган туфлиләр! Мин безнең җитәкчеләр алама киенеп йөрергә тиеш, димим. Ләкин туфлиләре кызганыч. Ул трассаны тикшереп йөргәндә, теләсә кайсы вакытта траншеяларга төшәргә, тимер юл күтәртмәсенә менәргә тиеш.

– Мин аңа әйтермен, – диде кәефе кырылган Афанасьев.

Алар әле бик озак шулай сөйләшеп утырдылар. Тополин белән Афанасьев шунда гына кунып калды, икенче көнне иртән партия конференциясе үз эшен дәвам итте. Ни гаҗәп, Тополин андагы чыгышында әллә ни кырыс булмады, булган кимчелекләрне атап чыгып, төзелешне һичшиксез сыйфатлы итеп һәм срогыннан алда башкарып чыгасыларына ышанычын белдерде.

Ильин үз чыгышында немецларга карата тискәре мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәклеген барыбер әйтте:

– Минемчә, кайбер төзүчеләрнең мобилизиацияләнгән немецларга карата мөнәсәбәте шактый ялгыш, – диде ул, трибунада сүз алгач та. – Иптәшләр, акны карадан аера белергә кирәк. Алар – корал күтәреп, безнең илебезгә ябырылган фашистлар түгел. Болар – башка немецләр, һәрберсен дә кабахәт рәтенә кертергә ярамый. Тоткыннар белән эшләргә күнеккән кайбер иптәшләр бу эшчеләргә авыр сүзләр әйтә, дорфалык очраклары күп. Бу, киресенчә, безнең эшкә комачаулый гына. Алар бит безнең, совет немецләре, шушы илдә яшәгән кешеләр. Читкә этәрмик, якынайтыйк, барлык гамәлләребез белән аларга ышануыбызны күрсәтик. Әгәр шулкадәр кеше эшен ташлап качып киткән икән, димәк, партия оешмасы аларны кызыксындыру өчен җитәрлек чаралар күрмәгән. Без – партия Обкомы – сезгә бар нәрсәдә дә булышырга әзер. Чәчү тәмамланып килә, эшче көчләрне Дәүләт Оборона Комитеты карарында билгеләнгән

күләмдә бүлеп бирербез. Атлар да булыр, аларны имгәтми эшләтегез. Колхозлардан килүчеләргә аерым игътибар итүегезне үтенәм. Без аларны колхоз эшеннән аерып, сезгә җибәрәбез, алар авылларында да бик кирәк. Ләкин алар, безнең сүзне тыңлап, сезгә ярдәмгә китә, урында калганнары ике кеше өчен эшләргә мәҗбүр була.

Конференция шулай бер-бер артлы чыгышлар белән дәвам итте. Азактан анда катнашучылар, карар кабул итеп, Идел яры буйлап сузылган очсыз-кырыйсыз төзелешкә таралышты...

***

Марфа Петровна колхозчыларны клубка җыелышка җыйды. Соңгы вакытта ул нык алҗыган, арыган кыяфәттә иде. Тормыш авырлыгы, колхозга йөкләнгән күпсанлы бурычларны үтәп, көне-төне чабу аның да көчләрен суырды. Бер яктан азык-төлек тапшыру планын үтисе бар, икенче яктан авылда юк җирдән балалар йорты калкып чыкты, кечкенәләрне ашатып-киендереп тору хәстәре дә колхоз рәисе өстендә. Марфаны якыннанрак белгән кешеләр аның соңгы вакытта бигрәк тә күп эчүен, ашаудан язуын, бөтенләй диярлек йокламавын сөйли иде. Ләкин Марфа Петровна бирешмәде. Ул халыкка клуб сәхнәсендәге трибунадан көр тавыш белән мөрәҗәгать итте:

– Иптәшләр! Колхозчылар! Ирләребез яу кырында сыналган мәлдә, безгә биредә, тыныч тормышта үзебезнең хезмәт белән җиңүне якынайтырга кирәк. Һәм без моны булдырабыз, моны районда да, Казанда да яхшы беләләр, югары бәялиләр. Сугыш аяусыз, ул бездән яңа үрләр яулавыбызны таләп итә. Безнең колхозга бик мәртәбәле бурыч йөкләнә – безгә авылыбыздан ерак түгел алып барылучы зур төзелештә катнашырга кирәк. Мин хәзер исемнәрен атаган колхозчылар иртәгә иртәнге өчтә шул төзелешкә чыгып китәргә тиеш булачак. Эш коралларын шунда ук бирәчәкләр, үзегез белән берни дә аласы түгел. Иртәнге алтыга сез билгеләнгән урынга килеп җитәргә тиеш булачаксыз. Яшәү эшләгән җирдә, шимбә-якшәмбе көннәрендә генә өйгә кайтырга мөмкин. Шуңа күрә алмаш киемнәрне, яңгыр ява калса бушлатларны, җылы әйберләрне дә онытмагыз, кирәге чыгар. – Аннан, сагыш тулы күзләрен халыкка төбәп, инде тынычрак, җылырак тавыш белән өстәп куйды. – Үзегез белән ризык алыгыз. Эше җиңел түгел, хәл җыярга бер кисәк икмәк артык булмас.

Колхоз рәисе, чыгышы тәмам икәнлегенә ишарәләп, колхозчылар исемлеге буенча сайлап алынган кешеләрне санап чыкты. Әлеге исемлеккә Зөбәйдә белән Хәмидулла да кергән иде.

– Нәсимә, син балалар йортында каласың, барысы да синең өскә күчә. Җыелыш тәмам, иптәшләр, таралыша аласыз.

Халык дәррәү урыннарыннан торып, ишеккә юнәлде. Алар арасыннан Хәмидулла гына, аерылып, Марфа Петровна янына килде.

– Ни кирәк сиңа?! – дип, дорфа гына сорады колхоз рәисе.

– Кызым, бераз үзеңне сакла, болай булса бетәсең бит син, – Хәмидулланың йөзендә чыннан да ихлас борчылу иде.

– Бетсәм бетәм, үземнеке. – Марфа Петровна ишектән чыгып баручы кешеләргә, ишетмиләрме дип, күз ташлады, аннан тәрәзәгә борылды. –

Таһир хәбәрсез югалган. Күптән икән инде, берәр атна элек кенә миңа әйттеләр.

– Исәндер, анда кемнең каялыгын кем белеп бетергән...

– Хәзер беләләр инде, баштарак кына буталчык булды. Хәзер барысын да беләләр... Йә, ярый, Хәмидулла, җылы сүзең өчен рәхмәт, юлыңда бул. Таһир турында син белдең дә мин белдем, кешегә сөйләп йөрмә.

– Алай да, үзеңне бераз тәрбияләргә кирәк, Марфа Петровна...

Марфа Петровна кызарып чыккан күзләрен Хәмидуллага төбәде.

– Ә ни өчен, кем өчен тәрбияләргә, Хәмидулла?! – Марфа Петровна кинәт яшьле күзләрен тәрәзәгә борды. Алар залда икәү генә калдылар, күрәсең, колхоз рәисенә күңелендә күптән җыелган ташларны бушатырга кирәк иде. – Минем чын исемем Марфа түгел, Маргарита мин. Әти мине Марго дип йөртә иде. Әтием бай кеше, Саратов урамнарына чыксак, як-яктан, баш иеп, «Исәнмесез, хөрмәтле Пётр Сергеевич!» дип калалар иде. Әнием мине тапкач та, озак тормаган, үлгән, мин аны хәтерләмим. – Марфа Петровна кул аркасы белән мышкылдаган борынын сөртеп куйды. – Әти кырыс кеше иде. Миңа да аның кырыслыгы күчте. Үсә төшкәч тә, арабызга кара мәче керде. Ул иске режимны яклады, мин яңасына омтылдым. Үзенә күрә яшьлек протесты булгандыр инде. Мин кызылларга кушылдым. Партиягә кердем. Шунда яше кырыклар тирәсендәге бер офицер бар иде. Самойлов. Мин аңа үлеп гашыйк булдым. Өйләнгән икәнен дә беләм, ләкин үземне бернишләтә алмыйм. Төн арты төн үтә, ул мине назлый, минем башым күккә тигәнмени... Көннәрдән бер көнне отрядны тезеп бастырдылар. Самойлов мине дә махсус төркемгә кертте. Юлга кузгалдык. Беләсеңме, Хәмидулла, йөрәк сизә икән ул. Кысып-кысып ала. Нигә икәнен үзем дә аңламыйм. Үзем атлыйм, үземә авыр. Аннан соң аңладым инде. Әтием өенә килдек... Мин туып-үскән өйгә... – Марфа Петровнаның күз яшьләре атылып чыкты, ул инде Хәмидулладан оялып тормый, чын күңелдән елый иде. – Аннан соң әтине алып чыктылар. Ул миңа соңгы тапкыр карады да «Марго» дип пышылдады. Ышанасыңмы-юкмы, Хәмидулла, аның карашында ачу да, үпкә дә юк иде. Ул миңа бәхиллеген бирде кебек...

Марфа Петровна авызын чишкәч, игене агып чыккан капчык төсле бөкшәеп калган иде. Ул һаман тәрәзәдән күзен алмый, әйтерсең, нидер күргән дә, шуны ычкындырырга курка. Үзе елый, үзе сөйли...

– Самойлов миңа берни дә әйтмәде. Читтән генә минем үз-үземне тотышымны күзәтеп торды. Кичен исә мине казармага ияртеп барды, шунда солдатлар белән аракы эчтек... Мин уянганда, Самойлов юк иде. Бөтен тәнем сызлый. Төнге вакыйгалар шул сызлаудан гына капылт итеп кисәк-кисәк исемә килеп төште. Бер солдат, ике солдат... Минем беркайчан да балаларым булмаячак, Хәмидулла. Саратовтан башка шәһәргә күчертүне сорадым, күчерделәр. Ләкин мин киткәнче, ишегалдында әтиемне атып үтерергә өлгерделәр. Рәхмәт, Самойлов чиктән тыш кыргыйлыкка ук бармады, мине әтиемне атканнарын карап торырга мәҗбүр итмәде. Аннан соң мин Казанга килеп чыктым, шунда Таһирны очраттым. Калганы сиңа мәгълүм...

Марфа Петровна елаудан һәм хәмер эчүдән шешенгән йөзен Хәмидуллага таба борды:

– Менә хәзер син минем тормышымны да беләсең... Ә хәзер бар, юлыңда бул.

Инде ишек катына җиткәндә, Хәмидулла Марфа Петровнага борылды. Колхоз рәисе букчасыннан шешә чыгарган, стаканы тулы, шуңа карап, үзенә генә мәгълүм уйга баткан иде...

Алар юлга кузгалганда, таң беленеп килә иде. Ике ат арбасына төялделәр. Алдан, кара айгырына атланып, Марфа Петровна бара. Районга җиткәч тә, бер бина каршында туктадылар. Биредә Хәмидуллалар шикелле үк төенчекләр тоткан кешеләр бихисап, күрше авыллардан да шактый танышлар бар.

Марфа Петровна, айгырын бәйләгәч, арбалы атларның хуҗаларына колхозга кайтырга кушты. Аннан соң контора эченә кереп югалды. Озакламый ул аннан бер хәрби хатын-кыз белән бергә чыкты. Бу хатын-кыз Марфа Петровна алып килгән исемлек буенча кешеләрне барлады, кайберләренең яше белән кызыксынды, буй-сыяфәтләрен җентекләп күзәтте. Аннан соң арырак торган төркемгә барып кушылырга кушты.

– Хәмидулла, безнең колхозчылар өчен җаваплы кеше итеп сине билгелим, – диде Марфа Петровна, авылдашлары янына килеп. – Берәрсе өстеннән шикаять ишетелсә, син җавап тотачаксың. Хәзергә сау булып торыгыз, иптәшләр!

Бөтен бу вакыйгаларда Хәмидуллага лагерь чорыннан таныш чалымнар бар иде. Теге исемлекләр белән йөрүче хатын-кыз да – НКВД вәкиле. Ул үзен әле кайчан гына котылган тоткынлыкка янәдән килеп эләккән төсле хис итте. Һәм бу охшашлыклар, чыннан да, тагын да арта барды.

Күп тә үтми, алар җыелган контора болдырына икенче бер хәрби чыкты. Ул көр тавышы белән кешеләргә колоннага тезелергә боерды. Колоннаны озата баручылар гына хәрби кешеләр түгел иде. Халык рәт-рәт тезелешкәч, алар юлга кузгалды.

– Әллә безне армиягә алалармы, Хәмидулла абый? – дип сорады аңардан куркынган тавыш белән авылдашы Шәмсекамәр.

– Армиягә алалар, сеңлем, армиягә. Тик сугыш армиясенә түгел, хезмәт армиясенә...

– Анысы ничек була?

– Анысы, сеңелем, бөкрең чыкканчы эшли торган фронт була.

Шәмсекамәр бүтән дәшмәде.

Буадан чыккач та, тагын хәтсез генә бардылар. Иртәнге бишләр тирәсенә төзелеш мәйданына килеп җиттеләр. Басу уртасын ярып, киң чокыр сузылган. Аның тирәсендә аннан-моннан җитештерелгән сарай сыман корылмалар төртелгән. Күпчәкле будкалар да бар.

Хәмидулла тирә-юньне күздән кичерде – төзелеш урынына төрле яклардан халык агыла иде. Берьюлы берничә колонна килә. Кайберләре Хәмидуллалар төсле колхозчылар. Яшүсмерләр, хатын-кызлар, карт-коры. Ләкин үзгә колонналар да күзгә ташланды. Боларын кораллы НКВД солдатлары озата бара. Таушалган киемнәр, бөкрәйгән аркалар, талчыккан йөзләр, төпкә баткан өметсез күзләр... Хәмидулланың йөрәге «жу» итеп китте. Әле кайчан гына үзе дә шушындый халәттә, аягын көчкә өстерәп, коммунизмның бөек төзелешләренә йөрде бит. Читтән караганда, бигрәк куркыныч икән. Өс-баш коточкыч, колоннада туктаусыз йөткерү тавышлары яңгырап тора, кайберләре бетләгән, күрәсең, атлап барган шәпкә кашыналар. Колонна якынайган саен Хәмидулла андагыларны

яхшырак күрә алды. Төпкә баткан күзләрнең күбесе зәңгәр төстә булып чыкты, чәчләре башлыча саргылт иде. Хәмидулла яныннан үтеп киткәндә, ул әлеге адәми затларның йөзендә ачы хәсрәт, үзенә карата ниндидер сәбәпсез нәфрәт хисен укыды. «Мин дә сезнең кебек кыерсытылган бәндә, рәнҗемәгез миңа!» – дип кычкырасы килде. Тик дәшмәде. Ә колонна, артыннан тузан өере калдырып, ерак түгел агып яткан елга ярына төшеп югалды. Тиздән ерактан әмерләр яңгырады, озак та үтми балта чапкан, нәрсәнедер дөбер-шатыр китереп әйләндергән тавышлар ишетелде.

Хәмидулла Зөбәйдәсе чакырган тавышка сискәнеп китте. Авылдашлары башка халык белән бергә янә шеренгага тезелә башлаган. Хәмидулла шунда ашыкты. Якынрак килгәч, шеренга каршында ул олы яшьтәге ак мыеклы бер агайны абайлады. Уң кулы юк, күлмәк җиңен терсәк тирәсендә төенләп бәйләп куйган.

– Тезелеп басыгыз! – диде абзый, килеп җиткәч тә.

Мондый командаларга күнекмәгән колхозчылар ничек эләксә шулай басты. Һәрберсенең кулында төенчек. Мыеклы абзый каршысындагы кешеләрне күздән кичерде.

– Исәнмесез, иптәшләр! – диде ул, ниһаять. – Мин сезнең прорабыгыз Вәлиулла Вахитович булам! – Прораб, исән кулын аркасына яшереп, колхозчылар алдында ашыкмый гына арлы-бирле йөренә башлады. – Иптәш Сталин кушуы буенча без биредә зур төзелеш эшләре алып барабыз. Аның нәтиҗәсендә безнең илебез өстенә ябырылган нимес хәшәрәтләренең артына тибеп, юк итәргә мөмкин булачак. Әлегә сугыш бик авыр бара. Яу кырында эскерт-эскерт өелеп солдатларыбызның мәетләре ята. Аларның һәрберсе – кемнеңдер ире, кемнеңдер газиз баласы. Хәзер төенчекләрегезне әнә теге алачыкка кертеп куегыз – аларга беркем дә тимәс. Мин сезгә эш коралларын өләшермен. Ни эшләргә кирәклеген аңлатырмын. Көн тәртибе болайрак – иртәнге биштә җыелабыз, алтыдан эшкә керешәбез. Эш көне кичке җидедә тәмамлана. Аңа кадәр минем ризалык белән генә кыска вакытка йомыш йомышларга барып килергә мөмкин. Кичкә кадәр түзсәгез яхшырак булыр. Әбәткә бер сәгать бирелә. Кичке җидедә ашау оештырыла. Төнгелеккә моннан ерак түгел бер авылда фатирларга урнаштырырбыз. Һәр иртә саен җыелып, шушында киләсез. Көн тәртибен бозарга ярамый. Аңлашылдымы?

– Аңлашылды, – диештеләр авыл кешеләре.

– Алайса төенчекләрне калдырып, минем арттан барыгыз.

Хәмидулла янәдән Беломорканал буйларына кайткан төсле булды. Аңа тачка эләкте. Киң траншеяны тирәнәйтеп, шуның төбендәге балчыкны өскә күтәрәсе иде. Буйдан-буйга башка авыллардан да алар шикелле үк китерелгән халык шул эш белән шөгыльләнә. Озакламый йөк машиналары килеп туктады – аларның арбасыннан тагын кешеләр коелды. Алар да тиешле инструктаж алу белән кичекмәстән эшкә керештеләр.

Төш вакытында прорабтан кыска гына вакытка ял сорап, Хәмидулла траншея төбеннән менде. Янә эшкә тотынганчы, тирә-юньне күздән кичерде. Гаҗәеп манзара иде бу. Траншея каядыр еракка, офыкка китеп юкка чыга. Буеннан-буена кешеләр кайнаша. Менә авылдашлары тир түгә, ир-атлар белән беррәттән аның кызы да башын күтәрми эшли. Аннанерактарак тагын халык, араларында башка авыллардан килүчеләр дә бар бугай. Ә

траншеяның теге башыннан аны башта ком, аннан таш белән тутырып киләләр. Ул ташларны һәм комны әледән-әле машина белән китереп аударалар. Траншея төбенә башта тачка белән ташып ком салалар. Аннан соң аны агач бүкән кисәге белән тыгызлыйлар. Комнан соң таш салына.

– Син кайдан, агайне? – дигән тавышка Хәмидулла сискәнеп китте. Янәшәсендә үк озын буйлы, чандыр гәүдәле абзый басып тора иде. Хәмидулланың кайсы авылдан икәнлеген белгәч, абзый күршеләр булуын әйтте, авылының исемен атады.

– Без монда инде бер атна буе чиләнәбез, – диде ул, кысык күзләре белән еракка карап. – Тимер юл төзибез, Зөя стансасыннан Сембергә кадәр җитәчәк. Ашыгалар, ашыктыралар... Теге яктан да, – абзый басуның әлегә кеше кулы тимәгән ягына төртеп күрсәтте. – Теге яктан да монда таба төзеп киләләр, ди. Кайда да булса очрашабыз, димәк... Эш болай тиз бара, инде рельсларны да сала баралар икән. Кеше генә җитми... Әнә теге кешеләрне күрәсеңме? Иртән машинага төяп алып килделәр. Алары Казаннан ук. Завод эшчеләре дә бар хәтта, аларны да производстводан алып, монда юллаганнар. Ә тегеләре, – абзый каршы якка, иртән Хәмидулла озаткан колонна киткән тарафка ымлады. – Алары – нимесләр. Тоткын нимесләр түгел, үзебезнекеләр, Советлар Союзыныкы.

– Аңлашылды, – диде Хәмидулла.

– Ни атлы соң үзең, сорамый да торам? Мин Вәли булам. Габделвәли.

– Хәмидулла.

Вәли дигәне, моны ишеткәч, сискәнеп үк куйды.

– Хәмидулла?! Хәзрәт Хәмидулламы?!

– Хәзер хәзрәт түгел инде...

– Ярый, китим... – Вәли дигәне борылды да, аннан-моннан тиз генә каккалап-суккалап куйган сарайлар арасына кереп югалды.

«Кая барсаң да, кара сакалың артыңнан калмый». – Хәмидулла эчтән генә көрсенеп куйды. Ниндидер Вәли, аны белмәгән, күрмәгән Вәли аның белән сөйләшеп торырга да курыкты. Аның турында «дошман» дип уйлаучылар бер ул гына түгелдер. Гомерлеккә ябышкан кара сакал...

...Кичке җидедә хәлдән таеп менгәчтен, аларны кәбестә ашы белән сыйладылар. Чын аш иде бу, лагерь баландасы түгел. Күрәсең, кемдер аны яратып, тәмле булсын дип пешергән. Буыннан ит шулпасы исе килеп тора. Зөбәйдәгә күз салды. Ашыга-ашыга шулпа чөмерә. Чәчләре тузгып төшкән, авылдан киткәндә генә, чип-чиста күлмәге пычракка баткан, өстен тузан баскан.

– Ардыңмы, кызым? – диде ул, Зөбәйдәнең хәлен бераз булса да җиңеләйтергә тырышып.

– Түзәрлек, әти. – Зөбәйдә мышкылдап куйды. Аннан, тәлинкәсе белән кашыгын җиргә куеп, канга кадәр уелып чыккан ике учын күрсәтте.

– Йа Хода! Бияләй алырга башка килмәде бит...

– Белмәдек бит мондый эш буласын. Ярый ла, төзәлер, иртәгә кулларыма яулык чорнап чыгармын, – дип тынычландырды аны кызы, янә ашауга керешеп.

Бүген төзелешкә төшкән һәркемнең дә куллары шул хәлдә иде. Билләр сызлавын әйткән дә юк. Авыл кешесе авыр хезмәттән курыкмый. Әмма

күнегелгән эш җиңел, яңасына исә яраклашырга, җаен табарга кирәк. Тачкалар, ком һәм ташны тыгызлаучы җайланмалар ярты-порты юнган агачтан эшләнгән, тоткалары җайсыз, кул да аларга ияләшмәгән. Җәйге чор булса да, балчык бик авыр, комы сулы.

Ашап алгач та, аларны бер авылга төн кунарга алып киттеләр. Зөбәйдә белән аны һәм Казаннан китерелгәннәр исәбеннән тагын бер хатынны кечкенә генә өйдә яшәүче олы яшьтәге мишәр карчыгына урнаштырдылар. Хөббениса әбинең киштәләре буш булса да, күңеле киң булып чыкты. Ул аларны кадерле кунак сыман каршылады.

– Ни атлы буласыз? – дип сорады ул, исәнләшкәч тә.

– Минем исемем Хәмидулла. Бусы кызым Зөбәйдә, ә бусы...

Хәмидулла таныш булмаган ханымга борылды. Тегесе чеп-чи татарча:

– Минем исемем Сәкинә! – диде.

– Сөбханалла, балакайларым, – дип, әллә нигә шатланып, Хөббениса әби кулларын чәбәкләде. – Кызлар сәкедә йоклар, сиңа, энем, идәнгә җәярмен, гаепләмә. Үзем мич башында йоклыйм. Әйдәгез, кулларыгызны юыгыз да, чәй куеп җибәрәм, табынга утырыгыз.

Табынга утыргач та, Хәмидулла никадәр арганлыгын тоемлады. Үтереп, йокы төште. Кызлар да яту ягын карыйлар, ләкин Хөббениса әби тиз генә бирешүчән булмады. Ул һәрберсен бәйнә-бәйнә сораштыра башлады. Башта кайсы авылдан икәнен белеште. Хәмидулла авылларының исемен атагач, каршында утырган Сәкинәнең, каушавыннан, кулындагы чәе түгелде, ул ничектер сәерсенеп, зур күзләре белән Хәмидуллага текәлде. Әллә бу хатын да минем хөкем ителгәнне беләме, дип, эченнән генә уфтанды Хәмидулла, ләкин аны-моны дәшмәде.

Хөббениса әбинең теләге буенча һәммәсе дә, мөмкин булганча, үзенең тормышы турында сөйләде. Әлбәттә, Хәмидулла элек мулла булуын да, лагерь аша узганлыгын да әйтмәде. Ә менә Сәкинә шактый ачылып китте бугай. Ул Казанга завод белән бергә Ленинградтан ук күчерелгән, улы фронтта командир икән. Улын ялгызы гына үстергән. Моны тыңлаганда, Хәмидулланың инде күзләре үк йомыла башлады. Хөббениса карчык та аңлады бугай, нидер сөйләнә-сөйләнә тиз генә урын әзерләде дә, йорт йокыга талды...

Янә таң белән тордылар. Әбигә иртәнге чәй өчен рәхмәт әйтеп, юлга кузгалдылар. Зөбәйдә арттарак калды, янәшәдә кеше-кара күренми иде, Хәмидуллага Сәкинә пышылдап диярлек эндәште:

– Сез авыл мулласы Тимерханов Хәмидулла бит?

Хәмидулла, ни уйларга да белми Сәкинәгә таба борылды. Ләкин Сәкинәнең йөзендә ул усаллык та, мәкер дә күрмәде.

– Әйе. Дөресрәге, элек мулла идем, хәзер менә каторжан... Ә сез мине кайдан беләсез?

– Сәгыйдулла... – Сәкинә кинәт елар дәрәҗәгә җитте, күзләренә мөлдерәмә яшь тулды. – Сезнең энекәшегез Тимерханов Сәгыйдулла... Ул – минем улым Хәмитнең әтисе...

– Сөбханалла! – Хәмидулла телсез калды. Аннан тиз-тиз пышылдарга кереште. – Сез бу хакта беркемгә, хәтта Зөбәйдәгә дә әйтмәгез. Мин – халык дошманы, зыяны тияргә мөмкин. Җае чыккач, тагын сөйләшербез.

Зөбәйдә яннарына килеп җиткән иде инде, ул Сәкинәнең күзендә яшьләр күреп, бик гаҗәпләнде:

– Берәрсе рәнҗеттеме әллә, Сәкинә апа?!

– Юк, сеңлем, беркем дә рәнҗетмәде. Менә хәзер иртә таңнан минем улым да пулялар астында каядыр бара дип уйлап алдым да, күземә яшьләр тулды...

Һәм ул, чыннан да, улы Хәмитне искә төшереп, үкереп үк елап җибәрде. Зөбәйдә, аны иңеннән кочаклап, тынычландырырга кереште. Бик рәхәт кочаклау иде бу Сәкинә өчен. Якын кешесе кочуы. Зөбәйдә аларның якын кешеләр икәнлеген белми, ләкин бу якынлык күренмәс җепселләр, аңлатып булмаслык көчләр аша һичшиксез кешенең күңеленә ирешә. Соңгы тапкыр шулай аны улы Хәмит кочаклаган иде. Кайчан булды икән ул? Хәмиткә бер 10-11 яшьләр вакыттадыр. Малайлар тиз кырыслана, үсмерлеккә чыккач, ул кочаклашып торулар бетте кебек. Юк, ялгыша Сәкинә. Училищедан сагынып кайткан вакытларында Хәмит, ишектән керү белән, әнисен кочаклап алырга өйрәнде. Хәзер күрешәсе иде дә бит, юк, сугыш...

Көн арты көн үтә торды, көннәр тоташ бер агымга әверелде. Кызуда эшләүнең бер михнәте булса, яңгыр астында балчык изү икенче яктан авыр иде. Хәмидулла күнеккән, ул бары тик яшьли ватылучы балаларны, көч-хәл белән аякта басып торучы картларны гына кызгана. Һәм, әлбәттә, хатын-кызларны. Төзелешнең төп авырлыгын нәкъ менә алар күтәрде. Зөядән килүче тимер юл аларның нәзберек иңнәрендә калкып чыга иде.

Атна азагында авылга кайтырга мөмкинлек туды. Кичке аштан соң аларны янәдән колоннага тезеп, Буага алып киттеләр. Анда колхозның арбалы атлары көтеп тора. Дөм караңгыда булса да, авылга да кайтып җиттеләр. Конторада ут яна иде. Димәк, Марфа Петровна биредә. Кереп, исәп-хисап тотасы булыр дип, Хәмидулла башта шунда юл алды.

Марфа Петровна тонык кына ут яктысында үзенең өстәле янында утыра, янәшәсендә шешә белән стакан. Хәмидуллага ул башын күтәреп, бер генә карады да янәдән каршындагы кәгазьләргә чумды:

– Тәртипме, гражданин Тимерханов?

– Тәртип, барысы да исән-сау...

– Эшлиләрме?

– Эшлибез, тырышабыз.

Марфа Петровна урыныннан торып басты. Хәмидуллага текәлде.

– Ник кердең?!

– Соң, мине сез безнең колхозчылар өчен җаваплы кеше итеп билгеләдегез бит, сезгә хисап бирергә кирәктер дип кергән идем...

Марфа Петровна кулын селтәде, көрсенеп куйды:

– Синең аркаң кычытмыймы, гражданин Тимерханов?

– Юк... Бетләмәдек шикелле, бер чиста татар әбисенә урнаштырдылар...

– Беттән әйтүем түгел, гражданин Тимерханов. Белеп тор – аркаң кычытса, димәк, сиңа фәрештә канатлары үсә дигән сүз. Бар, кайт, ял ит, хатының белән күреш! Үзеңне изгән властька хезмәт итеп арымадыңмы әле?!

Хәмидулла сүзсез калды, аннан акрын гына борылып чыгып китте.

Йокысыз төн булды бу. Башта Нәсимәгә төзелештә Ленинград кызы Сәкинә белән очрашуы хакында сөйләде.

– Икенче атнага безгә кунакка алып кайт, Сәгыйдулланың туган нигезләрен күреп китәр ичмаса, – дип, шунда ук тәкъдим итте хатыны.

– Ярамый. Безнең белән бәйләнешне белсәләр, аңа да, фронттагы командир улына да тормыш бетте дигән сүз. Зөбәйдәгә дә аны-моны ычкындыра күрмә, арты хәерле булмаячак.

– Алайса, адресын сорап ал, дөньялар үзгәрер, табышырбыз...

– Анысын уйлап бетерермен, карчык.

Тик бу төндә Хәмидулланың уйлары ул хакта түгел иде. Марфа Петровнаның сүзләре башыннан чыкмады. Нәрсә әйтергә теләде ул? Кимсетү идеме максаты? Әллә инде Хәмидулланы сынап каравы, махсус котыртуымы? Үзен яла ягып рәнҗеткән илгә хезмәт итү гөнаһмы? Әллә инде, язмышка буйсынып, ул да, Ходай кушканча, ил башына төшкән авырлыкны күтәрергә тиешме? Дөрес юлдан бара кебек иде Хәмидулла. Таң белән йокыга талганда, моңа иманы камил иде. Рәнҗетсеннәр, җәберләсеннәр, яла яксыннар, ә ул таш атканга аш атып яшәвен дәвам иттерәчәк. Намуслы хезмәте белән дошманнарының күңелен дәвалаячак. Башка юлны ул күрми. Бары тик үзе атлап барган авыр, ләкин хак юл гына насыйп аңа...

Ял көннәре генә бераз күңел тынычлыгын бирде, Хәмидулла Җиһангир белән аралашырга, өй тирәсендәге вак-төяк эшләрне башкарырга өлгерде. Баштарак тимер юл төзелешендә булган хәлләрне лагерь тормышы белән чагыштыруына бераз оялып та куйды. Аз булса да, ашарга ризыгы бар, эт белән куып йөртмиләр, якыннары, хатыны янәшәдә. Икенче яктан караганда, лагерь тормышы белән тәңгәл урыннары да җитәрлек. Кешене вата торган авыр хезмәт, кырыс режим. Хәтта агитбригадалар да лагерьныкына тартым – кайвакыт кичләрен халыкны җыеп, ялкынлы докладлар сөйлиләр, соңыннан кечкенә генә концерт куялар.

Дүшәмбе иртәсенә аларны янә атлар белән район үзәгенә илтеп куйдылар, янә бетмәс-төкәнмәс эш көннәре башланды. Форсат чыккан вакытта Хәмидулла Сәкинәдән энесе Сәгыйдулла турында сораштырды. Энесенең исән калуына өмет бар шикелле тоелды аңа. Калганында исә барысы да бер үк төрле. Тачка, таш, ком, көрәк... Көннәр атналарга, атналар айларга ялгана торды...

Шундый бер-берсенә охшаш көннәрнең берсе иде. Дөресрәге, кичке як. Көтмәгәндә, аны прораб чакыртып алды. Хәмидулла ул утырган алачыкка атлады. Алачык төбенә кара айгыр бәйләнгән, аның янәшәсендә тезгенле тагын бер ат. Кара айгыр коеп куйган сыман колхоз рәисенекенә охшаш. Хәмидулла, аңа якыная төшеп, айгырның кушаматын атады:

– Буцефал!

Тегесе шундук колакларын торгызып, зур күзләрен Хәмидуллага төбәде. Авылда бер-бер хәл булмагандыр бит дип шомланды ул һәм адымын кызулатты. Прораб бүлмәсендә, чыннан да, Марфа Петровна утыра иде.

– Хәмидулла Тимерханов сез буласыз бит? – дип сорады прораб.

– Әйе, мин. Исәнмесез, Марфа Петровна.

Марфа Петровна җавап кайтармады.

– Без сезгә ике көн ял бирәбез. Берсекөнгә режим буенча иртәнге якка килеп җитегез. Сез кичекмәстән колхозда кирәк.

– Бер-бер хәл булмагандыр бит, Марфа Петровна?! Нәсимәгә зыян килмәгәндер бит?! Җиһангир исән-саумы?

Марфа Петровна гүя бу сорауларны ишетмәде.

– Минем айгыр янәшәсендә ат бәйләнгән, хәзер шуңа атлан да авылга кайт. Атны колхоз абзарына керт. Мине өеңдә көтеп тор.

Берни аңламаган Хәмидулла урамга чыгып, атка атланды да авылга таба җилдерде. Башында әллә нинди хәтәр хәлләр турында уйлар калкып чыга торды. Тынычланыр өчен догалар укып барса да, бу борчуны җиңү мөмкин түгел иде.

Аның кайтып төшүен күргән Нәсимә нык гаҗәпләнде. Җиһангир да аларда, икесе дә исән-сау. Марфа Петровнаның сәерлекләрен барлап, ниһаять, тынычланды, атны колхоз абзарына тапшырды һәм колхоз рәисен көтәргә утырды.

Караңгы төшкәндә, ишек кагып тормый, рөхсәт сорамый-нитми, бусагадан Марфа Петровна атлап керде.

– Исәннәрмесез, – диде ул. Тавышы никтер бигрәк тә моңсу тоелды.

– Исәнме, Марфа Петровна, уз әйдә.

– Узып тормыйм, – диде хуҗалык рәисе, камчысын бер кулыннан икенчесенә күчергәләп. – Ярдәмең кирәк, Хәмидулла абзый.

– Ни булды, Марфа Петровна?!

– Әни... Гөлниса карчык китте.

– Иннә иләйһи вә иннә лиләйһи рәҗигун...

– Иртәгә әнине күмәбез. Син, Нәсимә, аны мөселманча итеп юып, кәфенлеккә төрерсең. Ә син тиешле догаларын укыйсың, Хәмидулла.

– Яхшы, – соңгы вакытта аны җеназага чакырмыйлар, колхоз рәисеннән куркалар, шуңа да бу сүзләр Хәмидуллага бераз сәеррәк тоелды. Ләкин ул Марфа Петровнаның шаяртмавын белә иде. Шаярта белми бу хатын. – Төнлә баш очында дога укып чыгарга кирәк.

– Җыеныгыз алайса.

– Җеназа укыйбызмы соң?

– Анысы ниткән тагын?

Хәмидулла аңлатып бирде. Марфа Петровна уйга калды.

– Тиеш икән, укыйбыз. Ничек икәнен иртәгә әйтермен. Җыеныгыз, киттек. Әгәр берәрсенә бу хакта берәр сүз әйтсәгез... – Марфа Петровна дәвам итмәде. Боларның беркемгә дә берни дә әйтмәячәген белә иде ул.

...Иртәнге якта Гөлниса карчыкны Нәсимә юып, кәфенлеккә төрде. Өчәүләшеп, ишегалдына алып чыктылар. Капка эчтән бикле иде. Хәмидулла карт, тавыш-тын чыгармый, ялгызы гына җеназа укыды. Аннан соң аларның икесен дә Марфа Петровна бакча ишеге аша озатты. Капканы ачып, урамда өелешкән ир-атларны чакырды. Гөлниса карчыкның ябык, җиңел гәүдәсен күтәреп, халык ашыкмый гына, зиратка юнәлде...

***

Вакыйф Сталинградка килгәч, биредә кичке мәктәпне тәмамлап, трактор заводына эшкә урнашты. Иван Никитичның энекәше Василий ага тыныч, артык сораулар бирмәс кеше булып чыкты. Балалары үсеп, бөек совет төзелешләренә таралган, әллә нигә бер генә кайтып китәләр. Аларга

Василий ага Вакыйфны бүлмә яллап торучы студент дип таныштырды. 1938 елда Иван Никитичның вафат булуын белделәр, ике елдан соң исә Василий аганы да соңгы юлга озатып, Вакыйф кечкенә генә фатирда берүзе калды.

Вакыйфның куллары техникага ятышлы булып чыкты. Аның осталыгы турында завод цехларында хәбәр таралырга өлгерде. Стахановчылар ярышында катнашу өчен дә бригада нәкъ менә аны сайлап алды, фоторәсеме заводның мактау тактасыннан төшмәде.

Эш Вакыйфның тормыш мәгънәсенә әйләнде. Иртән чыгып китә, кич соң гына кайта. Анда-монда сугылып йөрми, хезмәттәшләре белән эштән соң салып утырмый. Эш аңа Таһир кулы белән ботарланган язмышы турында уйланырга вакыт калдырмый. Үзен кызганудан да авыррагы – Зөбәйдәсен искә төшерү. Ул минутларда Вакыйфның йөрәге кысыла, хәле китә. Билгесезлек бик хәтәр нәрсә, ул кешенең күңелендә әллә нинди куркыныч күренешләр тудыра. Зөбәйдәсен Таһир көчләп, үзенеке иткәндер дигән уйны ничә тапкыр куып җибәрергә маташса да, ул һаман җанын агулап торды. Зөбәйдә белән кавышу насыйп булмагач, ул ник ялгызы йөри? Тирә-юньдә булдыклы, чибәр, тырыш егеткә кызыгучы җилбәзәкләр бик күп. Турыдан әйтүчеләре дә, читтән генә күз уйнатучылары да бар. Ул минутларда Вакыйф менә-менә җебеп китәр, Зөбәйдәсенә биргән антына тугры кала алмас төсле тоела. Ташып торган ирлек көчен дә кая да булса куярга кирәк бит. Әнә, цехтагы яшьтәшләре үзләренең кызлар белән чуалышулары турында ничек кызыктырырлык итеп сөйлиләр! Вакыйф кына мондый маҗаралардан мәхрүм. Тик бирешмәде. Бирешергә хакы юк аның. Күңеле сизә – озак елларга сузылган аерылышу барыбер мәңге дәвам итмәячәк. Моның азагы булырга тиеш. Һәм ул соңгы сулышына кадәр бәхетен көтәчәк.

1940 елда Вакыйфны танклар җыючы цехка күчерделәр. Бередә аны шунда ук мастер Максюта үз канаты астына алды. Тәбәнәк кенә буйлы, ямьсез кыяфәтле бу абзый егетнең ялсыз да эшләргә әзер икәнлеген чамалады, булдыклылыгын болай да белә иде. Максюта аны кирәк урында мактап, кирәгендә тиргәп торды. Мактаганда, артык төчеләнеп, селәгәйләрен агызып, егетнең аркасыннан каккалый, тирги башласа исә әче сүгенү сүзләреннән колагың шиңәрлек.

Ике ел эчендә Вакыйф танкларның башня механизмнары буенча иң шәп белгеч дәрәҗәсенә күтәрелде. Ләкин сугыш башланган көннән бирле күңеле монда түгел. Ул яу кырына, чын ирләрчә Ватанын сакларга ашкына. Әмма язмыш аны заводына бәйләп куйды...

Вакыйф фронтка җибәрегез дип гариза язса да, аны әлегә алмадылар. Моның төп сәбәбе – Вакыйфның булдыклылыгы. Алтын куллы хезмәткәрне бригадирының җибәрәсе килмәде. Шуңа күрә мастеры Максюта җитәкчелектән аңа бронь сорады. Моны ишеткәч тә, Вакыйф, чыгырыннан чыгып, бригадир янына ашыкты.

Ул кергәндә, мастер тәмләп, дуңгыз мае ашап утыра иде. Әрекмән яфраклары төсле зур колаклы бу агайның заводта дәрәҗәсе зур. Кеше белән сөйләшә белә, һәркемгә ачкыч табарга сәләтле. Теләсә нинди темага үзе катнашкан берәр очракны сөйләп бирергә әзер. Дөрес, Вакыйф соңрак аңлаганча, Максюта башкаларның бәяннарын да үзләштереп, төрле кешедән

ишетелгәнне «менә мин бервакыт» дип, бик ышандырып шыттыра. Ә, иң мөһиме, ул кешене эшләтә белә. Берәрсен куркытып, икенчесен юмалап, өченчесенә каядыр киләчәктә көтеп торган алтын таулары вәгъдә итеп. Җитәкчелек белән Максюта һәрвакыт мөлаем, кирәксә-кирәкмәсә төчеләнеп мактарга гына тора, андый вакытта аның йөзе май кояшы төсле балкый.

– Иптәш Максюта, ник сез мине фронтка җибәрергә каршы?! – дип бусагадан ук тавышын күтәрде Вакыйф.

Тегесе, бик җитди эшен бүлдергән кешегә караган сыман, Вакыйфка борылды.

– Аңламадым, Трифонов, – диде ул. – Син миңа рәхмәт әйтергә тиеш ләбаса!

– Нәрсә өчен? Башкалар фронтта сугышканда, монда – җылы заводта качып яткан өченме?

– Бер дә юкка кызасың, Трифонов, бер дә юкка. Менә син анда бардың, ди. Сине атып үтерделәр, ди. Синнән илгә нинди файда? Ә биредә шәп итеп танклар җыясың, аңа училищелар бетергән, шуңа махсус өйрәтелгән танкистлар утыра да, та-та-та-та-та... – Максюта мылтыктан аткан төсле итеп бармагын күтәрде дә таталап, төрле почмакларга төрткәләде. – Бетте, фриц капут. Сало ашыйсыңмы?

– Юк, мин... Миңа майлы ярамый. Иптәш Максюта, гафу итегез, фронтка китәр өчен миңа нишләргә кирәк?!

Максюта аңа, беренче мәртәбә күргәндәй, гаҗәпләнеп бакты.

– Бәтәч... – диде ул пышылдап ук диярлек. Аннан сало кисәге салынган ипиен киштәгә куйды да, майлы бармакларын чалбарына сөртә-сөртә Вакыйфка якынлашты. – Менә сиңа мә! Рәхмәт урынына... Мин монда сине эшкә өйрәттем, кеше иттем, урының җылы, паегың бирелә. Ә син?! Менә нәрсә, Трифонов, бу минем карар түгел – Ватан карары. Ватан өчен син хәзер фронтта түгел, биредә кирәк.

Вакыйф, сөйләшүнең мәгънәсезлеген аңлап, башын иеп, цехына чыгып китте. Аннан соң байтак вакыт үтте инде, бәлки, хәзер, немецләр бирегә үк ыргылганда, ул ничек тә булса фронтка китә алыр? Бу өмет аның күңелендә бик көчле. Икенче өмете – туган авылына кайтып, Зөбәйдәсен күрү. Кайчан бу өметләр, хыяллар чынбарлыкка әйләнер икән?! Нигә аның бәхетенә һәрчак Таһир белән Максюта кебекләр комачаулый?!

Таһир – җанын иблискә саткан кеше. Максюта да аның сыңары, үзен завод җитәкчелеге мактасын өчен ни генә эшләми, күпсанлы танышлары аша заводтагы гөрнәдирдәй таза, яшь егетләргә бронь юнәтеп ята...

1942 елның кызу август иртәсе иде. Вакыйф кечкенә генә фатирында уянып китте. Ул тәрәзәдән урамга күз салды. Агач ышыгында зенит пушкалар яшеренгән, солдатлар әлегә йоклыйлар булса кирәк, палаткадан чыкмаганнар. Соңгы вакытта Сталинградка әледән-әле һава һөҗүмнәре ясала, кайбер биналар да җимерелде, мәрхүмнәр дә шактый. Ләкин сугыш каядыр еракта, аларга җитмәс төсле тоела. Шулай да, туплар канонадасы көн дә, төн дә тынмый, аларга таба якынлаша бара.

Вакыйф тиз генә капкалап алды да эшкә кузгалды. Зенитка солдатлары да уянып чыккан, алар карбыз ашап утыралар. Урамда нык эссе, вакыт иртә булуга карамастан, уттай кыздыра.

Трамвай аны Сталинград урамнары буйлап җилдереп алып китте. Әледән-әле бомбага тотылган йортлар очрый, алар хәрабә хәлендә. Бер урында трамвай каршыннан халык төркеме үтеп китте. Букчаларын тоткан хатын-кызлар балаларын ияртkән, кулларына ни эләксә, шуны эләктереп, Идел яры буена эвакуацияләнергә ашыгалар. Ярда шактый кеше җыелган, диләр, аларны ташып бетерергә көймәләр җитми, барысы да фронт кирәгенә дип, армиягә бирелгән. Сул як ярга чыгаруларын көтеп, шунда төн куналар, чират көтү бик озакка сузыла...

Әле анда, әле монда зенитка туплары, көпшәләрен күккә төбәп, дошман авиациясе килгәнне сагалап торалар. Тик, күрәсең, зениткалар саны немесләрнең козгыннарына караганда, берничә мәртәбә азрак, тегеләр әледән-әле шәһәр өстенә снарядлар, ут чыгаручы бомбалар ташлап китә. Һава кызу, бөтен нәрсә дә коп-коры, шуңа биналар, хәтта ташлар да яна башлый...

Завод янына җиткәч тә, Вакыйф төньяктан шартлау, туплар гөрселдәгән тавышларны ишетте. Моңарчы самолётлар һөҗүмен генә күргәнгә, бу бераз сәеррәк иде. Әллә инде Гитлерның коры җир гаскәрләре дә шәһәргә якынлашамы?!

Вакыйфның шиге хак булып чыкты. Алар цехта озак эшли алмадылар. Сирена гүли башлады, ишегалдындагы мәйданга йөгереп чыктылар. Кайдадыр якында гына самолётларның шәһәрне бомбага тотуы ишетелде.

Заводның ополчениесе башлыгы хәрби киемнән, кулында мылтык.

– Кемнәр ополчениедә, бер адым алга! – диде ул көр тавыш белән. Вакыйф башкалар белән атлады. – Обмундирование белән мылтыкларны аласыз да, машиналарга төяләбез!

Алар хәрби кирәк-яраклар сакланган бинага йөгерделәр. Вакыйф үзенең әсбапларын, мылтыгын, патроннарын алды. Моңарчы ополчениедәгеләрне хәрбиләр килеп, ничек мылтыктан атасын, сугышта үзеңне ничек тотарга кирәклеген өйрәтеп киткән иде инде. Күрәсең, хәзер ул белемнәрен чын бәрелештә раслыйсы...

Йөк машиналары аларны төньякка таба алып китте. Шәһәр өстеннән дошман самолётлары әледән-әле очып үтә, бомбалар ярыла, бөтен тирә-юньне кара төтен баскан.

Арбадан коелышып, ополчение әгъзалары, иелә төшеп, хәрабәләр арасына йөгерделәр. Озакламый оборона тотучы совет гаскәриләрен эзләп таптылар, аларга тиз арада окопларда позицияләр алырга кушылды.

Вакыйф сугышка эләкте...

Сталинградның эре заводлары урнашкан районына немесләрнең танкларын һәм пехотасын үткәрмәү өчен аяусыз сугыш башланды. Кызыл армиячеләрнең кораллары җитенкерәми, кешеләре дә санаулы гына. Вакыйфлар ягына таба бүксәсенә свастика таккан авыр танк юнәлде. Ул, туктап-нитеп тормый, совет солдатлары яшеренгән позицияләргә тубыннан ата.

Әле бер якта, әле икенче якта таш өемнәре, алар белән бергә өзелгән кул-аяклар күккә күтәрелә. Тагын бераздан танк окоплар өстенә килеп җитәчәк тә бар нәрсәне тар-мар итәчәк. Вакыйф мылтыгыннан берничә мәртәбә атып караса да, танк өчен бу черки тешләү белән бер иде.

Кинәт ул янәшәсендә генә «Кадалып китегез!» дип кычкырган тавыш ишетте. Окоптагы бер солдат, кулына яндыргыч матдә салынган шешә күтәреп, өскә сикереп менде һәм танкка таба йөгерә башлады. Кайдандыр мылтыктан аттылар. Вакыйф, шунда ук немец пехотачысын күрде. Ул, берни булмагандай, торып ук баскан, винтовкасын танк өстенә баручы солдатка төбәгән. Тешләрен кысып, Вакыйф курокка басты. Немец авып китте, әмма совет солдатына атарга өлгерде. Тегесенең кулындагы шешә чәлпәрәмә килеп, яндыргыч катнашма өстенә сибелде һәм шунда ук солдатны ут ялмап алды. Солдат шашынган кеше сыман икенче кулындагы шешәне күтәреп танкка ташланды.

Вакыйф аның танк астында калуын абайлады. Солдат өстеннән чыгып, танк ары бара бирде. Ләкин солдатка чылбырлар тимәгән, ул, соңгы көчләрен җыеп, җирдә яткан җиреннән исән калган шешәне немец танкының арткы өлешенә томырды. Танкка шунда ук дөрләп ут капты. Ул, бераз гына хәрәкәт итеп, туктап калды. Люк ачылды, кап-кара төтен ыргылып чыкты. Аның белән бергә кара киемле немецләр коела башлады. Чыга барган берсен совет пулялары кыра барды...

Кайсыдыр бер мизгелдә немецләр ягыннан снарядлар белән пулялар сызгыруы тынып калды. Танкларның чылбырлары шалтыраганы гына тынлыкны яра иде.

– Чигенәләр, дуңгызлар! – дип, битендәге корымны сөртеп төшерде Вакыйф янындагы солдат. Аннан фляжкасына үрелеп, йотлыга-йотлыга су эчте, соңыннан Вакыйфка сузды. – Минем исемем Николай.

– Сергей, – Вакыйф солдатның кулын кысты.

– Син молодец, теге немецне бер ату белән аяктан ектың.

– Бераз гына соңардым шул, – диде Вакыйф, окоп аша танк артында яткан солдат мәетенә карап. Ул инде янудан туктаган, каралып калган.

– Әйе, Женяны коткарып булмады. Кызганыч, әйбәт кеше иде, күптән бергә иңгә-иң сугышабыз...

Сөйләшүләрен бүлдереп, көнбатыштан яман көчле гүләү тавышы ишетелде. Шәһәр эчендә тревога сиренасын кабыздылар, ул теге гүләүгә кушылып, әйләнә-тирә мохит әллә нинди бер куркыныч аһәңгә күмелде.

– Тагын авиация, – диде солдат. – Качар өчен берәр урын эзләргә кирәк.

Алар, башка солдатлар һәм ополченецлар белән бергә окоптан чыгып, тирә-юньне күздән кичерделәр.

– Әнә тегендә подвал булырга тиеш, шунда качыйк ,– дип, солдат завод хезмәткәрләрен үзе белән әйдәде.

Һавадагы тавыш көчәйгәннән-көчәя бара. Җир дерелди башлады. Вакыйф башын күккә күтәреп, көнбатышка күз салды. Күргәненнән имәнеп китте. Офык кап-кара, ул Сталинградка таба юнәлгән немец самолётлары белән капланган. Йөзләрчә генә түгел, меңнәрчә самолёт. Һәм һәрберсе шәһәр өстенә үлем алып килә. Бомбалар сызгыруы ишетелде кебек. Аннан көчле шартлаулар яңгырарга тотынды. Җир дер селкенеп куя иде. Вакыйф, сихерләнгән шикелле, бу коточкыч манзараны күзәтә. Шәһәрнең әле бер, әле икенче почмагында ут, кара төтен калкып чыга. Кичке якта баерга җыенып барган кояш күренмәс булды.

– Нишләп торасың, әйдә тизрәк бул! – дип кычкырган тавышка ул әйнып китте һәм подвалга йөгерде.

Ул кичне самолётлар Сталинградны берничә мәртәбә килеп, дулкын-дулкын рәвешендә бертуктаусыз бомбага тотты. Алар үзләренең кара эшләрен тәмамлагач, Вакыйфлар подвалдан чыга алдылар.

Күз алдына килеп баскан күренеш хәтәр иде. Шәһәр юкка чыккан. Бөтен тирә-юньне кара төтен һәм кирпеч тузаны каплап алган. Кая карама – ут ыргыла, август эсселегеннән болай да җебегән асфальт су булып ага. Асфальт кына түгел, Идел суы да яна иде... Яр буендагы ягулык һәм нефть саклагыч цистерналарга тигән снарядлардан алар ярылган, ут капкан сыекча Иделгә агып төшкән. Үзе белән бергә яр буена яшеренгән кешеләрне дә алып киткән...

Шушы көннән Вакыйф өчен солдат тормышы башланды. Аны Николай белән бер ротага билгеләделәр.

– Мәрхүм Женя кебек иптәш булырсың дип өметләнәм, – диде тегесе, бергә хезмәт итәргә тиеш икәнлекләрен белгәч.

Немесләрнең танклары һәм пехотасы санаулы көннәр эчендә Сталинградка килеп җитеп, аны бөтен яктан да камап алды, шәһәр эченә бәреп керде. Шартлы фронт сызыгы атна-ун көн дигәндә, Сталин исемен йөрткән каланың кайчандыр тыныч урамнарыннан, паркларыннан үтә иде.

Сталинград өчен көрәш хәрабәләр арасындагы аяусыз бәрелешләргә әверелде. Дошман, совет гаскәриләрен кысрыклап, аларга Идел яры буйлап сызылган тар гына бер ара гына калдырды. Кайда фронт сызыгы үтә, кайда безнекеләр дә, кайда немесләр – аңлавы кыен иде. Шул хәрабәләр арасында Сталинградтан эвакуацияләнми калган йөзләрчә мең гади халык гомер итә.

Көндез шәһәр калдыкларына немесләр хуҗа булса, төнлә белән – совет гаскәрләре. Люфтваффе көндез генә очарга җөрьәт итсә, совет очучылары төнге караңгылыкны хуп күрә. Идел яр буена яшеренгән «катюшалар» телгә килә, елганың сул як ярыннан авыр туплар эшли башлый. Ике яктан да кешеләр бер-берсенә кургаш, ут, ләгънәт ташкыны яудыра...

Вакыйф ротасының бер өлеше элек биш катлы торак йорт булган бинада оборона тота иде. Ярымҗимерек бина үзенә күрә бер ныгытма-кирмәнгә әверелде. Подвалда ял итәләр, өске катлардан һөҗүм алып баралар. Башны бераз күтәрдеңме – пуля сызгырып үтә. Аннан син немеснең башын төрткәнен көтәсең.

Беркөнне позициядә көтеп ятканда, Николай Вакыйфка төртте:

– Сергей, кара әле, нинди дөя шуыша ул безгә таба?

Вакыйф Николай күрсәткән якка борылды. Ташлар өеме арасыннан совет хәрбие шуышып бара. Аркасына капкачы ябулы зур кәтилүк беркеткән, андыйлар кыр кухняларында ризык ташу өчен кулланыла. Бичара, торып басып атларлык җай булмагач, шундый сәер ысул уйлап чыгарган.

– Бер өркәчле дөя бу, – диде Вакыйф. – Әйдә, Николай, без аңа бераз ярдәм итик, безгә ризык китерә бугай.

Алар икесе дә каршы яктагы йортка төбәп, әледән-әле атарга керештеләр. Ул йортта немесләр ныгытмасы урнашкан иде. Җавап озак көттермәде, теге яктан да кургаш сибелде. Ул арада повар, абалана-йөгерә, Вакыйфлар кулындагы бина эченә керде.

– Уф, җиттем, ниһаять, – диде ул, кәтилүген аркасыннан төшереп. – Кайнар җитмәсә, арканы пешерә.

Вакыйф егетнең урысчаны вата-җимерә сөйләшүен шәйләде.

– Исемең ничек, кайдан син?

– Казаннан мин, Сәетгәрәй булам. Ник сорыйсың?

– Болай гына. Татарга охшагансың, минем сезнең якта дусларым шактый.

– Ә, алай икән. Үзең ни атлы?

– Вак... – чак кына чын исемен әйтми калудан Вакыйфның эченә җылы йөгерде. – Сергей булам.

– Ярый, егетләр, минем монда бер сез генә түгел, кәтилүкләрегезне бирегез дә, ары китәм, – дип Сәетгәрәй зур кәтилүген ачып, солдатларга кайнар аш бүлә башлады.

Ашны бүлеп бетергәч тә китәргә җыенган иде, Николай аны туктатты:

– Иптәш повар, син бернәрсә дә онытмадыңмы?

– Әәә, – дип, кинәт исенә төшергәндәй маңгаена сукты тегесе һәм, елмаеп, кесәсеннән ике пачка махорка чыгарды.

– Шушы гынамыни?

– Ярый, тотыгыз, егетләр, – диде Сәетгәрәй, һәм билендәге сумкасыннан бер шешә аракы күренде.

Соңрак солдатлар моның һәрвакыт кабатлана торган бер уен икәнен аңладылар – тегесен яисә монысын оныткангa сабышса да, барыбер тиешлесен кырып-себереп биреп калдыра иде Сәетгәрәй. Әллә шулай үзенең кәефен күтәрә, әллә солдатларныкын...

Озакламый немесләр совет солдатларының нигә кинәт төш вакытында ут ачуларына төшенделәр. Сәетгәрәй шуышып килгәндә атып аркасындагы кәтилүген тиштеләр. Кайнар шулпага баштанаяк баткан Сәетгәрәй аштан чыккан итле сөяк исләрен аңкытып, алар янына көч-хәл белән килеп җитә алды.

– Гафу итегез, егетләр, – диде ул, тыны кысылудан тотлыгып. Билендәге сумкасыннан аракы шешәсе чыгарды. – Ашарга юк, бүген шушы гына.

– Нишләтәсең инде, – Николай, шешәне әйләндергәләп карап, елмайды. – Шуны, җанкисәккәйне, ашарга булыр.

Көннәрдән бер көнне Вакыйф сәер төркемгә тап булды. Ташлар арасыннан бер рәткә тезелеп, хатын-кызлар, балалар атлыйлар. Араларында карт-коры да бар. Кулларында ак чүпрәкләр. Өс-башлары тузган, кыяфәтләре нык алҗыган, бер ноктага текәлеп, бер-берсенә ияреп баралар да баралар. Шунда таныш йөз күренде.

– Иптәш Максюта! – Вакыйф чак кына башын чыгарды. Максюта, тукталып, тавыш килгән якка борылды. – Монда мин, иптәш Максюта, монда.

Максютаның да кулында ак чүпрәк. Ул як-ягына каранды да Вакыйф яшеренгән бинаның тәрәзәсе янына йөгереп килде. Максюта, башкалардан аермалы буларак, шактый таза күренә иде.

– Трифонов, мондамыни син? – диде ул, нигәдер кабаланып. Исәнләшергә дип кулын сузды, ләкин Вакыйф яшеренгән урыныннан кымшанмады.

– Кая киттегез болай, иптәш Максюта?

Максюта янә як-ягына каранды, аннан пышылдауга күчте:

– Тегендә... Немесләр өлешенә...

– Анда ни калган?

– Анда ризык бар. Безнекеләр ачтан үтерәләр, күрәсең бит, Трифонов, барыбыз да шыр сөяк...

– Ә, аңлашылды алайса... – дип сузды Вакыйф.

Тирә-юнь тыныч иде. Кешеләр төркеме үз юлы белән бара. Аларга атучы юк, димәк, немесләр дә юк. – Йә, ярый, иптәш Максюта, юлыңда бул. Нимес шулпасы тәмле булсын. Егетләр, сатлыкҗанны күрәсегез киләме? – Бу сүзләрне ишеткәч, агарынган Максюта, калтырана-калтырана, кулындагы төенчеген кысып тотты да бая ияреп килгән төркемгә таба кызу-кызу атлап китте.

– Кем ул? – Николай шуышып килеп тәрәзәдән башын тыкты.

– Трактор заводында бергә эшләдек, минем элеккеге мастер. Нимес калҗасын ашарга йөгерә.

Николай төкереп куйды. Кинәт Вакыйфның артына карана-карана абына-сөртенә баручы Максютага карата яман ачуы чыкты. Аның барлык бәхетсезлекләре, күргән михнәтләре өчен җаваплы бәндә нәкъ менә шул мастер Максюта төсле тоелды. Икейөзле, куштан, сатлыкҗан, вак кешеләр, алар үзләренең корсакларын тутыру өчен теләсә нинди адымга барырга әзер, алар туган иленнән дә, теленнән дә, диненнән дә, дененнән дә ваз кичәргә сәләтле. Максюта-Таһирлар басып алган җир йөзендә намус, тугрылык дигән төшенчәләргә урын юк.

– Максюта, сатлыкҗан син! – дип кычкырды Вакыйф һәм урыныннан сикереп торды. Мылтыгын күтәреп, Максютаның аркасына төбәгән иде, курокка басып өлгермәде. Ату тавышы яңгырады, ләкин бу тавыш Вакыйфның мылтыгыннан чыкмады. Икенче мизгелдә аягына, әйтерсең, пычак кададылар. Нык авырту бөтен тәнен өшетеп үтте, әгәр Николай арттан тотып калырга өлгермәсә, башы белән ташларга килеп төшәсе иде.

Аңына килгәндә, ул беренче булып Николайның йөзен күрде.

– Вәт юләр, тапкансың кешесен... Ярый, аяк кына, тиз төзәлер. Алай да, госпитальгә бармый булмас, пуля балтырыңда калган, сөякләреңә чәрдәкләнү ихтималы бар. Төзәлгәч тә, адресны беләсең, – диде ул, иптәшенең хәлен җиңеләйтергә тырышып.

Кичен аны шәфкать туташы килеп алды. Вакыйфны мөмкин булганча саклык белән плащ-палаткага салдылар. Аның инде тәне кызыша башлаган, ул үзе яртылаш кына аңында иде.

– Исемең ничек, кызый? – дип сорады Николай.

– Валя...

– Валя-Валентина... Син безнең иптәшне алып китә алырсыңмы соң? Бигрәк ябык күренәсең үзең.

– Алып китәм, – диде шәфкать туташы усал тавыш белән. – Менә аның урынында син булсаң, җиңә алмас идем, бигрәк симерткәннәр үзеңне!

– Йә инде, ачуланма, мин бит уйнап кына...

– Безгә ашыгырга кирәк, юкса паромга соңга калабыз, ә ул кызыша башлаган. Немесләрне күзәтсәгез яхшырак булыр, – диде Валентина, Вакыйф яткан плащ-палатканың озын башын йомарлап тотып һәм бинадан чыгу ягына юнәлде.

Вакыйф әле аңга килә, әле яңадан нindидер упкынга төшеп югала. Аңына килгән вакытта ул үзен сөйрәп баручы кешене күрә. Томан аша аның

кыз кеше икәнлеген чамалый. Тегесе әледән-әле борылган вакыттаниләрдер әйтә, елмая. Күрәсең, ул аңа бераз түзәргә кушадыр, ярдәм күрсәтеләсе урынга ерак калмагандыр.

Валентина яралы солдатны Идел яры буендагы паром кичүенә алып китереп җиткерде. Аңа шунда ук ярдәмгә ашыктылар, кемнәрдер Вакыйфны ике яктан тотып, паромга алып кереп, идәнгә сузып салдылар. Биредә салкынча иде. Вакыйф чак кына аңына килде бугай. Менә аның коткаручысы да килеп җиткән.

– Бераз гына сабырлык, солдатик, хәзер мин сине табиблар кулына тапшырам, – диде ул, юеш яулык белән Вакыйфның иреннәрен чылатып. Аннан соң корым белән кирпеч тузанына баткан битен сөртеп чыкты.

Паром кузгалды. Ул бик акрын бара. Караңгыда мотор тавышы чак кына ишетелә. Вакыйф үзен бишектә төсле хис итте, йокыга ук тала башлады. Ләкин шәфкать туташы аңа йокларга ирек бирмәде.

– Ярамый, солдатик, ярамый. Сөйләшик әйдә. Синең исемең ничек?

– Вакыйф...– дигәнен сизми дә калды Вакыйф. Тик шәфкать туташы аны аңламады булса кирәк.

– Әгәр авыр икән, сөйләшмә, кирәкми. Безнең табиблар бик шәп, сине «эһ» дигәнче аякка бастырачаклар, бер дә борчылма!

Кинәт яман сызгырган тавыш ишетелде. Паромдагы кешеләр кычкырыша, чабыша башладылар. Нәкъ паром янына мина төшеп ярылды. Барысының да өстенә Иделнең салкын суы чәчрәде. Паромга инде ярга да ерак калмаган, ләкин нимес миномётчылары тынычланырга уйламады. Бер-бер артлы миналарны паром ягына җибәрә тордылар. Берсе кешеләр белән шыгрым тулы паромны суга әйләндереп каплады...

Суга килеп төшкәч тә, Вакыйф тынсыз калды. Аягы бәгырьгә үтәрлек итеп сызлый башлады. Хәзер үлеп китүең хәерлерәк... Хәер, ул паром астында калган бугай, аның өстендә берни дә күренми. Бәхилләшер вакытым җитте дигәндә, аны кемдер кулыннан тотып алды. Нәзберек хатын-кыз куллары иде бу. Шуңа чытырдап ябышып, Вакыйф янә билгесезлеккә төшеп чумды...

Ул госпитальдә аңына килде. Янәшәсендә аны плащ-палатка белән Сталинградтан коткарган кыз утыра иде. Паром астыннан алып чыгучы ул түгелме икән, Вакыйф бит хатын-кыз кулы булуын хәтерли...

– Исәнмесез! Хәлләрегез ничек? – диде теге кыз.

– Рәхмәт, сеңлем, әйбәт...

– Мин Валентина булам. – Кыз аңа кулын сузды. Аның кулын кыскач та, Вакыйф инде бу кечкенә уч табанына тотынып, паром астыннан чыгуына тәмам инанды.

– Мин Сергей.

– Танышуыбызга бик шатмын, Сергей! Аягыгызның сөяге чәрдәкләнгән, төзәлер өчен бераз вакыт кирәк булачак...

– Мин нәрсә, йөри алмаммы инде?!

– Юк-юк, ул кадәр үк зыянлы түгел! Безнең табиблар могҗизалар кылырга сәләтле. Кечкенә генә операция ясадылар. Чатанлап калу ихтималы бар-барын, ләкин ике аякта да басып тора алачаксыз, монысын мин сезгә үзем вәгъдә итәм.

– Рәхмәт, Валентина! Мине коткаруың өчен рәхмәт! Син бит мине су астыннан да тартып алдың, кайдан көчең җитте?

– Эшем шул. Бурычым. – Валентина елмаеп, урындыктан торды да җитдиләнеп калды. – Миңа китәргә кирәк. Янә уң як ярга чыгасы. Мин сезнең яныгызга кергәләп йөрермен.

– Исән-сау гына йөр, сеңлем!

Валентина, чыннан да, еш керә иде Вакыйф янына. Зөбәйдә белән аерылышканнан бирле үзен хатын-кызлар белән аралашудан, хатын-кыз назыннан мәхрүм итеп яшәгән Вакыйфның күңелендә әллә нинди хисләр ташкыны уйнады. Валентина янында ул үзен бала-чага сыман хис итә, кабалана, ялгыш кына кагылып китсә дә, үзен ток суккан сыман була. Валентина җитди дә, шаян да була белә. Акыллы кыз, шул ук вакытта кечкенә генә гәүдәсендә зур көч яшеренгән. Курку белмәс, утка да, суга да керергә әзер икәнлеген Вакыйф үз күзләре белән күрде. Әллә соң бу – Алла тарафыннан аңа җибәрелгән фәрештәме? Әллә күкләр аңа Зөбәйдә белән беркайчан да очрашмаячакларына ишарәлиме, яңа тормыш башларга, бүген һәм хәзер яшәргә, үткәннәргә бәйләнеп ятмаска кушамы?!

Вакыйф акрынлап, госпиталь тирәсендәге бакчага чыгып йөри башлады. Көзнең якынлашуы сизелә, һава суына бара. Сталинград һаман да төти, әледән-әле атышкан тавышлар ишетелә, бомбалар шартлый. Вакыйф, урамга чыгып, шул үлем симфониясен тыңлый. Озакламый аңа янә шул мәхшәргә кайтасы.

Беркөнне алар Валентина белән бергә бакчага чыктылар. Аулак төштәрәк эскәмия табып, шунда утырдылар.

– Хәлең яхшыра бугай, Серёжа, озакламый таякны да ташларга мөмкин булачак, – диде Валя, Вакыйфның күзләренә текәлеп карап.

– Синең ярдәм белән ул, Валя... Минем бер нәрсәне беләсем килә, Валентина. Син барлык пациентларыңның да шулай хәлен белешеп йөрисеңме?

Валя рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

– Әллә көнләшәсеңме?!

– Юк ла инде, – диде Вакыйф, тәмам кызарып чыгып, кулларын кая куярга белмичә кабалана башлады. Валентина исә җитдиләнде һәм аның кулын ике учы белән кысты.

– Юк, Серёжа, барлык пациентлар янына да йөрмим мин. Беләсеңме, син... Син миңа ничектер якын, үз кеше шикелле...

– Син дә, Валечка...

Алар икесе дә сүзсез калды, аяк асларыннан нидер эзләгән булып, карашларын шунда төбәделәр. Көтмәгәндә Валентина аңа борылды, ике куллап, Вакыйфның ике яңагыннан сак кына тотты. Вакыйф күзләрен йомды. Үзенең иреннәрендә Валентинаның кайнар иреннәрен тойды. Куллары кызның нәфис билләренә үрелде. Ул Валяны нык итеп күкрәгенә кысты. Шулкадәр назлы иде кызның иреннәре. Аның буй-сыны һуш китәрлек сылу иде. Вакыйф бөтен тәне кызышып китүен тойды. Куллары, аны да тыңлап тормый, шәфкать туташын иркәләргә кереште. Валентина туктатмаса, моның ни белән бетәсен чамалавы авыр түгел. Ләкин ул, кинәт Вакыйфтан читләшеп, эскәмиядән торды һәм өс-башын рәтләде.

– Гафу ит, Серёжа, миңа китәргә вакыт. Янә уң як ярга чыгасы.

– Кайчан кайтасың?

Валентина, чак кына иелә төшеп, Вакыйфның колагына пышылдады, ул хәтта аның сулышын тойды:

– Кич белән. Мин үзем синең яныңа килермен, бер дә борчылма.

Вакыйф йокыга талган иде инде, кемдер аның битен йомшак кына назлауны тоеп, сискәнеп уянды. Күзләрен ачып җибәргәч, ул берара караңгылыкка күнегә алмады. Янәшәсендә Валентина басып тора иде.

– Әйдә, минем белән, тавыш кына чыгарма, – диде ул, Вакыйфның колагына пышылдап.

Кайнар сулыштан егет йөрәге ешрак тибүен тоемлады. Ул акрын гына торып утырды. Валентина, кулын җибәрми генә, аны үзе белән әйдәде. Бер аягында сикерә-сикерә, аны-моны аңышып җитмәгән егет шәфкать туташына иярде.

Валентина госпитальдәге бер кечкенә бүлмәгә алып керде, ишекне бикләде. Аннан, борылып, Вакыйфны иреннәреннән үбеп алды. Вакыйф карыша алмады. Икесе дә калтыраналар, куллары бер-берсенең тәннәрен назлый. Беразга гына үбешүдән аерылып, Валентина өстендәге гимнастёркасын җәһәт кенә салып ташлады. Аның астында берни дә юк иде. Вакыйфның да күлмәген салдырды. Вакыйф кызның кечкенә генә, як-якка тырпаеп торган күкрәк очларына иреннәре белән үрелде. Валентина ләззәттән еш-еш сулый иде. Вакыйфның куллары кызның бәдәннәренә төште. Санитарканың тән исе аны тәмам шашындырды. «Ә туган авылыңда сине, вәгъдәсенә тугры булып, Зөбәйдә көтәдер», – дигән уй башына әллә кайдан гына килеп керде. Ул сөйгәне белән булган беренче төнне, аннан соңгы сөйләшүне капылт кына исенә төшерде.

Егет кулларын кызның биленнән алды, күлмәгенә үрелде, Валентинага карамый гына аңа гимнастёркасын сузды. Валентина, хәтере калып, гимнастёркасы белән шәрә күкрәкләрен каплады.

– Ни булды сиңа, Серёжа? – диде ул, елар хәлгә җитешеп. Аның күзендә гаҗәпләнү белән бергә бик зур үпкә катыш иде.

– Гафу ит, Валентина, мин болай эшли алмыйм, – Вакыйф кызның күзләренә карамаска тырышты. – Минем вәгъдә биргән хатыным бар, ул мине өйдә көтә. Сәбәп синдә түгел, бары тик миндә генә...

– Серёжа, син бит өйләнмәгән, мин синең шәхси эшең белән дә кызыксындым... – Валентина калтырана-калтырана, гимнастёркасын кияргә кереште.

– Әйе, шулай. Ләкин безнең... Безнең вәгъдә ул законлы никахтан да зуррак көчкә ия...

Валентина тавыш-тынсыз гына елый иде. Ул, киенеп, өс-башын рәтләде, ишек келәсен ачты.

– Яткан урыныгызга үзегез барып җитә алырсыз дип өметләнәм, иптәш Трифонов, – диде тимер тавыш белән Валентина, һәм, күз яшьләрен сөртеп, коридор буйлап җил-җил атлап китте... Шуннан соң Вакыйф аны бүтән беркайчан да күрмәде...

Вакыйф таяксыз йөрергә тәмам өйрәнеп килә иде инде. Бер көнне иртән аның койкасы янына табиб белән ике хәрби килде. Урыныннан сикереп торып, Вакыйф хәрбиләргә честь бирде.

– Утырыгыз, утырыгыз, – диде майор, аннан кулындагы кәгазьләргә күз төшерде. – Трифонов Сергей Иванович?

– Әйе, мин.

– Стройга кайтырга әзерме сез?

– Әзер, иптәш майор!

Сүзгә НКВД вәкиле кушылды.

– Ничек итеп яралануыгызны хәтерлисезме? – диде ул, шулай ук кәгазьләр актарып. – Ничек итеп сезнең мылтыктагы пуля үзегезнең аякка ук килеп керә алды? Монысын аңлата аласызмы?

– Юк ла инде, иптәш капитан! Мин тыныч халык белән бергә нимесләр ягына чыгучы бер танышымны күреп алдым...

– Һәм ул сезгә үзе белән качарга тәкъдим итте...

– Юк! Мин аны атып үтермәкче булдым, ә шул вакытта нимесләр теге яктан минем аякка...

– Йә, җитәр, капитан, – диде майор, НКВД вәкиленә усал караш ташлап. – Трифоновның сөйләгәне аның иптәшләре биргән аңлатмалар белән тәңгәл килә, күрмисезмени? Безгә сугышчылар фронтта кирәк, ә Трифонов үзен бары тик уңай яктан гына күрсәтте. Сез, иптәш Трифонов, трактор заводында танклар җыюда катнашкансыз, шулаймы?

– Нәкъ шулай.

– Характеристикада башня механизмын яхшы беләсез диелгән.

– Әйе, мин аны энәсеннән җебенә кадәр өйрәндем.

– Яхшы, безгә танкистлар бик кирәк. Иртәгә иртән әйберләрегезне җыеп килерсез.

Сөйләшү тәмам икәнлеген аңлатып, хәрбиләр папкаларын шап итеп яптылар да госпитальдәге башка авырулар янына юнәлделәр. Вакыйф әле генә булган сөйләшүне аңларга маташып, койкасына утырды. Аны янә сугыш көтә иде. Сугыш – хыял түгел, ләкин омтылыш. Бер омтылышы тормышка ашты. Ә икенчесе белән ни булыр? Ул Зөбәйдәсе белән очраша алырмы? Болай да сызлап торган йөрәгенә кан саркытып, күз алдына үпкә тулы карашы белән Валентина сурәте дә килеп басты...

***

1942 ел көзгә авышканда, авыл өстенә үлем өрәге килде. Әйтерсең, сугышта гына һәлак булганнар җитмәгән, аннан читтәгеләрне дә аямый җыярга кереште.

Көзнең инде җирләр ката башлаган суык иртәсе иде. Хәмидулла, гадәттәгечә, колхозчылар белән бергә олауларга төялеп юлга кузгалды. Үтеп барышлый, ул контора тәрәзәсендә ут шәйләп алды. Марфа Петровна кара төнгә кадәр эштә кала, әлбәттә, ләкин бу вакытка кадәр утырганы юк кебек иде. Олауларны туктатып, Нәгыйм картны ияртеп, Хәмидулла конторага ашыкты. Күңеле нидер сизде. Марфа Петровнаның соңгы вакытта йөзендә нур калмады, көне-төне эчүдән ул тәмам эштән чыкты.

Хәмидулла ялгышмады. Колхоз рәисен йөзтүбән өстәленә яткан килеш табып алдылар. Аның авызыннан кара кан агып чыккан. Күзләре акайган, чәчләре тузган.

Районнан килгән тикшерүчеләр мәетне алып китеп, ярып карагач, авылга

хәбәр таралды – Марфа Петровнаның бавыры беткән, ашказаны да эштән чыккан, шуннан үлгән икән. Кызыл комиссарны зур дәрәҗәләр белән район үзәгендәге зиратка җирләгәннәр.

Таһирларның нык итеп салынган өенә йозак салынды. Колхоз рәисе итеп исә Фазылҗанны билгеләделәр. Фазылҗан, өстенә мондый бәхет ишелеп төшкәч, башта ышанмыйчарак торды, аннан соң, кинәт ничектер икенче кешегә әйләнеп, колхоз эшен үтә бер тырышлык белән алып бара башлады. Аның мөнәсәбәтен, әмерләрен, кыланмышларын күргән халык әле озак вакыт дәвамында мәрхүмә Марфа Петровнаны сагынып искә алдылар...

Хәмидулла да сагына иде Марфа Петровнаны. Ләкин ул аның мәрхүм булуына риза иде. Кая барып бәрелергә, алга таба ничек яшәргә белмәгән, чарасызлыктан интеккән кеше өчен үлем, бәлки, бердәнбер котылу чарасыдыр. Ходай да аны артык озак интектермәскә, үткәннәрнең өрәкләре белән бимазаламаска карар кылгандыр. Марфа Петровна яманлыкны да кылды, яхшылыклары да бар иде. Кайсы бизмәнгә күбрәк өлеш чыкканын бер Алла гына белә. Һәрхәлдә, адашкан кызның җан тынычлыгы өчен ул һәрвакыт дога кылды...

Төзелештә исә нәтиҗәләр күренә. Хәмидуллалар эшләгән участокка рельслар да салынып килә. Күрәсең, Казанга якынрак өлештә эш бетә, бу тирәдә тир түгүчеләр саны арта бара. Алар янәшәсенә дә яңа кешеләр алып килделәр. Дөресрәге, башта төзелештән бер читтәрәк аннан-моннан каккалап барак сыман, яртылаш җиргә баткан биналар төзелде. Аннан соң баганалар утыртылып, ул бараклар чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынды. Бер чатта сак хезмәте каланчасы да калкып чыкты. Барысы да әзер булгач, машиналарга төяп, бер төркем кешеләр китерелде. Озакламый юл төзүчеләр арасында хәбәр таралды – болары лагерь тоткыннары икән, немеслардән дә хәтәррәк кешеләр, шуңа аларны тимерчыбык артында гына тоталар. Тоткыннар төркеме аерым урында, кораллы сак астында эшли.

Хәмидуллаларның бригадасы тоткыннарга якын ук килеп җитте. Тоткыннар дәшмиләр, башларын иеп эшлиләр. Өстән мылтыклы солдатлар иренеп кенә күзәтеп тора. Солдатларсыз булмый – качып китүчеләр шактый.

Хәмидулла, билемне языйм дип киерелеп, тоткыннар эшләгән якка күз салды. Кинәт аңа ниндидер таныш йөз күренде кебек. Текәлебрәк карады. Бөкрәйгән, карачкы хәленә калган кешене ул кайдадыр күргән төсле иде.

– Эрнест, – диде ул кинәт үз-үзенә. Аннан траншеядан өскә күз салды. Сакчы солдат күренми иде. – Эрнест!

Бүреге астыннан аксыл чәчләре күренгән тоткын аңа борылды. Бу – Беломорканалдан Хәмидулла ярдәме белән азат ителгән Эрнест иде. Картайган, кипкән, ләкин йөзе барыбер аныкы. Шул ук ягымлы, усаллыкның әсәрен белмәгән чалымнар. Һәм шул ук елмаю.

– Хәмидулла абый! – диде ул, бу очрашуның һичшиксез булачагын белеп яшәгән кеше сыман бер дә гаҗәпләнмичә. – Исәнме, Хәмидулла абый!

Алар, эшләрен ташлап, килеп кочаклаштылар.

– Зур рәхмәт сиңа, Хәмидулла абый, шушы көнгә кадәр сиңа рәхмәт сүзләрен әйтә алмый яшәдем бит! – диде егет, ихлас елмаюыннан берничә елга яшәреп киткән сыман булып.

– Нәрсә өчен, Эрнест?

– Ипи өчен, сабак өчен. Без чыгып киткәч, Николай миңа барысын да сөйләде бит. Син булмасаң, миңа ирекне күрәсе юк, күптән сөякләрем череп ятар иде.

– Тик, син кабат лагерьда түгелме соң?

– Лагерьда, – егетнең йөзеннән елмаю качты. – Алай да, дүрт ел иректә йөреп калдым. Утыз җиденче елда янә кулга алдылар. Хәзер күнегелде инде, сиңа рәхмәт, монда кире кайтканчы сәламәтлек тә азмы-күпме ныгыды. Бу вакыт лагерьда яшәгәч үлмәм инде мин. Срогым тулу белән кайтарырлар.

– Ничек ярдәм итим мин сиңа, Эрнест?

– Ничек дип, – Эрнест, уңайсызланып, елмаеп куйды. – Тоткынга ни кирәк икәнлеген үзең беләсең. Бераз кием, бераз ризык. Шырпы ярап куяр иде. Монда артыгы кирәкми.

– Әй, сез, икәү, нишлисез анда?! – Өстәге солдат янә үз урынына килгән иде.

Хәмидулла тачкасына тотынды, Эрнест та эшкә кереште.

Икенче атнада авылдан чыгып киткәндә, Хәмидулланың төенчеге гадәттәгедән күпкә зуррак иде. Анда Вакыйфтан калган чалбар, күлмәк, бишмәт, бияләйләр, Нәсимә булган кадәренчә әзерләгән ризык ята. Боларның барысын да ничек тә булса Эрнестка тапшырасы.

Төзелеш участогына барган шәптә Хәмидулла куе чыршылар белән капланган уйсулыкны күргән иде. Йомышлыйсы бар дигән булып, ул колоннадан бераз артка калды, төенчеген шунда яшерде. Кичтән аны алып Эрнестка тапшырасы гына.

Тоткыннарга якынаю җае төш вакытларына гына мөмкин булды. Хәмидулланы күрү белән Эрнест та аңа табарак авышты. Алар бер-берсенә карамый, эшне туктатмый пышылдап кына сөйләшеп алдылар.

– Иртәгә кичке аштан соң барактан чыга аласыңмы?

– Җидедән соң була.

– Мине тимерчыбыкның бу якка якынрак урынында көтәрсең, – диде Хәмидулла, һәм, тачкасын тотып, баштанаяк эшкә чумды.

Кич җитте. Эш тәмам икәнлеге игълан ителде. Төзелештәгеләр, озын чиратка тезелеп, кайнар аш алырга әзерләнделәр. Хәмидулла исә, башкаларга белгертмәскә тырышып, акрын гына теге агачлыкка таба китте. Аннан төенчекне табып алды. Караңгы иде. Хуҗалык корылмалары тирәсендә генә ут яна, тоткыннар яшәгән бараклар дөм караңгыда утыра, бары ике төштә генә солдатлар учак тергезгән. Монысы әйбәт, аны беркем дә күрмәс.

Хәмидулла ач икәнлеген дә онытты. Ул баракларга таба атлады. Чәнечкеле тимерчыбык янына килгәч тә, бер багана артына аркасы белән елышып утырды. Көтәргә кирәк.

Ниһаять, кыштырдаган тавышлар ишетелде. Хәмидулла караңгыда кемнеңдер аңа таба килүен абайлады.

– Эрнест! – диде ул, пышылдап.

– Мин, – дип җавап кайтарды Эрнест.

Хәмидулла тимерчыбык аша кулындагы төенчекне сузды. Ялгыш эләгеп китеп, тимерчыбык аның кул аркасын шактый тирән итеп тырнап узды, кан агып чыгуын ук тойды ул. Ләкин кулын төшермәде. Теге яктан төенчекне кабул итеп алдылар.

Хәмидулла Эрнестка әллә нинди җылы сүзләр әйтәсе иде, егетнең күңелен күтәрерлеген тапмады.

– Рәхмәт! – диде егет, пышылдап кына һәм баракка таба атлады. Аннан кинәт Хәмидуллага таба борылды. – Алла чыннан да бар икән ул. Алла булмаса, без кабат очрашмас идек. Син, бәлки, аның фәрештәседер...

Хәмидулла да урыныннан торды.

– Туктагыз! Атам! – дигән тавыш аны сискәндереп җибәрде.

Учакларның берсе яныннан ике солдат аларга таба йөгерә иде. Бер-бер артлы ату тавышлары яңгырады. Халык ашап утырган яктан хатын-кызлар чырылдавы ишетелде. Хәмидулла Эрнестның гөрселдәп җиргә ауганын күреп калды. Икенче мизгелдә нindidер кайнар әйбер аның да күкрәгенә килеп керде. Авызыннан шаулап кан бәреп чыкты. Хәмидулла мулла, соңгы тапкыр чиксез галәмгә күз салды да җиргә барып төште.

Трассадагы гадәттән тыш хәл хакында хәбәр иткәч, Григорий Афанасьев шунда ук ТАССРның Эчке эшләр буенча халык комиссары Абдулла Габитовка шалтыратты.

– Исәнмесез, Абдулла Гыйсмәтуллович! – диде ул, комиссар белән үзен тоташтыргач та.

– Исәнме, Григорий Давыдович!

– Безнең трассада күңелсез хәл килеп чыкты әле...

– Әйе, миңа хәбәр иттеләр. Нинди тәкъдимнәр бар?

– Артык тавышын чыгармаска иде. Болай да күңелсез вакыйгалар шактый.

Халык комиссары дәшми торды, аннан көр тавышы белән:

– Григорий Давыдович, ничек әйтсәгез, шулай хәл итәрбез, бер дә борчылмагыз, – диде. Аннан инде рәсми булмаган тонда: – Сугыш барысын да тигезләр... – дип өстәде.

Габитовтан соң Шакир Әхтәмов белән сөйләшеп алдылар. Мулланың мәетен кичекмәстән туганнарына бирергә килешенде. Алар инде райкомга килеп тә җитәргә өлгергән икән. Әхтәмов мәрхүмнең туганнарын тынычландырырга сүз бирде. Ике кешенең гомере өзелү бернинди аерым рапортларга да кертелмәде, аларны җитештерү белән бәйле рәвештә вафат булганнарның озын исемлегенә өстәп куйдылар да оныттылар...

...Хәмидулланы бөтен авыл белән күмделәр. Фазылҗан ничек кенә өркетмәсен, мулла белән бәхилләшми беркем дә ул көнне төшкә кадәр эшкә чыкмады. Җеназа намазын урамда бөтен ир-атлар катнашында укыдылар. Мулланы җирләгәч тә, Нәсимә, Зөбәйдә һәм Җиһангир әле бик озак зират өстендә тордылар. Кичке якта өйгә кайткач та, елаудан шешенеп беткән Нәсимә кызын кочаклап алды.

– Беркемгә дә рәнҗемик, кызым, – диде ул. – Барчасына да риза-бәхиллегеңне бир. Бүгенге догаларын гафу үтенү дип кабул ит. Язмыштан узмыш юк, алар да, без дә гаепле түгел. Әтиең һаман түзем, сабыр, кичерүчән булырга өндәде, аның сүзләре – безгә васыять ул. Бернигә дә карамастан, Ходай биргән кадәр гомерне барча булган көчеңне эшкә җигеп яшәргә кирәк, дия торган иде. Онытма шул сүзләрне. Безгә яшәргә кирәк...

1942 елның кара көзендә тагын ике Язмыш Китабы язылудан туктады. Тагын ике җан күккә ашты...

***

Григорий Афанасьев киеренке шартларда эшләп, үзе дә нык үзгәрде. Йомшаклык күрсәтү төзелеш планнарын үтәмәүгә китерергә мөмкин. Эш урыныннан качып китүчеләргә карата суд органнарыннан мөмкин кадәр кырыс карарлар чыгаруны үтенде. Нәтиҗәдә үлем җәзасына хөкем ителүчеләр саны күбәйде. Качкыннар төркеме берничә кешедән торганга, берсен башкаларга сабак булсын дип аталар, калганнарына ун елга кадәр срок өстиләр. Мондый катгый чараларсыз эш бармаячагын аңлый иде Афанасьев. Җитмәсә, Мәскәү аңа беренче составларны сентябрь аенда ук җибәрү максатын куйды. Алты ай эчендә төзеп чыгасы иде тимер юлны!

Август башында, туктаусыз дезертирлык, эш урыныннан качып китү очраклары артуга тәмам гарык булып, Афанасьев Казанга кораллы сак хезмәте башлыгы Дмитрий Шишовны, Зөя аерым лагерь пункты начальнигы Бронислав Кацнельсонны һәм сак комиссары Сергей Шерстнёвны чакыртып алды. Бу сөйләшүгә төне буе әзерләнгәнгә күрә, йөзе талчыккан, хәрбиләр белән дә кул биреп тормый гына исәнләшеп, турыдан эшкә күчте.

– Иптәшләр, мин сак хезмәтеннән канәгать түгел! – диде ул каршындагы офицерларга. – Быелның 1 апреленнән 1 августына кадәр вакыт арасында лагерьдән 52 тоткын, эш урыныннан 234 мобилизацияләнгән немес качып китте. Моны ничек аңлатырга?! Барысын да тотып бетерә алмадыгыз, кайда йөргәннәре билгесезләр дә шактый.

Афанасьев, тәмәкесен кабызып, һавага төтен болыты җибәрде. Хәрбиләрнең дә тартасылары килә дә бит, мондый шартларда ярамый...

– Дүртенче отряд командиры Красильниковны кайсыгыз яхшы белә?

– Мин, – дип, кыяр-кыймас кына тавыш бирде Шишов.

– Аның булдыксызлыгы аркасында 34 кеше качып китә алган. Миндә Красильниковның эш вакытында эчеп йөрүе турында да рапорт бар! – Афанасьев кызганнан-кыза барды. – Красильниковны эштән алырга, кораллы сак хезмәтеннән куарга!

Афанасьев Зөя лагерь пункты начальнигы Кацнельсонга борылды:

– Сезнең лагерь пунктында да тәртип юк! 9 качу очрагы теркәлгән. Дивизион командиры Лабушевны эшеннән алырга!

– Иптәш майор, Лабушев... – дип, сүз башлаган иде Кацнельсон, Афанасьев аңа дәвам итәргә мөмкинлек бирмәде.

– Лабушевыңны әлегә бүлекчә командиры итеп билгели аласың. Тагын берәр шелтә чыкса, аны да куабыз! – Афанасьев кулына машинкада бастырылган кәгазьләрне алды. – Мин боларның барысын да хәл итеп, боерык чыгардым. Сез аның белән соңрак танышырсыз. Сак хезмәтен казарма хәленә күчерәсез, контингент янында булсыннар. Бу тәртип тоткыннарның һәм немесләрнең качып китүләре беткәч кенә гамәлдән чыгарылачак. Колонналарда тентүләрне көн саен үткәрергә кирәк. Һәрберсеннән тиешле форма буенча акт төзелергә тиеш. Немесләр моңарчы үз эшләре буенча сорап китә алалар иде, хәзер монысы да тыела. – Афанасьев янә хәрбиләргә карады. – Үзләре генә гаепле. Кибеткә дә җибәрә идек, анысына да, монысына да. Ләкин кадерен белмиләр, хайваннар. Гаеп бездә дә бар – торыр урыннарының рәте юк, бетләп беткәннәр. Монысын да төзәтергә кирәк булыр.

Хәрбиләр, барысын да аңлауларын белдереп, урыннарыннан тордылар

һәм кабинеттан чыгып киттеләр. Афанасьев исә әле озак кына үзенең боерыгы турында уйланып утырды. Шөрепләрне кысарга туры килә, кешечә мөнәсәбәтне нимесләр аңламый, күрәсең. Кырын сүзләр дә сөйлиләр. Шуңа күрә апрель аенда Афанасьев вәгъдә иткән ирекле «хезмәт армиясе» килеп чыкмый. Ирексезләп, хәрбиләрнең штыклары астында эшләтергә туры киләчәк...

Әлбәттә, хәрбиләр кайвакытта артыгын да кылаланалар, чөнки һәрбер «дошман» өчен аңа бүләк бирелә, званиеләре күтәрелә. Август аенда, мәсьәлән, төнлә белән Чувашиянең Татар Согыты авылы янында бер хатынны эләктерәләр. Тегесенең өстендә әллә кемнән калган гимнастёрка була. Үзен ул Анна Егорова буларак таныштыра. Сыеры көтүдән кайтмаган, шуны эзләргә чыккач, караңгыга калуын аңлаткан теге мескене. Тик аңа беркем дә ышанмый, хәрби киеменә ишарәләп, нимесләр тарафыннан махсус җибәргән шымчы дип игълан иттеләр. Анна Егорова өстеннән кыска вакытлы тикшерү үткәрелде. Ахыр чиктә ул үзенең гаебен тануын раслаучы документка кул куя. Танылган гаеп – дәлилләрнең патшабикәсе дигән гыйбарә ул елларда иң көчлесе иде. Егорованы Җинаять кодексының 58 маддәсендәге беренче пункт нигезендә хөкем иттеләр. Ул контрреволюцион эшчәнлек алып барып, хакимиятне бәреп төшерергә маташучы буларак танылды. Егорова этап буенча ун елга китеп барды, ә аны эләктергән НКВД сакчысы Николай Подлазовка премия яздылар.

Мондый мисаллар Афанасьевның күз алдыннан бик күп үтте. Дөресен әйткәндә, майор үзе тирә-юньне шулкадәр дошман басып алгандыр дип уйламый да. Ләкин каршы әйткәне юк. Система һәркемне дә бертөрле фикер йөртергә өйрәтә, әгәр аңа каршы чыксаң, «гадел хөкем» тегермәне үзеңне дә «эһ» иткәнче тарттырып, көлеңне җилгә очырачак.

Дезертирлык очраклары, башка төр хокук бозулар махсус контингент арасында күп булганга, хөкем чыгару конвейерга куелды. Моның өчен Волжлаг эшләре буенча ТАССР Югары Судының аерым сессиясе оештырылды. Карарлар тиз һәм камерадан чыкмый гына кабул ителә торды.

Төзелеш эшләре тәмамланып килгән вакытка Афанасьевның махсус контингенты исемлеге шактый сыегайды. Кемнәрдер төрле чирләрдән һәм авыр хезмәттән җан тәслим кылган, кемнәрдер атып үтерелгән. Аларның каберләре сафка басып килүче тимер юл читендә тезелеп кала бирделәр.

Сентябрь аенда Зөя станциясеннән Ульянга таба беренче составлар кузгалды. Мондый зур вакыйганы үз күзләре белән күрер өчен ТАССРга артык зур тавыш кубармый, яшертен рәвештә диярлек Нафталий Френкель үзе килде. Афанасьев аны бик нык куркып каршы алса да, Френкель нәтиҗәдән канәгать калды. Составлар хәрәкәтен ачарга мөмкин иде. Дөрес, кайбер участокларда тиешле эшләрнең соңгы этаплары тәмамланмаган, алардан сәгатенә 30 чакрым белән генә барып була. Тик бусы артык куркыныч түгел, поездлар җибәрү белән беррәттән дә эшләргә мөмкин.

Френкель килеп киткәннән соң озак вакыт үтмәде – Григорий Афанасьев белән бергә тагын тугыз кешегә Ленин ордены бирелү хакында хәбәр иттеләр. Рокада төзелешендә аеруча зур тырышлык күрсәткән 7 кеше – Хезмәт Кызыл Байрагы, 21 кеше – Кызыл Йолдыз, 117 кеше «Мактау билгесе» орденнары белән бүләкләнде.

Бүләкләр белән бергә төзелештә дә зур үзгәрешләр башланды. Кирәге калмаганга күрә, Ульяндагы лагерь пункты һәм андагы базаны яптылар. Барлык материаллар Зөя бистәсенә күчерелде. Трассадагы техниканы, төзелеш материалларын да шунда ташыдылар. Колхозчылар гадәти хезмәтләренә кайтты. Акрынлап, эшелоннар белән сөрелгән немесләр, лагерь контингентын Себергә, илнең башка төзелешләренә җибәрә тордылар. НКВД сакчылары да бер-бер артлы отряд-отряд белән башка лагерьларга күчерелә торды.

Тимер юлга якын-тирә авылларда яшәүчеләр каядыр ашыккан составларны шаккатып күзәтеп тордылар. Эшелон-эшелон танклар, солдатлар, туплар, цистерналар алар яныннан сызгырып узып, көньякка таба ашыга. Сугыш кырында булмасалар да, шушы төзелештә эшләп, Сталинградта немесләрне җиңүгә үзләре дә зур өлеш кертkәннәрен аңлыймы икән алар? Юктыр, үзләрен ул дәрәҗәдә батырлык кылучылар дип санамыйлардыр. Ә чынында исә нәкъ менә шул ябык кешеләр, сөялле куллар, ныгырга өлгермәгән үсмерләрнең фидакарьлеге Совет армиясенә дошманны тар-мар итеп куып җибәрергә мөмкинлек бирде. 1941 елда ТАССР җирләре аша сузылган бу юлның әһәмиятенә тарихның бәясе алда иде әле. Ә хәзергә... Хәзергә төзелештә норманы 200-300 процентка арттырып үтәгән кешеләргә бирелгән мактау грамоталары гына бар. Шул катыргы кәгазьгә ихлас күңелдән шатланалар. Аны, башлары сау булса, онықларына күрсәтергә дип, сандык төбенә үлемтекләр астына яшерәләр.

Эшелоннар көнчыгышка ашыга. Вагоннар ыңгыраша, көпчәкләр рельсларга бәрелеп, моңсу гына бер көй чыгара. Һәр чакрымы тир генә түгел, кан коеп төзелгән бу юлның. Ул чакрымнарда түгел, кеше гомерләре белән исәпләнә. Бирелән үтә калсагыз, догаларыгызны онытмагыз. Алар шушында мәңгелеккә күчкән әрвахлар рухына ирешеп, бакыйлыкта җаннарына тынычлык бирә күрсен иде...

***

1942 елның азагында Нанси тирәсендә немесләргә каршылык күрсәтү көчәя барды. Әледән-әле колоннарларга һөҗүм итү, комендатураларга ут төртү турындагы хәбәрләр ишетелә торды. Сәгыйдулла хәлләрнең нык киеренке икәнлеген шәһәргә кереп тулган гестапо вәкилләренең күплеген күреп, яхшы аңлый иде.

Төннәрен Гыйльмулла Франсуаның улы белән бергә каядыр китеп югала. Күрәсең, немесләрнең йокысын качыруда аларның да өлеше бардыр – таң белән генә йончылып, арып кайтып керәләр. Франсуа белән Сәгыйдулланы ул төнге сәяхәтләргә чакырмадылар, алар әледән-әле самолётлардан йөк кабул итүгә генә бергә йөрделәр. Йөк төшереләсе урыннар алмаштырыла торды, аларны алыр өчен утардан дистәләрчә чакрым араны үтәргә туры килә. Шуңа да карамастан, Сәгыйдулла барлык кушканны да карусыз үтәп барды. Немесләр белән көрәшкә үзеннән өлеш кертүен ул күңеле өчен бер рәхәтлек белән кабул итә иде.

Ул төнне Гыйльмуллалар янә каядыр чыгып китеп, таң белән генә кайтып керделәр. Сәгыйдулла ишек артындагы шау-шудан уянып, гомуми бүлмәгә чыкты. Андагы күренештән эсселе-суыклы булып китте. Бүлмәдәге диванда

Франсуаның улы Поль ята, бөтен дөньясы канга баткан. Гыйльмулла да әллә яралы, әллә Польның канына гына буялган, ләкин кыяфәте бик нык таушалган кешенеке иде.

Сәгыйдулла Франсуа белән бергә егетләргә ярдәмгә ашыкты. Табак белән җылы су алып килделәр, Польның яралы кулын юдылар. Гыйльмуллага пуля тимәгән, ә менә Польның кулындагы сөяк чәрдәкләнгән.

Поль тешен кысып булса да, түзде. Франсуа аңа француз телендә үзе генә белгән җылы сүзләрне туктаусыз кабатлый, үзе, яраны спирт белән эшкәртеп, бәйләргә кереште. Аннан соң улын йокы бүлмәсенә алып китте – өйдәгеләр әле егетнең яраланганы хакында хәбәрдар түгел, күрәсең.

Гестапо таң белән килде. Сәгыйдулла башта машина тавышларын, аннан эт өргәнен ишетеп, ишегалдына чыкты. Утар янына туктаган йөк машинасыннан кара киемле кораллы кешеләр сикерешеп төшә. Һәммәсенең дә фуражка кокардасы өстендә кешенең баш сөяге, аның астында урталай кисешкән кул сөякләре. Җиңел машинадан озын пәлтә кигән офицер чыкты.

– Тентергә! – дип боерды ул. – Барысын да кулга алырга! Берсен дә калдырмагыз!

Гестапочылар әмерне үтәргә ашыкты. Алар утарны урап алдылар, кайберләре өй эченә кереп китте. Бер солдат килә-килешкә Сәгыйдулланы җиргә сугып екты. Сәгыйдулла йөзтүбән килеш ятып калды.

Җирдә яткан урыныннан ул өйдәгеләрне урамга бер-бер артлы чыгарганнарын күрде. Аңа да торып басарга кушылды. Аларны өсте ябулы машинага таба алып киттеләр. Кинәт Гыйльмулла, атлаган җиреннән басуга таба йөгерергә кереште. Шунда ук немесләр автоматларын аңа таба төбәделәр, ләкин офицер атмаска әмер бирде.

Гыйльмулла басуга таба чаба. Немесләр, әмер көтеп, автоматларын аның аркасына төбәп, басып тора бирәләр. Качкынны куарга әзер торган этләрне хуҗалары көч-хәл белән авызлыклый. Кемнең дошман икәнлеген каян беләләр, диген?!

Ник йөгерде Гыйльмулла? Качып котыла алмаячагы билгеле бит. Күрәсең, сорау алырга барганчы үлү хәерлерәк дип хәл иткәндер.

Немес офицеры ашыкмый гына кобурасыннан пистолетын чыгарды, бер күзен йома төшеп Гыйльмулланың аркасына таба төбәде һәм атып җибәрде.

Йөгереп барган җиреннән абынып, Гыйльмулла җиргә барып төште. Немес, аның мәетеннән күзен дә алмый, пистолетын кире кобурага куйды.

– Алып килегез! – диде ул, һәм ике гестапочы мәет ягына йөгереп китте.

Сәгыйдуллалар утырган машина арбасына Гыйльмулланың да мәетен кертеп салдылар. Кечкенә генә колонна Нанси шәһәренә кузгалды.

– Нигә Берлиннан монда күчтегез? – дип сорады гестапо офицеры, кичке якта камерадан Сәгыйдулланы сорау алу бүлмәсенә алып килгәч.

– Берлинда мин эшләгән сыраханәгә бомба төште. Мин эшсез калдым.

– Эшкә кем урнаштырды?

– Гыйльмулла Әбҗәлилов. Без аның белән әле Берлинда вакытта ук белеш идек.

Гестапочы каршындагы кәгазьләргә күз төшереп алды.

– Яшерен оешмадагы ролегыз?

– Мин яшерен оешмада булмадым...

– Кем булды алайса?

– Белмим... Миңа аны-моны әйтүче юк иде...

– Рация кайда?

– Нинди рация?!

– Шундый. Син нәрсә башыңны юләргә салып утырасың?! – Нимес җикеренмәде, гаҗәеп дәрәҗәдә тыныч иде.

– Салмыйм. Белмим мин.

– Яхшы, алайса хәтереңне яңартырбыз. Густав!

Ишектә озын буйлы юан нимес пәйда булды, әйтерсең, чакырганны гына көтеп торган.

– Тыңлыйм, герр штандартенфюрер!

– Тынычлап гәпләшегез әле бу кеше белән. Франциядә яшәп, нимес телен оныта башлаган.

– Яхшы, герр штандартенфюрер!

...Нимеснең үзенә бер генә тапкыр сукканын хәтерли Сәгыйдулла. Аннан соң ни булганын сизмәде, дөм караңгылыкка чумды. Бер сәгатьтән соң аның аңсыз гәүдәсен камерага кертеп аттылар.

Ул аңга килгәндә, янәшәсендә, авызын сулы чүпрәк белән чылатып, бер ир кеше утыра иде. Сәгыйдулла тәне изелгән төсле авыртуын тойды. Ул үзе бөтен барлыгы белән бер авырту тирәнә әверелгән сыман. Теге адәм, аның күзләрен ачуын күргәч, елмаеп куйды:

– Исән, – диде ул, пышылдап. – Мин Изя булам.

– Сагди.

– Яһүдме?

Сәгыйдулла татар икәнлеген әйткәч, Изя, «зыян юк», дигән сыман, янә бер елмаеп куйды. Соңрак кына Сәгыйдулла бөтен камера да бары тик яһүдләр белән шыплап тулганлыгын белде. Биредә картлар да, яшьләр дә утыра. Яһүдләр бүтән камераларда хатыннары, кызлары, хәтта нарасый балалары да утыруын сөйләделәр. Аларны беркем дә кыйнамый, әйтерсең, нимесләр нидер көтә.

Өч көннән соң аларны Нанси буйлап, сак астында вокзалга алып киттеләр. Тар урамнарны тутырып барган озын халык ташкынында, чыннан да, хатын-кызлар да, карт-коры да, буе тездән артмаган балалар да бар иде.

Товар вагонына тыгызлап кертеп утырттылар. Аның бер почмагында идәндә йомыш йомышлау өчен ясалган тишектән гайре берни дә юк иде. Поезд, халык белән тулгач, акрын гына кузгалды. Салкын вагон бер-ике сәгатьтән кешеләр тәне һәм сулышы хисабына бераз гына җылынды кебек.

Бераздан салкын кайгысын ачлык, аннан да бигрәк су булмау басып китте. Поезд кайбер урыннарда туктый, ләкин вагоннарны ачмыйлар. Урамда көнме, төнме – белерлек түгел.

Бер көн чамасы баргач кына, ниһаять, поезд туктаган вакытта вагон ишеге ачылды. Нимес солдаты, кинәт караңгы вагонга ыргылып кергән яктыдан күзләре чекерәйгән тоткыннарга карап алды да вагонга бер чиләк су, бер әрҗәгә салынган икмәк куйды. Аннан, нәрсә оныттым соң дип, озак кына уйланып торганнан соң, җирдән иелеп алып, кружка ташлады. Икенче нимес, автоматын әзерлектә тоткан хәлдә, арттарак күзәтеп тора иде.

Алар, үзара көлешеп, тәмәке тарта-тарта вагондагыларның башта ризык

һәм су өчен чәкәләшкәннәрен, аннан соң, нindidер тәртип салынып, чиратлашып кружка белән чиләктән су эчкәннәрен, ипи алып вагон төбенә китеп югалуларын күзәтеп тордылар. Соңыннан буш чиләк, әрҗә һәм кружканы кире алып, вагонны шартлатып бикләп куйдылар.

Икмәк арыштан гына тормавын Сәгыйдулла яхшы сизде. Аңа йомычкалар да, тагын әллә нинди катнашмалар да кушылган бугай. Шуңа күрә ач карынга үзенә тәтегән ипи кисәге авыр таш сыман төшеп утырды. Бер кружка белән генә көне буе җыелган сусауны басарлык түгел иде.

Икенче көнне бер станциядә тукталгач, ишектә күренгән нимес солдаты:

– Үлекләр бармы? – дип сорады.

– Бар, – дигән җавап яңгырады.

– Чыгарыгыз!

Бер-бер артлы өч мәетне перрон читенә сузып салдылар. Сәгыйдулла аларның ничек һәм кайчан үлгәнен белми дә калган икән. Янәшәдә генә кеше җан биреп яткан, ә ул моны сизмәгән дә... Хәер, мондый шартларда кешелеклелек дигән нәрсә онытыла шул. Һәркем үз җанын саклап калу турында гына уйлый, башкаларның моң-зарына саңгырау бәндәгә әверелә. Нимесләрнең бөтен системасы нәкъ менә шуңа – ачлык аша, тамак кайгысы аша кешене кол хәленә калдыру, җан асраудан кала бүтән берни турында да уйланырга мөмкинлек бирмәүгә нигезләнгән.

Эшелон көнчыгышка таба шактый вакыт барды. Көннән-көн салкынрак, вагондагы халыкның җылысы да ярдәм итми. Сөякләргә кадәр үтә суык. Нансида кыйналудан сызланган яраларга каһәр суккан суыгы да өстәлә!

Ничә көн барганнардыр – чутын югалтты Сәгыйдулла. Шунысын гына белә: юлда очраган станцияләрдә платформа читендә аларның вагоныннан унбиш кеше мәете ятып калды. Шулай акрын гына кырылып бетәрләрме икән?!

Сәяхәтләре көтелмәгәндә тәмамланды. Поезд чираттагы тапкыр туктагач, ишекләр ачылды һәм караңгыдан СС гаскәре офицеры шәйләнде.

– Барыгыз да вагоннан чыгыгыз! – дип кычкырды ул. – Чыгыгыз тизрәк!

Халык ташкыны ишеккә ыргылды. Сәгыйдулланы кысып алдылар, тыны киткән төсле булды, ләкин, ахыр чиктә, ул да ирекккә чыкты.

Үзәккә үтәрлек салкын, өстән яңгыр сибәләп тора. Каяндыр прожектор нуры килеп чыгып, перронга коелган тоткыннарны ялап үтте. Аларга тизелеп басарга куштылар. Колоннаны ике яктан муеннарына мылтык аскан СС гаскәриләре уратып алды. Араларында эт иярткәннәре дә бар иде.

СС офицеры ашыкмый гына рәтләр буйлап атлап китте. Ул бирегә килгәннәрне, әйтерсең, өйрәнә, төс-кыяфәтләрен истә калдырырга тырыша. Кинәт ул бер тоткын янында туктады.

– Исемең?

– Танхум.

– Кайдан?

– Франция.

– Кайтасың киләме?

Танхум, урта яшьләрдәге яһүд ир-аты, ни дип җавап бирергә дә белми, офицерга текәлде. Тегесе аннан күзен дә алмый җавап көтә иде.

– Килә, әлбәттә, – диде ул, ниһаять, кыяр-кыймас кына.

– Килсә, бар, чаба-чаба кайт. – Нимес кулы белән караңгылыкка ишарәләде. Танхум кымшанмады. Нимес тагын да усалрак итеп кабатлады. – Чап дим, алдыңа-артыңа карама! Аңламадыңмы әллә мине?!

Танхум капшанган төсле адымнар белән колоннадан чыкты. Мылтыклы СС солдаты аңа юл бирде. Офицер Танхумның колагына ук:

– Йөгер! – дип кычкырды.

Тегесе, куркуыннанмы, шунда ук атылып чабып та китте. Офицер, ике кулын артка куеп, аңа карап калды.

Танхум ерак китә алмады. Аны караңгылыктан прожектор уты эләктерде. Теге юл биргән нимес солдаты, автоматын күтәреп, шатырдаттырып атып җибәрде. Танхум мәтәлеп китте.

Колоннада үле тынлык урнашты.

– Тагын кемнәрнең кайтасы килә?! – дип, бөтен колоннага мөрәҗәгать итте нимес офицеры. Йөзендәге елмаюы «шәп шаярту булды бу, әйеме» дигән төсле тоелды. – Рәхим итегез, басу киң! – Аннан җитдиләнде. – Колоннадан чыкканнарны ни көткәнен күрдегез. Башыгызда бераз акыл бардыр дип өметләнәм. Кузгалдык!

Алар перрон буйлап киттеләр. Ерак ара үтмәделәр, колонна янә тукталды. Алда, перронның теге башында кешеләрне ике төркемгә бүләргә керештеләр. Карт, авыру кыяфәтле, көч-хәл белән аягында басып торганнарны сул якка, нык күренгәннәрен уңга җибәрәләр. Сәгыйдулла перрон читендә үк торган өстәл янына килеп җитте. Өстәл янында бер нимес нәрсәдер теркәп утыра, икенчесе аягүрә килеш аны баштанаяк күзәтә.

– Исемең?!

– Сәгыйдулла Тимерханов.

– Милләтең?!

– Татар.

– Татар?! – дип гаҗәпләнеп, башын күтәрде теге нимес.

– Әйе, мин татармын. Шундый милләт бар.

– Кайдан?

– Нанси, Франция.

– Һөнәрең бармы?

– Һөнәрсез мин... Төрле эшләрдә эшләүче.

– Туган елың?

– 1895.

Нимес янәшәсендә торган иптәшенә күтәрелеп карады. Тегесе, ияге белән генә ымлап:

– Уңга, – диде. Сәгыйдулла төркемгә барып басты.

Перрон өстендә сулкылдаган, елашкан тавышлар гына торды. Күрәсең, бер-беренә теге яки бу яктан туган булган кешеләр икесе ике төркемдә калгандыр. Елашкан тавышка яман авыр ис өстәлә иде. Сәгыйдулла аның төтен икәнлеген аңлап алды. Ул төтендә сөяк, ит, чәч янган исләр бергә буталган, ул ис борынның сизгерлеген түгел, җанны әрнетә иде.

Поездан килүчеләрне ике төркемгә аеру тәмамланды. Сул якка күчерелгәннәрне СС солдатлары караңгылыкка алып кереп киттеләр. Алар китеп югалгач та, Сәгыйдуллалар төркеме дә кузгалды.

Кешеләрне алып бара торган биналар ерактан ук шәйләнде. Аннан-

моннан электр утлары белән яктыртылган корылмалар шактый булуын күрде Сәгыйдулла. Күрәсең, биналарны чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алганнар.

Аларның юлы куркыныч ерткыч авызы сыман ыржаеп торган биек капкага кереп югала иде. Капка үзе биек башня астында. Әле анда, әле монда коралны СС солдатлары. Алар капка өстендә дә, корылмалар тирәсендә караеп торучы каланчаларда да торалар. Прожекторлар якынлашып килүче төркемне әледән-әле ялмап ала. Эт өргән тавышлар ишетелә.

Капка аларның колоннасын үзенә йотты. Ярымкараңгылыкта Сәгыйдулла капка башына тимер хәрефләр белән язылган «Хезмәт ирекле итә» дигән сүзләрне укырга өлгерде.

Чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган зур гына бер мәйданда ике катлы таш биналар тезелеп киткән. Ерактарак озын морҗа күренә. Аннан кап-кара төтен чыга. Сәгыйдулла яман иснең шуннан килгәнлеген аңлады. Ис биредә бигрәк тә авыр һәм бөтен тәнгә сыланучан иде. Кичекмәстән юынасы килеп китте.

Аларны янә тезеп бастырдылар. Күзләренә прожектор яктысы китереп бәрде, мондый яктылыкка күнегер өчен бераз вакыт кирәк иде.

Тоткыннар каршына СС вәкилләре тезелеп баскан. Чак кына читтәрәк күсәк тоткан берничә кеше тора. Аларның түшләрендә кара өчпочмакларны абайлап була.

– Биредә басып торучы һәркем – Бөек Германиянең кан дошманы. Сез һәммәгез үзегезнең кылган гамәлләрегез белән Рейхка һәм Фюрерга зыян салдыгыз. Хәзер җәза алу вакыты килеп җитте. Сез Аушвицта! Биредән качып котылырбыз дип уйламагыз. Моннан чыгу өчен бер генә юл бар, – СС офицеры кара төтен чыгып торучы биек морҗага төртеп күрсәтте. – Әгәр берәрегез качарга маташса – үлем! Кушканны үтәмәсә – үлем! Рейхка каршы эшчәнлек алып барса – үлем! Чәнечкеле тимерчыбыктан югары көчәнешле электр энергиясе үтә, шуңа күрә аңа артык якынаймаска киңәш итәм. Ләкин Рейх сезнең шикелле җансыз җанвар түгел. Әгәр дә үз хезмәтегез белән гаебегезне тануны исбатлыйсыз икән – без моның өчен тиешле әҗерен бирәчәкбез.

Сүзе тәмам дип, СС офицеры күсәк тоткан кешеләргә әмер бирде. Тегеләре, йөгереп килеп, кешеләрне аралый, колоннаны аерым төркемнәргә бүлә башладылар. Һәрбер төркемгә йөзәр кеше чамасы кергәндер. Аңламаган, ни эшләргә белмәгән кешеләрнең аркасына агач күсәк төшә иде.

Төркемнәр бер-бер артлы тәбәнәк кенә таш бинага кереп югала торды. Сәгыйдуллаларга да чират җитте. Ишек төбендә анадан тума чишенеп, киемнәрне зур капчыкларга салып калдырасы. Бинага үткәч тә, стеналары акшарланган бүлмәгә эләгәсең. Анда өстәл артында нимес утыра. Ул үзенә таба борылып басарга кушты. Карашы белән, әйтерсең, Сәгыйдулланы капшап чыкты. Оят җирен куллары белән капларга маташса да, нимес, җикеренеп, тик кенә торырга әмер бирде.

– Яһүдме?! – диде ул, Сәгыйдулланың билдән түбән җиренә ишарәләп.

– Юк...

– Нигә соң алайса...

– Мөселман мин, бездә шундый гореф-гадәт...

Нимес өстәлендәге кәгазьләргә төртелде, нидер теркәде, нидер язды, аннан соң Сәгыйдуллага ак чүпрәккә төшерелгән номерны һәм кызыл өчпочмак сузды.

– Алга таба атла, – диде ул, икенче бер тоткынга, игътибарын күчереп.

Икенче бүлмәдә аның башын кырыктылар. Станоклары тупасланып беткән, берничә урында җәрәхәт калды. Күрше бүлмәдә түбәдән агып торган салкын су белән коенгач, Сәгыйдулла үзенең бик нык туңуын тоеп алды.

Ниһаять, аңа концлагерь тоткыны формасын бирделәр. Буй-буй булып төшкән зәңгәрле-аклы киемнәрдән алар барысы да бер-берсенә охшап калдылар.

Алар кебек үк киенгән, кулына кызыл чүпрәк бәйләгән бер кеше Сәгыйдулланы, каты гына сүгенеп, үзе янына чакырды. Алар бер егермеләп кешелек кечкенә төркемгә тупландылар.

– Мин капо булам, сезнең блоктагы җитәкчегез! – диде кызыл чүпрәкле адәм. Аның күкрәгендә кара өчпочмак беркетелгән – җинаять өчен хөкем ителүе билгесе. Хәтта салынып торган кием астыннан да Сәгыйдулла капоның нык беләкләрен, күсәген әйләндергәләгәндә бүртеп чыккан мускулларын күреп алды. Кечкенә ялтыравык күзләр, тирәнгә батып, бер-берсенә бик якын урнашкан. Маңгае ике бармак киңлегендә генә. Кыркылган башында бүртеп-бүртеп чыккан сөякләр. Ияге явыз этнеке төсле алга чыгып тора. – Минем исемем Болеслав!

Капо, көтмәгәндә, бер тоткынның тез артына күсәге белән китереп сукты, тегесе йөзтүбән килеш җиргә барып төште.

– Мине игътибар белән тыңламыйсыз икән, күсәгем дә, үзем дә нык, барыгызны да шушы хәл көтә, – диде ул, пычракта ятучы тоткынга күрсәтеп. – Ә хәзер минем артымнан атлагыз!

Аларны блокка алып килделәр. Зур булмаган караңгы бүлмә, ике яклап икешәр катлы агач ятаклар тезелеп киткән. Кайбер урыннар буш.

– Буш урыннарга ятыгыз! Иртәнге якта номерларыгыз һәм төсле чүпрәкләрегез тегелгән булсын! – дип, әмер бирде капо.

Ятакларда тоткыннар икәүләп йоклыйлар иде. Сәгыйдулла үзе генә яткан бер кеше янына барып утырды. Яңа гына киелгән агач аяк киеменә чыдарлык түгел – аны салгач та, хәл керде сыман.

Яңа килгәннәргә барактагылар инә белән җеп табып бирделәр. Тоткыннар чиратлашып номерларын, теге яки бу җинаять өчен утыруларын искәртүче өчпочмакларны тегеп куйдылар. Яһүдләрнең өчпочмак урынына алты почмаклы йолдыз иде: аларның җинаяте – дөньяга яһүд булып туудa...

Сәгыйдулла каты ятакка менеп ятты. Аның баш очында янәшәсендәге тоткынның аяклары. Алай боргаланып карады, болай – нәзек кенә тар матрас сыман әйбер җәелгән ятакта әллә ни уңайлы рәвеш табып булмады. Баш астына өске киемнәрен салды, алар эченә бик яхшылап, кәтилүге яшерелгән иде. Сәгыйдулла изрәп йоклап китте.

Күзен генә йомган төсле иде, чаң каккан тавышка сикереп торды. Ишектә инде Болеслав басып тора. Йокысыннан айный алмаганнарны күсәге белән суккалап уята. Тиз-тиз киенеп, кәтилүген кулына алып, Сәгыйдулла идәнгә төшеп басты. Аның белән бергә йоклаган күршесе, шыр сөяккә калган

бәндә, башта урын-җирне рәтләде, аннан соң «менә шулай кирәк» дигән кыяфәт белән Сәгыйдуллага усал караш ташлады.

Юыну бүлмәсендә стенага чисталыкның әһәмияте турында плакатлар эленгән. Краннан сасы су ага, теленә тидереп карамакчы иде, әлеге дә баягы күршесе туктатып калды.

– Ярамый, – диде ул, – суны эчәсе булма – үләчәксең.

Урамда әле караңгы иде, иртәнге салкыннан чирканчык алып, Сәгыйдуллалар янә блокка кайтты. Беренче кергәндә, монда ачы тир исе, тагын әллә нинди исләр күңелне болгатса, төн дәвамында борыны күнеккән, искә игътибар итмәде.

Ике тоткын зур бак күтәреп керде, калганнар баскан төштән кәтилүкләрен, банкаларын аңа таба суздылар. Бактан көрән төстәге сыеклык салалар иде. Сәгыйдулла эчеп карады – болганчык сыеклыктан кофега охшаш тәм килә. Барысы да шул «иртәнге аш» белән тамак ялгадылар.

Аннан соң аның тормышында, башка тоткыннар белән беррәттән, озын, очы-кырые күренмәгән, бер-берсеннән берничек тә аерылып тормаган көннәр башланды. Плацта тезелеп басу, капо җитәкчелегендә эш урынына бару, әбәт көтү, янә эш...

Блоктагы кешеләр алмашына тора. Кемдер госпитальгә киткән җиреннән кире кайтмый, кемнеңдер үлеген йә эш урыныннан, йә блоктан сөйрәп чыгарып, крематорийга илтеп ягалар. Озын морҗалы мич бер генә көнгә дә, бер генә төнгә дә туктамый, яна да яна...

Бер көнне Сәгыйдулла да ялгыз калды – күршесендә яткан тоткынны госпитальгә алып киттеләр. Ул аннан кайтмады. Әллә башка блокка күчергәннәр, әллә җан тәслим кылган – монысы караңгы калды.

Кичен, инде йокларга яткач, аның янындагы буш урынга икенче бер кеше килеп ятты. Моның бер генә яңалык булырлыгы юк – биредә кешеләр алмашына тора, шуңа күрә Сәгыйдулла аңа әйләнеп тә карамады. Кинәт ул теге бәндәнең нидер пышылдаганын ишетте. Тукта, безнең телдә түгелме соң?! Сәгыйдулла торып утырды һәм күршесенә күз салды.

– Син кем буласың? – диде ул.

Күршесе, татарча эндәшкәннән шулай ук гаҗәпләнеп, башын күтәрде:

– Мин кемме? Бер кеше. Сиңа нәрсәгә ул?

– Минем исемем Сәгыйдулла. – Ул милләттәшенә кулын сузды.

– Таһир, – диде тегесе сагайган тавыш белән.

– Кайдан буласың?

– Советлар иленнән. Солдат мин. Элеккеге солдат. Син дә солдатмы?

– Юк, мин эмигрант.

– Ә, аңлашылды. – Күршесенең тавышында мыскыл чалымнары сизелеп яңгыраса да, Сәгыйдулла моңа игътибар бирмәде.

– Совет иленең кайсы ягыннан? Авылданмы, шәһәрдәнме?

– Авылдан.

– Кайсы авылдан?

Таһир дигән кеше авылының исемен атагач, Сәгыйдулланың тыны кысылды.

– Син... Без... Без авылдашлар бит, энекәш!

Күршесе дә сәкедән аякларын салындырып торып утырды. Сәгыйдуллага текәлеп карады, ләкин йөзендә шатлыкның әсәре дә юк иде.

– Син кем малае, энем?

– Солтан малае. Әнием Гөлниса.

– Ә, алай икән... Солтан абыйны хәтерлим, Гөлниса апаны да күргәләгән бар. Мин авылдан яшьли чыгып киттем бит.

– Ә син кемнәр нәселеннән.

– Тимерхановлар. Хәбибрахман мулланың төпчек малае мин.

Таһир дәшмәде.

– Йә, сөйлә инде, энем, авыл ничек яши?! Мин бит унҗиденче елдан бирле үзебезнекеләр турында берни дә белгән юк. Абый исәнме, гаиләсе ничек? Мәчетебез ни хәлдә? Коммунистлар бик каты золым китергән дип ишеткәнем генә бар, безгә дә ул афәт җилләре тидеме?

– Тиде. – Таһир башын иеп, идәнгә текәлде. – Байларны Себергә сөрделәр. Синең абыеңны да алар белән бергә. Мин сугышка киткәндә, ул кире кайтты, белмим, ни хәлдәдер хәзер. Мәчетне яптылар, манарасын кистеләр. Бездә генә түгел, бөтен җирдә дә шулай булды.

Сәгыйдулла бөкшәеп төште.

– Абыемның хатыны Нәсимә, кызы Зөбәйдә ни хәлләрдә?!

– Бик әйбәт хәлләрдә, аларны сөрмәделәр бит. Бер коммунист Зөбәйдәгә гашыйк булып йөреп, аларны коткарып калган, диделәр. Аннан соң Зөбәйдә бер угры-карак белән зина кылып, бәбигә узды. Мулла кызы дип тә тормады... Менә шулай, Сәгыйдулла абый. Йоклыйк әйдә, төн кыска, вакыт тар. – Таһир сузылып ятты.

Сәгыйдулла, тетрәнүдән айный алмыйча, әле бик озак уйланып утырды. Менә бит дөнья! Җитмеш катлы катланган, ниләрне генә күрсәтми!

Иртән күршесенең әллә ни сөйләшәсе килмәде, Сәгыйдулла әле алай, әле болай мөрәҗәгать итеп караса да, Таһир ничектер сөйләшүне башлаганчы ук кырт кисеп өзә торган булды.

Плацка чыгып тезелеп бастылар. Гадәттәге СС солдатлары төркемендә Сәгыйдулла таныш йөзне күреп алды. Ахырзаман диярсең! Күзләрне камаштырырлык СС офицеры формасында төз атлап, чак кына елмаеп, плац буйлап Ганс атлап бара. Сәгыйдулла нишләргә дә белмәде. Рәтләрдән чыгып кычкырырга ярамый – капоның моңа мөнәсәбәте ничек буласын Алла гына белә. Нишләргә?!

СС хәрбиләре төркеме алар тирәсендә туктады. Ганс, үзенә нидер сөйләгән немеснең сүзләреннән шаркылдап көлде дә каршына тезелгән тоткыннарга борылды. Сәгыйдулла белән Гансның карашлары очраштылар. Ганс, елмаюдан туктамый, капоны дәшеп алды һәм кулындагы жезлы белән Сәгыйдуллага төртеп күрсәтте. Шундук йөгереп килеп, Болеслав аны башкалар арасыннан этеләп-каккалап чыгарды.

Ганс, кулларын артка куеп, аның янына килде.

– О, Сагди! – диде ул, барлык тешләре дә күренерлек итеп елмаеп. – Сәяси тоткын! Рейхка каршы явызлык кылдыңмы?

– Мин, Ганс...

– Герр штурмбанфюрер! – дип кырт кисте Ганс.

– Герр штурмбанфюрер, мин монда ялгышлык, яла ягу аркасында эләктем, Рейх алдында бер гаебем дә юк.

– Монда бөтен плац гаепсез кешеләр белән тулган. Ярый, үз урыныңа бас.

Ганс, СС солдатлары янына кире барып басып, капо Болеславка нидер әйтте дә, алар ары киттеләр, тоткыннар төзелеш эшләренә таралыштылар.

– Нәрсә әйтте ул сиңа?– дип сорады Таһир Сәгыйдулладан.

– Берни дә әйтмәде.

– Сине кайдан белә?

– Без бергә эшләгән идек. Берлинда.

Кичен блокка кайткач, Сәгыйдулланы Болеслав дәшеп алды. Алар, блок биналарыннан арырак китеп, СС корылмалары урнашкан якка юл тоттылар.

Ганс аны кечкенә генә кабинетта каршылады. Ишектән кергән һәрбер кешегә портреттагы Гитлерның усал карашы текәлә. Сейф, кәгазьләр белән тулган шкаф, уртада өстәл, аның янында, аякларын өстәл өстенә күтәреп куеп, Ганс утыра. Формасының изүләре ычкындырылган, бер кулында хәмер салынган бокал, икенчесендә – тәмәке. Ул капога чыгып торырга, ә Сәгыйдуллага утырырга кушты, аннан, аякларын төшереп, урындыгына җайлабрак утырды.

– Салыйммы? – диде ул, шешәгә ишарәләп.

– Юк, рәхмәт, мин эчмим, беләсез бит.

– Син Нансига ничек килеп эләктең?

– Фридрих... Ул үлгәч. Аның... Безнең сыраханәгә төнлә бомба ташладылар. Миңа бүтән чара калмагач, чыгып киттем инде.

– Синең документларда Франциядәге каршылык отрядларында катнашуың әйтелгән. Бу дөресме?

– Кая дөрес булсын инде, герр штурмбанфюрер! Мине беләсез бит, чебенне дә кыерсытканым юк! Бәлки, мин ялланып эшләгән кешеләр катнашкандыр, анысы миңа билгесез. Ләкин мине гаепсезгә кулга алдылар.

– Мин барыбер суд түгел, акланмасаң да була. Минем биредә, лагерьдан ерак түгел, кечкенә генә йортым бар. – Ганс бокалына хәмер өстәп, эчеп җибәрде, өстәлдән колбаса кисәге алып кабып йотты. – Аша син дә берәр кисәкне. – Ганс канәгать кыяфәттә елмайды. Аннан дәвам итте. – Менә шул йортны карап торырга ышанычлы кеше кирәк. Мин сиңа шунда йөреп хезмәт күрсәтергә тәкъдим итәм. Яшәвең блокта, көнең миндә үтәчәк. Ризамы?

– Зур рәхмәт, герр штурмбанфюрер! Мондый игелек көтмәгән идем! Ләкин бер үтенеч әйтергә мөмкинме?

– Әйтеп кара.

– Тагын бер кешене үзем белән алсам ярыймы?

– Нәрсә, тагын яшерен оешма төземәкче буласыңмы? – Ганс, кинәт усалланып, ике кулы белән өстәлгә терәлеп, торып ук басты, аннан, Сәгыйдулланың чын күңелдән курыкканлыгын күргәч көлеп җибәрде. – Кем ул?

– Хәрби тоткын, Россиядән. Авылдаш ул минем...

– Номеры?

Сәгыйдулла Таһирның номерын әйтте.

Тагын ике көннән алар Таһир белән икәүләп, Гансның йортына барып эшли торган булдылар. Иректә, ватмый торган хезмәттә үзләренә күзгә күренеп җан керде. Таһир аңа рәхәтләнеп, авыл турында матур әкиятләр

сөйли башлады. Аны, әйтерсең, алмаштырып куйдылар, ул Сәгыйдулланың һәрбер сүзен тыңлый, һәрбер соравына җавап бирә. Элеккеге салкынлык бөтенләй дә юкка чыкты. Чөнки Таһир яхшы аңлый иде – лагерьда исән калу өчен аңа Сәгыйдулла янәшәсендә булу кирәк. Һәм ул үз гомерендә инде ничәнче мәртәбә йөзенә яңа битлек тартып киеп, язмыш аңа биргән рольне уйнарга кереште.

– Мәчетне ничек юк иттеләр, Таһир? – дип сорады аңардан бер көнне Сәгыйдулла, ял алырга дип утыргач.

– Үзебезнең авыл кешеләре кисмәде манараны, күрше районнан алып килделәр залимнәрне. Түбәсенә менеп, балта белән каезлап бәреп төшерделәр.

– Халык дәшмәдеме?

– Монда ник дәшмиләр соң? Мылтык көпшәләре терәп куйгач, каршы әйтеп буламыни?!

– Кызганыч... Хәмидулланы да яклаучы булмадымы?

– Хәрбиләр килеп алып китте. Якын килерлек түгел иде.

– Мәхәллә кем кулында хәзер?

– Кем дип... Районнан эчә торган бер усал марҗаны китереп куйдылар...

– Бөтен авылдан кеше табылмадымыни?

– Юк. Коммунистларга бирешүче, аларны яклаучы табылмады.

– Алай икән... Бабамның, әтиемнең, абыемның вәгазьләре бушка китмәгән икән... Әйдә, Таһир, торыйк, эш көтә.

Һәм Сәгыйдулла, көрсенеп, урыныннан торып китте.

Ял көнне алар мәйданга чыгып, башка блоктагылар белән аралаша, алып-сату итә алалар. Таһирның бу көнне аеруча көтеп алуын сизенде Сәгыйдулла. Ул, Гансның өенә баргач, әле бер нәрсә, әле икенче әйберне эләктереп кайта да, биредәге «базарда» икмәккә, башка кирәк-яракка алмаштыра. Баштарак Сәгыйдулла иптәшенең бу гадәтен ошатмады. Бер әйтеп карады, ике. Ләкин Таһир аны тыңларга да уйламый:

– Менә бер кадак кыстырып чыктым. Аннан бу СС дуңгызының кайсы төше кителеп төшә? Яисә берничә бит кәгазь. Вак-төяк әйберләр, ул аларны бар дип тә белми. Миңа исә бу җан асрар өчен кирәк, ачтан үлмәскә. Ник син дә берәр нәрсә эләктермисең? Лагерьда бөтен нәрсә дә файдалы, безнең монда утыручы иптәшләргә дә ярдәм була, – дип аклангач, Сәгыйдулла, ахыр чиктә аның белән килеште, әмма үзе урлашуга бармады.

Шундый сәүдәле ял көне иде бу. Сәгыйдулла, кояшта бераз җылыныйм дип, аркасын блок стенасына терәп утыра иде. Янәшәсенә тагын бер тоткын килеп чүмәште. Сәгыйдулла аңа күз салды – моның Польшада сәяси маддә буенча кулга алынган бәндә икәнлеген аңлады.

– Исемең ничек синең? – диде тегесе нимесчәне вата-җимерә.

– Сагди.

– Син кайдан?

– Нанси. – Франциядән икәнлеге түшендәге хәрефеннән болай да аңлашыла.

– Син бит сәяси тоткын. Ни өчен кулга алдылар?

– Нахакка.

– Ә шулай да?

Сәгыйдулла моңарчы йокымсырап утырса, хәзер сагая калды. Ни кирәк моңа? Болай усал, мәкерле кешегә дә охшамаган югыйсә.

– Син үзең ни атлы соң?

– Вислав. – Бәндә аңа сөяк кулын сузды. Сәгыйдулла аны җиңелчә генә кысты.

– Мине немесләргә каршы эшчәнлек алып баруда гаепләделәр.

– Син иптәшең белән моннан чыгып йөрисең, көн дә кая барасыз?

– Тегендә, шәһәр тирәсенә. Бер офицерның өендә хезмәт күрсәтәбез.

– Адресын белмисеңме?

– Анысы нигә тагын?

Вислав пышылдауга ук күчте. Аның иреннәре Сәгыйдулланың колагына якынайды.

– Иректә минем хатыным белән ике балам калды, аларга исән икәнлегем турында хәбәр җибәрергә телим.

– Ничек итеп?

– Килешенгән урынга язу калдырып. Мин сиңа язуны бирәм, син аны яшереп калдырасың, хатыным килеп ала. Моңарчы без шулай аралаштык инде.

– Аңлашылды, – дип сузды Сәгыйдулла. Полякның сүзләренә ул, әлбәттә, ышанмады. Хаты бардыр да, бер дә хатынына атап язылмагандыр. Тагын Нансидагы кебек капкынга эләкмәсме? Язмыш бер генә тапкыр шаяртырга мөмкин, икенче тапкыр да шул ук хәл кабатланса, исән калуы икеле. – Тик мин адресны белмим шул, безне анда солдат озатып куя бит.

– Киләсе ялга кадәр белеп кайта аласыңмы?

– Бәлки...

Сәгыйдулланың коткаручысы булып, яннарына Таһир килеп басты. Поляк, аны күргәч тә:

– Ярый, киләсе атнага кадәр! – дип ашыга-ашыга китеп барды.

– Нәрсә, берәр әйбер кирәкме әллә моңа? – дип сорады Таһир, полякны күз карашы белән озатып.

– Юк, болай гына, буш сүз сөйләргә генә килгән...

– Берәр нәрсә кирәк булса, әйт, мин аңа үзем алып кайтып бирермен.

– Юк, әйбер турында сөйләшмәдек без.

Икенче көнне Сәгыйдулла Вислав белән сөйләшү турында уйланып йөрде. Аңа ярдәм итеп, үзенең гомерен куркыныч астына куймасмы? Әллә инде болай туган илең дошманына хезмәт иткәнче, ниндидер яшертен каршылыкта катнашу күңеленә бераз булса да җиңеллек алып килерме? Шулай да, ул Гансның өенең адресын истә калдырды.

Икенче атнада алар Вислав белән янә очраштылар. Сәгыйдулла адресны атады. Вислав бер мәлгә уйга калды. Ул нәрсәнедер искә төшергән төсле иде. Аннан соң ашыга-ашыга сөйләргә кереште:

– Ул йорттан ерак түгел бер алачык бар. Син аны таныячаксың, урам буйлап өскә табарак китсәң, күренә ул. Түбәсе кызыл чирәп, арткы стенасы ишелгән, өч ягы гына калган аның. Менә шунда кереп, түбә астына язуны кыстыра аласыңмы?

– Безне солдат әледән-әле күзәтеп тора бит...

– Җаен табарга тырыш инде, үтенеп сорыйм. Мин сиңа икмәк бирермен...

– Икмәк кирәк түгел, – дип уңайсызланып ук куйды Сәгыйдулла. – Китер язуыңны.

Вислав, як-ягына каранып, Сәгыйдулланың учына дүртпочмаклап төрелгән кәгазь кисәген сузды. Сәгыйдулла аны шунда ук кесәсенә тыгып куйды.

– Ни турында сөйләшәсең син бу поляк белән? – дип, янә гаҗәпләнде Таһир.

– Болай гына. Хәл белешәбез, – дип, кулын селтәде Сәгыйдулла.

Вислав әйткән алачыкны ул беренче көнне үк күрде. Гансның өеннән ерак түгел урнашкан ярымҗимерек бина нәкъ менә поляк тоткыны тасвирлаганча иде. Төшке аш вакыты җиткәч, аларны сакларга куелган нимес солдаты, мотоциклына утырып, каядыр китеп югалды.

– Мин урамны әйләнеп килим әле, – диде Сәгыйдулла Таһирга.

– Син нәрсә, безгә чыгарга ярамый бит, нимес күрсә тотып атачак!

– Мин озакка түгел, ерак та китмим. Иреккә чыкканбыз икән, бераз булса да дөнья күрәсе килә...

Сәгыйдулла як-ягына каранып, Гансның өен әйләндереп алган койма аша сикереп чыкты. Урам буш иде. Шулай да йөгерергә ярамый, берәрсе качкын дип уйларга мөмкин. Ул тынычрак атларга тырышып, теге алачыкка юнәлде. Эчкә кереп, хатны түбә киштәсе астына кыстырды. Кулдан ясалган конверт сыман кәгазьнең бер почмагы күренеп калды. Хатны алырга килгән кешегә аны табуы җайлырак булачак. Кеше-кара күргәләгәнче Сәгыйдулла кабат Гансның биләмәләренә кайтып җиткән иде инде. Таһир аңа сәер карап торды, ләкин бер сорау да бирмәде. Соңгы арада аларның аралары суынды. Моңа, беренче чиратта, Таһирның караклыгы сәбәпче, әлбәттә. Ләкин Таһир үзен гаепле итеп тоймый, шул ук вакытта җылы эш белән тәэмин иткән Сәгыйдулла белән дә артык сүзгә керергә курка. Шулай да Сәгыйдулланың бүген нindидер кырын эш эшләвен, һәм монда Виславның да катнашы барлыгын Таһир эчке тойгысы белән тоемлады. Бу хиснең аны алдаганы юк иде әле...

Сәгыйдулла шулай берничә мәртәбә Виславтан хәбәрләрне алачык түбәсе астында калдыра торды. Таһир аның чыгып йөрүен күрсә дә, башка сораулар белән аптыратмады.

Алар бер-берсенә бер тамчы судай охшаган чираттагы көнне тәмамлап, блокка кайтып йокларга яттылар. Төнлә белән блок ишеге дөбердәп ачылып китте. Тоткыннарга тезелеп басарга кушылды. Торып өлгермәгәннәрен капо күсәк белән дөмбәсли.

Каланчадай озын буйлы СС офицеры рәтләр арасыннан атлап китте. Аягында шпоралы биек кунычлы итек. Кулында матурлап эшләнгән, күн чуклар белән бизәлгән жезл. Үзе киптергән балык төсле ябык. Фуражкасының түбәсе шулкадәр киң – аэродром диярсең. Ул бөтен тоткыннарга да бораулап карый. Очлаеп торган нәзек борынын әледән-әле җирәнүдән җыерып куя – блоктагы искә анда озак торгач кына күнегергә мөмкин, беренче шәпкә нык сизелә шул ул.

Офицер рәтләрне үтеп бетерде, жезлын кул астына кыстырып, кесәсеннән кәгазь чыгарды. Бер тоткыннарга, бер кәгазенә карый. Иреннәре нидер пышылдый. Аннан соң кәгазен кесәсенә тыкты да, жезлы белән әле

бер, әле икенче токтынның корсагына сугып чыкты. Биш кеше, тыннары кысылудан, көчле авыртудан сызланып, идәнгә аудылар. Алар арасында Сәгыйдулла белән Таһир да бар иде. Тик озак ятарга мөмкинлек бирелмәде – офицерга ияреп кергән немес солдатлары аларны типкәләп торгыздылар да, ишеккә атларга куштылар.

Аларны блоктан алып чыгып караңгылык буйлап алып киттеләр. Бары тик этләр өргәне ишетелә дә, прожекторлар гына төнге караңгылыкны аркылы-торкылы ярып уза. Бер бина каршында тукталдылар. Сәгыйдуллалар төркеменә тагын берничә кеше кушылды. Бина эчендә караңгы тар гына бүлмәгә кертеп дыңгычлап тутырдылар. Ятарга мөмкинлек юк, басып кына торып була. Идән боз кебек салкын. Бераздан бүлмәдә һава бетте, тоткыннар исә хәлсезләнеп кысыла-кысыла идәнгә утырыштылар. Кемнеңдер сөякле аркасына төртелеп, тәмам алҗыган Сәгыйдулла йоклап китте.

Дөмбердәп ачылган ишек тавышына уянды. Бусагада ике СС солдаты басып тора. Берсе бозау кадәр эт ияртКән. Этнең авызыннан селәгәе агып төшкән, ул яман озын тешләрен ыржайткан.

– Син! – дип, Сәгыйдуллага төртте солдат. – Киттек.

Камыр төсле аякларына көч-хәл белән басып, Сәгыйдулла камерадан чыкты.

Урамда инде таң аткан. Аны икенче бер блокка алып киттеләр. Биредә кечкенә генә кабинетта теге озын буйлы СС офицеры утыра. Ул фуражкасын салып үз янәшәсенә куйган. Башы пеләш, ялтырап тора. Чак кына читтәрәк Ганс урын алган. Сәгыйдулла аңа күз ташлап алды. Ганс Сәгыйдуллага борылып та карамады.

– Димәк, син штурмбанфюрерның өендә хезмәт иттең? – офицер керешләр ясап тормады, сорау алуга бусагадан ук кереште.

– Әйе.

– Аның өе янындагы ярымҗимерек алачык танышмы?

– Алачык?! Белмим тагын...

– Димәк, белмисең. Лагерьдан полякларның хәбәрләрен син алып чыктыңмы?

– Нинди хәбәрләр? Миңа беркем дә хәбәр бирмәде.

– Менә мондый хәбәрләр, – офицер өстәлгә кәгазь кисәген чыгарып салды. Бөгәрләнгән сызыкларына күрә, ул Вислав бирә торган язуга бик охшаган иде. – Димәк, штурмбанфюрер исеме белән ышыкланып, син поляклар оештырган каршылык оешмасында эш алып баргансың?!

– Юк, мин бернинди эш тә алып бармадым. Мин гаепсез. Бернинди полякларны да, бернинди язуларны да күргәнем булмады, – әллә арыганлыктан, әллә куркудан Сәгыйдулланың бөтен буыннары калтырана башлады.

– Ә сез, штурмбанфюрер, кая карадыгыз?! Бу сәяси тоткын бит, аңа рәхәтләнеп иректә йөрергә рөхсәт иткәнсез!

– Герр оберфюрер, гафу итегез, мин аны Берлиннан ук белә идем, гаебем юк дип, миңа ант эчте, – Гансның тавышында моңарчы Сәгыйдулла беркайчан ишетмәгән курку хисе ярылып ята иде.

– Алып китегез, – диде оберфюрер.

Сәгыйдулланы бик каты кыйнаганнан соң карцерга кертеп ташладылар.

Таһир, аны күргәч, телсез калды. Сәгыйдулла болай кыйналып кайтарып ташланган беренче генә тоткын түгел, карцердагыларны каядыр алып китәләр дә шушы хәлдә өстерәп кертәләр. Таһирны әле беркая да чакырмыйлар. Ләкин чират аңа да җитәчәк бит. Ничек итеп котылып калырга?! Моның бер генә юлы бар иде...

Таһирны СС офицеры бүлмәсенә керткәндә, урамда инде караңгы төште. Офицер үзе дә нык арган бугай. Ул Таһирга нидер эндәште, ләкин Таһир аны аңламады. Нимес, көрсенеп, артта торган солдатка эндәште. Тегесе «Яволь» дип кычкырып, каядыр китеп югалды да юан гәүдәле таза нимесне ияртеп керде. Бу тәрҗемәче булып чыкты. Ул офицер әйткәннәрне – Таһирга, Таһир әйткәнне офицерга тәрҗемә итә торды.

– Герр оберфюрер: «Син штурмбанфюрер өендә эшләдеңме?» – дип сорый. – Тәрҗемәчесе дә урысчаны ярты-порты гына сөйли иде.

– Эшләдем, – диде Таһир.

– Син анда үзең белән яшерен оешма хәбәрләрен алып чыгып яшереп калдырдыңмы?

– Юк, мин түгел.

Җавапны ишеткәч, офицерның кинәт тәмам кәефе китте. Ул Таһирның артында торган солдатка «алып китегез» дигән кыяфәт белән ымлады.

– Герр офицерга әйтегез, миндә файдалы мәгълүмат бар, – дип сүз кыстырырга өлгерде Таһир. Тәрҗемәче тоткынның ни әйткәнен аңлаткач, офицерга бераз җан керде, ул солдатка туктарга ишарәләде.

– Мин ул хәбәрләрне кем ташыганын беләм. Без төшке аш вакытында күзәтүсез кала идек, минем белән барган тоткын шул арада урамга чыгып, язуларны билгеләнгән урынга яшерә торды.

– Номеры?

Таһир Сәгыйдулланың номерын атады. Оберфюрер Ганска борылып карады, аннан өстәлендәге карточкалар арасыннан берсен тартып чыгарып, тәфсилләп укып чыкты.

– Язуларны кем бирә иде?

– Ниндидер поляк... Мин аның исемен белмим, номерын гына...

Виславның номеры билгеле булгач, оберфюрер янә карточкаларны актарып чыкты, ләкин андый номерны тапмады. Димәк, тиешле кешене әлегә кулга алмаганнар. Әмма бу мәгълүмат полякларның яшерен оешмасының үзәгенә үтеп керергә булыша ала.

– Табып китерегез үзен, карточкасын да онытмагыз, – диде оберфюрер, аннан тәрҗемәчегә мөрәҗәгать итте.

– Тагын өстәрлек нәрсәсе бармы?

– Юк, – диде тәрҗемәче.

– Блогына кайтарсыннар. Шахт, – дип, оберфюрер Ганска борылды. – Бу тинтәктән капо ясагыз, яхшымы-начармы файдасы тиде. Башкаларга үрнәк булсын.

– Яхшы, герр оберфюрер!

Таһир бер солдат озатуында Ганс артыннан китте. Килеп җиткәч тә, Ганс тәрҗемәчене һәм капоны чакырып алды. Ул капоның кулыннан сүзсез генә кызыл бәйләвечен сүтте, тегенең кулындагы күсәкне тартып алды һәм Таһирга тоттырды. Таһир шунда ук свастикалы кызыл чүпрәкне уң кулына

бәйләде. Күсәкне кысыбрак тотты. Эшнең нидә икәнлеген аңлаган элеккеге капо, башын иеп, тоткыннар рәтенә барып басты. Ул чак кына еламый иде.

– Сезнең яңа капо! – диде Ганс. – Бүгеннән ул сезне тәрбияли! Моның өчен ул фюрер алдында зур бурыч үтәде, Бөек Германиягә каршы әзерләнгән фетнәне бастырырга, гаеплеләрне табарга булышты!

Ганс Таһирга борылды.

– Йә, күрсәт эшеңне.

Таһир баштарак аңышмый торса да, аннан үзеннән ни көткәннәренә төшенде. Ул, атылып барып, бер тоткынның аркасына каты итеп күсәк белән төшерде. Бер гаепсез бәндә сызланып, җиргә ауды. Таһир Ганска таба борылды. Тегесе елмая иде. Бүген бу Ганс Шахтның беренче елмаюы булды...

Ике-өч көн үтмәгәндер, барлык тоткыннарны да үзәк мәйданга җыйдылар. Биредә оркестр бәйрәм көйләрен уйный, урта җиргә кызыл чүпрәкләр һәм свастикалар белән бизәлгән трибуна урнаштырылган. Бер генә нәрсә моның бәйрәм булмавына ишарәли – ул да булса мәйданның бер читендә урнаштырылган алты дар агачы. Баулар әзер, элмәкләре дә яхшы итеп бәйләнгән.

Таһир кинәт кибеп киткән иреннәрен ялап куйды. Озак та үтми, бер яктан СС офицерлары күренде. Иң алдан төз гәүдәле, куе кара кашлы кеше бара. Бусы – лагерь коменданты Рудольф Хесс. Ниһаять, Таһир аны якыннан күрде. Үз-үзенә бик ышанган, күз карашы бик җитди, усаллык, явызлыкның әсәре дә юк. Бөтен лагерь коты очып торган комендант шушымыни инде ул?!

Икенче яктан СС солдатлары чолганышында көчкә атлап баручы алты кеше килә иде. Алар нык кыйналган, бер-берсенә тотынышканнар. Таһир алар арасында авырлык белән булса да, Сәгыйдулла һәм Виславны таныды. Тегеләрнең күзләре пешеккән кан белән капланган, иреннәре кабарып чыккан, баштанаяк пычракка батканнар.

Алты тоткынны алты дар агачы янына алып килеп, солдатлар ярдәмендә агач эксәмияләргә бастырдылар. Муеннарына элмәк салынды. Кайбер тоткыннар, егылып төшмәс өчен куллары белән шул элмәккә ябышты.

Оркестр тынып калды. Хесс трибунага менде.

– Бу – Бөек Германиягә каршы кул күтәргән кешеләр! – диде ул, дар агачларына таба кулы белән төртеп. – Алар яшерен оешма оештырганнар, фетнә куптарыр өчен җирлек әзерләгәннәр. Тик без теләсә нинди явызлыкны ачыкларга сәләтле. Шуңа күрә хөкемнән беркем дә качып котыла алмаячак. Моны һәммәгез дә колагыгызга киртләп куегыз!

...Кеше дигәнең гаҗәп инде. Аллаһы Тәгалә аны теләсә нинди катлаулы хәлдә дә үзен-үзе саклап калырлык көч биреп яралткан. Каты кыйнауларны Сәгыйдулланың тәне кайсыдыр бер мизгелдә бөтенләй сизмәс булды. Ул әледән-әле аңга килгәләп ала да, янәдән авыр йокыга талган төсле була. Менә бирегә атлап килүен дә ул төш дип кенә кабул итте. Муенындагы бау да чынында юк, ул уйдырма гына. Әллә инде бөтен бу мәхшәрдә аның катнашы бөтенләй дә юкмы, ул бер үзгә бәндәнең интегүләрен күзәтеп торамы?!

Ул кыска гына вакытка аңга килде. Зур авырлык белән күзләрен

ачты. Каршында тоткыннар тезелгән. Алар арасыннан ул таныш йөзләр табарга тырышты. Таһирны күрде. Тегесе Сәгыйдуллага карамый. Ничек ул анда соң? Аны да немесләр гаепләп, карцерга утыртты бит. Аны да кыйнаганнардыр. Юк, исән-сау килеш басып тора. Бәлки, бусы да саташу гынадыр?

Сәгыйдулланың күзе Таһирның беләгендәге свастикалы кызыл чүпрәккә төште. Ул барысын да аңлады. Ходай Тәгалә аны аңга китереп, үлеменең сәбәпчесе кемлеген күрсәтергә ният кылган...

Сәгыйдулла әчтән генә белгән догаларын укый башлады. Әти-әнисенең сабакларын чак кына онытып бетермәгән! Күптән дога кылганы, мәчеткә йөргәне юк. Ходай каршына ни хәлдә килеп басар?! Мал куу белән мавыгудан килеп чыккан гөнаһларын, зиначылыкны кичерерме?! Әллә инде яхшы гамәлләре коткарып калырмы?! Сәгыйдулла янә саташу чоңгылына чумды...

Һәрбер дар агачы янында берәр немес солдаты басып тора иде. Кыска гына нотыгын тәмамлап, Хесс аларга таба борылды һәм ияге белән ымлады. Шуны гына көткән солдатлар, йөгереп килеп, хөкем ителгәннәрнең аяк астындагы эскәмияләрне тибеп чыгардылар. Алты тоткын берьюлы муеннары белән элмәккә кергән килеш асылынып калды. Кемнеңдер аяклары берара селкенеп торуын күрде Таһир. Күңеле болганса да, бу коточкыч күренешкә карап тора бирде. Әйтерсең, Сәгыйдулланың чыннан да үләчәгенә инанасы килде...

Кичен Таһирны чакыртып, блоктан тагын ике кешене алырга куштылар. Кая алып баралар дисә, шул көндез асылганнар янына икән... Караңгы төшкәндә мәетләр аеруча куркыныч күренә, хаиннарга үрелергә маташкан төсле, җилдә акрын гына чайкалып торалар.

Мәетләрне баудан төшереп, ике тачкага төяделәр. Ничек эләксә шулай ташланган шыр сөякләр арасында Таһир Сәгыйдулланың да йөзен күреп алды. Ул кайчандыр атып үтергән немес солдаты кебек түгел иде бу йөз. Күзләре күренми, бите укмашып каткан кан белән капланган.

Тачкаларны озын торбалы бина янына алып килделәр. Эчкә озын таш коридор аша керәсе. Ут яктысы күренде, аннан таралучы сасы ис буылдыра башлады. Әллә хәле җиңеләер дип уйлапмы, Таһир тачка тартучы бер тоткынга салмак кына күсәге белән төртеп алды.

Коридорның теге башында мәетләр өеме. Алар тачкаларын шул өемгә аудардылар. Таһир бер генә мизгелгә тукталып, ике зур мичкә карап торды. Менә үзе кебек үк ике тоткын мичнең авызын ачты, махсус тәгәрмәчле арбадан шыр сөяккә калган мәетләрне утка ташлый башлады. Ут тиз арада аларны ялмап ала, авызлары, күзләре, күкрәкләре аша ыргылып чыга. Сәгыйдулла да озакламый көлгә әверелеп, Польша һавасында эреп юкка чыгачак.

Сәгыйдулланың Язмыш Китабы шуның белән тәмам булды...

***

1945 елның гыйнварында Освенцим-Аушвицкә канонада тавышлары якынайганнан-якыная башлады. Бу – авиация һөҗүме түгел, бу – туплар иде. Димәк, лагерьдагылар инде күптән сөйләгәнчә, Кызыл Армия бу якларга

килеп тә җиткән. Моның дәлиле булып, чәнечкеле тимерчыбык аша Гитлер армиясенең качуын күрергә мөмкин. Көне буе йөк машиналары, җигүле атлар көнбатышка таба ашыга. Аларны танклар, ярым-йорты дивизияләр узып китә.

Көннәрнең берендә лагерьны каты шартлау тетрәтте. Тоткыннар чыгып карагач, озын морҗалы крематорийларның берсе җимерелеп төшүен күрделәр.

Немецләр ашык-пошык лагерьдан китәргә әзерләнәләр иде. Аягында басып торган тоткыннарны төркем-төркем җәяүләп алып чыгып, каядыр югалалар. Лагерьдан бары тик исән-сау кешеләр генә китәргә тиеш, авырулар, гарип-горабалар биредә кала. Ләкин немецләр барлык тоткыннарны да көнбатышка таба куа алмады. Вакытлары бетте.

Көннәрнең берендә блоктан чыккач, Таһир шаккатты. Тып-тын. Каланчаларда беркем дә юк. Моңарчы электр тогы йөргән чыбыклар хәзер инде гүләми, көчәнешсез калган. Лагерь буйлап тоткыннар нидер эзләп, иснәнеп йөри.

Таһир кулындагы кызыл свастикалы бәйләвечне сүтеп, читкә ыргытты, күсәкне дә ташлады. Лагерь эченәрәк узды, үзгә бер блокка керде. Биредә шактый кеше бар иде әле. Совет гаскәрләрен аның капо булуын белмәгәннәр янында көтеп тору хәерлерәк.

Блоктагылар үз көнен үзләре күрергә калган. Таһир да уртак хезмәткә карусыз кереште. Блоктагы мичне ягар өчен утын җыеп керделәр. Өшеп беткән бәрәңгедән кәлҗемә пешереп ашадылар. Совет армиясе инде биредә, кул сузымы арада иде. Таһирга көтәргә һәм үзенекеләр белән очрашкач, дөрес сүзләр табып сөйләшергә генә кирәк...

...1945 елның гыйнвар азагында Польшаның Освенцим дип аталган борынгы шәһәре янәшәсендә совет гаскәрләре сәер корылмаларга тап булды. Немецләр ашык-пошык ташлап чыгып киткән зур бер территория чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган, аның эчендә бараклар, химик препаратлар җитештерүче заводлар, солдат казармалары һәм башка биналар урнашкан иде. Ә иң куркынычы – берничә лагерь системасында ачлыктан, авыр хезмәттән тәмам имгәнгән, шыр сөяккә калган дистәләрчә мең кеше табылды. Соңрак лагерь тирәсендә берьюлы йөзләрчә мәет күмелгән каберлекләр ачыкланды. Ярымҗимерек корылма исә немецләр качып китәр алдыннан шартлатылган крематорий булып чыкты – шундагы мичләрнең авызында күпме кеше көлгә әйләнгәнен ачыклыйсылар алда иде әле.

Авыр сугыш бәрелешләрен, канкоешны үтсә дә, мондыйдан капитан Хәмит Тимерхановның да йөрәге әллә нишләп китте. Немецләрдән соң калган мәет өемнәрен дә, асылган кешеләрне дә, соңгы казыгына кадәр яндырылган авылларны да күп күрде ул. Ләкин адәми зат үзенә тиң икенче адәми затны мондый хәлгә төшерер дип, башына да килмәде. Тере мәетләр – аларның хәтта сөйләшергә дә хәлләре юк. Сөяккә чатырдап ябышкан тире – анда ни хисабына җан тора икән?! Ач күзләр, күбесе мондый шартларда яшәүдән акылдан шашкан, хайвани инстинктлары гына калган. Госпитальдә йөргән вакытта Хәмит кешенең теләсә кайсы ерткычтан куркынычрак икәнлегенә янә инанды. Ерткычлар үз тиңнәренә беркайчан да тими. Һәрхәлдә, аларны мондый ук дәрәҗәгә төшерми...

Совет гаскәрләре килгәч корылган госпитальләрнең берсендә дәвалануга Таһир да яткырылды.

Совет гаскәриләре тоткыннан азат ителгәннәргә медицина ярдәме күрсәтү, ашатудан соң, кемнең кем булуын да ачыклау эшенә керештеләр. Кызыл погонлы кешеләр, аларның палатасына дә кереп, һәрберсеннән мәгълүмат җыеп чыктылар. Болары тоткыннарны азат иткән солдатларга да, йомшак күңелле табибларга да ошамаган, маңгай астыннан сөзеп карыйлар, текәлеп торып күзәтәләр, карашларында җылылыкның әсәре дә юк. Боларны Таһир яхшы белә, ул алар белән күп аракы эчте. Ләкин ул чакта Таһир алар ягында иде. Ә хәзер кем ул? Ватанын сатып, пленга бирелгән коммунистмы? Таһир янә янәшәсендә генә куркыныч йөргәнлеген тоемлады. Аны ничәмә тапкыр коткарган бәхете бу юлы да саклап кала алырмы? Күпме газап аша исән калгач та, менә хәзер генә тормыш сукмагы өзелмәсме?! Шул сораулар белән бимазаланып, ул йоклап китте...

...Таһирның яшь чагы. Ул үзенең өендә сәкедә ята, өстенә җылы юрган ябылган, баш астында мамык мендәр. Тәрәзәдән күзне авырттырырлык яктылык нуры сирпелеп керә. Ишек ачылып китте, бусагада әтисе күренде. Улы янына якын килеп, кырыс итеп аңа карады да борылып чыгып китте. Аннан соң әнисе пәйда булды. Гөлниса карчык, елмаеп, башыннан сыйпады, ул да чыгып китте. Таһир янә ялгызы калды. Тәрәзәдәге нур көлтәсе сүрелде, ахыр чиктә өй эче дөм караңгылыкка күмелде. Таһир, караңгыда калуына куркып, сәкедән төште, капшана-капшана, лампа табып алды, калтыранып, кабызып җибәрде.

Өстәл янында бер бәндә утыра иде. Ул кап-кара киемнән, башындагы озын чәчләре дә кап-кара, дулкын-дулкын булып иңнәренә төшә. Бәндәнең җыйнак кына кара сакал-мыегы бар. Ә күзләре исә янып торган ике ут ноктасы сыман. Күрәсең, лампа уты чагылганга шулайдыр, дип уйлап алды Таһир.

– Утыр, Таһир, – диде бәндә, кулын салмак кына күтәреп. Тавышы гырылдап, тамак төбеннән чыга, кайтаваз булып ишетелә. – Утыр, сөйләшик.

– Син кем? – Таһир иреннәре кибүен тойды.

– Мин – син, син ул – мин.

– Нигә соң син шундый кап-кара?!

– Чөнки мин – синең Чагылышың, синең Чын Йөзең.

– Минем чын йөзем кара түгел.

Тегесе гырылдап көлеп җибәрде.

– Әйдә, вакыт уткәрмичә, сөйләшик. Күрәсеңме, мин ничек ябыктым?

Таһир үзенә күз салды. Ул инде бер дә бала түгел, ә хәзерге халәтендәге тоткын иде.

– Соң, мин дә ябык бит...

– Дөрес әйтәсең. Мин синең чагылышың дидем бит инде. Минем ашыйсым килә. Исән калыр өчен, Таһир, миңа ризык кирәк. Мин ризыклы булсам, син дә яшәячәксең. Син ачлыкның нәрсә икәнлеген аңладың бит.

– Нинди ризык?!

– Җан. Чиста, саф, тапланмаган җан.

– Каян алыйм мин аны?

– Моңарчы андый җаннарны син миңа күпләп бирә идең. Хәзер дә тырышып кара. Юкса – үлем. Икебезгә дә.

Кара киемнәр кигән бәндә, урыннан атылып торып, аңа ябышты. Таһир аның озын тешләрен, ямьсез борынын, саргылт тән тиресен якыннан ук күреп, коты очты. Ул кычкыра башлады. Күршесе аны төрткәләп уятмаса, төшендә килеш үк үлеп китәр төсле тоелды Таһирга.

Иртәнге аштан соң госпитальгә кызыл погонлы ике солдат керде. Аларның берсе, ишек катына басып, фамилияләрне атый башлады. Солдатның кулындагы исемлектә Таһир да бар иде. Үзенең исемен ишеткәч, ул хәле китүен тоемлады.

Аларны кораллы солдатлар озатуында госпитальдән алып киттеләр. Урам буйлап барганда, Таһир ялга туктаган танкистларны күреп алды. Егетләр, көлешә-көлешә, нәрсәдер турында гәпләшәләр. Таныш тавыш ишетелгән төсле булды. Таһир, атлавын акрынайтып, шул якка төбәлде. Танк янындагы дүрт кеше арасыннан, ниһаять, үзенә кирәген эзләп тапты. Эченә җылы йөгерде. Менә бит ул, аның кан дошманы, биредә!

– Вакыйф! – дип кычкырды Таһир.

Күзләрен төбәп карап торган кеше кымшанмады, аның дәшкәненә игътибар итмәде, ләкин йөзендәге елмаю шунда ук юкка чыкты.

Таһир, колоннадан чыгып, кызу-кызу атлап, танк янына юнәлде. Аларны озата барган солдатларның берсе җикеренеп кычкырса да, борылып та карамады.

– Вакыйф, – диде ул, теге егет янына якын ук килеп. – Менә очраштык...

– Сез миңа нәрсәдер әйтергә телисезме? – дип, урысча сорады танкист.

– Ник кыланасың, синең исемең Вакыйф бит.

Ул арада кызыл погонлы солдатларның берсе килеп җитте.

– Ни булды монда, иптәшләр?

– Белмибез, бу кеше нindидер ят телдә эндәшә...

– Ни әйтәсез сез аларга? – дип, Таһирга борылды солдат.

– Менә бу кеше... Ул минем танышым... Ул куркыныч җинаятьче... Вакыйф аның исеме...

– Исемегез ничек, иптәш старшина? – Солдат танкистка борылды.

– Старшина Сергей Трифонов!

– Күрдегезме?! Колоннага кайтыгыз!

Үзен көткән төркемгә барганда, Таһир танкистка берничә тапкыр борылып карады. Юк, ялгыша алмый ул! Аның каршысында Вакыйф басып тора иде! Бераз олыгайган, чәчләре чаларган. Әйе, вакыт һәм сугыш кешене үзгәртә. Ләкин йөз чалымнары, тавышы – алар барыбер саклана бит. Соңгы тапкыр борылганда, ул танкның башнясына ясалган номерга күз салды. Номерны һичшиксез истә калдырырга кирәк иде...

Кайчандыр немесләр хуҗа булган бинада бүген совет гаскәриләре урнашкан. Таһир, чираты җиткәч, кабинетка керде. Стеналардан Гитлер рәсемнәрен алып ташлаганнар, аның урынында кадак караеп тора. Ә мебельләр шул ук – СС офицерлары эшләгән бүлмәдә портреттан кала берни дә үзгәрмәгән кебек.

Өстәл артында симез гәүдәле хәрби кеше утыра. Ул бусагадан атлап кереп, үрә катып калган Таһирга бер генә караш ташлады да өстәл читендәге өемнән бер папканы тартып чыгарды.

– Тәк, исемегез?

– Таһир Солтан улы Фәтхуллин!

– Званиегез?

– Рядовой!

– Кайда һәм кайчан пленга чыктыгыз?

– Пленга чыкмадым мин, мине пленга немецләр төшерде...

– Кайда һәм кайчан?!

– 1941 елның 7 ноябрендә... Мәскәү янында...

– 7 ноябрьдә үк?! Менә сиңа мә!

– Без парадтан соң позицияләргә кайттык, төнлә немецләр һөҗүм итте. Мин бер танкны яндырдым, икенчесе өстемә менде...

– Өстеңә үк?! Минем каршымда өрәк басып тора икән алайса!

Хәрби кеше симез бармаклары белән теге папкадагы кәгазь битен тартып чыгарды.

– Монда ничек исән калдыгыз? Сатылыпмы?

– Сатылмадым... Мин коммунист бит...

– Ә, коммунист икәнлегеңне искә төшердеңмени? Коммунистларны немецләр беләсеңме, нишләтәләр? Стенага терәп аталар! Сине ник атмадылар?

– Парадтан соң документларны кире бирергә өлгермәделәр, ә мин немецләргә коммунист икәнлегемне әйтмәдем...

– Монда немецләргә хезмәтче булганга исән калган син!

– Мин ватаныма хыянәт итмәдем. – Таһир бугазына төер килеп тулганын тойды. – Ләкин чын хыянәтчене атап бирә алам.

Хәрби кинәт кызыксыну уянган кыяфәт белән Таһирга карады. Бераз йомшарган төсле булды.

– Йә, әйтеп кара.

– Бирегә килгән гаскәрләр арасында бер танкист бар, ул 1933 елда безнең авылда фетнә чыгарып, качып киткән кеше. Аның чын исеме Вакыйф, ләкин ул үзен старшина Сергей Трифонов дип атады. Мин таныдым аны. Бик хәтәр җинаятьче, Сталинга каршы яла яккан кеше ул...

Бу юлы хәрбинең йөзендә чынлап торып гаҗәпләнү рәвеше иде. Ул сүзсез генә Таһирга карап торганнан соң, ишеккә таба кычкырды:

– Иванов!

– Тыңлыйм, иптәш майор!

– Капитан Тимерхановны табып монда алып кил әле. – Аннан янә Таһирга борылды. – Хәзер, барысын да ачыкларбыз.

Тимерханов ишектән кергәч тә, Таһир аның белән таныш икәнлеген шунда ук искә төшерде. Ул, аңа кулын сузып, елмаеп, татарчалата мөрәҗәгать итте:

– Иптәш капитан, рядовой Фәтхуллин! Хәтерлисезме? Парад, аннан соң землянкада кәгеп утырдык, шул вакытта һөҗүм башланды?!

Капитан бераз уйланып торды, аннан шулай ук елмаеп, үзенә сузылган кулны кысты.

– Ә, хәтерлим, әлбәттә! – Янәшәдә майор булганга, капитан Таһирга урысча җавап кайтарды. Таһирның кыяфәтен күздән кичергәч, йөзендәге елмаюы югалды. Капитан майорга борылды. – Чакырдыгызмы, иптәш майор?

– Сез нәрсә, әллә танышмы?

– Таныш, иптәш майор, таныш. 1941 елгы парадта бергә катнаштык, бергә немесләр белән сугыштык.

– Менә бу... Бу гражданин әйтүенчә, сездә күсе пәйда булган бит.

– Нинди күсе тагын?

Таһир яңабаштан Вакыйф турында сөйләп бирде. Кызыл погонлы хәрби дә аңа мөнәсәбәтен үзгәрткән иде, шуңа бу юлы иркенләп, тозлап-борычлап, булганына булмаганын да өстәп сөйләү мөмкинлеге туды. Ике хәрби аны бүлдермичә тыңладылар. Бәян тәмам булгач, кызыл погонлысы Таһирга:

– Сез китә аласыз. Иванов! – дип кычкырды да, Таһир артыннан ишек ябылгач, Хәмиткә борылды.

– Нәрсә әйтерсең, капитан?!

– Нәрсә дияргә дә белмим инде, иптәш майор. – Хәмитнең йөзе каралды, ул тирән уйга батты. – Ялгышкандыр бу кеше. Трифонов Сталинградтан алып бирегә кадәр килеп җиткән хәрби, ул үзенең хак юлдан баруын канлы бәрелешләрдә раслады.

– Андыйлар арасында сатлыкҗаннар да булгалый, капитан.

– Мөгаен, Фәтхуллинның башы киткәндер. Мондый мәхшәрдә дүрт ел яшәп, теләсә кем акылдан шаша ала...

– Анысы мөмкин, бик мөмкин. Ләкин! – Майор шап итеп симез учы белән өстәлгә китереп сукты. – Ләкин, капитан, сигнал бар икән, без тикшерергә тиеш. Гаеп итмә, яме.

## Эпилог

Зөбәйдә өйгә кергәч тә, мич каршына ашыкты. Вак йомычка, чыраларны утын астына куеп, Никита Хрущёвның озын доклады басылган гәҗитне салды, шырпы сызып, ут төргезеп җибәрде. Җиһангир булмагач, ялгызына авыр, колхозда эштә вакытта өе суынырга өлгерә. Улы район үзәгендә укуда, ялларга гына кайтып киткәли. Барлык өй хезмәте, каралты-куралар, юклы-барлы терлекләр бер Зөбәйдә җилкәсенә калды.

Мичтәге утыннар шатырдап яна башласа да, толыбын салырга ашыкмады – йорт җылынганчы шактый вакыт үтә. Чәйнеген, кичәдән пешергән шулпасын җылытырга куйды. Бер башына күп кирәкми, кайнар ризыкны ике көнгә бер генә әзерли. Хәер, анысы да тамагыннан үтми.

Ут алгач, эленгеләрне япты, өй эченә бераз гына булса да кот керде кебек. Толыпны да салырга мөмкин.

Зөбәйдә, мич артына кереп, тәһарәт алды, яшерен почмактан намазлыгын чыгарды. Тәрәзәдәге эленгеләр аша кеше-кара күзе үтмәгәнлегенә инангач, намазга басты.

Һәр көне менә шулай үтә иде аның хәзер. Вакыт, ялгызлык, авыр хезмәт, аннан да бигрәк кайгы-хәсрәт йөзенә мәңге төзәлмәслек эзен салса да, яшь чагындагы матурлыгы, нуры югалмаган. Башына төшкән бәлаләрне сабырлык белән җиңеп яши бирә. Инде әнисе Нәсимә дә гүр иясе...

Намаздан соң табынга утырыйм дисә, ишек кактылар. Кем булыр икән бу? Әллә инде янәдән колхоз рәисе Таһир исереп килеп җиткәнме?! Соңгы тапкыр керүендә дә Зөбәйдәнең бөтен күңел тынычлыгын алды, әллә ничә

төн буе йокламаслык итте. Әшәке, бәгырьгә кадала торган сүзләрне ул мөртәт таба белә шул!

Зөбәйдә ишек келәсен сак кына күтәрде. Чоланда караңгы иде.

– Кем бар? – дип сорады ул.

– Мин бу, Зөбәйдә. Мин – Вакыйф...

Ничәмә дистә ел ишеткәне юк иде аны Зөбәйдәнең. Тавышы бераз гына үзгәргән, ирләр кырыслыгы кергән, ләкин бу – өзелеп сөйгән, төшләреннән чыкмаган Вакыйфының тавышы иде!

– Вакыйф... – дип пышылдады Зөбәйдә. Аннан, шатлыгын һәм җан ачысын бергә кушып, кычкырып җибәрде: – Вакыйфым!!!

Вакыйф бусагадан атлап керде. Нык ябыккан, таушалган, җыерчыклар белән чуарланган. Күзләре генә элеккечә калган – шул, яшьлегендәге караш!

Алар берара дәшми генә бер-берсенә карашып тордылар. Зөбәйдә беренче булып аңга килде, акрын гына якынаеп, иренең иңнәрендәге карларны сыпырып төшерде, бүреген салдырды. «Вакыйфым, җаным, бәгырем» – дия-дия пышылдап, елап җибәрде. Иреннәр иреннәргә тартылды. Ике газиз җанның күз яшьләренә чыланган әче һәм шул ук вакытта татлы үбешү иде бу.

– Нигә син кайтуыңны хәбәр итмәдең? Колхоздан ат яллап, Буа станциясенә барыр идем, – диде Зөбәйдә, бераз тынычлана төшкәч. – Җиһангир белән бергә каршылаган булыр идек...

– Минем менә шушылай кайтасы килде. Китмәгән төсле. Сине борчыйсым килмәде. Башта үзең белән генә күрешергә теләдем...

– Өсләреңне сал, әнә теге сандыкта Җиһангирның кием-салымнары, сиңа ярарга тиеш алар, – дип, Зөбәйдә, ашыга-кабалана иренә хезмәт күрсәтергә ашыкты.

Вакыйф, мич артына кереп, җылы су белән юынды, төрмәдән чыгып, юлда узган вакыт эчендә шактый үсәргә өлгергән сакал-мыегын кырды. Чатнаган көзгегә күз төшергәч, үзенә-үзе шатланып куйды – болай матур гына күренә тагын үзе!

Ул арада Зөбәйдә табын корган. Шулпа исе борынны кытыклый, кара көнгә дип саклап торган урыннан бал да чыгарылган. Вакыйф, ач икәнлеген күрсәтмәскә тырышып, мөмкин булганча ашыкмый ашарга тырышты. Сөйләшергә шактый сүз җыелса да, берсе дә аны-моны дәшмәде. Озакламый өйдә ут сүнде...

...Вакыйф изрәп китүен тойды. Тәне генә түгел, җаны да моңарчы белмәгән ләззәт дәрьясына чумды. Менә ул үзенең туган өендә, кочагында мәңгелек мәхәббәте Зөбәйдә, алар икесе бергә бер җылы юрган астында... Беркая да чабасы, беркемнән дә качасы юк. Урамда буран түбә такталарын дөбердәтә, мичтә шатырдап утын яна, шундый җылы, тыныч, рәхәт! Бәхет менә шушы түгелмени! Һәм бер мизгел өчен мәңге иза чигәргә мөмкин.

– Җиһангир бигрәк үсеп киткән, – диде ул, түшәмдәге бер ноктага төбәлгән көе.

– Сиңа тартым. Буе да, килеш-килбәте дә. Киребеткәнлеге дә...

– Анысы әйбәт! Киребеткән булмасам, кайта да алмас идем, холкым гына коткарды. Хатларда барысын да язарга ярамаганлыгын беләм, йә, сөйлә, авылда, дөньяданиләр бар?

– Ниләр дип... Таһир сугыштан соң колхоз рәисе итеп билгеләнде. Хәзер дә ул җитәкче.

Вакыйфның йөрәге кысылды. Шушы көнгә кадәр төрмә газапларын кем аркасында күрүен Зөбәйдәгә әйтергәме-юкмы? Белмәсә, хәерлерәк булыр. Вакыты җитмәгән, анысын да ирештерер.

– Таһир каһарманмыни?

– Каһарман. Сугыш батыры. Медале дә бар. Аны кая барса да калдырмый, түшенә тагып йөри. Үзе әсирлектә дә булган.

– Әсирлек гаеп түгел, сугыш бит...

– Аңлыйм... Тик күрше авылларда әсирлектән кайткан ирләрне тикшерүчеләргә йөртеп бимазалап бетергәннәр, рәтле эш бирми интектерәләр, ә моңа – колхоз рәисе урыны.

– Булдыклы кеше, димәк. Безнең төсле имгәк түгел. Сиңа бәйләнмиме?

– Юк, миннән курка бит ул. Кайткач та, күрше авылдан хатын алды. Ике балалары үсеп килә. Тормышы түгәрәк.

– Эчәме?

– Эчә. – Зөбәйдә көрсенеп куйды. – Бер көнне исерек килеш өйгә килгән. Әллә ниләр сөйләп бетерде, хәмердән башы алмашына бугай инде. Имештер, әсирлектә минем әтинең энесе Сәгыйдулла абый да булган. Бергә тоттылар, ди.

– Бик мөмкин. Дөнья түгәрәк, кайда кем белән очрашканыңны белми дә яшисең. Ул очрашу хәерлегә дә булырга мөмкин, хәтәргә дә, – диде Вакыйф, Освенцим лагере янында Таһир белән күрешүләрен исенә төшереп. Бер карасаң, меңнәрчә чакрым ераклыкта авылдашыңны табу зур бәхет шикелле. Тик Вакыйф өчен ул дистә елга якын төрмәдә утыру белән тәмамланды...

– Абыйны сатлыкҗанлыкта гаепләде, нимесләргә хезмәт итте, диде.

– Тик, нигәдер, туган ягына Сәгыйдулла абый түгел, Таһир гына әйләнеп кайта алды... Ышанма син аңа, Зөбәйдә. Гомере буе ялган белән яшәүче кеше бит ул. Тик ялган мәңге дәвам итә алмый.

– Беләм, Вакыйфым. Кеше газаплары, күз яшьләре, әрнү-борчулары залимнәр тарафыннан корылган ясалма буа эченә җыела да җыела. Ләкин ул буаның да чикләре бар. Һәм, вакыты җиткәч, аннан чыккан ерганаклар ташу булып агып китәчәк. Ул ташуны беркем дә туктата алмас. Дөреслек шул чакта һичшиксез ачылыр!

– Син шул вакытны без күрә алырбыз дип уйлыйсыңмы?

– Мин моңа ихлас күңелдән ышанам!

Вакыйф Зөбәйдәне ныграк кочты.

– Мин сине һәрвакыт төшләремдә күрә идем, Зөбәйдәм-бәгърем...

– Мин дә...

– Безнең беренче төн... Ул меңнәрчә кат кабатланды, бетмәс саташуга һәм шул ук вакытта чиксез ләззәт чарасына әйләнде...

Зөбәйдә кыяр-кыймас кына сорарга җөрьәт итте:

– Вакыйф, син минеке генәдер бит?

Вакыйф Зөбәйдәнең күзләренә текәлде. Сәер сорау иде бу. Шул ук вакытта табигый һәм урынлы. Бер генә мизгелгә зиһенен чуалтып,

Сталинград янындагы хәрби госпиталь, санитарка Валентина хатирәләре килеп төште.

– Синеке генә, җаным... Шайтан коткылары булды, тик мин бирешмәдем. Без инде беркайчан да күрешмәбез дигән уйлар да кергәләде. Ул вакытта мин, күзләремне йомып, бергә кичергән назларны искә төшерә идем.

Зөбәйдә тынычланып калды төсле.

– Син Аллаһы Тәгалә, динебез хакына зыян күрдең, ул үзе сиңа бөтен сынауларны да җиңеп чыгарга көч биргәндер.

– Бер генә дә шигем юк. Ә мәчетнең ае? Ул исәнме?

– Исән. Мин аны ышанычлы урынга яшердем, беркем дә таба алмаячак. Ә вакыты җиткәч, туган авылыбызда мәчет салынгач, без аны синең белән халкыбызга кайтарачакбыз.

– Ул көннәрне дә күрә алырбызмы икән?!

– Әлбәттә. Синең кайтуыңа беркем дә ышанмады – бер мин генә көттем, һәм менә син минем янымда. Бу Ходайның могҗизасы түгелмени? Кешелек мәңге имансыз булып яши алмаячак, аның барыбер азагы була.

Вакыйф, ирексездән, елмаеп куйды.

– Дин кайтып, мәчет ачсалар, анда да мулла итеп Таһирны куярлар инде, – диде ул, усал мәзәгеннән тыела алмый пырхылдап көлеп.

Зөбәйдә бу сүзләргә бер дә аптырамады.

– Анысы да булырга мөмкин. Тик иман беренче нәүбәттә күңелдә булырга тиеш. Ә имансызлар барыбер җәзасыз калмас. Ахирәт бар бит әле. – Зөбәйдә Вакыйфка ныграк елышты. – Әтинең әйтеп калдырган бер васыятен үтәмәдем. Лагерьдан кайткан вакытта ул мари урманнарында Абдай атлы бер кешедә сыену урыны тапкан, төн кунып чыккан. Саубуллашканда, әтием, рәхмәтемне ничек җиткерим дип сораган. Абдай, дөньялар тынычлангач, кунакка чакырырсың, дигән. Шул агайны эзләп табып, гаиләсен безгә дәшәсе булыр...

– Анысын да эшләрбез, җанкисәгем.

– Ял ит инде, йокла, йөрәк маем...

Әче җил дулаган тавышка тибрәлеп, Вакыйф белән Зөбәйдә татлы йокыга чумдылар. Әйтерсең, буран аларның газапларын, кайгы-хәсрәтләрен күмеп китәргә маташа. Ә иртән... Иртән яңа көн башланачак. Җиргә яткан хәтфә кардай ак, якты һәм чиста. Анда инде явыз залимнәр дә, канлы хаиннар да, мәкерле бәндәләр дә, сугыш-җәберләр дә булмас төсле. Хәсрәт һәм гаделсезлек буасын бары тик сабырлык һәм вакыт кына җимерә алачак...



Энҗе
Хөсәенова

# МИН СИҢА ОШАРГА ТЫРЫШМАМ

## Җиңеп чыгар

– Сез – беткәннәр! – диде миңа берәү,
– Сезнең инде юктыр киләчәк!
– Син үзең дә безнең милләттән бит,
синең юлың кая илтәчәк?!.

Мин яшермим, егылган да булды,
абынылды инде мең тапкыр.
Нәкъ шул чакта булсын бердәм халкың –
ярдәм кулын сузар һәм тартыр.

Юк итәргә берәү омтылса да,
баш калкытып, барыбер чыгарбыз!
Еллар, дәверләрне уза алган
корыч кебек үтә чыдам без!

Ә син, беткән, дисең, кискен итеп...
Милләтемнең хәтер коймасын
ут та, су да, җил дә юк италмас!
Югалтмасын гына кыйбласын!

## Тибәрделәр мине...

Тибәрделәр мине...
Башта – яулык, кулда – «Һәфтияк».
Заманага әгәр ярыйм дисәң,
кыска итәк, тузган чәч кирәк.

Тибәрделәр мине... Атлаганда
мәдрәсәгә илткән юллардан.

---

Энҗе ХӨСӘЕНОВА (1996) – *шагыйрә; «Иделем акчарлагы» яшь иҗатчылар бәйгесенең 2021 елгы Гран-при иясе. Казанда яши.*

Юлаучылар юкса мәхрүммени
хак юлда ул дигән уйлардан?!

Тибәрделәр мине... Укыганда,
кабат-кабат «Ихлас» сүрәсен.
Замананың шайтани көйләре
кадерлерәк күпкә, күрәсең!

Тибәрделәр мине... Мин аларны
кичердем һәм гафу сорадым.
Дога кылдым: «Раббым, ярлыка!» – дип,
һәм куәтлә, диеп, иманын.

## Саклар әле...

Салдырылган челтәр-пәрдә,
шаулап үскән гөлләр шиңгән.
Бабай салган агач йортның
бүрәнәсе инде иңгән.

Шәһәргә дип тутырылган
әйберләр дә капчык-капчык.
Моңсуланып калган сыман
әби төсе – мендәр-ястык.

Элек гөрләп торган нигез
сагыш төсле күлмәк кигән.
Әмма һаман чиста һәм пакь,
балкып тора такта идән.

Безнең якты балачакны,
барлык-барлык хатирәне
саклар әле ул бик озак.
Чарасыздан... күз яшьләре аша
туган йортка элдек йозак.

## Син көн дә берүзең

Синең дә хәлләрең шул укмы:
юк иптәш күңелең ачарга?
Көннән-көн сулыккан йөрәгең
телидер ташларга, качарга!..

Бушаныйм дисәң дә – тилмерү,
табылмый тыңлаучы аңларлык.
Дустың дип саналган кешеңә
эндәшсәң... ул да бит алдарлык...

Син көн дә берүзең һәм уйлар...
Туңасың бөркелгән салкыннан.
Югыйсә синең дә кешечә
шатланып яшәргә хакың бар!

Юлыңда очраган йөзләрне
гамьсезлек битлеге бизәгән...
Үзең дә көтмәгән бер мәлдә
табылыр тыңлаучың меңләгән.
..............................................
Тик инде ул чакта соң булыр!..
Мәңгегә кул гына изәрләр...

## Күзләр

Кырыс итеп баккан күзләр була,
усаллыгын эчкә яшереп...
Өмет белән баккан күзләр була,
белеп-тоеп синең дәшереңг.

Хөрмәт белән баккан күзләр була,
җиткерергә теләп мең рәхмәт.
Көнләшеп тә баккан күзләр була,
күңеленнән юрап мең зәхмәт.

Ялган белән баккан күзләр була,
ышанычын бетереп үзенең.
Җылы өстәп баккан күзләр була,
бетә калса әгәр түземең.

Һәм яратып баккан күзләр була,
сөю тамар була үзләреннән.
Бар җылыны җыйган шушы күзләр
үбәр була синең эзләреңнән.

***

Мин сиңа ошарга тырышмам –
кимәм дә иң матур күлмәгем.
Югыйсә күптәннән алынган,
эленгән шкафка түрдәге.

Мин сиңа ошарга тырышмам –
такмам да чәчемә тасмалар.
Җил үрер тузгыган чәчемне,
тузанга исемем язсалар.

Мин сиңа ошарга тырышмам –
тартмамын күземә сөрмәләр.
Бары тик ягымлы елмаю
ирнемнән күземә үрмәләр.

Мин сиңа ошарга тырышмам –
йөрәгең әкренләп ут алыр.
Бер мәлне биләр дә ят хисләр,
көн белән төнең дә буталыр.

## Чәчемне яңадан үр әле

Чәчемне яңадан үр әле,
сүтелде ярсулы җилләрдә.
Кайтыр дип әйләнеп киредән,
минут та яныңнан җибәрмә.

Чәчемне яңадан үр әле,
тузгыды койганда яңгырлар.

Тын алмый тыңлачы бер генә,
сиңа дип аталган сүзем бар.

Чәчемне яңадан үр әле,
чыланган һәрберсен киптереп...
Үр әле чәчемне яңадан,
гомергә сүтелмәс иттереп...

## Онытылыйк

Әйдәле, күзләрне йомыйк та
уйламыйк бернәрсә хакында.
Тукталыйк шаукымнан, тын алыйк,
онытылыйк беразга тагын да.

Хуш исле чәчеңнән назласын
бу җәйнең ялкынлы җилләре.

Күзләрең йомылган халәттә
йөгереп каршыма кил әле!

Кулларың тирбәлсен, болынны
бизәгән чәчәкләр өстендә.
Күңелне биләгән хыяллар
нәкъ шул ук чәчәкләр төсендә!

Читләтеп башкалар тавышын,
тыңлыйкчы сандугач баласын.
Кайгырмыйк – ерактa кәккүк тә
гомерне санаса санасын!

Ирек бир... Балкыган йөзеңнән
иркәләп бер үпсен күбәләк.
Йом әле күзләрең, карышма,
онытылыйк мизгелгә бергәләп...

***

Шигырь ташый миннән...
Күзләремдә очкын кабына!
Уем белән синең кочагыңда –
хыял юрганымны ябынам!

Бер көй ташый миннән...
Елмаюдан балкыйм тагын да!

Кояш миндә, бары кояш кына
яңгыр ишеп яуган чагында!

Бәхет ташый миннән...
Йөрәк тулы иркә-наз гына!
Бер сәерлек чәчәк ата миндә –
мин яратам бугай... аз гына.

## Егерме биш иде ул чакта...

Егерме биш иде нәкъ ул чакта –
акыл утырган чак,
юләрлекне читтә калдырып.
Ихлас күзләр белән
караган чак,
алсу күзлекләрне салдырып.

Егерме биш иде нәкъ ул чакта –
кеше аерган чак:
кайсы яхшы, кайсы яманат.
Сөйләвеннән белә
башлаган чак –
кайсы чынлап, кайсы ялганлап.

Егерме биш иде нәкъ ул чакта –
тоя башлаган чак
яшәү ямен, кеше күңелен.
Инде аңлаган чак
бу дөньяда
беркемнең дә мәңге түгелен.

Егерме биш иде нәкъ ул чакта –
ныклап уйланган чак:
хәерлеме, әллә түгелме?
Сорый башлаган чак,
насыйп ит, дип,
рәхәт тормыш,
җиңел үлемне.

Егерме биш иде нәкъ ул чакта –
җигелеп тырышкан чак:
җиңел микән, әллә кыенмы?..
..................................................
Егерме биш иде нәкъ ул чакта –
барсын аңлыйм кебек тоелды...



*Ләйсән Низамова (1986) – журналист. Теләче районы Югары Кибәхуҗа авылында туган. Бүгенге көндә Казанда яши. Бөтендөнья татар конгрессының Милли мәгариф һәм мәдәният комитетында әйдәп баручы референт. «Тиле» хикәясе – авторның беренче әдәби әсәре.*

Ләйсән
Низамова

# ТИЛЕ

хикәя*

Янып китә алмый пыскып кына яткан чи утыннан иске агач өйнең караңгы бүлмәсенә борыннарны әчеттереп, төтен исе таралды. Гомер-гомергә өйнең җаны булган мичтәге учак аша күңелләргә дә үрли, өй һәм гаилә рәхәте, тәмле сый вәгъдә итә торган ис түгел иде бу. Әйтерсең лә, өйнең бүрәнәләре мәрткә киткән дә, синең яккан учагыңа да, хуҗаның әле чыра, әле кәгазь эзләп өйалды белән мич арасында дөп-дөп басып атлап йөрүенә дә исе китми. Ир исә көндәлек эш булган учакны һаман тергезә алмавына үртәлә, үзалдына ямьсез итеп сүгенеп куя, вакыт-вакыт утын пүләннәрен типкәләп ала иде.

Ишегалдындагы ишелгән иске абзарның такталарын алып кереп тыккач, ниһаять, коры утынга риза булып, мич тә биреште – учак дөрләп китте. Үзеннән канәгать калган ир иркен сулап куйды да мич белән әвәрә килеп тирләп беткән булса да, өс киемен салып тормый гына, өстәл янына утырып, тәмәкесен кабызып җибәрде. Учак исенә кушылган арзанлы тәмәке төтененнән күздән яшьләр атылып чыгарга тиеш иде кебек, тик ир шушы халәттән ләззәт алып, ашыкмый гына тартуында булды.

Иске салкын өенә әз генә җылы кертсә дә, рәхәтлек һәм нур иңдерергә кодрәтсез мичкә тагын ике такта ыргытты да, ул рәттән икенче тәмәкесен

*Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән әдәби әсәрләр конкурсының «Хикәя» номинациясендә икенче урынны алган әсәр.

кабызды. Әллә җәй көне генә очраткан бәләкәй дустын юксына, әллә һәркемне үз өенә куып керткән көзне ачулана – аңлата да алмас иде. Барлык хисләре бергә буталган халәттә тәрәзәгә карап, уйга чумды ул.

...Һәр авылның бер тилесе була, ди бит халык. Фирдүс Ходайның менә шул «авыл тилесе» дигән «вазифа» йөкләнгән сөекле бәндәсе иде. Моңа кадәр авыл тилесе булып йөргән әтисе Фәрхәт әле иллесен генә тутырса да, инде олыгаеп килә, картлар тирәсенә елышып, мәчеткә дә йөри башлагач, бераз басылып калды. Юк-барга тавыш чыгара башласа, аны шулай мәчет белән куркытып, җай гына авызын томалыйлар иде. Халык телендә медицина терминнары белән мавыкмыйча, «тулы түгел» дип кенә йөртелү Фәрхәтләрнең нәселеннән килә. Мәрхүм әнисе Мәмдүдә түти дә үзенә бертөрле шаукымлы булып, юк кына сүздән тузып, «ычкынып китә» торган гадәтле иде. Ике өлкән кызы башка сау булып туып, үз тормышларын матур гына корып җибәрделәр. Төп йортта калып, иң нык терәк булырга тиеш дигән өметләр баглап тапкан төпчеге Фәрхәттә исә нәсел чире ачыкланды. Тиле улының ялгыз картлык кичерүенә, апаларына бер йөк булуына борчылган Мәмдүдәне Ходай ишетте бугай. Читтән караганда йомыкый гына тоелса да, күңелендә бар бәхет – берәр егетне эләктереп, кияүгә чыгу дип инанган Рәүхия өчен Фәрхәтнең тозсыз шаярулары дәрт кенә өстәде. Кызларының акылга тулы булмаган егет белән чуала башлавын белеп алган ата-ана каршы төшәргә дә өлгермәде – Фәрхәт Рәүхияне «урлап» алып кайтты. Урланган кызларның ата-ана йортына кире кайтуы хурлык саналуын, әлеге йолага каршы бара алмавын белеп эш итте кәләш. Кода-кодагыйларга туй көнен билгелисе генә калды.

Ирле булу хыялы тормышка ашкан кыз бәхетле иде. Иренең кызулыгы, тузга язмаган сүзләре, анасы белән шыр-шыр талашуы, хатынына кайчак кул да күтәрүе – барысы да гадәти бер гаилә тормышы булып, үз җаена гына гомер иттеләр. Нәсел дәвамчысы булып туган уллары Фирдүстә әтисенең сау булмаган геннары ачыклангач та артык борчылмады ана. Менә бит, Фәрхәте белән дә кешедән ким яшәмиләр. Бер дигән йорт җиткезделәр, абзар тулы мал-туар. Авыл җирендә хуҗалык алып барырга көче җитәр әле улының. Ана кеше шулай фикерләде.

Фирдүс сабый чагында башка балалардан артык аерылмады. Кызлар кызыгырлык озын керфекләре арасыннан туры итеп баккан чем-кара күзләре дөньяга самими һәм тулы ышаныч белән карый иде. Дуамал әтисе алдына алып сөеп утырмады билгеле. Әнисенә дә, төп йортта алар белән бергә яшәүче Мәмдүдә әбисе өчен дә малайның тамагы тук, өсте бөтен булуы тәрбия дигәненең нигезе иде. Рәүхиянең апасы күптән Казанда кияүдә, әтисе дә Фирдүс тууга гүр иясе булды. Алты почмаклы йортында мәчесе һәм бер сыеры белән ялгыз калган әнисе Роза апа акыл ягыннан «тулы» булмаган оныгын үлеп яратты. Башыннан сыйпап яратучы, якты дөнья белән таныштыручы, һәр соравына җавап бирергә вакыт табучы кеше Роза әбисе булды. Елан да җылыга елыша, ди бит халык. Малай да көннән-көн әбисенә ныграк тартылды, еш кына куна калды. Тора-бара инде әти-әнисе янына кунакка гына барып кайтыр булды.

Авыл – үзе бер аерым ыру, кабилә. «Авылдаш» дигән сүз синең бер җирлектән икәнлегеңне генә аңлатмый. Бер урманда үскән агачларның

тамырлары тармакланып, кушылып, берегеп беткәндәй, тамырдаш җаннар да булып чыгасың. Чит җирләргә чыгып китеп кара әле: авылда чакта барлыгын да белми яшәгән апаны очратсаң, шуннан да якынрак кешең булмаячак. Тамыр бер, туфрак бер шул. Шушы авылга гына хас сөйләм, мәзәкләр, тарихлар берләштерә. Әйтик, күрше апасының очраклы рәвештә очрап, аты-юлы белән сине сүгеп китүен дә, югары оч абзыеның кибеттән кирәк-яракны  чиратсыз гына алуын, чәчәкле яулыгын чөеп бәйләгән мөлаем ханым барында бар кешенең су капкандай дәшми генә торуының хикмәтен бары тик әлеге җирлектә туып-үскән кеше генә аңлый бит. Гаепләми, талашмый – аңлый, чөнки сәбәбен белә. Сүгенүче апаның сөйләме әдәпсез тоелса да, аның беркатлы, ихлас һәм ярдәмчел булуын белгән авыл халкы нык хөрмәт итә. Чөнки ул чәчәкле яулыклы әдәпле ханым кебек йомшак җәеп, катыга утырта белми. Чиратсыз кергән абзый вакытсыз бакыйлыкка күчкән улын җирләгәннән соң, үз эченә йомылып, беркем белән озак аралашмас булып калганга, аның тиз генә кибеттән чыгып китәсе килү теләген аңлыйлар һәм әлеге тынлык белән генә булса да, аңа ярдәм итәргә телиләр. Авылда һәркемнең тормышы уч төбендәге кебек.

Фирдүс тә туган авылының бишегендә үз булып үсте. Аның сәерлеген белеп шаярткаласалар да, усаллык белән үпкәләтүчеләр юк иде диярлек. Әйтик, берара хәрби кием киеп алып, үзен полиция хезмәткәре дип хыялланып уйнап йөргәнен күргән авылдашлары иске шкафларын актарды. Абзыйларның армиядә хезмәт итү истәлеге булып тузан җыеп яткан костюм-фуражкалары Фирдүснең гардеробына күчте. Берсендә шул киемнәрне киеп, олы юлга аклы-каралы таяк тотып чыгып басып, документлар «тикшерү» өчен, бер «КамАЗ» йөртүчене туктатуын мәзәк итеп сөйләп, рәхәтләнеп көлеште халык.

Югары оч Рәшит абзый ташларга җыенган баянын Фирдүскә кертеп биргәч тә, авыл халкы шактый гөрләп алды. Ник дисәң, Фирдүс төн буена шул гармунын тартып, кибет каршындагы баскычка утырып җырлап чыгар булды. Җәйге эссе төннәрдә тәрәзәләре ачык күршеләренең түзәр чамалары калмагач, хәйләсен таптылар тагы. «Фирдүс, безнең урам үзәнлектә бит ул. Менә югары урамга менеп уйнасаң, сине бөтен авыл ишетәчәк. Рәшит абыең да үз гармунын ишетеп, бик сөенер. Аларның капка төбенә утырып уйна син», – дигәч, тыныч йоклый башладылар. Ә гармунның элеккеге иясе Рәшит абзый капка төбендәге концертка ике төннән артык чыдый алмады, мең төрле сәбәп белән бүләген кире алырга мәҗбүр булды. Алга таба төне буе чыбыркы шартлатырга өйрәнүме, иске абзар тактасыннан бакча уртасына теплица ясыйм дип (кабат төне буе!) кадак кагумы, җәйләрен көнозын балыкка йөрүме – мавыгулары үзгәреп торды Фирдүснең. Әмма авыл халкы беркайчан каты бәрелмәде, хәйлә белән җайлап-майлап, хәл итәргә тырышты. Ачуланудан, ызгышудан нәтиҗә юк иде. Үзен үпкәләтергә тырышучыларга үч итеп, аеруча бер үҗәтлек һәм усаллык белән киресен эшлисен көт тә тор.

Сабый чакта аның акылына дөнья гел бик матур күренә иде. Яшьтәшләренең төртмәле сүзләре аның зәгыйфь акылына барып җитми, чит итмиләр, уйныйлар бит әле. Мәктәпкә беренче сыйныфка укырга

кергәч тә, уңыш елмайды аңа: гел елмаеп эндәшеп йөргән күрше укытучы апасы сыйныфына туры килде. Мөгаллимә балаларны чын күңелдән яратып эшләүче, яшь булса да, педагогика дигәнне институттагы белеменә генә таянып түгел, ә тормыш тәҗрибәсе аша өйрәнеп эшләүче ханым иде. Сыйныфына Фирдүс кебек үзенчәлекле бала туры килүенә башта борчылса да, уртак тел тиз таптылар тагын. Сыйныфташлары беренче мәлдә «тиле бит ул» дип, өстән карап йөрсәләр дә, ярты ел дигәндә, укытучы аларны бер гаилә итеп туплый алды. Фирдүснең сәерлегенә игътибар итмәскә өйрәнделәр, ә малай үз чиратында мөгаллимгә дәрес алып барырга комачауламады.

Башлангыч мәктәп белән хушлашып, бишенче сыйныфка да күчтеләр. Фирдүс, гадәтенчә, үз укытучы апасының сыйныфына килеп утырды. Ләкин биредә инде аның сыйныфташлары юк, беренчегә кечкенәләр килгән. «Сез инде зур үстегез, хәзер башка укытучылар укытыр, башка бүлмәләрдә белем алырсыз», – дип ипләп кенә аңлатып, классташлары янына озатты аны укытучы апасы. Бер-ике ай шулай аптырап йөрде Фирдүс. Хәзер инде аның көен көйләп торучы юк, һәр укытучының үз тәртибе. Сыйныфташлары да уйнарга атлыгып тормый, җитдиләнеп килгәннәр. Шул мизгелдә үк өенә торып чапса да, аңа сүз әйтүче булмас, җиңел сулап кына куярлар иде дә бит... Тик үз сыйныфларына күрше авылдан килеп кушылган кыз гына тынгылыгын алды аның. Үзе дә сизмәстән, ул гел Алияне күзәтер булды. Алар авылында мондый чибәр кыз юк бугай. Аның сөйләшүе дә икенче, Фирдүснең әнисе кебек авызын каплап, күзләрен генә уйнатып көлә. Башка кызлар кебек әз генә чәчен тартуга да чырыйламый, шелтәле караш ташлый да авызын бүлтәйтеп куя. Фирдүс аңа якын барырга да, эндәшергә дә кыймады. Шулай да мәктәпкә Алияне генә күрер өчен йөрде бугай ул.

Инде укытучылар да сорагач, шуның өстенә табиблар белешмәсе дә булгач, мәктәпкә йөрүдән туктады һәм хыяллар илендә яши башлады үсмер. Менә үсеп кенә җитсен әле, мәктәпне тәмамлауга «КамАЗ» машинасына утыртып, выжт итеп кенә әбисе йортына Алияне килен итеп төшерәчәк ул! Әбисе картаеп килә, аңа да ярдәмче булыр. Өйләнгәнче, әбисе белән бергә картайган нигезне ныгытырга, «КамАЗ» алып җибәрергә кирәк булыр...

Әлеге хыяллар аның зәгыйфь акылында гына яралып калмыйча, теленә дә күчте. Үткән-сүткәне дә кайсы малайны котыртып, кайсы кызганып сорап уза торган булды: «Йә Фирдүс, кайчан өйләнәсең инде? Алия укып бетереп, Казанга китеп бара бит, сузып йөрсәң». Алия турында сүз чыкканга, аннан бигрәк үзен кызның исеме белән янәшә куеп сөйләшүләренә күңеле булып, олыларча җавап кайтара Фирдүс: «Кая китсен ул минем кулдан, мин дип үлеп тора! Менә «КамАЗ» гына алыйм да, урлап алып төшәм мин аны». Артык хис-кичерешләр аеруча дәртләндерә иде егетне. Алиянең мәктәпне тәмамлар чагы якынлашкан саен, кичләрен күрше авылга җәяүләп үткән юлларының озынлыгын да сизмәде. Кая ул аңа сүз кату! Кызның күз карашыннан гына да югалып кала иде егет. Кич буе клубтагы дискотекада читтән генә күзәтеп тора иде дә үз авылына кайтканда, юл буена хыял диңгезенә чума иде. Менә алар Алия белән бергә яшиләр, имеш. Фирдүс

«КамАЗ» машинасында капка төпләренә кайтып туктауга, хатыны йөгереп каршы чыга да аны суырып үбеп каршы ала. Эх!

Егетләргә аның шул рәвешле исәрләнеп йөрүе – үзе бер мәзәк. Кызлар кыюларны ярата, бераз чиерттереп алсаң, чын ир буласың, дип, хәмердән авыз иттерделәр. Тәмәке тартмаган егет – егетмени инде ул дип, сигарет тартырга да өйрәттеләр... Болай да акылга туймаган егетнең кыланмышлары исереп алгач, бөтенләй бер кысага да сыймый иде. Аның: «Алия минеке ул! Миңа гына чыгачак. Миннән калган кызны кем кияүгә алсын», – дип кәпрәюеннән тәгәрәшеп көләләр иде.

Балачакта Фирдүсне бер мескен дип кызганып караган кыз, үсә-үсә үз исемен гел Фирдүс белән бутап сөйли башлагач, пошаманга төште. Зыяны тигәне юк-югын да, якын килеп дәшми, үзе исәнләшсә генә сәлам бирә. Тик куе кара керфекләре арасыннан кылый күзләре белән сөзеп каравын һәрдаим сизә иде Алия. Инде өлгергән егет рәвешләре кереп, клубта очрашкан мәлләрдә аның карашында үз корбанын очраткан җәнлек кебек ниндидер бер кыргыйлык та сизелгәч, аннан хәтта бераз курка да калды. Җәйге ялга кайткан бер шәһәр егете озатып йөри башлагач, «Алиянең тәмен мин татыдым инде, миннән калган кыз белән озак йөрмәс шәһәр кунагы», – дип сөйләп йөри башлаганын ишеттерделәр кызга. Хурланып үлә язды, дип әйтү генә берни әйтмәүгә тиң булыр. Чирканды, җирәнде, нәфрәтләнде ул! Башкаларны әнә: «Фәлән белән фәлән очраша икән. Көндез оялмыйча, авызга-авыз куеп сөйләшеп торганнарын күргәннәр, оятсызлар», – дип сөйли иртән сыерларын көтүгә куучы апалар. Ә Алияне ни диләр? Егетләргә кулын да тоттырып карамаган кыз дип тормыйлар, шул күрше авыл тилесенең шакшы сүзләреннән хихылдашалар. Оятыңнан үләрсең!

Кыз бер атна клубка да чыкмады бу хәлдән соң. Инде иптәш кызлары тынычландырып, кабат клуб капкасыннан килеп кергәндә, карашы атна буе сөйгәнен бер күрергә зар булган Фирдүснең күзләре белән очрашты. Җанын бимазалаган нәфрәт бер дулкын булып, бар тәненә таралды, башын томалады. Егетнең каршына ук барып басып, карашы белән көйдерде дә, үзенеке булмаган тавыш, юк, хәтта бер иңрәү белән бары бер сүз әйтә алды:

– Тиле!

Дөрес, үзенә шулай дип дәшүләрен моңарчы да күп ишетергә туры килде егеткә. Үзенең башкалардан аерылып торуын аңлап ук бетермәсә дә, тоемлаган хәлдә андый гына үртәүләргә гадәтләнгән иде ул. Тик бу кадәр үк чиркану белән, сынны катырырдай итеп, бәгырьгә үк үткәреп әйткәннәре юк иде моңарчы. Яңагына суккандай, телсез калды Фирдүс.

Төне буе кайларда йөреп, өенә ничек кайтып җиткәнен дә хәтерләми ул. Әбисе янына кереп тормады, печәнлеккә менде дә кыйналган эттәй бөгәрләнеп ятты һәм шунда гына сабый баладай үксеп елап җибәрде.

Хыял белән чынбарлык арасындагы аерманы сизмәгән, табигатьтән бирелгән тойгылар нигезендә Алияне инде үз хатыны исәпләп йөргән Фирдүс кызның нигә үпкәләве, нигә аңа шулай ачулануы турында гадәти кешедәй фикерле, анализлый белми иде. Әмма ул кул җитмәстәй хыялга тиң кешесенең үзен читкә тибәрүе, хис-кичерешләренең берни дә тормавын эчке бер тоемлау белән, бар табигате белән аңлады.

– Тиле!

Колагында бары шул бер сүз чыңлады. Зәгыйфь акылы белән аңлый да, аңламый да кебек бу сүзнең бар мәгънәсен. Әмма бу сүз аңа тумыштан күзгә күренми ябышып йөри. Шушы сүз аның Алия белән бәйле барлык хыялларын чәлпәрәмә китереп, кырыйдан ыржаеп карап торачак...

Фирдүс күрше авыл клубына йөрүдән туктады. Алия дип төрттерүчеләргә җавабы ачы иде: «Кирәге бар кешедән калган кызның!» Хисләре нечкәрәк булган саен, сүзләре ямьсезрәк, карашы усалрак иде бугай аның. Тора-бара егетнең Алия дип саташып йөрүләре халык арасында онытылды, бу хакта сүз катучылар да сирәгәйде. Ара-тирә авыл апалары гына: «Карале, ниндидер Алия дип саташып йөргән иде бу балакай», – дип, искә алгалыйлар иде. Ә егет хыялланудан туктамады. Печәнлектә бөгәрләнеп елап, кунып төшкән теге кичтән соң, кешеләргә күңелендәге әлеге хыялларын сөйләргә ярамаганлыгын аңлады ул. Алия – хәзер үзе генә белә торган бөек сер иде. Кемгәдер кыз турындагы хисләрен сөйләсә, кабат Алиянең «Тиле!» дигән сүзе галәмне яңгыратыр да, күк капуслары ачылып, сөйгәнен күңелендәге йөз кат йозакка ябылган шул сер сандыгыннан тартып алыр кебек иде.

Роза әбисенә нигезгә килен төшкәнне күрү насыйп булмады. Картлык иңеп, аз гына вакыт авырып ятты да бакыйлыкка күчте карчык. Дөньясында әнисеннән дә якынрак булган газиз кешесен югалтуны авыр кичерде Фирдүс. Җаны-тәне белән аны шулай ихлас яратучы, аңлаучы, кабул итүче кем бар соң тагын дөньясында? Болай да үзенең башкалар кебек булмавы сәбәпле, үз яссылыгында яшәүче егет инде бөтенләй ялгыз калды. Һәм шул ялгызлыгына үртәлеп, усалланып та китте бугай. Әбисе үлгәч тә, аның нигезендә яшәп калу табигый хәл иде аның өчен. Әти-әнисенең үгетләвенә ачы итеп сүгенде дә борын төбендә ишекне дөбердәтеп ябып, өйгә кереп китте. «Бу – минем өй!» Инде яшь ир булып җитешкән, көч-гайрәте ташып торган улына каршы дәшәргә этисе дә шикләнде бугай, башка әйтеп тормадылар.

Ике өй арасында йөреп гомер итте Фирдүс. Әти-әнисе янына менеп, ашап-эчеп, мунчаларын кердә, киемнәрен алыштыра да кунарга барыбер үз өенә төшеп җитә. Әбисеннән калган, инде картаеп беткән биш тавыкны карагандай итә. Авыл буйлап кагылып-сугылып йөри торгач, бер ташландык песи ялгыз хуҗаны үз итте, ә көчекне исә Фирдүс үзе юллап алып кайтып, бәйгә утыртып куйды. Эт дигәне карап торышка үскәч тә көчектән әллә ни аерылмый иде, картайгач, бөтенләй йончыган кыяфәткә керде. Шул эт бер көзне балалап куйды. Фирдүснең сабыйларча шатлыгының чиге булмады. Үткән һәр кешегә: «Пушок алты бала китерде, әмма тугызынчысы үлде», – дип сөйләп йөри торгач, эт кыйссасы халык телендә бер мәзәк булып сакланып калды.

...Тормыш шулай да уза икән, йа Аллаһ! Яшьтәшләре инде ир уртасы булып, балалар үстереп ята. Сабан туена яңа машиналарда ыспай гына киенеп, хатыннарын, бала-чагасын төяп кайтып җитәләр. Чабалар, табалар, югалталар, кайгыралар, үзгәрәләр, үзгәртәләр... Ә Фирдүснең каралтысында тормыш тукталган иде. Фирдүснең дөньясында тормыш тукталган иде. Әйе, яңа көн туа. Һәр көн үз мәшәкатьләре белән үтеп китеп, кояш байый.

Ләкин бер көнне икенчесеннән аерырга кушсалар, болай да аңы зәгыйфь ир аптырашта калыр иде. Авылдагы вакыйгаларга бик исе китми генә яши бирде ул. Кызыксынуы бик көчле булса да, аның акылы өчен куркыныч булган тетрәнүләрдән организмы, табигате үзе саклый иде бугай аны. Сеңлесенең кияүгә чыгуы, бер-бер артлы ике бәби алып кайтуы, күршеләре йортында янгын чыгуы, авылларында таш юл салу, яңа Мәдәният йорты ачылышына Президентның килүе, коточкыч юл һәлакәтендә туганнан туган энесенең һәлак булуы... Бу вакыйгалар Фирдүснең аңына кереп, зур кызыксыну уятып алалар иде дә, инде икенче көнгә «хәтер» дигән архивка җибәрелеп, шунда тиз арада эреп югалалар иде.

Таң ату белән көндәлек мәшәкатьләренә чума ул. Этен, мәчесен ашата. Кышын кар көри, җәй буе балыкка йөри. Соңгы шөгылен аеруча ярата иде, һәркөн балыкка барырга әзерлек, абзар артындагы тиреслектән суалчан казу, сәпитенең төзеклеген тикшереп алу бер йола кебек ашыкмыйча, тәфсилләп башкарыла иде. Авылларындагы елга балачакта бик киң булып тоелса да, вакыт узгач, инеш кенә булып калды. Су коенырга да, балык тотарга да якын-тирәдә яшәүчеләр күрше авыл читендәге зур елгага килә иде. Җәйләрен Фирдүс моннан кайтып та керми. Сәпитенә атлана да, теге алты көчек арасыннан исән калган бердәнбер Акдусны ияртеп, күрше авылга юл ала. Тал астында үзе генә белгән урын инде тапталып, такырланып беткән. Яшереп куелган җиреннән иске урындыкны тартып чыгара, чиләгенә су ала. Минутның тәмен озаккарак сузарга теләгәндәй, салмак кына хәрәкәтләр белән кармагын сүтәргә керешә. Читтән карап торсаң, һәр хәрәкәте төгәл кебек үзенең. Ләкин якынрак килеп тыңласаң, аның үзалдына нидер мыгырданганын, кайчак көлеп, кайчак сүгенеп, чын-чынлап янында кемдер бардай сөйләшкәнен күреп, тән дә чымырдап китә.

Беркөн аның аулак почмагы булган таллык артындагы тауда балачага тавышлары ишетелде. Гадәттә, көн үзәгендә елга буенда этем дә калмый: чын-чынлап балык тотам диючеләр таң белән бергә уянып яисә кичке эшләрен тәмамлап килә, су коенучылар буаның каршы ягында йөзеп кинәнә. Фирдүснең кызыксынуы җиңде, кармагын җиргә куеп, таллыктан чыгып, тавыш килгән якка атлады. Биш-алты яшьләр чамалы зур башлы, түгәрәк корсаклы малай үзеннән шактый олы өч малайга елау катыш акыра-бакыра чирәм йолкып ыргыта иде. Ул шулхәтле ярсыган ки, чирәмле яр буенда басып тормаган булса, кулына таш алып, берәрсенең маңгаен җимереп кайтаруын көт тә тор! Тал арасыннан кинәт килеп чыккан ирне күргәч, балалар берара тын калды. Фирдүс таушалган солдат киеменнән, кырынмаган йөзен тагын да караңгылатып торучы калын кара кашлары арасыннан сөзеп карап тора иде. Әллә кыяфәтеннән, әллә көтмәгәндә килеп чыгуыннан коты алынган балалардан мизгел эчендә җилләр исте, чырыйлап, авылга чаптылар.

– Ник сугышасың? – диде ул, йомшарган борынын сөртергә дә онытып, кыргый җәнлек кебек астан гына туп-туры күзенә карап торучы малайга.

– Үзләре алар, үзләре алар, үзләре алар, – дип тотлыга-тотлыга бер сулышта җавап кайтарды тегесе. Аның бөтен кыяфәтеннән бернидән дә

курыкмавы, бу таныш түгел абыйдан да коты алынып качмаячагы, кирәк булса, аңа да бер уч чирәм йолкып ыргытачагы күренеп тора иде.

– Балык тота беләсеңме?

– Белсә соң, белсә соң, – дип такмаклады бәләкәч.

Фирдүс берни дәшми генә таллыкка кереп китте. Кармагын алып чыкканда, малай урыныннан кымшанып та карамаган, тик инде тынычланган, ни булыр дип кызыксынган кыяфәт белән әлеге танышлыкның дәвамын көтеп тора иде.

– Кил монда, мә сиңа да кармак, – диде Фирдүс.

Шуны гына көткән кебек, шикләнеп тә тормыйча, малай яр кырыена килеп тә утырды.

– Чели киертә беләсеңме?

Малай җавап биреп тормады, суалчанны кармакка аркылыга эләктереп тә куйды, ул арада бармагына да чәнчеп алырга өлгерде. Еларга уйламады да үзе, пычрак бармагын авызына кабып ялап куйды да, шуның белән авыртуы әллә бетеп китте, әллә онытылды шунда.

Зурбашның кармакка җимне киертә белмәве Фирдүснең ачуын чыгарды:

– Иии, хәчтерүш, шуны да киертә белмәскә. Менә Фирдүс абыеңнан өйрән! – дип, үзенекен киертеп күрсәтте.

Алар сирәк кенә шундый төртмәле сүзләр белән алышып, сәгатькә якын балык тоттылар. Сөйләшүләренә колак салсаң, яшь аермасы сизелми дә иде. Фирдүс балалар белән аларча уйный һәм фикерли, өлкән абзыйлар янында әче итеп сүгенеп, тәмәкесен тартып, ирләрчә сөйләшкән була, гомумән, тирәсендәгеләр ни эшли, ул да шуларча кыланырга тырыша иде. Аның табигате шулай әз булса да, ирнең ялгызлыгын, башкалар төсле булмавын «тигезли» иде бугай.

...Апасының балаларына ияртеп, урамга уйнарга чыгарып җибәргән улының елга буенда калганын Алия күпмедер вакыттан соң гына белеп алды. Балаларны ашарга чакырыйм дип, чыккан ана капка төбендә утыручы энекәшләренең үзләрен генә күргәч, өстенә салкын су сипкәндәй булды.

– Әмир кайда?!

– Апа, ул ни… Буа кырыенда… Без уйнадык кына, ул үзе сугыша башлады. Аннары бер куркыныч абый килеп чыкты...

Алия аларны тыңлап бетермәде, малайлар күрсәткән якка чапты. И Ходаем! Исән-сау гына булсын аның йөрәк парәсе! Ул арада иренең сүзләре хәтереннән сызылып үтте: «Тиле! Катмый да ичмасам!» Йа Аллам! Ул кансыз атаның сүзләрен кабул итә күрмә, зинһар, гөнаһсыз сабые исән-сау гына була күрсен!

Алиянең шәһәр егетенә бөреләнгән беренче саф мәхәббәте җаваплы булып, бик матур гаилә корып җибәргән иде алар. Икесе дә пар килгән, барлык туганнарын җыеп, никах һәм туй мәҗлесләрен уздырдылар. Әти-әниләре булышлыгы белән фатир алып җибәрделәр, икесе дә яраткан эшләрендә хезмәт куеп, аңлашып яшәделәр. Тормышларын түгәрәкләндереп, гаиләдә ир бала да аваз салгач, аягы җиргә тимәде әти кешенең. Шатлыгы гына озакка бармады, табиблар балага «олигофрен» дигән диагноз куйды. Ирнең күңелендә нидер өзелде. Дөрес, баштагы мәлләрдә яратырга тырышты ул аны. Аннан яратуны (бәлки, ярату да булмагандыр) кызгану


хисе алыштырды. Соңрак улына һәм сау булмаган бала тапкан хатынына карата ачу белән тулды аның күңеле. Нинди гаделсезлек бу? Дуслары әнә сау-сәламәт бала сөя, мактаныша-мактаныша фотога төшереп, интернет битләрен тутыра. Шарлар, уенчыклар тулы өйләренә кунаклар чакырып, туган көннәрен бәйрәм итә. Ә ул гаиләсе белән түгел, үзе генә дә кеше янына чыгарга кыенсына. Танышлары: «Бу бичараларның балалары акылга туймаган бит», – дип, бармак төртеп сөйләп калалар кебек. Әти кеше хурлыгыннан нишләргә белми, өенә кайткач, ачудан Алиягә һәм улына җикеренә иде.

Алия улын ире өчен дә икеләтә яратты бугай. Аның җитешсезлеген, шул сәбәпле бәхетсезлеген әз булса да җиңеләйтергә мөмкин дисәләр, бар яратуын гына түгел, гомерен дә жәлләмәс иде ул. Алия алга таба да шулай сабыр итеп, газиз иренең, яшьлек мәхәббәтенең йөрәге йомшарыр, аталык хисләре уяныр дип, өметләнеп яшәгән булыр иде, бәлки. Үзенә килгән бар кыенлыкларга чыдар ул, авыр сүзләрне дә күтәрер, улына гына тимәсеннәр... Ләкин көннәрдән бер көнне әти кешенең улына җикеренгәнен ишеткән ана өчен барысы да бер мизгелдә хәл ителде. Бер сүз, нибары бер сүз барлык киемнәрен җыеп, ике көн дигәндә, авылга – әти-әнисе янына кайтып китәргә мәҗбүр итте аны.

– Тиле!

Иренең авызыннан үз улына әйтелгән әлеге сүзне ишетеп, катып калды Алия. Мизгел эчендә күз алдына үзенең кайчандыр Фирдүскә ачыргаланып, нәкъ менә йөрәгенә үткәрердәй итеп, шулай дәшкәне хәтерендә сызылып үтте... Йа Раббым, әллә соң шул гөнаһсыз бәндәнең рәнҗеше төштеме аның сабыена?

Ут капкандай чабып, елга буена килеп җиткән Алия яр буенда икәүнең бер җайга гына гәпләшеп утыруын күреп, дәшәргә түгел, хәтта үзен сиздерергә дә кыенсынып туктап калды. Алдындагы кешеләрне рәшә артына яшергәндәй, су өстендә ялтыраган кояш нурлары күзне чагылдыра, ирексездән кулыңны каш өстенә куеп карарга мәҗбүр буласың. Биредә җил дә исми, ахры. Икәүнең сирәк кенә, әмма үз итеп сүз алышулары да тынлыкны бозмый, киресенчә, бу тынлыкның бер авазы булып, таллыкны да изрәтә иде бугай. Туганлык җепләре булмаса да, рухлары бердәй, төрле яшьтәге ике табигать баласы өчен әлеге тынлык барлык сүзләрдән дә артык бер бәхет иде.



Илдар
Кыямов

# МИН – БАРЫ ТИК ГАДИ КЕШЕ ГЕНӘ...

* * *

Юл газабы – гүр газабы, диләр,
Шул «газаплар» әллә ничек якын.
Күрермен күк юлда шигъриятнең
Пар канатлы, сылу тулпар атын.

***

Еллар узар. Беркем бакый түгел:
«Авылым!» – дип, мин дә җирсемәм...
Һаман шулай таңнар каршылап
Яши бирер Туган җир генәм!

***

Җир әйләнә, кояш нурын сибә,
Кар ява да җиргә, кар эри.
Кешенең исе китми бернигә дә –
Кырык төрле эш бетереп йөри.

* * *

Тыйма, кеше, йөрәгеңне –
Типсен, янсын көчлерәк!
Бу янулар күгәрүдән
Саклану өчен кирәк.

***

Тәрәз  ачтым иртә таңда –
Бик хуш кына кошлар сайраша.
Бер карга да кушылып бакырмаса,
Китек булыр иде тамаша.

Илдар КЫЯМОВ (1971) – *шагыйрь, журналист, нәфис сүз остасы, җырчы, актёр; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Җырларымда җирсүем» исемле шигырьләр җыентыгы һәм төбәк тарихына багышланган берничә китап авторы. Казанда яши.*

## Киңәш сораучыга

Минем юатуны телисең син.
Кул тыгалмыйм язмыш эшенә.
Илаһи эш килми кодрәтемнән,
Мин – бары тик гади кеше генә.

## Манекен

Бик охшаган безнең дөнья
Кибеттәге манекенга.

Манекенның бетми эше:
Кием ала һәммә кеше.

Бер туктамый ала-сата,
Суыкларда ката-ката.

Гаҗәпләнәм күп уйлагач:
Ул гел эшли, гел ялангач...

***

Кара Чишмә кыйбла якта булыр,
Казан тарафыннан карасаң.
Болытларга карап күңелем тула,
Шунда йөзгәннәрен аңласам.

Кара Чишмә – Казан арасында
Ике йөз дә илле чакрым.
Мәркәзебез үзенә тартып алды,
Шунда кордым гомер чатырын.

Туган төбәктәге хатирәләр
Биләп алган бөтен барлыкны.
Медаль итеп тагып йөрим менә
«Читкә китте» дигән ярлыкны...

## Әнкәй хакында уйлану

Туган төбәк Кояш иле сыман,
Һәрчак нурлы анда биек күк.
Улы кайтканлыгын күреп алса,
Әнкәй чыга ишек төбенә үк.

...Шулай иде элек, мин яшь чакта.
Бүтән бүген ишек-бусага.
Бар җанымны бирер булып хәзер
Улым көтәм үзем тупсада...

Илгә кайту гына сирәгәйде –
Тормыш йөге басты иңнәрне.
Туган төбәк шулай яшь саркытып
Елата ла бездәй ирләрне.

Газиземнең кабер өстен утыйм,
Сагышыма тынгы тапмадым.
Кычытканның чагып алуын да
Әнкәй үпкәсе дип аңладым.

Бу фикерем – тик бер фараз гына,
Үпкә тотмас Ана улына.
Әнкәй җаны – кояш, җылылыгы
Җитәр бөтен гомерем юлына!

## Киләчәккә кайтам

Туган йортка кайту нинди рәхәт,
Сулышлар да китә киңәеп.
Кайту һәрчак сөенечле була,
Көтеп торса газиз әнкәең.

Туган йортта канат чыныктырды,
Очып китте кече, олысы.
Дүрт ел* кинәндерде туган йортның
Әткәй саклап торган җылысы.

Кайту! Кайту! Нинди җылы бу сүз,
Кайтыр җирең булган тәкъдирдә.
Ничә еллар кайттым үз ояма,
Рәхмәтлемен шуңа тәкъдиргә.

Үткәннәргә кайталмау сагышы
Гомер буе мине өтәчәк.
Тик боекмыйм: кайту шатлыклары
Киләчәктә мине көтәчәк!

## Каршылык

Килеп кердем шулай зур кибеткә.
Каршы алды мине каршылык:
Бер агайның кәрзинендә ята
Аракы һәм... хәләл казылык.

## Бер кабер янында

Гаҗәп тә бай булган, ди, бу егет.
Яши белгәндер ул «матур итеп».
Хәсрәт төшә тик кайвакыт башка –
Акча киткән... үзе хәтле ташка.

## Сафсата түгел

Бу фикерем ачыш түгел һәм түгелдер сафсата.
Шайтан таягы да, дуслар, ни гаҗәп: чәчәк ата!

*Дүрт ел – әни вафатыннан соң әткәй шулкадәр гомер ялгызы яшәде.



Рафига Усманова

# ЯРЛЫКАНУ БӘХЕТЕ

ПОВЕСТЬ

**Зират – мәңгелек йорт**

Җай гына барган автобуста юлчылар әллә ни күп түгел иде. Булганнарының да игътибары бер-берсенә сыенышып утырган парда иде шикелле. Бердән, аларның күгәрчендәй гөрләшеп барулары, сөю-сәгадәтле мөнәсәбәтләре күңелләрне яуласа, икенчедән, алсу битле, оялчан карашлы, зифа буйлы сылу кызның бер кулы гарип булуы кызгандырып куйгангамы, алар бер дә күз уңыннан читтә түгел иде.

Менә мәхәббәтле пар, киләсе тукталышта төшәргә әзерләнеп җыена, өс-башларын төзәткәли башлады. Автобус туктауга җитез генә төшеп калсалар да, егетнең бер аягы икенчесеннән озынрак сыман аумаклап атлавы да, хәләленнән өлкәнрәк булуы да күзгә чалынмый калмады. Тукталыштагы каршы якка автобус көтүче берничә юлчы да бу парны сынаулы караш белән озатып калды. Ә яшьләр исә, алар белән ипле генә исәнләшеп, олы юлдан ерак түгел урнашкан зиратка таба атлады.

– Кемнәр соң болар, хәтерләмим? – дип сорап куйды ак яулыгын мөслимәләрчә бөркәнгән, чәчәкле озын күлмәге өстеннән бизәкле камзул кигән ханым, алар киткән якка кызыксынулы караш ташлап. Бераз тынлыктан соң шакмаклы базар сумкасын җыйнаклап маташкан өлкәнрәк яшьтәгесе, яшь пар киткән якка сынаулы караш ташлап:

– Кара, танымый да торам икән... Бу теге түбән оч мәрхүмә Хәдичәттәйнең яшьли якты дөньядан киткән кызы Разиянең улы лабаса... Нәкъ үзе. Әнә бит атлавы шул. Тумыштан аягы гарип иде ул баланың. Минем улым белән яшьтәш иде, кырык яшьләр чамасыдыр үзенә. Өйләнмичәрәк йөрде бугай. Ә янындагы чибәркәен хәтерләмим. Бәлки, соңлап булса да үзенә тиңне тапкандыр мескен балакай, – дип өстәп куйды, бераз кызгангандай итеп.

Рафига УСМАНОВА (1954) – *шагыйрә, прозаик, публицист; Башкортстан һәм Россия Язучылар берлеге әгъзасы, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Җиде чишмә», «Балачагым диңгезе», «Бәхет алмасы» һ.б. китаплар авторы. Башкортстанның Бөре районы Бустанай авылында яши.*

Чыннан да алар мәрхүмә Разиянең улы Зиннәт белән аның сөйгән кызы Нәзифә иде.

Яшьләр тынчу автобустан төшеп, тузанлы юлны артта калдыруга, икесе дә саф һавага куанып, елмая-елмая, тирән итеп сулап куйды. Әнисенең кендек каны тамган изге җирнең һавасы егеткә шундый тансык тоелды: мөмкин булса, ул ике дә уйламый шушында калыр иде, күпме генә сулама, йотлыгуың һич басылмас!

– Нинди йомшак, назлы һава! – Нәзифә дә әнә шулай хисләнде, ә ялан чәчәкләре исә аны тәмам әсир итте бугай, ул сoклануын яшерә алмый әйтеп куйды:

– Ә гөлләре соң, чәчәкләре?! Искиткеч ямьле, исерткеч хуш исләләр! Алар, болын чәчәкләрен кочакларына өсти-өсти, пар адымнарын зиратка таба ешайтты. Ә анда шомлы да, серле дә иде. Ара-тирә яфрак лепелдәвен, еракта ялгыз кәккүк тавыш бирүен исәпләмәгәндә, бүтән өн-мазар тою читен иде. Каршыларына зираттан чыгып килүче олы яшьтәге түбәтәйле бабай белән ак яулык бөркәнгән әбекәй очрады. Сәлам алышканнан соң, бабакай иплəп кенә:

– Бу йорттагы мөэминнәргә, мөселманнарга сәлам, Аллаһыдан тынычлык, дип кeрeгeз, бәбкәйләрем, – диде, бик ягымлы гына итеп. Яшьләр, рәхмәт әйтеп, ул өйрәткәнне кабатлап, алга узды. Әбекәй бабайга кушылып:

– Каберләрегезне зиярәт итегез, дөреслектә зиярәт итүегез үлемне искә төшерә, дигән бит пәйгамбәребез (с.г.в.с.). Менә бу иманлы балалар да үлемне искә төшерәчәкләр, ахирәт хакында уйлаячаклар. Аллаһ кушса, гыйбадәтле бәндәләр булырлар, инша Аллаһ, Амин! – дип, изге теләкләрен ирештереп калды.

Ә әни кеше бу газизләрен рәсеме аша елмаеп каршы алды. Ул гүя: «Ни хәлләрең бар, улым? Ә бу чибәркәй кем?» – дип сорарга җыена иде. Нәзифә, чәчәкләрен кабер өстенә салып, карашын рәсемгә төбәде. Аннан ике калын толымын ике якка үреп салган, мөлаемлыгы йөзенә кершәндәй ягылган гүзәл бер ханым сәламләгәндәй текәлеп тора иде. Зиннәт тә гөлләмәләрен әнисен төреп каплагандай җәелеп үскән чирәм юрганы өстенә, Нәзифәнеке янына таратып салып, шунда тезләнде, газизенә сыенырга теләгәндәй, чәчәкләр өстенә башын салып тын торды: әнисез ятим калган сабый чагын яңадан кичергәндәй, күзләреннән ирексездән кайнар күз яшьләре атылып чыгып, чәчәк таҗларына тама иде. Шунда әнисенең ятим Апуш хакында сөйләгәндә, җыр итеп көйләгән юллары исенә төште: «Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы».

– Әни, мин сиңа килен алып килдем, – диде ул, кычкырып елап җибәрүдән үзен көч-хәл белән тыеп. – Фатихаңны сорыйм, әнием!

Бите буйлап аккан күз яшьләренә ирек биреп, Нәзифә дә, сөйгәненең җилкәсенә кулын салган килеш, аның янына иелде. Зиннәт исә, бернигә әһәмият бирмәгәндәй, әнисе белән сөйләшүен дәвам итте: «Әнием, газизем! Минем сине хәтерләмәгән бер генә минутым да булмады. Мин сине гел өзелеп сагынып яшәдем».

Ана хакы – Аллаһ хакы икән. Балалар өстендә булган хакларның да

иң зурысы булганга, һәр эштә, бигрәк тә гаилә корганда, ана фатихасын алу фарыз. Шунсыз юлың уңмас. Болар егетнең күңеленә бала чактан ук кереп оялаган хаклык иде. Балалар бакчасына йөргәндә, Зиннәтнең әниләр турында җыр да җырлаганы булды әле:

Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын.

Тик, ни кызганыч, мондый бәхет аның әнисенә тимәде шул. Әмма ул аның гомерен үз күңелендәге матур хатирәләр аша озайтачак әле, һичшиксез озайтачак. Амин! Ул, дога укыгандай, күз яшьләре дә кибеп бетмәгән битен сыпырып куйды. Нәзифә дә аңа кушылды. Аллаһ бар. Ул ташламас!..

...Кире үзләре яшәгән шәһәргә кайтып җитүгә, Зиннәт, икенче автобуска билет алып, сөйгәнен туган авылына ялга озатты: «Онытма, мин синсез – исемсез, бәхетсез мин синсез», – дип, ихлас такмаклап калды.

Хатын-кызның үз планнары шул. Нәзифәнең дә никахларына кадәр туып-үскән өен җыештырып, бераз әзерлек чаралары күреп киләсе бар иде. Ул да әнисез үсте бит, әтисе аны ялгызы тәрбияләде. Әнисен исә кыз томанлы гына хәтерли: күзләрен генә ачып калдырып, башы, аяк-куллары да ап-ак бинт белән уралган иде аның. Кызның үзен дә әнисе янына авыр хәлдәге чирлеләрне күчереп йөртә торган тәгәрмәчле арба-каталкага салып кына алып керделәр. Аның үзенең дә бәрелгән, яраланган, сынган урыннары җитәрлек иде. Ә әти-әнисе белән кунакка җыенуларын, җиңел машиналарында бозлавык юлдан читкә тәгәрәүләрен бүгенгедәй хәтерли әле. Авариядән соң әнисе, аерыласы килмәгәндәй, кызының кулларын кысып тоткан килеш, өченче көн дигәндә җан бирде. Кызга, әниең йокыга китте, диделәр. Нәзифәнең бәрелгән, сынган урыннары тиз төзәлеп, ялганса да, сул кулы гына, нишләптер, терсәктән буыны катып, гарипләнеп калды. Рульдә булган әти кеше авариягә юл куюга үзен гаепле санап, битәрләнеп өзгәләнсә дә, өсләренә томырылып килгән, шофёрын инсульт бәргән йөк машинасыннан котылуның, ни үкенеч, бүтән юлы юк иде шул. Аны хәтта милиция хезмәткәрләренә кадәр шулай юатса да, кызының әнисе белән исән калуы яхшы булырына инанган хәлдә, шул очракта үзе һәлак булса да үкенмәслеген уйлап, әрнеп-әрнеп куя иде. Хәер, бер башка ике язмыш юк инде анысы. Берни әйтеп булмый, күрәчәкне күрми, чыннан та гүргә кереп булмый икән лә... Әйтәләр бит, газапны тауга биргәннәр, күтәрмәгән, кешегә биргәннәр күтәргән, дип. Ул да күтәрергә, кызын җил-яңгыр тидерми тәрбияләп үстерергә тырышты. Үги әни кагу-сугуларына юл куймас, кимсетелүгә мәҗбүр итмәс өчен димләүләргә, хәтта кайбер чибәрләрнең үзләре үк сырпалануларына карамастан, өйләнмәде, үзенә толлык йөген бик теләп йөкләде. Әмма гаилә фаҗигасе турында хәтерләгәндә (билгеле инде бу хәл бөтәшмәс чи яра булып, бәгырьне гел кан саркытып тора иде), моны беренче хатыныннан киткәндә, әти тәрбиясеннән мәхрүм иткән бер гаепсез баласының күз яше, әрнеш-каргышыдай кабул итеп, йөрәге гел сызлап, һаман да чәнчи, сыкрый әле. Гөнаһына күрә җәзасыдыр: тәүбә итәргә гомер генә җитсен!.. Амин!

## Үксезлек

Нәзифә белән Зиннәт икесе дә сыңар канат астында үскәнгәме, дөньяга карашларында уртаклык тоепмы соң, әллә бүтән сәбәптән, бер-берсенә җиңел тартылдылар. Аягында кимчелек булуга карамастан, егет һич кенә дә үзен бүтәннәрдән түбән дә, җитешсез дә санамый әле. Чөнки фатиры да, тормыш өчен кирәк-ярагы да, кием-салымы да дигәндәй, башкаларныкыннан ким түгел. Хәер, хәтта бик ярлы кеше дә үз алачыгында хан һәм патша инде анысы. Иң мөһиме, аның үз куышы бар. Үз түреңдә үзең генә түрә буласың, билгеле. Әз-мәз пенсиясенә канәгатьләнеп, түшәмгә төкереп ятучылардан да түгел әле, эш урыны да бар. Кулы эшленең – авызы ашлы. Өстәмә акча таба, җитмәсә, шәһәр яны бакчасында җиләк-җимеш, төрле яшелчәсен дә мулдан үстерә... Шулай училищедан соң бүгенгәчә ялгызы гына көн күреп килде. Ә әнисе исән-сау булсамы?! Ничек гөрләтеп гомер итәрләр иде бит! Зиннәт анасының чиксез кайгыртучанлыгын, иркә күз карашын, назлы кочак җылысын онытмый, күңелендә саклап, шуннан көч-куәт алып яшәде һәм яши. Баксаң, ана назы кешене гомере буе озатып йөри икән.

...Зиннәтнең беренче сыйныфка йөри башлаган гына көзе иде. Көннәрдән бер көнне мәктәпкә соңга калганын сизеп, кинәт ашыгып торып, әнисен уята башлады: селкеткәләп тә, кочып та карады. Аһ! Күзе генә бераз ачык көе бер хәрәкәтсез катып калган иде инде әнисе. Малай башта, күзләрен зур ачып, бер аваз да чыгара алмый хушсыз калып торды. Курку катыш билгесез хис аны хәрәкәтсез калдырды: тамагына утырган йодрык кадәр төер, тын алырга да форсат бирми зурайганнан-зурайды. Аннары сабый үксеп елап җибәрде... Әнисенең йөрәген тотып сызлануы юкка булмаган икән!

– Сине үстереп, кеше итәргә каян көч табарга икән, балам? Аллаһым! Ятим итмә улымны, – дип елаганын да күргәне бар иде Зиннәтнең.

– Ә-ә-ә-әһ, әни! – Шулай әрнеде малай. Хәзер ул кем белән яшәр? Кем аны мәктәпкә озатыр? Кем дәрес әзерләргә булышыр?.. Шул уйлар белән өзгәләнде бала. Әмма күз яше белән генә ачы кайгынны юып төшереп булса икән ул? Үзен әнисе сөйләгән ятим Апуш итеп тойды кечкенә Зиннәт. Ярый әле әнисенең абыйсы бик вакытлы килеп, ишек шакыды. Бүген ул, машинасына утыртып, сеңлесен шифаханәгә алып барырга тиеш булган икән дә бит...

Ятимнең күңеле сынык була, билгеле: соңыннан исә малай көлмәс, еламас, хәтта сөйләшмәс булды. Ә кайнар яшьләре исә күзләрендә пәрдә булып, озак эленеп торды. Үксез ятимлек йөрәген талкыды аның...

...Кызганыч, әтисен дә бик томанлы гына хәтерли. Зиннәтнең, бала чагында авырып, су да йота алмый яткан чаклары еш була иде. Баланың бармагы авыртса, ананың йөрәге сызлый, билгеле. Ул авырган саен җанын да кызганмастай булып, әнисе бөтерелә. Бер шулай чираттагы үрсәләнеп ятуында эш урыныннан бераз эчеп кайткан әтисенең:

– Каян алдың, кире илтеп куй бу имгәкне! – дип, аяк тибүеннән сүз үзе урамнан алып кайткан иясез песи баласы турында бара дип уйлады бала. Әтисе шул йомшак йомарламны кире чыгарып ташларга куша дип уйлап, песиен кочып, сулкылдый башлады. Ә әтисе:

– Туйдым мин мондый тормыштан, мәңге терелмәс әтәмби бәрәңгедән,

– дип, чемоданына кием-салымын ыргытты, шкафта эленеп торганнарын кайсын иңенә салып, кайсын кочып чыкты да китте. Бүтән чакта, хәтта эшкә киткәндә дә, улын кочып сөя, машинасына утырганда, тәрәзәдән карап калган баласына елмаеп, кулын изи торган иде. Ә бу юлы борылып карамады, елмаймады, кулын да изәмәде: китте, бүтәнчә күренмәде, кайтмады, тәмам югалды...

Әнисен җирләп кайтканнан соң, әби-бабайлар, туган-тумача өчен табын әзерләнде. Мулла бабай әнисенә догалар укып, сабыйның аркасыннан сөя-сөя: «Аллаһ ярдәменнән ташламас, инша Аллаһ, иманлы бала булып үсү насыйбы телим, – диде, яшьле күзләрен (Бабайлар да елый икән!) сөртә-сөртә. Йомшак күңелле мулла бабай Зиннәтнең кесәсенә үзенә бирелгән хәер акчаларын салып китәргә дә онытмады.

Ә икенче көнне ниндидер матур киемле ят апалар килде. Бер кочак кәгазьләргә ниләрдер язып, әтисе турында да сораштырганнан соң, кансыраган җәрәхәткә тоз сипкәндәй, балалар йортына бару турында сүз кузгаттылар. Моны ишетүгә малай елый башлады. Соңыннан әнисенең Сәмига апасын кысып кочып:

– Мин анда бармыйм, бирмә мине, Алма апа, – дип үкседе. Ике улын ялгызы үстергән, югары уку йортлары тәмамлаткан, яңа гына аларны олы тормыш юлына чыгарып, ялгызлыкта калып, балаларын юксынып яшәгән чагы иде аның. Үзен дә, Зиннәтне дә ятим тоеп, ул сабыйны күкрәгенә кысты. Тыштан усал, җитди тоелса да, йомшак күңелле ул. Ятимне елый-елый сөйде дә, үзенә алырга ризалашты. Бала тумыштан күп авырулар белән туып, әле һаман саулыкка туймагангамы, килүчеләр мондый чишелешкә каршы килмәделәр. Фатирга яшәргә кеше кертеп, аның акчасын малайның махсус исәпләмәсенә күчерү мәнфәгатен хәстәрләп тынычландылар. Бер тапкыр шифаханәдә ятканда, хәлен белешеп, икенчесендә мәктәпкә килеп, укытучысыннан нәрсәләрдер сораштылар да, тынычландылар, ахрысы. Бүтән борчып йөрүче күренмәде. Һәрхәлдә Зиннәткә шулай тоелды. Алма апасы әнисе кебек үк назлы тоелмаса да, какмады, ач-ялангач йөртмәде, тормышта бәхетнең күктән төшмәвенә төшендереп, үз-үзеңне хезмәтләндереп яшәргә, пөхтәлеккә, җыйнаклыкка, бүтәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтеп үстерергә тырышты. Зиннәт тә, балалыгы белән кайчак карышып алса да, гомумән алганда, тыңлаучан булып үсте. Бер нәрсәдән дә мәхрүм булмаса да, кеше арасында үзенең ятимлеген барыбер сизә иде ул.

## Сер сандыгы

Никахларыннан соң Зиннәт кәләшен үзенең фатирына алып кайтачак. Нәзифә үзенә тартмакчы булган иде дә. Егет ризалашмады. Ата-бабадан калган йоланы бозып булмый....

Өе барның – көе бар. Сылуын авылына озатканнан соң, берничә көн үтүгә, эштән соң торагын энә күзеннән үткәреп җыештырырга булды. Буйдакның үз тәртибе. Кем белә, ир-егеткә охшаган – хатын-кызга охшамас. Дөнья якты булсын дисәң, үз өеңдә ут кабыз, диләрме әле? Алма апасы белән бергә тәрәзәләргә яңа челтәр һәм пәрдәләр тектергәннәр иде. Тәрәзәләрен юып, сөртеп, шуларны элде, чәчәк кибетеннән берничә бүлмә гөле сатып алып,

матур чүлмәкләргә күчереп утыртты. Урын-җир әйберләрен җилләтеп, япмаларын, мендәр тышларын өр-яңага алмаштырды. Зал диварлары заманча обойлар белән балкыды, идән келәмнәрен тазарттырып алды. Кыскасы, юды, сөртте, буяды, яңартты... Искергән, төсе уңган, чатнаган савыт-сабаны кайсын ташларга, кайсын бакча йортына илтергә әзерләп куйды, яңаларын аш бүлмәсендәге шкафларга тезде. Кем әйтмешли, себерке килсә, чүп качар: электән дә тәртип сөйгән егетнең фатиры тагын да матурланып, ялт итеп калды. Ике атна чамасы вакыт һәр көнне эштән соң әнә шул мәшәкатьләр белән сизелми дә үтеп китте. Ә менә залны (чынында исә ул зал да, йокы бүлмәсе дә иде) матурлап, күңелне якты хатирәләр белән бизәп утырган, күпереп торган, кайберләре чигүле нәкышләре белән әнисенең елмаеп торган йөзен хәтерләткән ястык-мендәрләр өелгән сандыкны Нәзифә үз итәрме, искелек калдыгы санамасмы? Шулай шомланды Зиннәт. Эчендәге вак-төякнең кирәген-кирәкмәсен барлап, әллә соң сандыкны бакча йортына илтсенме икән? Мөгаен, шулай дөрес булыр. Шул уй белән кияү егет сандыкка ревизия ясарга тотынды...

Зиннәт дәү әнисе белән сандыктагы әйберләрне карарга бик ярата иде. Капкачын ачып җибәрүгә, иң өстә ап-ак сөлгегә төрелгән, инде саргаеп беткән, дәү әнисенең ата-бабаларыннан ук калган, битләре телгәләнеп беткән, начар абыйлар учакка ташлагач, көлгә әйләнүдән кемдер коткарып калган Коръән китабы. Нигәдер, дәү әнисе аны күз яшьләрсез кулына алмый иде. Шунда ук төрледән-төрле дисбеләр килеп чыга...

Дәү әнисе бәйрәмгә әзерләнгәндәй юынып, яңа күлмәген киеп, ап-ак яулыгын туздырып бәйләп, намазын укыгач, бисмилласын әйтеп кенә ачып җибәрә сандыгын. Ә Зиннәт аннан нәрсәләр чыгарын кызыксынып, әмма сабырлык белән тыйнак кына көтеп утыра иде. Олы кеше – солы төше. Сандык белән һәр очрашу тантанасы дәү әнисенең тарих, тормыш, әдәп-әхлак дәресләренә тиң булган икән лә...

Менә, ниһаять, ниндидер бер рәхәтлек белән дәү әнисеннән әнисенә, аннан үзенә мирас булып калган сандыкны ачып җибәрде Зиннәт. Ничә еллар бикле торганнан сандык капкачының эчке ягына тезеп ябыштырылган фоторәсемнәр аша аның балачагы карап тора иде. Әниле чак – бәхетле чак. Сандыкны ачып куюга әнисенең бетмәс күңел җылысы килеп бәрелгәндәй тоелды аңа, әйтерсең, Зиннәт өчен шунда сарылып, ягылып калган?! Менә аның кечкенә чактагы уенчыклары, киемнәре, калын бер альбомга тупланган фоторәсемнәре... Ә монысы? Әнисенең җәйге бер күлмәге белән бизәкле яулыгы икән. Аларны кочып, егет бераз сүзсез утырды. Ә күзләрендә яшь иде. Ничек бу җанга газиз әйберләрдән аерылмак кирәк? Юк, ул моны булдыра алмас!..

Шулай хисләнеп актарына торгач, чират чигүле кызыл сөлгегә төрелгән төенчеккә җитте. Баксаң, әллә нәрсә дә түгел, берничә дәфтәр, ниндидер иске документлар гына икән. Дәфтәрләр әнисенең чәчәк өлгеләре белән бизәлгән истәлекләр, шигырь, төрле җырлар, такмак-такмазалар белән тулы язмалары икән. Ул аларны вакыт табып, соңрак укымакчы булып, читкәрәк куйды. Шулчак аның игътибарын төенчек эчендәге кечерәк бер чигүле янчык җәлеп итте. Кызыксынып, бавын тартып җибәрүгә, эченнән ниндидер кәгазьләр килеп чыкты. Аһ! Нигә ачты да, нигә чиште соң ул бу

төенчекләрне?! Анда үзенең җанын айкап, бәгырен көйдереп ташларлык хәбәр ятар дип кем уйласын?!. Хәбәр генәме соң? Анда Зиннәттән шушы көнгәчә яшереп сакланган, аның бар тормышын җимерергә, ирегән, бөтен шатлыгын буып ташларга теләгән зәһәр еландай шөкатьсез һәм дегеттәй кап-кара сер сагалап ята иде... Баксаң, әти-әнисе Зиннәтне (аның исеме дә Зиннәт түгел, Җәмил булган әле) үзенең күке әнисе ташлап калдырган бала тудыру йортыннан уллыкка алган икән бит. Нинди хурлык! Бу хурлыкны күтәргәнче, нигә ул тугач та, шунда җанын тәслим кылмады икән? Нигә үсте? Ничә тапкыр ятим калды? Инде өйләнәм дип шатланып йөргәндә генә... Нинди көч аңардан шул сөенечне дә күпсенде икән соң? Дөнья – кешенең сынамыш мәйданы, диләр. Ә шәхсән аны нинди туктаусыз сынау икән ул? Кем алдында гаепле булган икән яңа туган сабый? Яшьләнгән күзләрен йодрыгын төйнәп сөртте Зиннәт, әйтерсең, шулай ачуы басылачак та, ул тынычланачак. Ничек күтәрер дә алга нинди матур планнар кора алыр соң ул? Ә Нәзифәгә ничек әйтер? «Син затсыз, туган-тумачасыз, тамырсыз», – дисә?! Тормыш нишләптер берәүгә – ана, берәүгә үги ана икән шул. Димәк, этисенең дә «имгәк», «әтәмби» диюләре песи баласына түгел, Зиннәткә төбәп әйтелгән булып чыга түгелме соң? Нәкъ шулай. Җитмәсә этисе әнисенә: «Койрык үстергәнсең икән, үзең өстерәп йөр», – дип тә ачуланды бит әле. Чит күреп, кирәксез койрык санап, үзе өстерисе килмәгәнгә ташлаган инде ул аларны... Әмма Сәмига әнисе генә түгел (Алма апасын да Зиннәт әнисәдәй якын күрә иде) яратып, иркәләп, сөеп назлы сүзләр белән үпкән-кочкан, бишек җырлары җырлап, әкиятләр сөйләп туймаган йөрәгенә халык моңнары салган газизе – Разия әнисе дә бөтенләй чит бавыр булып чыга икән ләбаса... Акылга, аңга сыймаслык коточкыч хәл! Юк, булмас, дөрес аңламыйдыр Зиннәт. Шундый соклангыч әни үги була алмас!

Ә менә сабыен ташлап киткән затны кем дип атарга? Карамас булгач, нигә тудырган? «Кашың кара, күзең кара, үз көнеңне үзең кара», дигәнмени? Шулай, димәк. Күзенә карыйсы, йөзен күрәсе, сәбәбен беләсе иде. Авыр хәлдә яшәп, карап үстерерренә әллә ышанычы булмаганмы? Имчәген ана бирсә, ризыгын Аллаһ бирер, диләр ләбаса... Әллә соң ир дигәне ышанычсыз булганмы? Шунлыктан, халык әйтмешли, ут ачуын – табадан, ир ачуын баладан алганмы? Ничә ай күкрәк астында күтәреп йөргәндә дә аналык хисләре тумавы бик кызганыч. Ун бала тәрбияләп үстергән дәү әнисе, ана булуны гомерлек вазифа саный иде югыйсә. Кемгә-кемгә, дәү әнисенә ышана ул.

Зиннәтнең ятим балалар хакында укырга, тапшырулар, кинолар карарга яратмавы да бер дә юкка булмаган, күрәсең. Күзләре бик тиз яшьләнә шул, кызгана ул андый сабыйларны. Әмма үзенең дә тумыштан ук шундый кирәксез, ташландык булуы башына да кереп чыкмады... Сандыгын да ябарга онытып, ятагына капланды егет. Башта, тешен кысып, сүзсез генә тәгәри-тәгәри әрнеде. Аннары күз яшьләренә дә ирек бирелде. Разия әнисен югалтудан да ачырак иде бу әрнү, үкенечлерәк иде бу күз яшьләре. Шушы халәт аның аягына тышау, тамагына зур төер булып утырды. Тормышы аңа аста упкын, өстә капкынны хәтерләткән, һич чыга, котыла алмаслык тирән бер чоңгылдай тоелды. Бу авыр хистән котылыр көчне каян табарга да, ничек гаилә корырга соң? Ышанычың булмаса, яшәү

көн дә кыямәт икән. Кем каһәре төшкән аңа? Бу кара язмыш аны алда да сагалап тормасмы?..

Нәзифәнең дә, Алма апасының да телефон аша эзләвенә карамастан, аларга җавап та бирми, ашамый-эчми, ятагында шул аңлаешсыз хисләр чолганышында бәргәләнде егет. Алма апасы килеп, үзендәге ачкыч белән ишекне ачканда, ул ни үле, ни тере кыяфәттә, бер ноктага карап, хәрәкәтсез ята иде.

– Нәрсә булды, балам? Берәр хәлгә тарыгансың дип торам. Йөрәгем купты.

– Менә сәбәбе, – дип, Зиннәт кинәт сикереп торып һәм янчыктан чыккан шомлы кәгазьләрне өстәлгә бөгәрләп ташлаган урыныннан алып, Алма апасына сузды һәм чиксез гаҗәпләнүдән телсез калган түтәсен кочып алып:

– Сез Разия әнием белән икегез мине үлем якасыннан тартып алгансыз, сезнең изге йөрәк белән мин исән калганмын. Рәхмәт йөзеннән, бурычымны кайтарыр өчен мин яшәргә тиеш. Кәккүк әниемә: «Күр, мин дә үсеп, кеше булдым», – дип әйтер өчен.

...Алма апасы Зиннәтне бу халәттә ялгызын калдырырга кыймады, үзенә алып китеп, пешеренде, мунча ягып җибәрде, әниләрчә киңәшләрен бирде. Тынычландыра, яшәргә көч тудыра, якты киләчәккә ышандыра белә ул... Нәзифәсен исә егет телефонының эш урынында онытылып калуына сылтады. Берни дә юк, янәсе. Ул үзе, бары тик үзе генә барын да ерып чыгачак әле. Аллаһ булышса, нәкъ шулай булачак, иншаллаһ!

Оясыннан алып ташланган кошчык йә талпынып күтәрелергә, яисә аска, чоңгылга мәтәлергә тиеш. Ул күптән инде беренчесен сайлады.

## Кем син, кәккүк әни?

Биологик әнисенең исем-шәрифләре билгеле: Фисә Кәепова... Бала тудыру йортында эшләгән җиңгәсе аркылы анын архивта теркәлеп калган адресын табу авыр булмады. Баксаң, ул күрше республикадан булып чыкты. Нишләп сабыен – Зиннәтне биредә тудырган икән соң? Качыпмы? Гаҗәп!.. Ул инде бераз тынычланып өлгергән иде диярлек. Беркемгә әйтми, беркем белән киңәшләшеп тормый, эшеннән ике көнлек ял сорап, адрес буенча юл алды. Тик анда студентлар тулай торагы урнашкан булып чыкты. Бәхеткә, комендант бик ачык йөзле, сүзчән ханым икән. Егетнең «туганын эзләвенә» һич шик-мазар белдермичә, шул елларда яшәгән студентлар исемлеге теркәлгән журнал аша Фисәнең туган җире адресын язып та бирде. Менә сиңа мә! Искиткеч хәл! Кәккүк әни дә Зиннәтнең шәһәрдәше икән, биредә торып, техникумда белем алган булып чыкты. Инде хәтсез еллар узганга, шәһәргә кайтып та, тиз генә табарына бернинди дә ышаныч тоймады Зиннәт. Шулай булып чыкты да. Күршеләре Фисәнең күптән инде кияүдә булуын, фатирларында апасы гына яшәвен әйттеләр. Анысы да әлеге вакытта җылы якта ялда икән.

Бу көннәрдә Зиннәтнең үз язмышы турында белгәннәре болай да чиктән ашкан иде инде... Мөгаен, фикер төйнәргә, бераз утырып уйлар уйларга вакыттыр... Күңел шулай сизә. Йөрәкнең үз законы. Кабаланудан ни файда?

«Сабырсызлану – хата чишмәсе. Ашыгу шайтаннан», – ди иде дәү әнисе дә. Аллаһ та шуны искәртә ахрысы, эзлисең – табып булмый...

Әнә шулай төрлечә фикер йөртте егет. Әле эзләргә омтылды, әле икеләнде. Ныклап уйласаң, инде үсеп, буй җиткергәч, нигә ул затны эзләү кирәк соң? Кем ул Зиннәт өчен? Ят бер ханым гына түгелмени? Ташлап китүенә ачу чыгудан гына башланган эш ләбаса. Ачу – дошман, акыл дус. Акылны җигү дөресрәк булыр, мөгаен. Шулай тынычланып йөргәндә, Илгиз абзыйсы – Алма апасының кече улы дәшеп алды. Өч кеше белгән сер инде сер түгел икән. Зиннәтне борчыган хәбәр аңа да барып ирешүгә, туганына ярдәм итү юлын эзләгән: паспорт өстәлендә хезмәт салган күршесе аркылы Фисәнең бүгенге адресын табуга ирешкән. Аллаһ бирсә колына, чыгарып куяр юлына шушы буладыр инде. Ышанырлык та түгел: алар бер үк шәһәрнең бер үк урамында көн күреп яталар икән. Бәлки, күзгә-күз карашып та үткәннәрдер, бәлки, ул улын танып та йөргәндер, кем белә? Булмас димә, дөнья бу!.. Фамилиясе генә үзгәргән: Акрамова Фисә Әхмәтнур кызы. Кияүдә булуы дөрес, димәк. Бүтән балалары булганмы икән? Әллә соң тудырган саен калдыра торганмы? Зиннәтне шундый сораулар тынычлыкта калдырмады. Шунысы хак: баласын ташлый алган адәмнең иманы камил булмас. Кеше күңеле – кара урман, диләр, су түгел, тирәнлеген үлчи алмыйсың...

## Гафу ит, улым!

Кызулык белән эшләнгән гамәлләр җүнлегә илтми. Алма апасы да шулай өйрәтеп үстерде Зиннәтне. Шуңа никахлары узганчы үзен борчыган ул мәсьәләне бүтән кузгатмаска булды. Моңа Нәзифә дә сәбәпче иде, әлбәттә. Сөйгәне авылдан урап килеп, аның белән сагынычлы очрашуга, күңел ярасы да бөтәшкәндәй, әрнүе дә сүрелгәндәй булды. Никахларына кадәр Нәзифәнең әтисе белән танышырга, аның фатихасын алырга кирәклеге дә көн кадагына килеп басты.

– Әтием булачак кияве белән танышырга тели, көтә безне, озакка сузмыйк, – диде Нәзифә дә, фирүзә карашы белән ягымлы өтеп.

Шулай да ике атналап вакыт үтеп китте әле. Үзләренчә әзерләнделәр: Алма апасы өйрәтүенчә, бүләкләр, күчтәнәчләр хәстәрләделәр, өс-башны да бераз заманчалап яңарттылар. Уфага бара торган автобус Нәзифәнең туган авылы аша уза икән. Ике сәгать ярымлап вакыт үтүгә, үзләре төшәсе тукталышка килеп тә җиттеләр. Авылны бик ярата Зиннәт. Чыннан да шәһәрдә – дәүләт, авылда – җәннәт шул.

Урам буйлап бераз атлауга, ни гаҗәп, ниндидер таныш күренешләр пәйда булгандай тоелды егеткә. Әкияттәгечә, авыл-авылга охшый ул, дияр инде, бу турыда кәләшенә белгертсә. Ә нигә менә бу тыкрык башындагы карт юан имән дә, әнә теге борынгылык аңкып торган таш кибетнең тарихи нәкышләре дә таныш соң?.. Ниһаять Нәзифә үз йортларына борылды. Әмма бу яңа йортны тәү тапкыр күрүе иде Зиннәтнең. Нәзифәнең туган йорты бик матур да, килешле дә итеп төзелгән. Җитмәсә, милли бизәкләре белән дә күңелне үзенә тарта. Дөнья синең үз йортыңнан башлана, диләрме әле? Әти кеше моны уена нык сеңдергән булырга тиеш. Йорт-ихатага беренче күз ташлауга ук, биредә ныклы һәм алтын куллы хуҗалар яшәвенә бер

шигең дә калмый. Һөнәрле ир хур булмас анысы. Нәзифә этисенең тимердән чәчәкләп, капка-коймалар коюга көйләнгән остаханәсе булуын да әйткән иде инде. Кызының:

– Әти, син көткән егетне алып кайттым, – диюенә, остаханәсе ишек төбендә иелеп нидер эшләп торган җиреннән эти кеше тураеп, булачак киявенә кулын сузды:

– Исән-лек....ме-е-е-е? Ул шулай сүзен тотлыктырып, гаҗәпләнүдән этенеп калды. Алдында тәнгә-буйга үсеп ныгынган, әмма төскә әллә ни үзгәрмәгән, үзе кайчандыр ташлап киткән улы елмаеп басып тора иде.

– Улым! – Әнә шулай, гаҗәпләнүдән икесе дә беравык сүзсез торганнан соң, кочакка кочак ташланды бу икәү. Менә ни өчен бу авыл таныш тоелган икән! Зиннәт кечкенә чагында этисе белән аның туган авылында еш була, карт имәндәге таганда атына, таш кибетне әйләнеп, авыл малайлары белән качышлы уйный иде. Әмма бу яңа өй урынындагы кечкенә, ягымлы йорт кына сүтелгән икән...

– Гафу ит мине, улым! – диде этисе, улын кочып.

... Разия белән дистә елга якын яшәсәләр дә, балалары булмады. Ә гаярь ирнең үз сабыен сөясе бик килә иде. Дөрес, ул Зиннәтне үзенекедәй күреп яратты. Тик бик чирләшкә иде шул бала. Терелеренә аз гына да ышаныч булмады. Бергә танышып йөргән Әлимәсе авырга калгач, ике дә уйлап тормастан, кызы туар алдыннан элекке гаиләсен ташлап чыкты да китте.

Разияның вафатын ишетеп, аның апасы Сәмигага берничә тапкыр шалтыратып, улы турында сорашса да, Зиннәтнең үзендә булуын ул әйтмәде, чөнки сеңлесенең вакытсыз бу дөньяны калдыруына Сәмига Назыйфны да гаепле саный иде.

– Бер гаиләгә уллыкка биргәннәр, кайда булуын әйтмиләр, – дип ялганлады ул. – Сорашып йөрмә, эш бетте, поезд китте...

Ә Назыйфның улын уйламаган көне булмады диярлек. Үзе гаепле булуга карамастан, тиргәшеп чыгып китүенә бик үкенде. Терсәк якын да, тик тешләп булмый икән. Искә алган саен, барып йөрмәвенә, үзе тәрбияләп үстерә алмавына әрнеп, сызланып куя иде.

Нәзифә дә этисенең уллыкка алган сабые булуын, аның тагын ятим калуын, социаль челтәрләр аша эзләп тә, таба алмавын белә, үзе дә вакыт табып, эзләшергә уйлый иде. Әмма шулай булуга карамастан, бүген сөенергә дә, көенергә дә белмичә, югалды да калды:

– Хәзер безгә өйләнешергә ярамыймыни инде? – диде ул, еламсыраган да, үкенгән дә тавыш белән.

– Нишләп ярамасын, ярый, ярый, – диде этисе белән улы бертавыштан. Шунда гына яңа хушына килгәндәй:

– Үзең абый, үзең җаный буласың инде алайса, – диде, күз яшьләре аша сөенечле елмаеп Нәзифә.

Фамилияләре адаш булганга куанып йөргән бу мәхәббәтле парның этиләренең исеме дә Нәзифәнеке – Назыйф, Зиннәтнеке исә Назиф дип язылган иде. Бала тудыру йортыннан алганда, малайның исем-шәрифләрен үзгәртеп, булачак әти-әни аны үзләренеке итеп теркәгәннәр иде.

– Сез, балакайларым! Безнең хатаны кабатламагыз берүк. Һичшиксез бәхетле булырга бурычлысыз һәм йортыбызны оныклар белән тутырырга,

– дип, ул кызын да, яңа гына табылган улын да чиксез шатланып, кочагына кысты. Бүген аңардан да бәхетле кеше дөньяда юк иде.

– Әниләрегез һәм үзем өчен дә сезгә, канатларыгызны парлап, гаилә корырга фатихамны бирәм...

Зиннәт кичке чәй табыны янында гына әтисен очратуданмы, сөйгәне янында булуданмы, ачылып китеп, үзенең ташландык бала булуын әле күптән түгел генә белүен, шуңа бәйле авыр кичерешләрен, инде үзен читтән бәяләгәндәй, бик дулкынланмаска тырышып кына сөйләп бирде.

– Ә мин сине бер дә, бер дә ташламам, – диде Нәзифәсе, сабый баланы юаткандай, аның чәчләреннән сыйпап. Ә әтиләренең шатлыгы эченә сыймады, аларга карап сокланып, белгәнен укынып, изге теләкләрен теләп утырды:

– Аллаһым, рәхмәт, – диде ул, эченнән генә, тәрбияләп үстерергә дип алган улына соңлап булса да, кулдан килгәнчә булыша алачагына, терәк булачагына куанып. Кечкенә песи баласын күкрәгенә кысып, яшь тулы күзләре белән артыннан берни аңламый карап калган улының ялварулы күз карашы әлегәчә исендә булды. Кызы «әти» дип дәшкән саен, улын да искә алып, кемнәр кулында икәнен белми өзгәләнепме-өзгәләнде.

...Әтиләре йокларга үз бүлмәсенә кереп киткәч тә, әле Зиннәт белән Нәзифә озак чөкердәшеп утырды. Кыз гаилә альбомнарыннан үзенең балачак фоторәсемнәрен күрсәтте. Күренеп тора, кадерләп үстергәннәр, бәхетле булган ул.

Әтиләренең яшь чагында мәктәп формасы өстеннән ап-ак челтәр алъяпкыч ябынган кыз белән кулларын тотышып, бер-беренә мәхәббәтле карашып төшкән фотосы исә Зиннәтнең дә игътибарын үзенә тартты.

– Әтинең беренче мәхәббәте ул кыз. Шәһәр кызы Фаина гаиләсе белән җәйләрен безнең авыл янындагы дачаларына ял итәргә килә торган булган. Аның соңгы звонок көнендә төшелгән бу фоторәсем. Тик ул зур начальник кызы булган, кияүгә дә шәһәр егетенә чыккан бугай. Әтине Фаинаның апасы үз итмәгән: «Хәерче безгә иш түгел, бүтәнчә күзгә күренмә», – дип куып җибәргән. Әти гарьләнгән, күрәсең, соңынан аны эзләп йөрмәгән, армиягә алынгач, юллары аерылган.

Йоклар алдыннан урамга һава суларга чыгып-кереп йөргәндә, балаларының кем турында гәпләшүләре колагына чалынып калган әтиләре яшьлек мәхәббәте турында матур хатирәләр белән тәмле йокыга китте. Тик ул үзенең Фаинасы белән бала тудыру йортында сабыен калдырган Фисә Әхмәтнур кызы арасындагы уртаклыкны, ә Зиннәт исә фоторәсем аша үзен якты дөньяга китергән биологик әнисе белән беренче танышуын исләренә дә кертеп чыгара алмадылар... Аллаһ әле һаман бу серне яшереп саклый иде.

## Никахлы пар – бәхетле пар

Икенче көнне йокыдан торып, чәйләп алуга, йортка хәл-әхвәл белешергә күршедә генә яшәүче, ак яулыгы өстеннән ап-ак шәл бөркәнгән, вак кызыл чәчәкле күлмәгенә пар милли бизәкле камзул кигән Нәзифәнең Агәбисе – әтисенең түтәсе килеп керде. Зурлап, матур теләкләрен такмаклап, ике куллап ихлас исәнләште. Күрешкәч, кеше өенә кергәч укыла торган Коръән

аятен – «Мөэмин» сүрәсен уку тиешлеген искәртеп, үзенә хас бер моң белән тезеп китте:

– Рабби әңзилнии мүңзәләм мүбәәракәү үә әңтә хайруль мүңзилииин. Алтын алма, дога ал.

Аннары озаклап, догаларын, теләкләрен ирештерде. Аны этиләре Назыйф кичтән күреп чакырып куйган, балаларына никах һәм аның хөкеме хакында аңлатуны үтенгән иде. Чөнки яшьләр кайчак ЗАГСта язылышу, туйлауны гына хуп күрүчән. Агәбинең исә иманы камил: никахлы гаилә – тотрыклы, ныклы гаилә, никахлы гаилә таркалмас...

Агәбинең ай-ваена карамый, самавырны яңартып, шәһәр күчтәнәчләреннән авыз иттергәч, ул бисмилласын әйтеп, никах турында сүз кузгатты:

– Су буйсыныр буага, ил буйсыныр йолага, балалар. Сәламәт булган һәркем парлы-парлы булып яшәргә, сабыйлар тәрбияләп үстерергә, нәселен дәвам итәргә тиеш. Аллаһның безгә кушкан боерыгы бу. Ә гаилә кору уен түгел, үз өстенә бик зур җаваплылык алу... Никах исә – ант, вәгъдә ул, балалар. Ә инде антка тугры булырга кирәклекне дә, вәгъдәнең иман булуын да сез инде аңлый торгансыздыр. Никах көнегездә бер-берегез белән гомер буе тугры яшәргә ризалык бирәсез. Менә шуңа күрә дә никах – иң саваплы эш. Никахның табыны да тик ифтар табыны белән генә тиңләшә ала, диләр, онытмагыз. Шуңа кайбер имансыз бәндәләр кебек, никахтан соң, аракы белән пычрана күрмәгез. Бер генә парның да шайтан суы белән бәхетле булганы юк әле. Шулай дип аңлата дин галимнәре дә.

Соңыннан Агәбисе Нәзифә сылуы белән аулакта никахлы тормыш, хәләл һәм хәрам нәрсәләр, тәһарәт һәм госел тәртипләрен аңлатуны да хуп күрде. Яшьләр Агәби вәгазен баштарак теләр-теләмәс кебек кенә кабул итсәләр дә, (Аллаһ сүзе зиһенгә азау ярып керә) соңыннан, ул әйткәннәр тәэсирендә, бер башка үсеп, җитдиләнеп киттеләр, сәдака һәм бүләкләр биреп, бик рәхмәтле булып калдылар...

Менә, ниһаять, никах көне дә килеп җитте. Яшьләр шәһәргә кайтып, никах киемнәрен, якыннарына сөенечле көннәренең истәлеге итеп өләшәчәк бүләкләрен, табынга куячак күчтәнәчләрен һәм Зиннәт ягыннан булган кунакларны (әнисе урынына калган, тәрбияләп үстергән Алма апасын, хәләл җефетләре белән аның улларын, берничә дустын һ.б.) ияртеп килде. Нәзифә ягыннан өй тулы кунаклар исә аларны колач җәеп каршы алды. Авылның имам-хатыйбы Әхмәтсафа хаҗи чараны башлар алдыннан егет белән кызның мөселман икәненә ышану кирәклеген искәртте. Никахның төп бер шарты шул икән. Яшьләр шаһитлар алдында: «Лә иләһә илләллаһ Мүхәммәд расүлуллаһ», – дип, үзләренең мөселман икәнлеген раслап күрсәтте. Егет кызга үзенең никах бүләкләре итеп, алтыннан йөзек кидереп, муенса белән пар алкалар такты. Никахның тагын бер мөһим шарты шулай үтәлде.

Никах табыны исә милли ашлардан сыгылып тора иде. Табынны Нәзифәнең һәм әнисе, һәм этисе ягыннан туган-тумачалар бергәләшеп, искиткеч муллык һәм милли зәвык белән әзерләгәннәр, табынга бәрабәр күчтәнәчләр дә авыз суын китерерлек иде мәгәр. Токмачлы шулпа, каклаган каз, төрледән-төрле бәлешләр, тутырган тавык, кияү пилмәне, кияү

коймагы, тәбикмәк, гөбәдия, чәкчәк, бавырсак, итле өчпочмак, куллама, йөземле пылау – халкыбыз милли ризыкларының бу йөзек кашларын тәмләп кенә түгел, санап та чыгу мөмкин түгел иде. Никахлы парның бәхетләре дә берүк шушы табын кебек мул булсын! Шундый изге теләктә таралышты кунаклар. Яшьләрнең куанычларының иге-чиге булмады.

Зиннәт тә, ниһаять, үзенә бәхет кояшы елмаюын тойды, борчулы уйларыннан да бераз арынгандай булды: сөбханаллаһ, күз тимәсен берүк. Ул сөенече эченә сыймый балкып утырган сөйгәненнән күзен дә алмый:

– Әкияттә түгел, бер бите ай, бер бите кояш сылу син икән ул, җаным, – диде. Ә Нәзифә аңа җавапка һич кесәгә кереп тормады, үсмер чагында, Агәбисе янында көзгегә карап, «чибәрләр нигә без түгел» дип такмаклаган чагында тәҗрибәле туганы әйткән тапкыр сүзләр белән җаваплады:

– Булма чибәр, бул бәхетле, бәхет чибәр күрсәтә.

Икесе дә, нур чәчеп, канәгать елмаештылар. Әйе, картлар сүзен кар басмас диюләре бик тә дөрес анысы.

## Таныш булмаган таныш

Туйларын яшьләр көзге эшләр бераз тәмамлангач, чагу төсләргә бай әбиләр чуагына таба уздырмакчы булды. Бераз әзерлек чаралары да күрәсе бар. Никахтан соң атна чамасы узуга, Зиннәтнең дөньяга тудырган анасын күрәсе килү теләге янә көчәйде. Көненә бер булса да, аның адресында күрсәтелгән йорт тирәсен әйләнеп кайтырга булды. Узганда, фатиры урнашкан подъездга кереп-чыгып йөрүчеләргә текәлеп-текәлеп үтсә дә, «менә монысы, мөгаен, минем әнидер» диярлеген очратмады.

Кем белә, бәлки, әнә теге утыргычта бер ир белән көлә-көлә нәрсә хакындадыр гәп коручы, чәчләрен биек итеп артка өеп куйган, җәйге затлы ак костюмдагы хатын шул үзедер? Ә әнә теге аягын чалыштырып атлап, култыгына шешә кыстырып кереп баручы хәсрәт төенчеге шул Фисә булса? Күрмәгәннең күрәсе, күргәннең качасы килә кебек булмасын тагын. Дәү әнисе әйтмешли, һәр тишеккә бармак тыксаң, еланга эләгерсең... Шулай да сер яшеренгән нәрсәгә җан мавыга икән шул... Бәлки, дөньяны борын тишегеннән күзәтеп, бүтәннәргә мыскыллы караш ташлап узучы менә шушы фырт ханымдыр ул? Кем соң син, кем соң?.. Икеләнгән шикләнер, шиге белән чикләнер, дигәндәй, нигәдер һаман аның фатирына керергә һич аягы тартмый Зиннәтнең? Авыр төенне чишәрлек көч һәм куәтне туплый алмый һаман азаплана әле. Көннәрдән бер көнне Нәзифәнең:

– Уйланасың да утырасың, әйдәле бүген кич әниемнең түтәсенә – Чибәр әбиемә барып килик. Дәваханәдә калып, никахыбызга киләлмәде. «Кияүне алып кил, күрәсем килә», – дип өзми дә куймый дигәч, аңа иярми булдыра алмады. Әмма бик тиз генә чыгып китеп булмады әле өйдән.

– Сират күпереннән үткәргәндәй бәяләп караячак Чибәр әбием безне. Ул бик зәвыклы кеше. Күп еллар үзешчәннәр театрында уйнаган, һөнәре буенча табибә. Белмәгәне юк. Инде мәдрәсәләрдә ислам динен ныклы өйрәнеп, үзе мөслимәләргә гыйлем бирә... Менә кара кашлы, кара чәчле син матурыма ак күлмәгеңнең үтергеческий килешә торганы һәм кара

чалбарың, яхшылап үтүкләдем, үземнекеләр дә әзер, – диде Нәзифә, ирен чите белән генә елмаеп.

– Диңгездәй зәңгәр күзләреңә пар блузкаң сине тагын да серлерәк итә. Ә мин гашыйк булган җитен төсле чәчләреңә беләзек һәм алкаларың төс, – диде Зиннәт, Нәзифәнең сылу тәнен тагын да сылурак күрсәткән кофтасының арткы төймәләрен каптырышып.

Очраклылык һич очраклы түгелдер. Шундый уй килде Зиннәтнең башына, Чибәр әбинең кәккүк әни яши дип фаразланган серле йорттан булуы, торакларының да шул ук подъездда, хәтта терәлеп торган күршеләр дә икәнен белгәч. Җитмәсә, ишекләре дә бер-берсенә колач җәеп ачыла икән, хәтта фатирларны, икесенә уртак кечкенә коридор калдырып, бер тимер ишек белән берләштергәннәр. Зиннәттә чын ир-егетләр холкы – ул сүзчән егет түгел. Шул сәбәпле Нәзифә әле аның бу көннәрдә әнисен эзләгән мәшәкатьләрен дә, аның адресын табуын да белми иде. Зиннәт исә һаман бар аңлаганын тик күңеленә генә беркетеп барды. Идел күрми итек салма, танымый әйтеп салма, дигәндәй, Нәзифәсенә берни белгертмәде. Кем белә, бәлки, адресы ялгыш булуы да бар. Шулай килеп чыкса, гарьлеккә калуыңны көт тә тор?!

Чибәр әби аларны, сөенеп, якты йөз, тәмле сүз белән каршылады. Нәзифәнең әнисен искә төшереп, балавыз сыгып алганнан соң, аңа җәннәт рәхәтлекләре теләп, дога кылды. Күчтәнәч һәм никах бүләкләре өчен рәхмәтләрен белдерде. Яшьләрнең аркаларыннан сөеп, аларга мәхәббәтле, парлы озын гомер, дүрт саны төгәл тәүфыйклы һәм иманлы сабыйлар теләде. Никах мәҗлесенең ничек узуын сорашып:

– Бигрәкләр дә пар килгәнсез. Ризыкларыгыз киң, бәхетегез мул булсын берүк, балалар, – дип, белгәннәрен укып, изге теләкләрен җиткерде.

Бергәләп гәпләшеп чәйләп алганнан соң, Нәзифә табынны җыештырышып, гөлләргә су сибәргә, туганына аш-су бүлмәсе мәшәкатьләрендә булышырга тотынды. Зиннәткә дә эш табылды: Нәзифә аңа чүп кәрзиннәрен бушатып керүне җөпләде. Ул чыгар өчен аягына туфли киеп торганда, кинәт ишекне сак ачып, бер хатын кереп, аңа бәрелә язып туктап калды. Артыннан күрше фатирның ачык ишегеннән берәүнең, олы базар, кече туй ясап, дөбер-шатыр кыланып, дорфа тавыш белән:

– Фисә – таракан түрәсе, бер яртысыз кайтсаң, өйгә аяк басасы булма! – дип җикеренүе ишетелде. Кухнядагылар бу хәлне ишетмәсә, күрмәсә дә, Зиннәт исә шундук аңлап алды: аның алдында һичшиксез үзен бала тудыру йортында язмыш кочагына, үлемгә ташлап калдырган әнисе Фисә басып тора иде. Кулындагы тышы таушалып беткән сумкасы, өс-башы, төс-кыяфәтенә карап һәм артыннан ишетелгән сүзләрне чамалап, егет шундый нәтиҗә ясады: бу мөртәт эчкече икән, шулай булмаса, сабыен ташлар идеме?

– Бәй, кемнәр, дисәм, ку-ку-ку-наклар ба-аррр икән, – диде анысы, каушап. Каушамаслыкмы соң? Алдында ире Марсның япь-яшь чагы пәйда булып, Фисәгә ачулы карап тора иде. Анысы, кухнядагыларның ишетүеннән сагайгандай тешен кысып һәм чиксез ачыну тойгысын йөрәгенә туплап, әйтә салды:

– Кунаклар?.. Түгел шул, хәсис. Мин – синең яшьлек ялгышың, хәчтерүш әни.

– Ә-ә-ә-ә-ә! Җә-ә-ә-ә-м-м-мил! – Хатын артка чигенеп, кулы белән тотынырга, яисә аркасына сөялергә урын табалмыйча, яшен суккан агачтай, аяк киемнәре өстенә шуып төште. Зиннәт ни эшләргә белми торганда, тавышка Нәзифә белән аңа ияргән Чибәр әби килеп чыкты.

– Тагын өянәге тоткан бит күршемне, – дип, ул, табибәлек гадәтенчә, ярдәм күрсәтергә тотынды. Нәзифә исә ашыгыч ярдәмгә шалтырата башлады.

«Димәк, өянәге дә бар икән әле алкашның». Шулай фикерләде егет, аны шундагы диванга күтәрешеп салып, һәм чүп савытларын тотып, подъездга чыгып югалды. Ашыгыч ярдәм озак тормый килеп тә җитте, Зиннәт кергәнче авыруны алып та китте.

## Комсызлык корбаны

Хатын-кыз кызганучан да, кызыксынучан да була. Бу яктан, әлбәттә, Нәзифә дә искәрмә түгел иде. Ул чибәр әбисеннән бу күрше хатынның кем икәнен, нинди авыруы булуын сораштыра башлады. Юыну бүлмәсендә кулын чайкап, белмәмеш кыяфәттә Зиннәт тә алар янына чыкты.

– Кем булсын? Билгеле инде, алкаш хатын. Ире дә артыннан аракы таптырып кычкырды, – диде ул.

– Нинди алкаш? Аның аракы түгел, өендә чәй эчәргә дә хокукы юк диярлек. Карашыннан сөт әчерлек дорфа Сәгыйдәнең, уң як күршемнең килене ул. Килен дә бит, чынында исә бер хезмәтче урынында гына шул. Күзеннән яше китми, карашы түбән, үзе сүрән, дигәндәй, мескенкәйнең, – диде әбекәй, аны кызганып. Артыннан җикеренгәне – аның ире Марс, бер газраил шунда. Аның кояшы һәр көнне рюмка эченнән чыга.

– Нигә аерылмый, нигә яши соң ул алар белән, үз кадерен белмичә? – дип сорады Нәзифә, хатынның әллә хәленә керергә теләгәндәй, әллә гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

– И балалар! Бер бәхетең булмаса, булмый ул. Бигрәк тә намуслы кешеләргә авырга туры килә. Язмыш шобагасына бәхетсезлек откан бала ул. Үз күлмәгеңнән беркая качып булмый шул.

– Ничек?

– Менә шулай... Миннән башка беркемгә сөйләми ул хәлләрен. Кайгы-хәсрәтен түкми-чәчми иңенә йөкләп, үзе белән йөртә дигәндәй. Ирле тол булып, зәгъфрандай саргаеп көн күрә инде. Күптән түгел генә күршеләр булдык бит әле. Аның каравы, монда күчкәннән бирле мин – аның яклаучысы.

...Әтиләре совет чорында зур түрә иде шәһәребездә. Врач буларак, миннән ярдәм сораганы бар иде. Әйтергә кирәк, начар кеше булмады. Ул үлгәч башлана да инде бәхетсезлек. Гайбәт түгел, гыйбрәт булсын. Бүтән этидән туган апасы, әниләрен юмалап, ак сүз сөйләп, кара эш эшли: зур фатирны, булган мал-мөлкәтне, җиңел машина, гараж, тегесен-монысын дигәндәй – барын да үзенә яздыра. Ул мәктәп директоры булгач, урысча әйткәндә, как за каменной стеной булырбыз, дигәндер, әниләре, ризалаша һәм оттыра. Кызыл алма эчендә дә кара кортлар булучан, диләр бит. Үзе хуҗа булганнан соң ул әнисе белән сеңлесен җимерелергә торган бер агач йорттагы начар гына фатирга куып чыгара. Монысы әнисен шунда тәрбияләп, күптән түгел генә җир куенына

тапшырды. Ул йортта бөтенләй торырлык түгел хәзер. Әнә шулай газиз әнисен дә караган, бу фиргавеннәргә дә бил бөккән. Болары әле аның соңрак булган хәлләр. Элегрәкләрен сөйләсәң, озакка китәр. Язмыш сәхнәсендә аңа трагик роль уйнау язган. Комсыз кешеләр корбанына әйләнгән ул, дияр идем.

– Сөйлә инде, Чибәр әби, бәлки, берәр ничек ярдәм итеп булыр, – диде йомшак күңелле Нәзифә, еларга җитешкәндәй, шәфкать тулы күзләрен яшьләндереп.

– Дачаларына якын бер авылда, – дип дәвам итте Чибәр әбисе, – Фаинаның, әйе, Фисәнең инде, яратышып, сүз бирешкән егете дә булган. Әлеге дә баягы, апасы араларын бозган. – Нәзифә этиләренең беренче мәхәббәте Фаина турында сүз баруын төшенеп, берчә гаҗәпләнеп, берчә шатлангандай, Зиннәткә карап, бу турыда тизрәк хәбәр салырга уйлап, авызын ачуга, анысы, бармагын иреннәре янына куеп, «дәшмә!» дигән ым ясады. Баксаң, ире Марс Фисәнең сыйныфташы булган, зур түрә кызы күреп, артыннан йөрергә тырышкан, соңрак кызның әтисе үлгәч, тулай торакта берүзе чагында әрәм иткән...

Шуларны ишетүгә Зиннәтнең ачудан битләре кызышты, тешләре кысылды, ирексездән йодрыклары төйнәлде. Ул халәтен сиздермәс өчен бер кухняга кереп су эчсә, бер балконга чыгып йотлыгып һава сулады, ваннага кереп, ачуын басар өчен йөзен, кулларын озаклап, суык су белән юды. Калган хикәятне инде ул тыңлый алмады.

...Саф һава сулар өчен алар фатирларына җәяүләп атлады. Ул шунда гына Нәзифәгә этиләренең беренче мәхәббәте Фаинаның үзен якты дөньяга китергән, бүген ашыгыч ярдәм белән дәваханәгә озатылган Фисә булуын, аның адресын ничек табуын, биологик әнисен ничек эзләүләрен бәйнә-бәйнә сөйли алды. Нәзифә, ышана алмыйча, атлап барган җиреннән туктап калды:

– Ничек син боларны сер итеп сакладың? Нигә бүлешмәдең, авыр булгандыр боларны күтәрүе, – дип, ул аны кочып алды, юатырга тырышты. – Әйтәм аны урыныңда утырып тора алмадың?! Инде аңлашыла хәлең, матурым.

Зиннәткә аның әнисенең тормыш тарихының дәвамын Чибәр әбисе авызыннан тыңлап беткән Нәзифә, дулкынланып, ашыга-ашыга сөйләп бирмәкче булган иде, аны телефонга яздырып баруы исенә төште. Телефоннан Чибәр әби сөйләмен тыңлый-тыңлый, алар тынып калган парк аша үзләренә таба атлады:

– Көчләнгән дә авырга да калган, балакаем, – дип дәвам итте телефондагы Чибәр әбинең үкенечле тавышы. – Моны белеп алган апасы Дәрига чәчрәп чыккан: «Син фәхишәләрдәй, нәселебезгә тап төшерәсең, кара ягасың, зина кылып, миңа, мәгариф отличнигы йөзенә, кызыллык китерәсең», – дип, тел белән дә, кул белән дә җәзалаган. Яман кеше тәхет саклар, яхшы кеше намусын, диләр бит. Бик тә дөрес бу.

...Яшьләр тиз кайтып житте, калган язманы инде, бер-берсе куенына сыенып, диванда тыңлады алар:

– Дәрига сеңлесенең кемнән авырга калуын әйттереп, Марсның райкомда инструктор булып эшләүче әнисенә барып, тавыш чыгарган. Таныш-белеш аша улын яңа гына вузга укырга урнаштырган анасы хәлне фаш иттерү

ягында да булмый, өйләндерәсе дә килми. Бу ике газраил, Сәгыйдә белән Дәрига, берләшеп, ничек тә авырны төшертү җаен карыйлар. Төрле дарулар табып эчерү дисеңме, уколлар кадаумы, эссе мунчада чабындырумы – берсе дә калмый.

Нәзифә боларны тыңлаганда, күңелендә туган хисләрне яшерә алмыйча, тойгыларын ярып салып барса, Зиннәтнең кичерешләрен йота барудан тәне кызышты, кан тамырлары бүртеп чыкты, ул бер сүзсез йөренде.

Туктаусыз уйланды, үткәненә нәтиҗә ясады: менә нигә авырулардан бушамаган, чирдән арынмаган икән ул?! Аякның гариплеге дә бер дә юкка булмаган, күрәсең, ничек акылына зыян салмаганнар?

– Кычкыр, ела, сүген! Эчеңә генә бикләнмә! – дип үтенде, сөйгәнен кочаклап Нәзифә. – Чирли күрмә! Син бит тугансың! Син бит бар! Син бит минеке! Без бит бәхетле! Азаккача тыңлыйк язманы, чөнки, иң мөһиме, әниең начар кеше түгел, ул сине ташларга теләмәгән. Син исән, ул исән. Безнең туйга Аллаһның зур бүләге бу... Син нык булгансың, үлмәгәнсең, тугансың. Әниең үзе белем алган техникумыннан каникулга кайткач, вакытсыз тулгаклый башлый һәм сине тудыра. Әмма хәшәрәтләрнең сине юк итәргә тырышулары бушка китми, син башта бик хәлсез, чирләшкә, төсең дә сап-сарыдан була. Баш врачны куркытыпмы, котыртыпмы, баланың чирләшкә булуын, яшәмәячәген әйттереп, ананы баладан баш тартырга мәҗбүр итмәкче булалар...

– Әйдә, шул урыннан дәвамын тыңлыйк әле, – диде Зиннәт кинәт, назлы сүзләрдән бераз юаныч тапкандай тынычланып.

Янә телефоннан Чибәр әбинең сөйләме агыла башлады:

– Алдыңда ышанычың, артыңда таянычың булмаса, берни эшләп булмый. Бер генә үлчәү дә үзен үлчәми бит. Бу райкомбикә дә дәваханәгә килеп, сафура бураннары куптара: «Кемнән көмәнле булып, минем улымның йөзенә пычрак ягасың?! Не позволим! Укыган урыныңа житкереп, мәсхәрә итикме, баш тартасыңмы үләксәңнән? Тиз уйла! Минем улымның укып, кеше буласы бар. Аны алда зур вазифалар көтә. Син – өстерәлчек, зиначы», – дип, өстәл суга. Баланың туу турындагы таныклыгына да әтисен билгесез итеп яздыруга ирешә. Чөнки власть, көч алар кулында. Көч капкадан керсә, гаделлек ишектән чыга, билгеле. Алладан курку юк, бөтен дөньяга хуҗа итеп тоеп, шулай үзен югалта кеше. Ә бу балакайның укып та бетерәсе бар, әнисе дә авыру, апасы да кертмим дип яный, кыскасы, бар дөнья каршы. Нишли алсын яклаучысыз япь-яшь кыз бала? Басым астында ул, гомере буе үкенәчәген аңлый торып, елый-елый, баладан баш тартырга мәҗбүр була. Шул елны диплом алып, укуын тәмамлап кайткач, ул әнисе ризалыгы белән сабыен эзләп тә карый. Әмма баланың озак яшәмәвен, мәрхүм булуын әйтәләр. Гомер буена шул газиз баласын кызганып, яшь түгә мескен. Бүтәнчә балага да уза алмый. «Әти исән булса, апа фатирдан кумаса, ташлар идемме сабыемны, юк!» – дип, миңа кереп, гел яшь түгә: «Балам төшләремнән һич югалмады. «Әни!» – дип өзгәләнә. Исәндер, ярдәм кирәктер, авырыйдыр». Фисә үзе, балакай, дәваханәдә ятканда, улын ун көн буе имезә алуы өчен куанып бетә алмый – бар шатлыгы шул.

Телефонда Нәзифә тавышы:

– Фатирында аның да өлеше булгандыр лабаса?

– Булмыймыни? Әмма һәр тегермән суны үзенә коя бит. Таләп итә башлагач, апасы, иблис, бу тәмуг кисәвенә, әйе, Сәгыйдәгә инде килеп: «Сез бала үтерттегез, Марсны сеңлемә өйләндермәсәгез, фаш итәм!» – дип, Фисәне дә шулай куркытып язылыштыра да, болар киленне пропискага кертергә мәҗбүр була, әмма ул, мескенкәй, биредә кол урынында. Өйләнгәнче дә Марс җүнләп бер җирдә дә эшләмәгән, гел куылган, чөнки эчкән, отышлы уеннар белән мавыккан, әле дә шешә кочып, диван саклый хәшәрәт. Аның каравы, йокласа, аруны белми ялкау. Яшәп тә камилләшүгә бармау – мунчага барып та, юынмау белән бер ул. Хәер, әнисе нинди – баласы шундый. Халык төгәл әйтә бит, яхшы картлар юк урында яхшы яшьләр булырмы, дип. Гел хатыныннан аракы, азык, закуска таптыра. Фисә әллә ничә урында эшли. Фатирларына йөреп, ярдәмчесе булмаган өлкәннәрне карый, ремонтлар ясый, бер офисны юа да бугай әле. Өендә, бакчаларында да бар мәшәкать аның җилкәсендә. Кояшны айга ялгап тырыша, сагышын эш белән баса, ахрысы. «Бәлки, Марс белән бергәләп, улыбызны табарбыз дип кенә, аңа кияүгә чыгарга ризалашкан идем. Бу хакта сүз кузгаткач, икәүләп котырындылар, Марс мине кеше төсеннән чыгарып кыйнап, изеп ташлады», – дип елады берчак. Кеше бәхеттә дә, газапта да ялгыз шул, нишләмәк кирәк. Алган ире яратса, кара хатын ак булыр, диләр дә бит. Бу ләгънәт төшкере нинди алтын хатынны типкедә яшәтә. Мин дә әлегә гел тыелып торам: «Мине яклап, каты эндәшә күрмә, куып чыгарсалар, кая барам?» – ди. Этләр өргәндә, сандугачлар сайрамый шул. Күтәрелеп, бер каршы сүз әйтми ул аларга. Өметең булмаса, язмышка буйсынасыңдыр. Прокурорга керсәм киңәшкә дип торам әле. Аллаһ кушса.

Нәзифә тавышы:

– Ә апасы?

– Явызлык чәчсәң, үкенеч урасың. Берзаман бөтен шәһәр шаулады: махинацияләре өчен эшеннән алдылар аны. Бер үрдән төшкәч, менү кыен шул. Аллаһ бар ул, сеңлесенең күз яше тоткандыр, кияүгә дә бара алмаган, ялгызы картая икән, авырый да бугай.

Шунда телефон язмасында ишек ачылуы ишетелде. Нәзифә аның исерек Марс булуын искәртте. Чибәр әби тавышы: «Марс, Фисә миндә юк, аны скорый алып китте. Сак бул, әниең дә өйдә түгел бугай, ут-күз чыгара күрмә!»

«Катса, катмады инде, котылыр идем имгәктән!»

Нәзифә кушыла: «Кара, гыйбрәтне, нәрсә ди?! Төскә матур гына кеше сыман үзе».

Чибәр әбисе: «Әстәгъфируллаһ, тәүбә! Тышы бизәк – эче кибәк шул була инде. Әнием мәрхүмә әйтмешли, матурлык күлмәк белән сәдәфтә түгел, оят белән әдәптә бит».

Сөяленә бассалар, сөялеп тора алмассың, билгеле. Зиннәт тә, ачу ташы йоткандай, арлы-бирле йөренә башлады.

– Шунда үзем булсам, стенага селтәр идем ул хөрәсәнне. Үчемне бер алмый калмам калуын. Үземнең дә, әниемнең дә күз яшьләре өчен. Тик көне бүген түгел. Хәзергә тапкан һәм баккан әниләрем хакына түзим тагын бераз. Хәер, болай да беткән кеше инде ул, мәхлук. Аллаһ миннән яхшырак белер, җәзасын да бирер.

Шулай да шатлыгы чиксез аның бүген. Әнисе чын әни икән бит, аңа күкрәк сөтен имезгән, ташларга теләмәгән, мәҗбүр иткәннәр. Ул улын эзләгән, яшь түккән. Баласын табарына өмет белән барына да түзгән. Ана мәхәббәтенә тиң мәхәббәт юк икән дөньяда. Исән генә булсын, ул аны бүтән җәберләүгә бирмәячәк. Әнә Чибәр әби дә сүзен ничек йомгаклаган бит, театр сәхнәсендә монолог укый диярсең:

– Нигә түзә? Нигә көрәшми? – дибез. Өметен җуйган дип санавым да ялгыш, чөнки аналык хисе бар аңарда, ә аналарның көчсез булырга хакы юк. Юк, көчсез түгел, улын табар өмете аны көчле итә.

Нәзифә белән киңәшләшеп, Зиннәт хастаханәгә шалтыратып, әнисенең хәлен белеште.

– Саташамы? Нигәдер «Үләсем килә!» дип бәргәләнде, елады да, уколлардан соң йоклап китте, – диде шәфкать туташы. Иртүк хастаханәгә барырга булып, яшьләр дә йокларга ятты.

## Гөнаһ кылсаң, тәүбә ит

Зиннәт белән Нәзифә төнне йокылы-уяулы катыш, әни кешене ничек юатып, ничек җәбердән коткару турында фикерләшеп чыктылар. Әмма аның үзенең теләгеннән башка аларның фикере, әлбәттә, әле буш хыял гына иде.

Иртән чәйләп алуга, яшьләр икесе бергә дәваханәгә җыена башлады. Кибеткә кереп, җиләк-җимеш, төрле сутлар алдылар. Күңелләре дә кичәгегә караганда күтәренке иде аларның. Иртән Зиннәт шалтыратып белешкәч, шәфкать туташы әнисенең хәле уртача булуын, процедуралардан соң иртәнге ашны капкалап алуын әйтте. Шуңа да борчылулары бераз кимегәндәй булды.

Фисә чынында исә кичке уколлар һәм дарулардан соң үзен тынычлангандай тоеп йоклап китсә дә, төннең икенче яртысын йокылы-саташулы үткәрде. Ниндидер кара көчләр аны тирән чоңгылга сөйри, ә сабый улы: «Әни, китмә! Аларга иярмә, әйдә минем белән», – дип үзенә дәшә. Фисә сабыйны итәгенә алып сөя, аңа күкрәк сөтен имезә, шатлана, көлә, имеш. Әмма уянып, күзләрен ачуга, кичәге хәлләрне, улы белән очрашуын, аның ачулы карашын исенә төшерүгә, сөенеченең эзе дә калмады. Улының үлемен юрап алдаганнар. Улы исән, ул тере! Монысы нинди шатлык та бит. Тик аның нәфрәте дә нинди чиксез?! «Хәсис», «хәчтерүш» дип атады бит. Аның моңа тулы хакы бар, әлбәттә. Анасының үзен ташлап калдыруына сөенеп, кочакка ташлансынмыни? Нинди авырлыклар кичкәндер, кем кулларында үскәндер, мескенем, юк, газизем? Әллә аны күпләр яратып, Чибәр әби дип йөрткән Мәрфуга апа эзләп тапканмы соң? Ул гына белә минем сызлануларымны, ул гына керә минем хәлемә. Әллә саташтым гынамы, күземә генә күрендеме соң улым? Юк, юк, саташмады да, төшләнмәде дә, өнендә күрде ул аны, ачулы карашы белән очрашты, җаны-тәне белән аның чиксез нәфрәтен тойды.

Мәрфуга апа ислам динен тирәнтен белә. «Гөнаһ тәүбәсез булмый. Гөнаһ кылсаң, тәүбә ит!» Ул әнә шулай ялгыштан, гөнаһтан тәүбә итү кирәклеген сөйләгәне бар: «Аллаһ рәхмәтенең чиге юк. Тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ

бөтен гөнаһларны ярлыкаучы. Син мәҗбүр ителгәнсең, гөнаһың да зур түгелдер, бәлки?.. Кояш мәгърибтән чыкканчы, тәүбәләр кабул ителә. Ә дөреслектә, үлем алды гырылдыгы ишетелгәнче, Аллаһ үз колының тәүбәләрен кабул итә».

– Аллаһым, гөнаһларымны кичерсәң иде. Улымның тормыш юлында очраган иманлы кешеләргә рәхмәтләрем барып ирешсә иде. Улым калган гомерен бәхеттә, шатлыкта үткәрсә иде. Аңа иманлы, бәрәкәтле, хәерле гомер насыйп итсәң иде. Амин! Амин! Амин! – Ул үзе белгәнчә әнә шулай бирелеп, ихлас теләкләр белән догасын кылды. Ә үзенең ике күзеннән чишмәдәй булып кайнар яшьләре ага, ә йөрәге дөп-дөп кага иде.

Бәлки, Җәмил аны үзе эзләп килгәндер? Нәфрәтен белдерергә, битенә төкерергә? Тәүбә! Нинди гарьлек! Ул, димәк, тагын киләчәк әле. Өзелеп: «Әнием!» – димәячәк, аны табуына шатлыктан елмаеп көлмәячәк, кочып сөймәячәк. Ә Фисә күпме хыялланды шул хакта. Яшене алдан булса, күкрәве арттан булмый калмас. Улының күзенә ничек күренер дә, нәрсә дип җавап бирер? Аллаһ мәрхәмәтле, ул аның күз яшьләренең шаһиты, бәлки, кичерер дә, ә улы, юк, кичермәс, кичермәсен дә, кирәкми, тиеш түгел! Аклап, гафу итеп, кичереп буламы соң мондый әнине? Нигә шунда улын тудырганда яисә кичә хуштан язып егылганда, җан тәслим кылмаска? Аллаһым моны минем өчен бик җиңел үлем була дип уйлагандыр, мөгаен?!

Шунда йөрәге чәнчеп-чәнчеп куйды... Бәй, ул палатасында берүзе ләбаса. Күрше койкадагы ханымны иртән чыгардылар, яңалары иртәгә генә кабул ителәчәк. Җыештыручы исә бүлмәне сөртеп, юып, җилләтер өчен тәрәзәне каерып ачып калдырды. «Күпме әрнеп яшәп була ул? Яшәргә хаклымы соң әле син? Җиңел үлем – тәрәзә ачык, сигезенче кат, тот та сикер! Менә чишелеш! Әллә шуңа да йөрәгең җитмиме? Күз ачып йомганчы син юксың, бөтен гөнаһларың, әрнүләрең, күз яшьләрең белән». Уйлады да, сикереп торып, урындыкка басып, тәрәз тупсасына менеп тезләнде...

Түбәндә баш әйләнерлек чоңгыл! Булсын! Аска очсын! Бары да бетсен! Менә ул тезләреннән күтәрелеп, аякларына басты. «Кай якка ташланырга? Исән калырлык та, интегерлек тә булмасын! Шул мизгелдә үк якты дөнья белән хушлашсын!»

* * *

Зиннәт белән Нәзифә дәваханәгә килеп җиткәндә, таксидан төшеп ятучы Чибәр әбигә очрадылар. Аның да, күчтәнәчләр төяп, хәл белергә килеше икән. Ял көне сәбәпле халык та хәтсез иде, лифтка да чират тезелгән. Тик Зиннәткә бу бик озак тоелды. Ул ак халатны иңенә салып, аяк киеме өстеннән бахиллаларын кидерде дә, баскычтан йөгерә-атлый менеп тә китте. Үзенекеләр килеп җиткәнче, ул әнисеннән кичәге сүзләре өчен гафу үтенеп өлгерсен. Анасын танымаган Алласын танымас.

«Синең хакта начар уйлавым өчен гафу ит, әнием, дияр, минем аркада күргән җәберләнүләрең өчен гафү ит», – дип, тезләнеп гафу сорар.

Палата ишеген сак кына шакып, әкрен генә ача башлауга, ул каерып ачылган тәрәзә төбенә күтәрелеп ятучы әнисен тиз шәйләп алды. Әллә атлады, әллә канатлар үсте? Бер омтылуда: «Әни!» – дип, аякларына барып ябышты.

– Әни! Кирәкми! Калдырма мине бүтәнчә үзеңнән! Йә түбәнгә икәү бергә очыйк! Гөнаһың тузан – таудай җәзаң. Мин аңладым, син гаепсез. Зинһар, әнием!.. Мин сине шундый сагындым! – Улы аны тәрәз төбеннән күтәреп төшереп, кочагына алды.

Әни кеше гәүдәсен дә тота алмый сыгылып төште:

–Улым, Җәмилем! Гафу ит, балам! Мин гаепле! Мин көчсез! Мин юньсез! Син гафу итсәң, үлем миңа һич куркыныч түгел! Түгел! Ярлыкану! Нинди зур бәхет!

Лифтка чират көткәндә һәм аннан чыгып, палатага килеп җиткәндә, Нәзифә туганына соңгы яңалык һәм ачылган серләрне сөйләп өлгергән иде инде. Алар балкып, сөенешеп килеп кергәндә, ана белән улы бер-берсенең кочагында шатлык яшьләре түгә иде.

## Аның исеме мәхәббәт иде

Чәчәкләрнең хуш исе бөркелеп торган җәйге көннәрнең берсендә бакчада алмагач күләгәсендә бизәкле диванчыкта сыенышып утырган, бер-берсенә тартылу хисләре тышкы кыяфәтләреннән үк сирпелеп торган, өлкән яшьтә булуларына карамастан, яшьлек чибәрлекләрен җуймыйча, үзләре белән ияртеп йөргән бер матур парны күрергә мөмкин иде.

– Чәең суына, гөлкәем, – дип, аркасыннан кочып дәште ире назлы тавыш белән хатынына. – Күзең сукыраеп, башыңа кан савып куймасын ул кадәр алсыз-ялсыз язуыңа. Гашыйк булгандай, кәгазеңә мөкиббән карап утырасың. Билләһи, мине дә тәмам оныттың бугай, – диде ул шаяру катыш.

Ә хәләле аңа күтәрелеп карап елмайды да:

– Онытып буламы соң синдәй егет асылын?! – дип, соңгы битен ябып, калын дәфтәрен иренә сузды:

– Гаиләбез тарихын сиңа тапшырам, алтыным. Балаларга, оныкларга истәлек, үзебез дә гел укырбыз искә алып...

– Хәерле булсын, өлешемә көмешем минем, рифмалап сөйләшә башладың лабаса. Туган телне авылда үскән кешедән дә яхшырак белүең соклануга лаек. Яшьли гел русча сөйләшеп, исемеңне дә Фаина дип белә идем югыйсә. Югары партия органнарында эшләгән әтиеңнең, баласын милли мәктәптә белем алдыруы, ул гына да түгел, җәйләрен авыл мохитендә дәү әниләр итәгендә тәрбияләнүең нәтиҗәседер бу?!

– Бәй, онытмадыңмы, хәзер озакламый синең улың белән минем кызым кайта, әнкәсе, әй, кодагый, студент оныкларыбызны ияртеп... Синең «Ярлыкану бәхете» дип исемләгән бу тарихыңны алар белән укырбыз, бергәләшеп, – дип, ире чәй янына кып-кызыл бакча җиләкләре китереп куйды. – Искитмәле хәл: җиләкләрдә синең ироннәрең тәме!

Бу икәү янында, аларның җаннарын бербөтенгә берләштереп, илаһи бер кодрәт сирпелеп йөрде: аның исеме мәхәббәт иде...

Ә бу мәхәббәтле затлар, ярлыкану бәхете кичереп, балалары туенда кавышкан Назыйф белән Фисә, аларның өзелеп көткән газизләре исә – Зиннәт белән Нәзифә һәм оныклары, булачак табибә Разия белән, нефтьче һөнәрен сайлаган Җәмил иде.

# КЫСКА ЮЛНЫҢ ДӘВАМЫ ЯКИ МӘҢГЕЛЕК СЕР

«Казан утлары» журналы редакциясендә эшләүчеләр белән аралашу юлым бик кыска иде. Декабристлар урамындагы газета-журналлар нәшриятының (хәзер «ТАТМЕДИА») беренче катыннан сигезенче катына лифтта менүдән гыйбарәт иде ул. Узган гасырның 80 нче еллары башы. Сигезенче каттагы «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасы редакциясендә эшләп йөрим. «Казан утлары» редакциясендә эшләүче язучыларны лифтта күргәлим. Берсендә шулай кабинага бер-бер хикмәтле сүз әйтеп куя, җиңелчә генә төрттереп ала торган баш мөхәррир Зәки Нури килеп керде. «Зәки ага, сез ничәнче катка менәсез? Кайсы кнопкага басыйм?» – дип сорады бер кыз. «Минме? Мин азат, бик азат хатыннар янына менәм. Алардан бер катка өскәрәк», – диде З.Нури һәм, югарыга карап, борынын килешле генә тартып куйды. Кыз фронтта булган, партизаннар белән карурманнар гизгән шагыйрьнең тел төбен, дөресрәге, юморын, «азат хатыннар» дигәндә, тугызынчы каттагы «Азат хатын» журналы редакциясен күздә тотканын бик тиз аңлап алды, нәзек-нәфис бармаклары белән 10 нчы төймәне кабызып куйды. Елмаеп-көлешеп алдык. Мин исә сигездә төшеп калдым.

Ходайның рәхмәте, байтак еллар үткәч, «Казан утлары»на эшкә Татарстан Язучылар берлеге, «Чаян» журналы мәктәпләрен үтеп, прозаик Камил Кәримов килде. Без «Яшь ленинчы»да бергә эшләгән идек. Шунда таныштык. Беренче көннән үк җеннәребез килеште. Миңа да пионерлар һәм мәктәп балалары басмасыннан соң Татарстан китап нәшриятында (ул вакытта Бауман урамында), «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә (Чистай урамы, 5) кәгазь тузанын суларга туры килде. Газета-журналлар нәшриятына юлым төшсә, Камил абый янына кермичә калмыйм. Бер керүемдә ул миңа «Яз әле безгә! – дип әйтеп куйды. – Шуны бел: әсәре «Казан утлары»нда басылмаган язучы язучы түгел!» Мине – ул вакытта Татарстан китап нәшриятында балалар өчен дәфтәр калынлыгында гына булса да «Бүре кадәр бүрек» дигән бер китабы чыккан авторны уйландырды бу сүзләр. Тик менә республикабызның төп әдәби басмасына ни турында язарга соң? Моңа кадәр язганнарымның геройлары – бераз гына мактанчыграк, бераз гына ялкаурак, бераз гына һавалырак малайлар. Алар белән шундый дәрәҗәле журналга ничек керәсең?! Шулай уйланып йөргән көннәрнең берсендә беренче сыйныфта укучы улымны мәктәпкә барганда, коймасы да булмаган төзелеш янында пычрак юл аша чыгалмый интегеп йөргәндә, машина бәрдерде. Баш мие селкенгән, таз сөяге сынган. Ай буе бүлнистә улымны саклап яттым. Шунда «Җиденче палата» дигән повестем язылды. Аны «Казан утлары»на Камил абыйга биреп карадым инде. Бирдем дә җавап көтә башладым. Өстәл почмагындагы тын телефон гел шалтырап алган кебек тоелды. Рәхмәт төшкере, эшне озын-озакка сузмыйча шалтыратты Камил Кәримов: «Укыдым. Әйбәт! Киләсе санга ук тәкъдим итәм». Шатлыгымнан күккә очардай булдым. Тик шатланып, канатланып йөрүләрем озакка бармады. Бер-ике атнадан кичен телефон тагын шалтырады. Журналның баш мөхәррир урынбасары Рәфикъ Юныс:

– Вакыйф! Бу повестеңны журналга биреп булмастыр...

– Нишләп, Рәфикъ абый?

– Безгә бармый...



*«Казан утлары» журналы редакциясендә эшләгәннәр һәм эшләүчеләр белән очрашу истәлеге. Утырганнар (уңнан сулга): Рәфикъ Юныс, Мансур Вәлиев, Илфак Ибраһимов, Рашат Низамиев, Рәдиф Гаташ; басканнар (уңнан сулга): Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Элеонора Җамалиева, Лилия Гатауллина, Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Рәзилә Хәйретдинова, Рамил Ханнанов, Фәнил Гыйләҗев. 2017 ел.*

– Проза бүлеге егетләре ошатты бит, Рәфикъ абый! Камил Кәримов «әйбәт» диде. Мансур Вәлиев «Шәһри Казан»га рецензия яза, дип тә ишеттем әле.

– Ярый, тагын бер кат укып карыйм әле...

Өстәл почмагындагы телефон идәнгә төшеп чәлпәрәмә килгән кебек булды. Тәнем эсселе-суыклы. Нәрсәсе ошамады икән соң Рәфикъ абыйга?! Журналның киләсе санына планга кергән иде бит инде. Хәзер төшереп калдырырлар микәнни?!

Иртән борчулы уйлар белән эшкә килеп, бүлмә ишеген ачсам – телефон! Тагын Рәфикъ абый шалтырата:

– Вакыйф, бара икән, бара повестең! Котлыйм!

– Рәхмәт, Рәфикъ абый!

Башка сүз әйтә алмадым. Тагын канатланып киттем.

Повесть басылып чыкты. Мин – күктә! «Җиденче палата» чыгуга, Мансур Вәлиев – «Шәһри Казан»да, Арчадан якташым Радик Фәизов – «Мәдәни җомга»да, Балтачтан Рәфыйк Шәрәфиев «Казан утлары»нда әлеге әсәрем турында рецензияләр язып чыктылар. Боларын көтмәгән идем. Рәхмәт инде!

Бер-ике ел үткәч, Рәфикъ абый белән булган хәл тагын кабатланды. «Казан утлары» журналына «Соңгы йөреш» дигән хикәя тәкъдим иттем. Егетләргә тагын ошады. Рәфикъ абыйга тагын ошамады. Үзе нәрсәсе ошамаганын тәгаен әйтми. Арча районы Сеҗе авылыннан фронтовик, укытучым, остазым, рәссам, шахматчы Үзбәк Яхин турында иде ул хикәя. Авылдашым, язучы Гөлчәчәк Галиеваның бертуган абыйсы. Гөлчәчәк апа белән аның ире, татар дөньясында күренекле шәхес, «Компрессормаш»ның генераль директоры, галим Әхмәт Галиев (аларга хикәямне журналга биргәнче үк күрсәттем, тәкъдим-киңәшләрен исәпкә алып, байтак урыннарын үзгәрттем, ошаттылар дип уйладым) Рәфикъ абыйның дуслары да бит инде югыйсә. Үземчә болай фараз кылдым: «Соңгы йөреш» – шахмат уены белән бәйле, ә Р.Юныс – оста шахматчы. Димәк, хикәямдә бу тылсымлы уенның асылын, могҗизасын күрсәтә алмаганмын». Бу юлы Рәфикъ абыйның хикәямне ошатмавы белән күпмедер дәрәҗәдә килешкән дә идем инде. Иртән тагын шалтыратты бит: «Вакыйф, бара икән, бара!» Тагын котлау! Тагын миннән рәхмәт!

Лифтта «Казан утлары»ның җилен тоеп менгән еллар еракта калды. Аллага шөкер, ул кыска юлның дәвамы бәрәкәтле булды. «Казан утлары»нда тагын «Мәһдиев һәм...», «Ни хәлең бар, балам?», «Кышның озын бер төне», «Казан күркәсе» дип

аталган бәяннарым, унлап хикәям басылып чыкты. Үзләре белән күрешергә насыйп булган яки янымнан үтеп киткән күренекле шәхесләр (шагыйрь Евгений Евтушенко, СССР оборона министры, Советлар Союзы маршалы Дмитрий Устинов, партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Рәшит Мусин, заманында Казанга килгән Германия Демократик Республикасы социаль-бердәм партиясе Үзәк Комитеты генераль секретаре Эрих Хонеккер, полководец, генерал-лейтенант Якуб Чанышев, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы Рәисе Шамил Мостаев, «Социалистик Татарстан» газетасы баш мөхәррире Шәмси Хамматов һ.б.) турында хикәяләр циклы да шушы журналда дөнья күрде.

Татарстан Язучылар берлегендә эшләп йөргән көннәремнең берсендә тагын телефон шалтырады. «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин: «Әйдә, безгә эшкә кил әле!» – дип чыкты. Әүвәл проза бүлегендә азау тешен ярган Камил Кәримов белән киңәшкәннәр, дип аңладым. Республикабызның төп әдәби журналында эшләүдән ничек баш тартасың?! Ризалык бирдем. Редакциягә кичә генә килгән кебек, бактың исә эшли башлавыма 9 ел тула икән бит инде. Өч баш мөхәррир белән эшләгәнмен, редакция баскычларының (бүлек мөхәррире, җаваплы сәркатип, баш мөхәррир урынбасары) барысын да үткәнмен, югыйсә теләгем проза бүлегендә тыныч кына утыру иде. Шунысын да әйтеп китим: үзең редакциядә эшләгәч, азрак язарга, аларын да әллә нигә бер генә чыгарырга туры килә икән. Капиталь ремонттан соң «Казан утлары» редакциясе үзе унынчы каттан сигезенче катка – кайчандыр «Яшь ленинчы» редакциясе булган бүлмәләргә төшеп утырды. Ходайның рәхмәте, без Камил Кәримов белән танышкан, элек бергә эшләгән бүлмәбезгә 40 елдан соң кире әйләнеп кайттык.

Рәфикъ абый белән бергә эшләдек. Аның бөтен теләге – «Казан утлары»н яратып укысыннар. «Әйдәгез, журналны кызыклырак итеп чыгарыйк әле!» – ул бу сүзләрне редакциянең «планёрка»ларында, «летучка»ларында әйтмичә калмый. Бервакыт укучылар арасында иң яхшы хикәягә конкурс үткәрергә тәкъдим итте ул. Бу бәйгенең үзенчәлеге шунда: беренче җөмләне без үзебез язабыз һәм журналда бастырып чыгарабыз. «Фәхрине үтереп ташладылар» кебек зәһәр, уйландыра торган җөмлә булырга тиеш ул. Укучылар шуны дәвам иттереп хикәя яза. Хикмәти хода, без аткан «җим»гә балык шактый капты бит, әй! Җиңүчегә бүләкне Р.Юныс үз акчасына, кибеткә үзе барып алды. Бизәкләре балкып торган ваза иде ул.

Рәфикъ абый ашханәдә төшке ашны (ул ит ашамый, сөттә пешкән ботка белән җиләк компотын ярата) ашап менгәч, еш кына безнең бүлмәгә керә дә әйтеп куя:

– Югарыдан хәбәр килде.

– Нинди хәбәр?

– Тормыш дәвам итә, дигәннәр...

Кәефләр күтәрелеп, күңелләр хушланып китә.

Рәфикъ абый миңа бүтән «бәйләнмәде». Нигә теге чакта повесть белән хикәямне башта ошатмады, аннары ошатты соң ул? Әллә әсәрләрем кич кояш баегач – бер төрле, иртән кояш чыккач, икенче төрле тәэсир итте инде? Әллә аның үзенә күрә бер шаяртуымы? Әллә серкәсе су күтәрә микән дип, якташын сынап каравы булдымы? Әллә иҗат юлының сикәлтәле булуын кисәтүе идеме? Әллә... Байтак еллар күрше бүлмәләрдә Рәфикъ абый белән бергә иңгә-иң терәп эшләргә туры килсә дә, бу сорауларны аның үзенә бирергә өлгерә алмадым. Бу минем өчен сер булып калды. Ул серне заман зәхмәте аркасында көтмәгәндә вафат булып (организмына зыян сала торган гадәтләрдән азат, сау-сәламәт кешенең озак яшәячәгенә ышанмадыкмыни – ышандык), фидакяр, ихлас, чиста күңелле Рәфикъ абый Юныс мәңгегә үзе белән алып китте.

**Вакыйф НУРИЕВ**

# «КАЗАН УТЛАРЫ» – ТАТАРНЫҢ «ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ»

Бу исемне аклап яисә аңлатып торуның хаҗәте юктыр. «Казан утлары» безгә газиз балабыз, якын туганыбыз кебек кадерле, аның һәр санын сөенечле хәбәр, күчтәнәч кебек күтеп алабыз, баскычтан өебезгә күтәрелгәндә үк, түземсезләнеп эчтәлеге белән танышабыз. Чөнки татар сүз сәнгатенең төрле жанрларга караган иң затлы әсәрләре шунда басыла, тәүге бәяләрен шунда алалар. Шул басмада дөнья күргәннән соң, әсәр мәдхия нурында коенса да, тәнкыйть утына эләксә дә, инде ике кеше «җаваплы санала»: иҗатчы һәм журнал хезмәткәре. Г.Бәшировның «Намус» романы Сталин өстәленә килеп кергәнче, А.Расихның «Ике буйдак» әсәре Ф.Табеев күзенә чалынганчы, беренче сынауларын әдәби журналыбызда узганнар. «Совет әдәбияты» – «Казан утлары» баш мөхәррирләре элек-электән күренекле язучылар, танылган каләм ияләре, сүз сәнгатебез үсешенә өлеш керткән зыялы һәм милләт гаме белән яшәүче җитлеккән шәхесләр булдылар.

Шәхсән үзем, әүвәл «Совет әдәбияты», хәзер «Казан утлары» дип аталган басмаларны мәктәп баласы чагымнан ук укып бардым дип, күкрәккә сугып кәпрәя алмыйм. Туган авылым Кычытканлы кергән Нурлат төбәге матди яктан бай булса да, мәдәни-әдәби үсеш җәһәтеннән мәркәзебез Казанга сыланып утырган Арча, Биектау, хәтта шактый каләм ияләрен, сәхнә әһелләрен биргән Балык Бистәсе районнары белән ярыша алмый. Җитмәсә, урманга, тәпиләрне «иркәләп» алуны изге бурычы санаган кычытканга, елга-күлләргә бай авылыбызны әүвәл Биләр, аннан Тельман (мишәрчә Тилмән), Октябрь, ниһаять, Нурлат районына теркәп, почтальоннар «эзләп тапмаслык» дәрәҗәдә бутап бетергәннәр. Шулай да, һәр татар авылында уку-язуга һәвәс якты йолдызлары үсеп чыккан шикелле, Кычытканлы да искәрмә булмаган. Андый затларның берсе булмышы һәм язмышы белән кабатланмас шәхес – әтинең бертуган кече сеңлесе, күпләрнең һәм минем миемә әлифба сеңдергән, беренче укытучым Рәисә Хафизова иде. Сугыштан соңгы елларда укытучыларга кытлык булу сәбәпле, элек-электән мәгърифәтле, беренче татар профессионал режиссёры Габдулла Кариевны биргән, ул чорда әйләнә-тирәдә бердәнбер урта мәктәпле авыл Күлбай-Морасада өлгергәнлек аттестаты алуга, аны Кычытканлының башлангыч сыйныфына укытучы итеп билгелиләр. Соңрак аңлавымча, ул даими рәвештә «Совет әдәбияты» мәҗмугасын алып, үзе укып, якыннарын таныштыргач, мәктәп китапханәсенә тапшыра барган икән. Бишенче-җиденче сыйныфларда укыганда инде, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барган апам журналда басылган әсәрләр белән таныштыра, минем дә иҗатка, «такмак» чыгаруга һәвәслегемне сизеп хуплаганын, «ни өчен журналыбызның «Совет әдәбияты» дип аталуын шәрехләүне сорап, башын катырганымны һәм аның «таралып утырган татарларны һәм барча төрки халыкларны күздә тотып кушылган исем», дип иренмичә аңлатуларын яхшы хәтерлим.

Студент елларымда, өлкән курсларда укыганда, атаклы журналист, язучы М.Гәрәев кулы астында радиода корреспондент булып йөргәндә, журналыбызда басылган, бигрәк тә зачёт-имтиханнарга кертелә, курс эшләренә бирелә башлаган әсәрләр белән «аралашсам» да, чын-чынлап әдәби мәҗмугабызга читтәрәк, Алабугада яшәгәндә якынаеп киттем. С.Хәким иҗатына багышланган беренче мәкаләм журналга «юл яргач», Ш.Галиев, Г.Афзал, И.Юзеев, Л.Шагыйрьҗан, Г.Зәйнашева, замандашларым Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Р.Мингалим, Р.Гаташ, Ә.Гадел һәм башка шагыйрьләребез

турындагы язмаларым басылды. С.Хәким, М.Мәһдиев, Ф.Миңнуллин, Ш.Галиев, И.Юзеевлар пединститут студентлары белән очрашуларга даими килеп йөри башлагач, Алабуга ул чорда үзенә күрә икенче мәдәни үзәккә әверелде. Без еш кына соңгы чорда «Казан утлары»нда басылган әсәрләр турында студентлар, укытучылар белән бергә сөйләшә, бәхәсләшә идек. Әдәбият, тел мөгаллимнәре, соңрак фән докторлары Р.Салихов, Н.Вәлиев, Ф.Юсупов һ.б. талибларына курс эшләре итеп, яңа басылып чыккан әсәрләрне бирә башладылар. Шул чорда минем әдәби, тәнкыйди эшчәнлегемне дә «күреп алдылар» һәм әүвәл Язучылар идарәсе әгъзасы итеп сайладылар. Г.Ахунов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, М.Мирзаларның баш мөхәррирлек чорында «Казан утлары»ның редколлегия әгъзасы идем. Бу мактаулы иҗтимагый вазифалар ректорлыгымның абруен да күтәреп җибәрде һәм «Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре» факультетын, аның каршында Төрки телләр һәм әдәбиятлар буенча яклау советын ачканда да, рухи терәк булып торды.

Алабугада яшәгәндә дә, бигрәк тә Казанга күчкәч, мин бер утырышны да калдырмадым дисәм дә, ялган булмастыр. Чөнки каләмдәшләрең белән очрашуларны көтеп аласың һәм, Ф.Бәйрәмова истәлекләрендә язганча, үзеңне җанлы әдәби процесс өчен җаваплы һәм кирәкле шәхес итеп сизәсең. Ул елларда редколлегия утырышларында әүвәл журналның әле генә табадан төшкән коймактай, соңгы санында басылган әсәрләр турында кызу-кызу, тузаннар туздырып, яшермим, һәркайсыбыз үзебезне күрсәтеп калырга да тырышып, бәхәсләшеп ала идек, аннан соң агымдагы һәм алдагы айларга тәкъдим ителә торган байлыгыбызны «уртага салып» фикер алышырга, беришесен укып, фикер туплап килергә «өйгә» дә биреп җибәрә торганнар иде.

Әлеге очрашуларда «Казан утлары»ның мөхәррирләре, аларның үз-үзләрен тотышлары белән тирәнрәк танышып, психолог булып бетәсең. Һәр баш мөхәррирнең үзенә генә хас холкы, эш ысулы булуы табигый. Мин якыннан белгән журнал хуҗалары арасында Гариф Ахунов чын демократ иде. Адәм баласы шундый: иң яраткан кешесенә кушаматлар тага. Без аны артыннан әсәрләренең исеменнән алып, әүвәл «Хыялый Хәйрүш», соңрак «Габбас хәзрәт» дип йөртә идек. Үзенә әйтсәң дә, үпкәли белми, көлеп кенә куя иде. Аңардан соң килгән мөхәррирләр белән мондый шаяртулар үткәндә калдылар.

Аңарга алмашка килгән Р.Харис, «Казан утлары»н чирек гасырга үз кулына алган Р.Фәйзуллин – икесе дә үз иҗатлары белән татар поэзиясен дөнья сүз сәнгате дәрәҗәсенә күтәргән шагыйрьләр, журналның сыйфат дәрәҗәсенә хилафлык китерү генә түгел, әсәрләргә таләпләрендә, Х.Туфан әйләнешкә кертеп җибәргән «рифмачыларны» басмага якын да китермәделәр дип беләм. Шул ук вакытта алар һәркайсы үзләренчә уйлый, эшли торган кабатланмас җитәкчеләр буларак ачылдылар. Р.Харис, үз иҗатындагы шикелле, утырышларны алып баруында да, фикерләү, сөйләү рәвеше буенча философ булып калды, үз гоманын, бәясен рус, дөнья әдәбиятыннан мисаллар китереп дәлилли иде. Үз карашын, мөнәсәбәтен көчләп такмаса да, үзгәрәк фикер белән килешкән була да, без «мәрткә китебрәк» утырган мәлдә, үз уен уздырып куя белде. Барыбыз да «кылган гамәлләребездән» канәгать калып, елмаешып, эрелек касәфәтен саклап таралыша идек.

Югары Советка депутат булып сайланып, соңрак Рәис урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелгән Р.Харисны журналда алыштырган Р.Фәйзуллин шактый гамәли тәҗрибәле шәхес иде. Әлмәт язучылар оешмасы сәркатибе, башка җаваплы вазифалар үтәгән әдип, редколлегия утырышларында кемгәдер үзен кырысрак тоткандай, нәтиҗәләрен дә кискенрәк ясагандай тоелгандыр. Миңа аның холкы, табигате үз каләменнән төшкән «Сагыныр дип уйласаң да, ялыныр дип уйлама», дигән дүртьюллык парчасындагы фикеренә тәңгәл килгәндәй тоелды. Ул уен, бәясен берничә төгәл җөмләгә сыйдыра алу сәләтенә ия иде. Журнал хезмәткәрләренең, «без ул кулъязмаларның барысын да укып

бармый торгандыр дип уйлап, аның тәнкыйтенә «юлыгып», авыр хәлдә калганыбыз булгалый иде», дип зарланганнары хәтердә.

Р.Фәйзуллин «ТАТМЕДИА»га киңәшче итеп билгеләнгәч, «Казан утлары»на башка хуҗа килде. Актаныш хакимиятендә, Мәдәният министрлыгында чирканчык алган, шигырь-поэмаларында чорыбызның катлаулы халәтен, көтелмәгән борылышларын шактый бай тел, халыкчан сурәт-хисләр белән чагылдыру сәләтенә ия М.Мирза, 2005-2012 елларда Язучылар берлеге рәисе вазифаларын башкарганнан соң, «Чын мирас» журналында эшли башлаган җиреннән «Казан утлары»на «күчеп утырды». Мөнәсәбәтебездә юк кына бәхәс өчен (ни өчен икәнен хәзер хәтерләмим дә) ул мине редколлегия әгъзалыгыннан «азат итте». Мин үпкәмне дә белдермәдем, тавыш та күтәрмәдем. Берничә ай үтәр-үтмәс, өй телефоны шалтырады. М.Мирза икән.

– Тәлгат абый, төштән соң минем янга кагыла алмассызмы икән?

– Әлбәттә, – дим. – Пенсионерның вакыты күп.

Иркен, затлы бүлмәдә Мөхәммәт Мирза белән озаклап чәй эчеп, гәпләшеп утырдык. Миннән ул, В.Белинскийның «Взгляд на русскую литературу такого года...» мәкаләләре тибындарак, төрле басмаларда урын алган 2016 ел шигърияте турында күзәтү язып чыгуымны сорады. Риза булдым һәм җиң сызганып эшкә керештем. Ул тиз арада «Казан утлары»нда басылып та чыкты. Бик мул итеп гонорарын да тамыздылар.

М.Мирзаны яшь галим һәм прозаик Р.Галиуллин алыштырды. Халыкта мулласы нинди, мәхәлләсе шундый була, дигән мәкаль бар. Дөньяга таралган татарларны җыеп, берләштереп йөрүгә гомерен багышлаган затлы каләмле, кыю фикерле язучыларыбызның берсе Тәүфикъ Әйди иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклап, татар филологиясе фәне үзәге ТӘҺСИдә гыйльми сәркатип булып эшләгән кешенең журналда да фәнни юнәлешне игътибарсыз калдырмавы табигый иде. Җан исәбен алу тарихына, нәсел-нәсәбе татар булган галимнәргә игътибар үсүне хупларга кирәктер. Р.Галиуллин уку чорында иң яхшы старосталарның берсе, аспирантым иде. Фәнни җитәкчесе буларак, аңа иҗади уңышлар һәм әдәби көчләребезне берләштерүдә маяк булуын телим.

«Казан утлары» халкыбызның «визит карточкасы» булуы белән беррәттән, язу-сызуга һәвәс шәхесләр өчен осталык мәктәбе, милләтебезнең тормышын, горефгадәтен, моңын, сыкрануын чагылдыруда, тел-сүз байлыгын саклауда ныклы терәк тә икән. Исеме әдәбиятыбыз тарихында калган кайсы гына язучыны телгә алма, аның каләмен «Казан утлары»нда чарлаган булуын күрәсең. Баш мөхәррир нинди талантлы вә эшчән булмасын, үзе генә журналны тиешле кондициягә җиткереп, әзерләп чыгара алмый. Басманың сыйфаты урынбасарларыннан, төрле дәрәҗәдәге хезмәткәрләреннән дә тора. Үзе дә нечкә психологик күзәтүләргә бай, тормышчан хикәяләр, истәлекләр авторы В.Нуриев озак еллар дәвамында баш мөхәррирләрнең урынбасары вазифаларын уңышлы башкара. Мин аны төрле жанрдагы әсәрләргә бәяләрендә арттырмый да, кимен дә куймый торган гадел белгеч дип саныйм.

Йөзек кашыбыз «Казан утлары» йөген тартып баручыларга үҗәтлекләрен киметмичә, «кирелекләрен» арттыруны теләп, язмама нокта кую да хәерлерәктер. Кадерле мәҗмугабыз талантлы сүз осталарына һәм игелекле укучыларына кытлык кичермәсен!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# ЧЫН ШАГЫЙРЬ... ҺАМАН ДА ШАГЫЙРЬ!

Татар поэзиясенең җитмешенче-туксанынчы еллар үсешендә якты һәм тирән эз калдырган иң талантлы шагыйрьләребезнең берсе – ул, һичшиксез, Зөлфәт. 1968 елда дөнья күргән «Беренче карлыгачлар» альманахында басылып чыккан ике дистәләп шигыре үк аны шигъриятебезгә килгән өр-яңа зур шагыйрь буларак таныта. Тиз арада ул күп санлы шигырь сөючеләрнең (ә бу чорда алар бүгенге көннең футбол, хоккей фанатлары кебек гаять киң массаларны колачлый һәм шактый актив иде) ябырылып укый торган авторына әверелде. Шигырьләре еш кына үзешчән һәм профессионал сүз осталары башкаруында сәхнәләрдә яңгырады.

Зөлфәт шигъриятебездә үзеннән 4-6 яшькә өлкәнрәк остазлары, укытучылары Р.Фәйзуллин, Р.Гаташлар буынының яңа дәрәҗәле поэтик фикерләү алымнарын тормышка ашыруда аларның үкчәсенә үк басып килгән гаярь-актив дәвамчысы буларак кабул ителде. Алар Мөдәррис Әгъләмов белән Казан университетының татар бүлегенә 1965 елда бергә укырга кергән студентлар иде. Бу ике автор әлеге елларда һәм аннан соң да шигъриятебез дөньясында һич аерылмас ике шук, талантларына күрә азрак иркә һәм шуңа күбрәк тә кыйналган игезәк пар кебек булды. Шунысы кызык, әлеге уртаклык аларның тууларыннан башлап (Мөдәррис Әгъләмов Татарстанның Зәй районы Биш Субашы авылында 1946 елның 13 октябрендә, ә Дөлфәт Маликов (Зөлфәт) Татарстанның Мөслим районы Үрәзмәт авылында 1947 елның 3 гыйнварында туган, ягъни аларның туган төбәкләре якын булган кебек, яшь аралары да нибарысы ике ай ярым), моннан соңгы уку, иҗат, хезмәт эшчәнлекләре дә (Мөдәррис 1965 – 1968 елларда, Зөлфәт исә 1965 – 1969 елларда берничә ел гына укып, икесе дә университеттан китәргә мәҗбүр булдылар), җитди шигъри дебютлары да бер үк 1968 елда үтеп («Казан утлары»нда һәм «Беренче карлыгачлар»да), университетны бетергәнче үк олы сәнгать дөньясына чыгу сәбәпле, иҗатларының да шәриктәш дусларына караганда, иртәрәк өлгерүе, алтмышынчы еллар азагында инде шигырь сөючеләр арасында тәмам танылып (җитмешенче еллар башында Мөдәрриснең 1970 елда «Кыңгырау», 1973 елда «Учак урыннары», 1971 елда Зөлфәтнең «Язмышлар ярында» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыкты – икесенең дә мөхәррире – Татарстан китап нәшриятының күренекле классик редакторы Рәис Даутов иде), СССР (Татарстан) Язучылар берлегенә кабул ителүләре дә бер үк 1973 елда булып, хәтта иҗатлары һәм гомерләре белән алыш-бирешләре дә (алар икесе дә 60 яшен тутырып: Мөдәррис 2006 елның 26 ноябрендә, Зөлфәт 2007 елның 15 маенда бу якты дөнья белән араны өзде) бер үк сценарийга буйсынгандай – яшәүләре дә, үлемнәре дә, үлемсезлекләре дә гел бергәлектә-янәшәлектә дәвам итте һәм итә.

***

Зөлфәт кырык еллык иҗат гомерендә шактый гына шигырьләр иҗат итәргә өлгерсә дә, аның басылып чыккан китаплары саны, иҗатында мөмкин кадәр ешрак китап чыгаруны алга куеп яшәгән күп каләмдәшләреннән аермалы буларак, алай күп түгел – нибарысы җиде китап. Аның каравы шагыйрьнең чордаш авторлардан нык аерып куйган икенче бер төп үзенчәлеге дә күз алдында – ул да булса шигъри сүзенең, сәнгатьле фикерләвенең югары профессиональ дәрәҗәдә яңгыравы!

Шагыйрьнең бай иҗат эшчәнлеген ачыграк күзаллар өчен аны ике этапка бүлеп карау отышлы.

Беренче этапка без шагыйрьнең ун еллык иҗат гомерен үз эченә алган: альманахтагы шигырьләре (1968) һәм ике мөстәкыйль китабы – «Язмышлар ярында» (1971), «Утлы бозлар» (1978) җыентыклары басылып чыккан чорны, ягъни авторның егермедән утыз яшенәчә булган иҗат гомерен кертеп карыйбыз. Болар шагыйрьнең тыелгысыз дәрт, чиксез ашкыну, оптимистик максат күтәренкелеге белән сугарылган – нигездә, Казан университетында һәм Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы икееллык курсларда уку еллары рухы белән бәйле әсәрләр.

Әйтергә кирәк, Зөлфәтнең «Язмышлар ярында» китабы бу елларда татар поэзиясендә басылып чыккан шигъри җыентыкларның иң көчлеседер, мөгаен. Монда кергән 49 шигырьнең һәрберсендә югары профессиональ каләм чаткысы сизелеп тора. Аның тиз арада киң катлам укучылар арасында зур танылу алуы да гаҗәп түгел.

Җыентыкны ачып җибәргән гадәти бер «Таңның Идел кичеп яткан чагы...» шигыреннән кайбер өзекләр китереп үтик. Биредә авторның сиземле-картиналы микросурәт белән ни дәрәҗәдә табигый эш иткәнлегенә игътибар итегез: *Таңның Идел кичеп яткан чагы... / Ул дулкыннан баса дулкынга...*

Күрәбез, таң ату күренеше әсәрдә күзәнәкле зурайткыч пыяла аша күренгән җанлы-тәэсирле рәсем ярдәмендә тасвирлана. Икенче строфада әлеге шигъри күрү, шул ук масштабын саклаган көе, инде авторның төп тасвир объектына күчерелә: *Шәһәремә офык күз сирпеде, / Шәһәремдә таңгы тамаша... / Йөзә Казан! / Гигант кораб сыман / Бәхет гаванена, / Таң аша.*

Классик үрнәк булырлык әлеге метафора ялгыз түгел, ул, концентрацияләнеп, игътибарыбызны Казанның үзәк мәйданына юнәлтә: *Нәкъ капитан күперчеге сыман / Балкып ята Ирек мәйданы. / Күперчектә – Бәхет капитаны, / Туар көнгә карый уйланып.*

Шигырь азаккача әнә шундый ачык буяулы, сәнгати тасвир камиллеген югалтмыйча дәвам итә һәм, иҗтимагый-тарихи колачлы хис-фикер үсеше белән баетылып, иң баштагы ике юлга кабат әйләнеп кайта – үзенең классик яңгырашлы финалында тәмамлана.

Әсәрнең сәнгати эшләнешенә биредә сокланырга һәм эстетик ләззәт кичерергә генә кала. Әмма ләкин... әлеге дә баягы «ләкин» сүзенең генә азрак эшне бозып торуын әйтми китеп булмый. Әгәр дә бүгенге укучыга бу елларда Казанда нибарысы чит ил кунакларына күрсәтергә дип, бер-ике татар мәктәбенең калдырылуын, барлык предметларның (нәкъ ярты гасырдан соң ил сәясәтенең төгәл кабатлануын кара син!) урысча укытыла башлавын һәм, әллә кая бармыйча, шагыйрьнең студент буларак «чыгымчылаган» үз язмышының да шул кара еллар шаукымы нәтиҗәсе икәнлеген искә төшерсәк, биредә автор тасвирлаган дөньяларның бик үк бәхет белән сугарылмавы аңлашыла. Без бүген яшь авторның сәяси кыйбла аныклыгын да, аның ихласлыгын, үзе инанган фикерләргә иҗатында ни дәрәҗәдә тугры калуын да бәяләргә җыенмыйбыз... Безнең өчен бүген монда бер нәрсә мөһим: әсәрдән күренгәнчә, шагыйрьнең бу беренче шигырьләрендә әле эчтәлектә әллә ни эше юк, идеясе, инерция буенча, куелган партия сызыгы юнәлешендә дәвам итә, аның төп игътибарын исә үз укучыларын аяктан егарлык эффектлы сурәт алымнарын табу күбрәк били! Һәм ул моңа ирешә дә!

Илленче елларның рифмалы такмакларыннан соң, шигъриятебезгә «Офыкларга дулкын кага...» исемле икенче әсәрендәге: *Күккә тигән тупыл ябалдашы, / Менә-менә кичке җил өрер, / Тупыл ботаклары, шыбырдашып, / Йолдызларны коеп төшерер... / Нәкъ офыкка чыга тыкырыгы, / Болытларга тигән казыклар. / Айга тигән кибән бастырыгы, / Һәр тавышны, күңел, язып бар...* – кебек С.Есенин темпераментын һәм аның авыл пейзажы картиналары сурәтен хәтерләткән масштаблы, тәэсирле микрообразларның табигый төстә килеп керүе, һичшиксез, бу инде милли әдәбиятыбызның зур казанышы иде. Мондый нечкә шигъри каләм белән рухи дөньяның теләсә нинди катлаулы тирән катламнарына да үтеп керү шагыйрь өчен зур проблема тудырмый. Зөлфәт бу елларда ук инде әнә шундый бәхетле шагыйрьләрнең берсе иде.

Бер уңайдан аның бөек музыка дөньясына үтеп кергәндә кулланган нечкә поэтик

ачкыч табу осталыгына да тукталып үтик. Сүз авторның «Айлы соната»сы турында бара. Әсәрдә без шигъри тасвир ярдәмендә тудырылган тылсымлы бер югары илаһи гармония тоябыз. «Теплоходның ак салонында пәрдәләргә, тәрәзәгә тиеп» салмак кына башланып киткән һәм агылган бу гүзәл музыка, тора-бара, Бетховенның ярсу темпераментына буйсындырылып, тышка бәреп чыга – киң Идел өстенә җәелә. Тыелгысыз омтылыш-дәртне күрсәтү өчен автор, үзендәге ут-ялкынлы төрки кан агышы кайнарлыгын да өстәп, табигать-Иделнең яшенле-давыллы мизгелен, бабаларыбыз яшәешенең характерлы бер ярсу манзарасы – кызу ат чабышы күренешен тасвирга китереп кертә: *...Ә дулкыннар авызлыгын чәйни / Чабышларга чыккан ат кебек. / Кан саугандыр, бәлки, йөрәгенә, / Ял төпләре аның чат күбек.*

Бу тасвирга, яшен уты сугып, «яр өстеннән каерылып ауган» имән, «чәрдәкләнгән ай»ның суда чайкалуы, күңелен «киереп ачкан Идел» кебек хыялый шартлылык һәм гайре табигыйлек чикләрендә торган реаль тормыш детальләре өстәлә. Әсәр, сүз-мәгънә логикасын тарсынып, дулкынландыргыч, эмоциональ, рәсемле бер музыка агышына әверелә: *Актарыла, күбекләнә Идел, / Акчарлакның сына канаты... / Нишләттең син сабыр Иделемне, / Нишләттең син, әйтче, соната?!*

Шулай итеп, сиземле микросурәтләргә корылган тасвир шигъриятебезне давыллы, кодрәтле сәнгать көченә әвереләдерә. Шушы урында укучыларыбызның игътибарын тагын бер нәрсәгә юнәлтәсе килә: Зөлфәтнең шундый нечкә кичерешле югары сәнгать очышында без җирнең каршылыклы көрәш һәм көрәшкә чакыру авазларын да ишетеп алабыз. Тикмәгә генә Бетховен Ленинның яраткан композиторы булмагандыр, күрәсең. Әмма игътибар беләнрәк карасаң, хикмәт монда бер Бетховенга гына кайтып калмый. Моның төп сәбәпчесе, һичшиксез, шагыйрь Зөлфәт үзе. «Язмышлар ярында» китабының икенче бүлеге тулаем мәхәббәткә багышланса, аның беренче бүлеге тоташы белән милләт язмышы һәм көрәш темасына барып тоташа. Авторның Моцарт темасына мөрәҗәгать итүе дә, табигать, туган авыл һәм, гомумән, теләсә нинди темага килеп кагылуының да, ахыр чиктә, төп сәбәпчесе әнә шушы киеренке эчке көрәш рухының чагылышы булып тора. Хәер, монда әллә ни гаҗәпләнер нәрсә юк, әлеге шигъри көрәш дәрте шагыйрьнең аерылмас үз эчке бер халәте, димәк, хикмәт тышкы тема үзенчәлегендә түгел.

Менә аның гадәти бер татар авылы – туган авылы «Яңа Сәет»кә багышланган шигыре: *Бабаларым монда чана бөккән, / Агаларым тәртә каерган. / Кул тотынып авыл әйләнәсен / Әйлән-бәйлән уйный карурман. / Тагор кыяфәтле картлар миңа / Гыйлем ягы, белəм, кыскарак – / Гыйльми лекцияләр укыдылар / Профессорлардан да остарак. / Өйрәттеләр хөрмәт итү фәнен / Һәм төзәтү фәнен ялгышны. / Йөгәнләргә / башта усал тайны, / Тайлардан соң – усал язмышны*.

Яшәү фәненә өйрәнү – моңардан да зуррак вазифа бармы икән тормышта? Әлеге фәннәрне бүгенге яшьләребезгә һәм, һич югы, Дәүләт Советы әгъзаларына өйрәтсәләр икән ул! Әйе, милли традицияләребезне буыннан-буынга тапшыру – шулай ук җаваплы, тарихи зур бер көрәш төре.

Әйтергә кирәк, шагыйрь үз иҗатында кабатланмас тәрбия чыганагы булырлык геройларының тулы бер галереясен тудыруга ирешә. *Авторның иң яхшы әсәрләреннән берсе «Тимерче турында баллада» шундыйлардан: Язмышын да чүкеп ясаган ул, / Сандалына салган ачуын. / Сандалында яньчемәкче булган / Бөлгенлекне, сугыш-ачлыгын. / Дене дә шул тимер иде аның, / Чүкеч тавышы булды догасы. / Берлиннарга кадәр алып барды / Җирән кашкасының дагасын. / ... Кызган тимер кебек яшәде ул, / Кызган килеш керде сугышка, / Кызган тимер сукты йөрәгенә, / Кызган килеш ауды камышка.*

Тимер белән гомерлек алыш-биреш шулай өзелә. 30-40 нчы еллар атмосферасында тәрбияләнгән милләттәшебезнең рухын, фронтның «кызган килеш керде сугышка» кебек иң конкрет деталенә кадәр күзалларлык итеп, совет чоры кешесенең сүнмәс оптимизмын да, тирән фаҗигасен дә шулай түкми-чәчми укучыга илтеп җиткерә алган әсәр ватандашларыбызга, һичшиксез, мәңгелек тере һәйкәл ул! Һәм, әлбәттә, авторның

– сугыш арты баласының, этиләре каһарманлыгын гомумиләштереп, йомгаклап куюы да. Тагын берничә елга соңарып, әдәбиятка килгән әдипләр инде, бик теләсәләр дә, бу теманы мондый натураль һәм мондый символик ачкычта (кеше белән тимер көрәше) мондый шигъри кодрәт белән сурәтли алмаячаклар.

«Йодрык» балладасы рәхимсез «халыклар төрмәсе» булган патша Россиясенең халыклар дуслыгын бозар өчен махсус оештырган Кабан күле бозындагы канкойгыч бәрелешне тасвир итә. Үсмер Гәрәйнең этисе үлемен күреп, үзенең дә фаҗигале көрәш корбанына әверелүе әсәрдә Зөлфәт каләменә хас масштаблы, киеренке психологик эпизодлар ярдәмендә җанландырыла.

Мондый эпик колачлы көрәш (бәрелешү) картиналарын авторның гражданлык позициясен ачыктан-ачык чагылдырган фәлсәфи-хикмәтле көрәш лирикасы алыштыра: *Муса кайсы шул кошларның? / Җанына сыйган җир, күк... / Сугыша белгән былбыл ул / Һәм җырлый белгән бөркет. («Җырлый белмиләр бөркетләр...»)*

Китапка турыдан-туры публицистик накалда тәкъдим ителгән көрәш мотивлары килеп керә: авторның «Күз яшьләренә ышана Мәскәү...», «Җилдерде ул дала атларында...» кебек шигырьләре шундыйлардан: *Үз-үзеннән яманрак татар / Дошман барда җирдә, үч барда. / Чакырылмаган кунак – / дошманнарга, / Көтеп алган кунак – дусларга...*

Мондый тарихи кырыслык һәм җитдилек белән белдерелгән көрәш авазлары татар шигъриятендә бик еш яңгырамый. Җитмешенче-сиксәненче елларда бу шигырьнең укучылар арасында нинди фурор кузгатуы әсәрнең генә түгел, ул чордагы милләттәшләребезнең дә нинди хис-тойгылар кичереп яшәве хакында бик ачык сөйли.

«Без бит көрәшчеләр затыннан» шигыре шагыйрьнең милләт-көрәш темасына язылган шигырьләрен йомгаклап куюы рәвешендә яңгырый: *Томырылдык тормыш эченә без, / Сабан туе атлары сыман. / Мәйдан кирәк безгә, мәйдан кирәк! / Без көрәшче халык затыннан!*

Күрәбез, әсәрдә көрәш рухы тагын да якыная, конкретлаша төшә кебек. Герой үзенең көрәшергә килгәнлеген һәм мәйдан кирәклеген дә инде кистереп әйтә. Ә шулай да... көрәшнең асылы традицион Сабан туе һәм аның символик сурәтеннән әлегә узмый: *Чыгып бастык, нәкъ уртага бастык – / Күрсен заман кемнәр чыкканын! / Көрәшербез – сөлге өзелгәнче, / Билен сындырганчы дошманның. / Безнең кулда шул ук сөлге бүген, / Бу – көрәшче халык сөлгесе. / Сөлге таза! Гасырларны кичкән! / Көрәшченең кирәк җиллесе!*

Бүген дошман синең белән мәйданга чыгып көрәшмәячәк, күптән инде ул итәк астыннан эш йөртеп, мәкер-яла-хәйлә белән сине җиңүнең күпкә отышлырак вариантларын сайлап алып, максатына ирешү юлын тапкан. Шулай да әсәрнең туксанынчы еллар милли хәрәкәте күтәрелешенә күпмедер йогынты ясавын да бирелә һич кенә дә инкарь итеп булмый. Хәер, бу темага әле автор шул ук фольклорга бәйле төстә тагын бер әйләнеп кайтачак.

***

Әйтеп киткәнебезчә, Зөлфәтнең бу башлангыч чор иҗатында мәхәббәт лирикасы шулай ук аерым бер үзәк урынны биләп тора.

Исеме китабының тышына ук чыгарылган «Язмышлар ярында» әсәре үзе генә дә шагыйрьнең мәхәббәт кичерешләрен ни дәрәҗәдә тирән һәм нечкә тоемлавын, яшәеш-сөюнең ни кадәр каршылыклы, драматик мөнәсәбәтләрдән корылуын ачык күзаллавын күрсәтә: *Мин торам язмышлар ярында, / Упкынга атларга әзермен. / Мин сине сөйгән күк, син дә бит / Башканы сөясең, кадерлем.*

«Пар толым» шигырендә дә шул ук беренче ихлас сөю тойгылары, аларның ихласлыгын укучыга түкми-чәчми китереп җиткергән сиземле халәт сурәте: *Ык төбеннән, яшьлек сыман, болытлар агып бара»... «Болытларга тиеп булмый – яшьлектәй изге сыман!*

Олы мәхәббәтнең табигать белән бербөтенлеге, җан ияләренең әлеге якты, изге омтылышта бер-берсенә теләктәшлеге авторның бик күп әсәрләрендә чагылыш таба, иң әһәмиятлесе: алар шундый табигый кабул ителәләр ки, монда шагыйрьнең шартлылык законнарыннан шундый оста файдалануын башка да китермисең: *Таң атуга сылу керфегендә / Күз яшьләре кибеп өлгерде; / Ул йөрәген кысты учларына. / Былбыл исә, былбыл җан бирде. («Былбыл»)*

«Мәхәббәт» балладасында шагыйрь укучыга үзе яшәп узган 50-60 нчы елларның гаять истә калырлык бер типик каһарманы образын тәкъдим итә. Бу герой – пассажир *(«акбаш»ка һәм Такташка гашыйк»)*, күңеле белән кырыс һәм нечкәлекне берләштергән – шушы чорның гади-беркатлы, эчкерсез, киң күңелле һәм сәрхуш бер типик агае. Әмма аның бу типиклыгы әсәрдә икенче планда тора, үзенең шәхси бәхетен эзләүче бу каһарман – кырыс сугыш елларының бәхетсез бер баласы, безнең алга иң әүвәл үзенең индивидуаль кабатланмас кыяфәте һәм характер үзенчәлекләре белән килеп баса. Әлеге «утырса – урындыгы сына», «биесә – өрлек сыгыла» торган, аюга каршы бергә-бер пычак белән чыга торган абзыйны кайнар мәхәббәте аяктан еккан. Аның мәхәббәт объекты да Пушкин заманы балларының аристократкалары түгел, ә көн дә ире тарафыннан кыйналган, пекарняда камыр изүче чибәр («балерина сыман гүзәл сынлы») хатын. Аның өчен ул миллион яртыдан баш тартырга, фани дөнья малыннан ваз кичәргә әзер... *Юк, китми бит! Китми шул иреннән... / ярата ул аны, сволочь!* – ди ул кызганып, ярсып-дуамалланып... – *Миңа чыксын иде ул кияүгә – / сарай салыр идем мин аңа! / Юлларына келәм җәяр идем! / Ханша итәр идем дөньяга!* – ди абзый, якты хыялына бирелеп һәм сөю газабын бергә кушып. Ул инде дөрес фәлсәфи фикергә дә килгән: *Тик мәхәббәт... көчкә бирелми шул! / Кош күк төшми җимгә – бодайга...*

Шулай итеп, геройның тупаслыгы, кырыслыгы, күңеленең нечкәлеге, хыялыйлыгы, ихласлыгы, җан романтикасы белән бергә кушылып, укучыда җир мәхәббәте турында фәлсәфи күзаллау, караш, фикер уртаклыгы, хәтта теләктәшлек тойгысы да барлыкка китерә. Җитмешенче-сиксәненче елларда балладаның зур массалар тарафыннан гаять яратылып укылуы бер дә юкка түгел бит. Бу – күңел уртаклыгы булганга шулай.

Алда без авторның мәхәббәт темасын да гаять төрле яклап – аны лирик кичерешләр аша да, хикмәтле фикерләү итеп тә, эпик әсәр каһарманы дөньясы ярдәмендә дә ачарга омтылуын күрдек. Ә инде аның «Сөю мәңгелек» шигыре ул елларның гына түгел, яшәешебезнең бөтен чорында да һич искермәс мәңгелек җыр булып яңгырый: *Узар гомерләр, искән җил кебек, / Сөю – мәңгелек, сөю – мәңгелек!..*

***

Шагыйрь иҗатының алдагы этабын тәшкил иткән әсәрләргә без аның икенче китабыннан соң унике ел үткәч чыккан «Адашкан болыт» (1990), «Ике урман арасы» (1995), «Йөрәгемне былбыл чакты» (1999) һәм үзе әзерләп тә, китап итеп күрергә насыйп булмаган соңгы «Ходай сулышы» (2007) җыентыкларын кертеп карыйбыз. Шунысын ассызыклап үтәргә кирәк: аларда шагыйрьгә хас гомуми тел-стиль, иҗат омтылышы нигездә саклanса да, алдагы башлангыч сыйфатларның шактый үзгәрүен, ә кайчакта капма-каршы якка әйләнүен дә әйтеп китми булмый. Җәмгыятебез һәм милләтебез тормышының тискәре якларына күбрәк игътибар итү, кай ара аннан күпмедер читләшү, чынбарлыкны аңлауда еш кына мәңгелеккә төбәлеп тирән уйга төшү, аптырашлы уйларында әледән-әле Ходайга мөрәҗәгать итү, үткән белән киләчәкне чагыштырып, күңел төшенкелегенә бирелү кебек элекке этапта һич күренмәгән сыйфатларның калкып чыгуы, яшерен-батырын түгел, иҗатындагы гомуми сыйфат югарылыгының да шагыйрьнең алда үзе яулаган иҗат биеклегеннән күпмедер төшүе, еш кына тасвирның күп сүзлелеге, композициянең көпшәклеге, Зөлфәт шигъриятендә без күнеккән хис-тойгы пружинасының йомшара төшүе күзгә ташлана. Әгәр дә бу чорның туксанынчы еллардан соң, ягъни Республикабыз

язмышы өчен шактый гына өмет уята башлаган вакытны үз эченә алуын исәпкә алсак, гаҗәпләнүебезгә сәбәпләр тагын да арта кебек... Әмма чын шагыйрьнең дөньяны сиземләүдә һәрвакыт үз логикасы, үз үлчәм-параметрлары, үз масштабы барлыгын белгәнгә, безгә калса, бу кискен борылышның да шактый ук табигыйлеге аңлашыла.

Әлеге үзгәрешләр барыннан да элек шагыйрьнең мәхәббәт шигырьләрендә чагылыш таба. Дөрес, бу чорда да ул мәхәббәтнең тормышта иң зур көч икәнлеген һәрдаим ассызыклап күрсәтергә омтыла: *Дөньялыкның һәрбер дене дәшә, / Дәшә Коръәндәге һәр аять: / Мәхәббәтсез яшәү дөрес түгел, / Мәхәббәтсез яшәү – Җинаять!*

Әмма беренче чордагы сөю шигырьләре белән чагыштырып карасаң, шул аңлашыла: мәхәббәт темасы биредә ничек кенә киңәймәсен, ничек кенә төрләнмәсен, ул мәхәббәт шигыре булып түгел, ә бәлки, мәхәббәт турындагы шигырьгә әверелеп кала. Алдагы китерелгән өзекне дә без, барыннан да элек, олы мәхәббәткә чакыру буларак кабул итәбез.

Әмма хикмәт автор әсәрләрендә сөю хисенең күпмедер сүрелеп калуында гына түгел. Бу проблема, гомумән, объектив тормыш чынлыгы белән бәйле. Төп сәбәп җирдәге олы мәхәббәтнең, гомумән, мәгънәсе үзгәреп, замандашларыбыз яшәешендә аның тоткан үзкыйммәтен югалта баруында. Димәк, шагыйрь иҗатындагы бу чор мәхәббәтенең дә чын дөрес исеме – гомумән, кешелекнең аны югалта бару этаплары, югалта бару тарихы турында.

Әлеге яшәешнең үзәгендә, билгели ки, барыннан да элек автор карашларының үзгәреше, көндәлек иҗтимагый яшәеш шартлары, гомер үтүе, балалар, оныклар, милли тормышыбыз, ахыр чиктә милләт язмышы тора.

«Имансызлар», «Язылмаган дастан» шигырьләреннән күренгәнчә, шагыйрь туган тел һәм милләте язмышы турында борчыла: *Һәр иҗегем, һәр сулышым канлы, җәрәхәтле килеш мин китәм... («Татар теленең каргышы»).*

Авторның үз-үзенә, милләтенә әче сатирасы барлыкка килә: *Телне кисеп, артны ямасалар, / Безнеме соң ачу җилкетер? – / Юк, без сабыр! Безнекеләр һәрчак / Рәхмәт укып, сакал селкетер. («Безнекеләр»)*

*Мең дәһшәтле, мең афәтле татар иле! – / Чынлапмы ул мифлардагы Тартар иле? / Ахыргача үзен үзе мактар инде, / Ахыргача үзен үзе ватар инде, / Ахыргача үзен үзе сатар инде – / Чынлап мәллә син мифтагы Тартар иле? («Аң җитмәслек бер төпсезлек»)*

Шулай итеп, шагыйрь милләтебез язмышының соңгы үсеш чорына да үзенең төгәл поэтик бәясен җиткерүгә ирешә. Моның өчен бер шигъри талант кына аз, әлбәттә, моның өчен катлаулы көрәш кырын исән-имин кичеп чыккан туры сүзле, кыю йөрәкле олы шәхес каһарманлыгын күрсәтү дә кирәк. Күрәбез, Зөлфәттә боларның барысы да бар. Иң мөһиме, бу соңгы шигырьләре белән ул иҗатының беренче чорына – үз иҗат чишмә башына әйләнеп кайтуын, иҗатының тулы бер гармониясен тапкан, шигъри камиллегенә ирешкән иҗат эволюциясен үтүен раслый. Шуңа да Зөлфәт укучыларыбыз күңелендә гомер буена үз-үзе булып калалган олы шагыйрьләребезнең берсе булып яшәвен дәвам итә.

Бу җанны талаган каршылыклы проблемалар милләт проблемасы гына булса, бәлки әле, гадәттәгечә, үз эчеңә йомылып түзәр дә идең... Монда фаҗига гомумкешелек масштабларына барып тоташа, сүз биредә Кешелекнең юкка чыгуы белән бәйле: *Нитрат чәчеп, / гарип урабыз да / Үле судан балык тотабыз. («Тутык»)*

Аның «Курку», «Аваз» шигырьләрендә укучыга үз замандашларының йөрәк шомы, һәр нәрсәгә уянган шик-шөбһәсе, курку тойгысы, эчке җан авазы китереп җиткерелә: *«Кыямәтнең соң илчесе күземә карап тора...»* («Кыямәт кичәсе») – нәкъ менә шундый аптыраулы авыр чакларда ул бер Ходайга эндәшергә мәҗбүрдер дә: *Әллә кеше акылыннан шашты, / Әллә инде дөнья тилерде? – / Кем уйлаган, / Кеше булган өчен / Оялырдай көннәр килерне? («Терелербез...»)*

Шуңа авторның үз яшәешенә һәм заманага биргән бәясе дә югары түгел: бу якты

дөньядан ул зур фаҗига-әрнү белән китә: *«Ни әйтсәң дә, өлгермәдек дөньялыкта яшәп!» («Көз яңгыры»)* Аның «Язылмаган дастан»ы да, һичшиксез, нәкъ шушы һәлакәтле тойгы белән сугарылган: *Астыртын сулар шикелле / Каезлый гел астан, / Булмый калган гомерен даулый / Язылмаган дастан...*

Килеп чыкмаган гомер азагының төп сәбәпләре турында еш уйлана шагыйрь. «Юхалык» шигырендә бу хакта ул хикмәтле шигъри тел белән әйтеп бирүгә ирешә: *Мәкер – бөек. Иң бөеге – юха! / Сак була күр, бәндә, шулардан! / Куенына юха сыендырып, / Һәм изгесе итеп юханы, / Яшәгәннәр гади бәндәләре, / Имамнары, морза һәм ханы.*

Инде без шуның әче җимешен татыйбыз: *Үз нәҗесе белән уйный Ватан. / Барып җиттек – / Ватан тилерде...*

Иң гаҗәбе, әлеге гайре хәлгә бүген беркемнең дә диярлек исе китми: *Ач өерләр туеп ял итәрләр, / Ырылдашып җирдә кан кыйгач, / Һәм шуларны / Ярлыкауны сорап / Өзгәләнер ялгыз сандугач... («Ялгыз сандугач»)*

Бәланең бер татар фаҗигасе генә булудан узганын бик яхшы белә шагыйрь. Бу хактагы уй-фикерен ул бик төгәл поэтик ачкычта чишеп исбатлый алган. Әлеге вәхшәтнең эзе шактый тирәндә. Тамырда. Әмма тамырга карашның асылы дошманның империалистик варварлык мөнәсәбәтендә. «Тамыр көлләре» (338) шигырендә автор шуның мәкерле эзләрен ача: *Бу төбәктә тайга шаулаганын / Кемнәр, ничек искә алырлар? – / Ул шаулардан инде җилләр искән, / Тау-тау булып яна тамырлар.*

Бу шагыйрьнең кешелеккә төбәлгән гаҗәеп тирән борчулы соравы! Шушы сорауга ул, шагыйрь буларак, планета гражданины буларак, ачык җавап эзли: *Яна тамырларда алтын дастан, / Дастаннарда – кавем тарихы, / Тарихларда яна Җир өмете, / Өметләрдә нәрсә? – / Барысы! / Тамырларда яна батырлыклар, / Батырлыкта – синең намусың, / Намусыңда яна горурлыгың, / Горурлыкта – олы язмышың.*

Кыскасы, биредә «мең буынга җитәр бер хурлык» януы күрсәтелә. Шигырьдә бүгенге заман татар поэзиясенең шәхеслек намусы, публицистик көрәш ялкыны, аның югары сәнгатьлелеге бергә үрелгән. Бу очраклы түгел, тормыш-яшәешебездәге гаделлек көрәшендә югары поэзиянең урынын яхшы белә шагыйрь… Аның иҗатында чын шагыйрьләргә урын һәрвакытта түр башында булды. Авторның Пушкинга, Тукайга, Бабичка кат-кат багышлап язган әсәрләрендә бу мөнәсәбәт бик ачык сизелә. Замандашларыбыз Х.Туфан, Рәшит Әхмәтҗан, М.Әгъләмовларга атап язылган әсәрләре дә, гади истәлек булудан бигрәк, чын сәнгать әсәре буларак кабул ителә.

Авторның дусты М.Әгъләмовка багышланган «Карлар тик тора» әсәре кабатланмас ихласлыгы, фикер колачы, шигърилеге белән истә кала: *Ява карлар, ашыккандай җирнең / Караларын акка күмәргә. / Шагыйрьлек тә ярый – моның өчен / Җырлы иткән җылы көннәргә / Үзең белән кирәк түләргә.*

Бу – ике дус шагыйрьнең үз алдына куйган конкрет көрәш позициясе.


*Ага вакыт җиргә ак кар булып, / Бәгырьләрдә гүли бу вакыт. / Күзләренә кара, / Көчең җитсә, / Шул вакытны кара туктатып.*

Монысы шигырьнең төп шартлылыгы – автор идеясенең җиһан киңлегенә сикерер алдыннан ясалган соңгы тукталышы.

*Их син, сәйях дустым, нәни гигант! / Карлар төшми, карлар тик тора! – / Тибрәнгәләп күккә күтәрелә / Безнең шушы иске йорт кына. / Моңсу бүген... Иске планетаның / Үзеннән дә иске шул Вакыт – / Көче җитте! / Сорау ала бездән, / Күзгә карап, юлда туктатып...*

Шагыйрьнең, вакытны туктатып, шигъри вөҗдан телендә сөйләшергә әзерлеге – татар поэзиясенең мәңге сүнмәслеге хакында сөйләүче ныклы бер дәлил ул!

**Равил РАХМАНИ**



Ренат Харис.
«Казан утлары» журналының
1982-1989 еллардагы баш
мөхәррире.






*«Казан утлары»нда Американдан килгән милләттәшебез, галим Юлай Шамилоглы белән очрашу истәлеге. Сулдан уңга: М.Харисов, Н.Акмал, И.Хәйруллина, Р.Туфитуллова, Ш.Маннапов, М.Вәлиев, М.Галиев, Ж.Миңнуллин, Р.Низамиев, Ю.Шамилоглы, Р.Гаташ, Р.Харис, Ф.Латыйфи, Р.Фәйзуллин (Акъегет), Ф.Хәкимҗанов, Н.Шәйдуллина. 1989 ел.*





*Фото islsm-portal.ru сайтыннан алынды.*

*2019 елның җәендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Татар китабы йорты – Шәриф Камалның музей-фатирында язучылар белән очрашты. Фотода илбашы хозурында Ш.Камалның туганы Эльза Шакирова.*



*Фәрваз Миңнуллин (1934-1994) 1959-1961, 1965-1976 елларда «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеген җитәкләде. 1975 ел.*



*Әхмәт Фәйзинең вафатына дүрт көн кала төшерелгән соңгы рәсеме. Сулдан уңга: Абдулла Әхмәт, композитор Мансур Мозаффаров, Нури Арслан, Әхмәт Фәйзи, Риза Ишморат. Аккош күлендәге язучылар дачасында. Август, 1958 ел.*

# ЧИКЛӘРНЕ ТОТАШТЫРУЧЫ



Юлай Шамилоглы – дөнья тюркологлары, гуманитар фәннәр белгечләре арасында танылган галим. Тикшеренүчеләр өчен катлаулы урта гасырлар төрки-татар тарихына, мәдәниятенә, теленә, сәяси процессларга үз карашы булган бу шәхеснең күп кенә гипотеза-тәгълиматлары, вакытлар узу белән гыйльми хакыйкатькә әверелеп, гомуми фәнни фикердә үзгәрешләр китереп чыгарды. Алтын Урда тарихының күп кенә мәсьәләләрен 1970-1980 еллар чигендә инглиз телендә яңгыратучы да, XX гасыр ахырында татарларның һәм башка төрки халыкларның тарихи-мәдәни мирасын уникаль һәм уртак тамырлы күренеш итеп танытуга дөнья фәне мәйданында юллар ачучы да ул. Шуңа да татарлар гына түгел, төрки халыклар «ул – безнеке» дип горурлана.

Американы татар галиме һәм тарихчысы, тарих фәннәре докторы, Висконсин-Мэдисон университетының (АКШ) Алман, скандинав һәм славян телләре кафедрасы профессоры һәм Назарбаев университетының (Казакъстан) казакъ теле һәм тюркология кафедрасы мөдире, профессоры, Татарстан Фәннәр академиясенең чит ил академигы. Висконсин-Мэдисон университетында – Якын Көнчыгыш, Үзәк Азияне өйрәнүче; Урта Азия телләре һәм мәдәниятләре программаларын эшләүче һәм гамәлгә куючы, Америкада һәм Европада күпләгән белгечләрнең остазы.

Әлбәттә, Татарстанда Юлай Шамилоглыны Алтын Урда һәм Казан ханлыгы, татар һәм Татарстан дәүләтчелеге тарихы буенча хезмәтләр авторы буларак беләләр, таныйлар, ихтирам итәләр. Казанда гына түгел, Америкада яки Азәрбайҗанда, Алманиядә яки Төркиядә, Венгриядә яки Үзбәкстанда һ.б. җирләрдә бер генә җитди фәнни җыен да аның катнашыннан башка узмый.

Тарихчы гына түгел, төрки телләрне чагыштырып, аларның хәзерге һәм тарихи үсеш-үзгәрешен өйрәнү, урта гасырларда төрки халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен, Евразиянең урта гасыр һәм хәзерге чор иҗтимагый, икътисади һәм интеллектуаль тарихын, Үзәк Азия мәдәниятен, Үзәк Евразиядә ислам һәм мөселман цивилизациясен; хәзерге мөселман төрки интеллектуаль хәрәкәтләрен тикшерү белән дә шөгыльләнә.Үзе күп телләр белә: туган татар һәм инглиз телләреннән тыш, француз, алман, кытай, венгр, гарәп, рус, төрек, фарсы, монгол, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, хәтта төркиләрнең борынгы (баба) телләрен дә үзләштергән. Гуманитар тикшеренүләрне ул менә шушы нигездә, шуларны чагыштырып алып бара! Шуңа күрә дә аның һәр хезмәте – фәнни ачыш, көтелмәгән тәгълиматны аңлату, яңа эзләнүләр өчен чишмә башы булып чыга.

Ул – киң карашлы, тирән белемле галим, предметара, бер фән чикләре башкалары белән тоташкан урында, күп предметларның өр-яңа нәтиҗәләрен үреп алып барылган тикшеренүләргә өстенлек бирә. Шул ук вакытта үзенең тикшеренү объектлары да бер-берсеннән бик нык аерылалар. 100 дән артык фәнни хезмәтләре арасында, «Россия

мөселманнары. Исламның Азия, Үзәк Азия илләрендә үсеше һәм йогынтысы» (Филадельфия, 2006, инглиз телендә), «Алтын Урдада ырулар сәясәте һәм иҗтимагый вазгыять» (Казан, 2019, рус телендә; якын арада инглиз телендә Нурсолтанда басылып чыгарга тиеш), «Шиһабетдин Мәрҗани» (Казан, 2018, 2019) кебек монографияләр бар. «XIII-XIV гасырларда Алтын Урда: дисциплинаара якын килү» дигән методологик пландагы яңа хезмәте әзерләнә.

Монографияләре кебек үк, галимнең күпсанлы мәкаләләре белән дә һәм инглиз телле фән даирәсе, һәм Россия укучысы таныша ала, аларны табып алу авыр түгел. Үзе дә хезмәтләрен төрле телләрдә яза. Аның иң яратып, кабат-кабат әйләнеп кайтып язган темасы – Җучи Олысы (Алтын Урда) дәүләтенең корылышы, яшәеше, тарихи-мәдәни үзенчәлеге икәнлеге бәхәссез. Нәкъ менә шушы материалда галим аерым бер дәверләр тарихына комплекслы якын килү мөмкинлеген бик ачык күрсәтүгә ирешә. Күпсанлы чыганакларга: сәяхәтчеләрнең язмаларына, шул чордан сакланып калган язма истәлекләргә, архив материалларына, төрле фән тармаклары галимнәренең күзәтүләренә таянып, Юлай Шамилоглы Алтын Урда дәүләтенең тарихын – икътисад, сәүдә-сәнәгать, көнкүреш, тормыш итү тәртибе, географик урынчылык, халыкара мөнәсәбәтләр, дин, мәдәният, дәүләти корылыш, язмачылык, шәһәрләр үсеше, миграция-күчешләр, пандемияләр һ.б. күренешләрнең берлегендә, киселешендә тергезә. Тарихка болай якын килү моңа кадәр күз уңыннан читтә калган яки аерым бер тар тикшеренүләр кысаларында барланган күренешләрне калкуландыра, мозаика кебек җыеп, бөтен бер дәвер тормышы-яшәешенә бәя бирергә ярдәм итә. Әйтик, журнал укучысына галим ясаган күпсанлы күзәтүләр-нәтиҗәләр арасында берсен аерып күрсәтү урынлы булыр иде: ул Җучи Олысында Югары ислам мәдәнияте формалашуны һәм дәүләт таркалганчыга кадәр Харәзем, Кырым, Идел-Кама кебек югары мәдәниятнең традицион үзәкләре белән бәйләнештә үсүне, алай гына да түгел, XIII-XIV гасырларда бу югары үсешне ислам һәм төрки мәдәниятнең синтезы тәэмин иткәнлекне дәлилли. Ягъни Җучи Олысының – монгол түгел, бәлки төрки-татар дөньясының үзәге, аның элгәрге төрки дәүләтләр һәм соңгырак татар ханлыклары белән дәвамчан бәйләнештә булуын киң материалда тагын бер кат исбат итә.

Юлай Шамилоглы пандемияләр тарихы һәм аларның дөнья цивилизациясе язмышындагы роле турында хезмәтләр язарга керешкәндә, Болгарда табылган ваба бактерияләренең Европада таралган штамм белән бер булуы сенсация тудырса да, галимнең ваба сәбәпле – яшәү рәвеше, халык саны, урнашу урыннары гына түгел, әлифба-язу, мәдәният, дини-фәлсәфи, иҗтимагый-сәяси вазгыять тамырдан үзгәрү, дәүләтләр-цивилизацияләр җимерелү хакындагы нәтиҗәләре бары тик урта гасырларга гына кагылышлы булып тоелган иде. Инде 2019-2020 еллардагы пандемия бу мәсьәләдә дә галимнең алдан күрүчәнлеген, гыйльми сиземләү-интуиция сәләтен раслады! Аның әлеге теориясен бүген күп галимнәр күтәреп алды.

Юлай Шамилоглының фәнни эшчәнлегендә татарларда тарихи аң формалашуга багышланган хезмәтләр аерым урын тота. Ислам мәдәнияте, мәктәп-мәдрәсәләр, заманча фикерләү, милли бердәмлекне тупларлык тәгълиматлар барлыкка килү һ.б. мәсьәләләр белән беррәттән, төрки дөньяда зур урын тоткан күп кенә мәшһүр шәхесләр дә кызыксындыра аны. Хезмәтләре арасында Кол Галигә, Хәразмигә, Гаспралыга, Абайга, Г. Тукайга һ.б. караганнары да бар.

Әмма иң зур ачышлар ерак гасырлар төпкеленнән килә! Бүгенге тюркология фәнендә борынгы төрки телләрне бу дәрәҗәдә үзләштергән һәм фәнни хезмәтләрдә чагыштырып куллана алган башка бер галимне аерып күрсәтүе дә кыен. Шуңа күрә Юлай Шамилоглының рун, гарәп язулы эпиграфик һәйкәлләрдән алып, кыпчак теле, госманлы теле, чыгтай теле, аерымланган төрки: татар, үзбәк, казакъ, төрек, азәрбайҗан, төрекмән, кыргыз телләренең тарихи үсеш-үзгәреш юлын тергезүе, үз чиратында, төрки мәдәниятләргә реконструкция ясау булып әверелә.

Юлай Шамилоглы – ачык, аралашучан, ярдәмчел, шул ук вакытта, актив гражданлык

позициясе булган һәм шуны тормышка ашыру өчен бер мыскал да артка чигенмичә көрәшүче шәхес. Ул Америка төрки телләр укытучылары ассоциациясенең президенты (2003-2017), Үзәк Азияне өйрәнү мәсьәләләре оешмасы әгъзасы, Европада Үзәк Азия проблемаларын өйрәнү оешмасын нигезләүче, Казакъ теле укытучыларының халыкара ассоциациясе, Төрки, госманлы һәм төрек тикшеренүләре җәмгыяте һ.б. берләшмәләр әгъзасы буларак, фәнне, төрки тарихны һәм мәдәниятне тикшерү, популярлаштыру эшендә әйдәп баручы да. Төрки дөнья тарихи-мәдәни мирасының энҗеләрен – инглиз теленә тәрҗемә итәргә, яки төрки ядкарьләр хакында энциклопедия-белешмәлекләр аша дөнья укучысына сөйләргә дә вакыт таба ул. Җитди фәнни хезмәтләр белән бергә, шигырьләр тәрҗемә итүдән дә курыкмый.

1989 елны, мөмкинлек ачылуга, Казанга беренче мәртәбә килеп, Юлай Шамилоглы элеккеге СССР, анда яшәүче төрки халыкларның фәнни җәмәгатьчелеге белән аралаша башлый, бик күп уртак проектларда катнаша. Фәнни хезмәтләр белән беррәттән, югары квалификацияле кадрлар үстерүгә зур өлеш кертә. 2010 елны Казакъстан башкаласы Астанада Президент Нурсолтан Назарбаев исемен йөртәчәк яңа уку йортын оештыру, аның чит илләрдәге иң югары бәяләнә торган университетлар дәрәҗәсендә укыту концепциясен әзерләүгә Юлай Шамилоглы чакырыла. Әйтерсең лә, аның 2001 елда Татарстанга тәкъдим иткән Татар милли университетын оештыру концепциясен гамәлгә куярга юл ачыла. Инглиз телендә, Америка университетлары үрнәгендә белем бирә торган бу уку йортында казакъ телен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү дә таләп ителә.

Юлай Шамилоглы бүген Назарбаев исемендәге университетта эшли, Евразия тикшеренүләре һәм тюркология үзәге оештыру белән шөгыльләнә. Галим бу университет аша Казакъстанга гына түгел, бар төрки дөньяга, төрки халыкларга, шул исәптән, татарларга да хезмәт итә. Аның өчен – чикләр дә, милләт яки тел аермасы да, гыйльми чикләүләр дә юк. Ул – фәндә дә, тормышта та, фикердә һәм эш-гамәлдә дә – чикләрне тоташтыручы!

XX гасырда дөньяга төрки-татарларны танытуга гомерләрен багышлаган татар галимнәре аз түгел: Йосыф Акчура, Садри Максуди, Габделбарый Баттал-Таймас, Әхмәт Тимер, Тамурбәк Дәүләтшин, Әгъдәс Курат, Надир Дәүләт... Татар халкының горурлыгы булган бу мәшһүр затларның һәрберсе бу өлкәгә үз юлы белән килгән. Әмма аларны бер нәрсә берләштерә: чиктән ашкан тырышлык, үз халкыңны бик нык ярату һәм ихтирам итү, гомереңне аның киләчәге өчен хезмәткә багышлау.

Америкада туып үскән татар галиме Юлай – шуларның лаеклы дәвамчысы, аның фәндә үз якты сукмагы, сукмагы гына түгел, чикләрне тоташтырган үз олы юлы салынган. Ул журнал укучыларына да кызык һәм мәгънәле булыр дип, без аннан гаиләсе, балачагы, фәнгә килүе хакында язып бирүен сорадык.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

Юлай
Шамилоглы

# МИНЕМ ТОРМЫШ ТАРИХЫМ

Мин 1958 елның 2 маенда Нью-Йорк шәһәренең Бронкс районында дөньяга килдем. Минем әтием – Мөхәммәд Шамилоглы, әнием – Фаилә (Фагыйлә) Аги Шамилоглы.

Әтием Зөфәр Әхтәмов исеме белән 1916 елның 22 маенда Башкортстанның Чакмагыш районы Митрәй-Әюп авылында туган. Әтисе Госман шул авылдан, әнисе

Нурҗиһан күрше Карьяуды авылыннан булган. Бабам әтиемнең әнисен ташлап, башка бер хатын белән икенче тормыш корган. Шуңа күрә әтием әнисе янында үскән, бәлки шул сәбәпле, ул әнисен бик кадерли иде. Ялгышмасам, алар сигез бала булганнар: бер кыз һәм җиде ир бала. Әтиемнең кардәшләреннән берсе, үзлегеннән өйрәнеп, нindидер мәктәптә Европа телләрен укыткан дип хәтерлиләр. Бәлки, телләр өйрәнүгә сәләтем ягыннан мин бераз аңа охшаганмындыр.

Әтием Чиләбе өлкәсе Пласт шәһәрендә яшәгән. Әнисе белән бергәме – моны әйтә алмыйм. Бабам соңрак кулак дип гаепләнгән, шуның өчен әтием техникумнан чыгарылган, укуын тәмамлый алмаган.

Әнием Фаилә Аги, аның гаиләсе Пенза якларыннан, Нагур авылыннан дип беләм. Әнием үзе 1922 елның 4 гыйнварында Благовещенск на-Амуре шәһәрендә дөньяга килгән. Аның әтисе Хөсәен егерь хезмәтләрендә эшләгән. Кызыллар белән аклар арасында сугыш якынлашкач, ул, хезмәтен ташлап, Кытайга качып киткән, гаиләсен дә шунда чакырган. Харбинда төпләнеп, сәүдәгәр буларак, еракларда терлек сатып йөргән, соңрак мех кибетләрендә эшләгән.

Әниемнең абыйсы Әмруллаһ Аги (Фәрит Аги, ягъни Фәрит Иделленең әтисе) шул турыда истәлекләрен калдырган иде. Ул вафат булганнан соң, уллары шуны табып, Казанда оригинал язылган телдә (русча), татарча һәм инглизчә тәрҗемәдә бастырып чыгардылар. (Мин инглизчә китапның редакторы булдым һәм аз гына кушымта мәгълүмат та бирдем).

Гаяз Исхакый Ерак Көнчыгышка барганда, алар белән күрешкән: Әмруллаһ абый китабында шул хакта да яза. Татарлар ул дәвердә кайда барсалар – мәчет һәм мәктәп төзегәннәр. Әнием андагы татар мәктәбен тәмамлый алмый: күрәсең, аларга түләү күтәрә алмаслык авыр тоела. Ул бер христиан мәктәбендә монашкалардан инглизчә өйрәнә (соңрак АКШта яшәячәген белгән кебек!). Кытайдагы коммунистик революциядән соң, Төркия Республикасы кардәш халыкларны үзенә ватандаш буларак чакырырга карар чыгара. Әниемнең гаиләсе, шуннан файдаланып, Төркиягә күченә. Кызганычка күрә, Татар җәмгыятендә президент урынбасары булган Әмруллаһ абыйны Совет хөкүмәте кулга алып, соңыннан ГУЛАГка җибәрә. Хатирәләренең икенче бүлеге ГУЛАГтагы аяныч тормыш турында иде. 1960 еллар башында гына, Төркиянең мөрәҗәгате буенча, Әмруллаһ абый хатыны Шәмсинур һәм уллары белән кавыша.

Әтием егет чагында Урта Азиядә сәяхәт иткәнен сөйли иде. Бөек Ватан сугышында Ленинград тирәсендә сугыша, алманнарга әсирлеккә эләгә. Үзен Төркиядән дип күрсәтеп, котыла алган. Алманиядә Миттенвальд лагеренда тотыла, аннан АКШка күченергә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Ул белгән күп татарлар Төркиягә, Австралиягә күченеп китәләр. Ләкин АКШ татарларны, «сары җенес»тән (монголоид) дип, кабул итмәгән. Әти, Тамурбәк Дәүләтшин һәм башкалар белән бергә, АКШтагы эмиграция хезмәтен судка бирә, алар җиңеп чыгалар. Миндә шуның турында мәгълүмат саклана.

1951 елны әти Нью-Йорк шәһәренә килә, монда гомере буе картлар йортларында яисә хастаханәләрдә (госпитальләрдә) эшли.

Ватандашлык алганнан соң, 1957 елны әти, Мәхмүт Ураллы исемле дусты белән күрешер өчен, Истанбулга бара, анда әнием белән таныша да тормыш корырга карар бирәләр. Әнием октябрь аенда Нью-Йоркка килгәндә инде бала көтә. Мин ул килеп алты ай узганнан соң туганмын, энем Идел 1959 елгы. Ул Нью-Мексико дәүләт университетында (Албукерке шәһәрендә) фән белән шөгыльләнә, профессор.

Без шәһәрнең Бронкс районында яшәдек. Мин кечкенә вакытта ул күбрәк яһүдиләр яшәгән бер мәхәллә иде. Фатирыбызга якын 70 нче мәктәптә балалар бакчасыннан алтынчы сыйныфка хәтле укыдым. Беренче сыйныфка укырга килгән беренче көнне бер сыйныфта идем. Икенче көнне мине тиз генә икенче сыйныфка күчерделәр. Бәлки, әниемнең инглизчә яхшы белүе дә әзерлекле булуыма йогынты ясагандыр?

Әти-әни безнең белән өйдә татарча гына сөйләшәләр, әмма телевизордан инглизчә

дә өйрәндек. Балалар бакчасында инглизчәдә хаталар ясаганым әле дә исемдә. Соңыннан мәктәпне алтын медаль белән тәмамладым.

Мәктәпне тәмамлаган елларда Бронкста зур демографик үзгәрешләр булган иде инде. Яһүдиләр һәм башка ак тәнле кешеләр башка мәхәлләләргә киттеләр, алар урынына кара тәнле һәм испан чыгышлы (күбрәк Пуэрто-Рико утравыннан) халык килде. Мәхәлләдәге мондый үзгәрешләр белән бергә, куркынычсызлык мәсьәләсе калыкты: әти-әни башка җиргә күчү турында уйлый башладылар.

7 һәм 9 сыйныфны шул мәхәлләдә булган 117 нче үсмерләр мәктәбендә укыдым. Ул вакытта яхшырак укыганнарга 8 сыйныфта уку мәҗбүри түгел иде. Шуның өчен мин урта мәктәпне ике елда тәгәлләдем.

Ул елларда Нью-Йорк шәһәрендә өч махсус гимназия эшләде: Бронкс Югары фән мәктәбе, Стайвесант югары мәктәбе, Бруклин югары технология мәктәбе. Мин, имтихан тапшырып, Бронкс Югары фән мәктәбенә кабул ителдем. Ул мәктәп көчлеләрдән хисаплана, аның элеккеге сигез укучысы – Нобель бүләге лауреатлары булган.

Кечкенә чагыбызда әти-әни укуда ярдәм итә башладылар. Әти безнең белән 1-2 сыйныф дәрес китапларын укыды, ләкин без аларны бик тиз үзләштердек. Йортыбыз каршысындагы китапханәдән китапларны өйгә алып, шулар дөньясына чума идек. Әти русча азбука өйрәтү омтылышы да ясады.

Инде еллар узгач, мин үземнең Бронкс Югары фән мәктәбенә имтихан бирергә ниятләвемне язмыш бүләге дип карыйм. Ничек бу уку йортын таптым, ничек югалмадым – әле дә шуңа гаҗәпләнәм: чөнки мәхәлләбездәге гимназиягә барган булсам, тормышым башкарак юлдан киткән булыр иде.

Шуңа бер дәлил китерим: Казакъстанда физика-математика мәктәпләре бар. Бронкс Югары фән мәктәбе дә шушы предметлар буенча көчле иде. Дөрес, мин математикага мөкиббән китмәдем, 12 сыйныфта аны бөтенләй сайламадым. Физиканы бик яраттым. Әмма мәктәпнең гомуми юнәлеше төгәл фәннәрдән ныклы, системалы белем алырга мөмкинлек бирде. Фән юлын сайлаган кеше өчен бик мөһим бу.

117 нче мәктәптә француз телен өйрәнә башлаган идем, шуны Бронкс Югары фән мәктәбендә дәвам иттем. 11 сыйныфта рус телен өйрәнә башлап, гимназияне бетергәнче ике ел аның белән шөгыльләндем. Гимназиядә Иҗтимагый фәннәр департаменты бар иде, алар тарих белән бәйле фәннәр укыталар. Мин, ничектер кызыксынып, ул Департаментның җитәкчесенә ярдәм итәргә теләк белдердем. Шулай итеп, Марица Цаггос мине волонтёр итеп эшкә алды. Әрмән милләтеннән булган бу ханым Колумбия университетында укыганда (магистр буларак, күрәсең), төрек телен өйрәнгән. Ул миңа шундый киңәш бирде: «Колумбия университетына барып укы, анда Тибор Халаши-Кун исемле бер профессор бар – аннан төрек теле дәресләре ал». Марица ханым минем Колумбиягә кабул итүне сораган мөрәҗәгатемне яклап, хат та (тәкъдимнамә) әзерләгән иде.

Шулай итеп, 1975 елны Бронкс Югары фән мәктәбен тәмамлап, көзгә Колумбия колледжында (Нью-Йорк шәһәрендәге Колумбия университеты) укый башладым. Университетка килгәндә, ниятем политология юнәлешендә белем алып, халыкара хокук белгечлеге сайлау булды. Гарәп, фарсы һәм төрек телләрен өйрәнү фикерем дә бар иде. Андый теләк кайдан килеп чыккандыр инде?

Шуны да искә төшерергә кирәк: мин гимназиядә чакта Индиана университетыннан заказ биреп, Николас Поппеның «Tatar Manual» («Татар теле өйрәнү өчен ярдәмлек») дигән китабын да алдым. Димәк, гимназиядә укыганда ук, әдәби татар телен кирилл хәрефләре белән өйрәнергә тырышканмын... Шулай ук ул елларда теләсә кайсы университеттан анда укытыла торган дәресләр исемлеген (каталогын) сорарга мөмкин, моның өчен бер открытка җибәрү җитә иде. Мин дә Һарвардтан каталог соратып, тюркология буенча андагы дәресләр турында да хәбәрдар булдым.

1975 елны, мин университетта укый башлаган атнада, без Бронкстан Йонкерска

күчтек. Укуның беренче көнендә гаилә дустыбыз Азамат Алтай мине төшке ашка чакырды. Ул үзе кыргыз, хатыны татар, шул елларда Колумбия университетының китапханәсендә эшли иде (соңрак «Азатлык» радиосындагы кыргыз редакциясенә җитәкче булып күчте). Ул мине Колумбия университетына якын венгр ресторанына алып барды. Без утырганнан соң, әйтеп куйды: «Әнә анда утырган кеше – безнең университетның тюркологиядән мәшһүр профессоры Тибор Халаши-Кун». Исем таныш булганга, Алтай абыйдан мине аның белән таныштыруын үтендем. Халаши-Кун кабинетына чакырды һәм шул көннән минем тюркология буенча гомер юлым башлангыч тапты. Колумбия университетына, тюркология юлын ачып биргән өчен, мең рәхмәтле мин. Ул остаздан өйрәнгәннәрем өчен аеруча мең рәхмәт...

Без бала чакта өч ел язын Төркиягә бардык, шуңа бераз төрекчә белә идем. Халаши-Кун танышыр өчен дәресенә чакырды. Икенче семестрдан башлап, мин аның төрек теле дәресләренә язылдым. Башта авыр тоелса да, татар теленнән аермасын аңлагач һәм сүзлекләрне бертуктаусыз куллана торгач, үзләштерә башладым. Күзен, укуның беренче көнендә үк, тышкы сәясәт турында беренче дәресне тыңлаганнан соң, ул предметны ташладым. Хәзер миңа куелган бурыч – университетта шәрык телләрен һәм мәдәниятләрен өйрәнү, шуның эчендә төрек телен үзләштерү калды. Ни эшләргә? Бер карарга килә алмадым. Үземә елның ахырына белгечлек сайларга сүз бирдем.

Мин беренче елны рус һәм француз телләреннән укуымны дәвам иттем. Француз телен урта мәктәптә, гимназиядә 3 ел укыган булсам да, университетта мине 2 нче семестр курсына билгеләделәр... Профессор Халаши-Кун, француз телемне канәгатьләнерлек тапмыйча, 1976 елны Парижга барып укырга киңәш итте. Бронкста туып-үскән бер татар баласы буларак, Парижга бару фикере акылыма һич килмәгән иде, әмма әти-әни белән сөйләштем, алар кабул иттеләр (яткан урыннары җәннәт булсын!).

Табигый, 18 яшендәге татар егете Юлай Парижга ничек гашыйк булмасын? Бик тыйнак яшәргә тырышсам да, музейлары, Сена елгасы, мәхәлләләре үзенә тартты. Бер мәртәбә институт экскурсиясенә катнашып, Шато ля франсларны да күреп кайттым. Арзан радио алдым: көн саен, колагым ияләшсен өчен, французча радио тыңладым.

Уку бетеп, 1-2 атна узгач, мөгаллимебез укучыларны өенә күңел ачарга чакырды. Кичнең уртасында ул гаҗәпләнеп, миңа: «Син французча сөйләшәсең икән!» – ди. Шул кичне мин бер җәйдә бер телне сөйләшер дәрәҗәдә өйрәнерлек сәләт-кабилиятем барлыкны аңладым.

Парижда гаиләмнең дуслары аркылы кызык кешеләр белән таныштым, кайберләре белән якынлашып киттем. Берсе белән (Аликбер Топчибаши, Али-Мәрдан Топчибашиның улы) академик мәсьәләләр буенча аралаштык. Профессор Халаши-Кунның ярдәме белән Париждагы күп кенә танылган тюркологлар белән очраштым. Берсе – Чикаго университетында һәм Сорбоннада профессор булган Александр Беннигсен миңа бик нык тәэсир итте. Ул мине татар тарихын тикшерү юлына этәрде. Нью-Йоркка кайтканда инде, мин тюркология һәм татар тарихын өйрәнүне дәвам итәргә карар бирдем.

Профессор Халаши-Кун миңа мәкаләләр тәкъдим итә башлады: әйтик, Һарвард профессоры Эдвард Кенанның Казан ханлыгы турындагы бер хезмәтен бирде. Университетның икенче курсында русча китап укып карарга исәпләдем. А.Ю. Якубовский һәм Б.Д. Грековның «Золотая Орда и ее падение» китабы башта бик авыр тоелды. Әмма 5-10 бит укыганнан соң төшенә башладым.

Ул елны төрек әдәби телендә фәнни мәкаләләрне аңлап укырга күнектем. Шул ук вакытта алман телен өйрәнергә керештем, 1977 елның җәендә Алманиянең Фрайбург им-Брайсгау шәһәрендәге Гёте институтында телемне шомартып, университетта укырлык дәрәҗәгә үстем. Фрайбург университетына танышырга баргач, ислам тарихы буенча профессор Ганс Роберт Роемер мине үзендә укырга чакырды.

Колумбия колледжында укуларның 3 нче елында «Якын Көнчыгышның телләре

һәм мәдәниятләре» темасын сайлап, рәсми беркетелдем: гарәп телен өйрәнә башладым, госманлы теле (гарәп графикасындагы иске төрек теле), төрек әдәбиятыннан һ.б. дәресләр алдым. Рәсми остазым профессор Кэтлин Р.Ф. Берилл төрек әдәбиятын өйрәтә, әмма ул миңа кызык тоелмады. Үзем укыта башлагач, әлеге дәресләрдә алган белемнәрдән хәзер дә файдаланып торам...

Катлаулы һәм диалектлары күп булган гарәп телен үзләштерү өчен мохиттә яшәргә кирәк. Шуңа күрә 1978 елның җәендә Дәмәшекъка барып, анда «Мәдрәсәт Дәр әл-Сәлам»дагы «Чит ил кешеләренә гарәп телен өйрәтү институты»нда белем алдым, мондагы мөгаллим күбрәк әдәби телгә күнектерде. Колумбия университетына кайтканнан соң, тагын 4-5 ел гарәп теле белән шөгыльләндем. Гарәп теле, госманлы теле – даими белем җыюны таләп итәләр.

Фарсы телен өйрәнү программада каралмаган иде. Ул телне һәм венгр телен (1976 елны Парижда өйрәнә башладым) камилләштерүне дәвам иттем. Минем теләгем – 1979 елның язында Иранга бару иде, ләкин андагы революция сәбәпле, ул вакытта да, соңрак та бу насыйп булмады. 1979 елның җәендә Венгриягә киттем һәм төрле программалар буенча белем тупладым.

Университетны тәмамлаганда, мине Шәрыкны өйрәнү өлкәсендәге Тараккнат Дас премиясе белән бүләкләделәр. Инде 1978-1979 уку елында магистратура-докторантурага керергә кирәк иде. Профессор Берилл Якын Көнчыгыш телләре һәм мәдәниятләре Департаменты буенча урын булыр дип көтте, ләкин Тарих департаментына күчеп, яңа килгән профессор Ричард В. Буллиет белән эшләргә теләвемне белгәч, минем белән берничә ел хәтта исәнләшмәде. Еллар узганнан соң гына арабыз яңадан төзәлде.

Буллиетның укучысы буларак, ислам, Византия, Урта гасыр Россия тарихы буенча гыйлемнәрне тирәнәйтергә тырыштым, шул ук вакытта кытай телен өйрәнә башладым. 18 ай дәвамында кытай теленнән 3,5 еллык дәрес укыдым. Интенсив дәресләр сәламәтлегемә зыян салды. Бик авыр иде...

Телләр өйрәнү белән бергә, фәнни эш алып бару да сорала бит әле! 1979-1980 уку елында магистратурада тезис язу таләп ителә. Мин карачы бәкләр темасын сайладым. 1984 елны басылып чыккан «Монгол империясендә карачы-бәкләр турында фикерләр» («Notes on the Qaraçı Beys of the Mongol World Empire») дигән мәкаләм – шул тезисның үзе. Аннан соң Нугай Урдасы буенча диссертация язарга ниятләдем, ләкин соңрак, Алтын Урдадагы олыс бәкләрнең шул ук карачы бәкләр институты икәнен аңлагач, диссертациям «Алтын Урдада ырулар сәясәте һәм иҗтимагый вазгыять» («Tribal Politics and Social Organization in the Golden Horde») булып калды.

Беренче уку елымнан башлап, профессор Халаши-Кун («Кун»нар – куман асыллы венгрлар) миңа Венгриягә барып укырга киңәш бирә торган иде. Ул мәшһүр венгр тюркологы Дьюла Нейметнең беренче докторанты булып, Венгриядәге тюркология мәктәбен югары бәяләде. Профессор Халаши-Кун үзе дә 1949 елны Анкара университетының Тел һәм тарих-география факультеты журналында Казан ханлыгыннан калган дүрт ярлык турында күләмле мәкалә чыгарды.

Аның теләге тормышка ашты: 1982 елның көзендә Сегед университетында Алтаистика фәнен укырга грант оттым. Сегедта профессор Андрас Рона-Таштан – иске болгар теленең тарихы, борынгы төрки рун язмалары, К. Адьягасидан – чуваш теле, Иштван Зимонидан монгол теле дәресләре укыдым. Уку венгр телендә барганга, башта Дебрецен университетында телне күбрәк өйрәнергә туры килде. 1979 һәм 1982 елларда Венгрия бик күп кызыклы кешеләр белән очраштырды. 1982 елда профессор Халаши-Кун да Будапештта иде, һәм аның янына килгән Андреас Титзе һәм башка тюркологлар белән танышу насыйп булды. Алардан тыш, мәрхүм Иштван Мандоки Конгурны да еш күрә идем.

1983 елның башында кайтып, бераз әти-әни белән яшәгәннән соң, 2 айга

Индианадагы Блумингтон университетына чакырдылар. Анда мине чакырган Денис Синор һәм Халаши-Куннның укучысы Гюстав Баерле белән гыйльми тикшеренүләр башладык. Урал-Алтай тикшеренүләр департаментына төрки телләр мөгаллиме кирәк булып чыкты: 1983-1986 елларда шул вазифаны башкардым. 1986 елдан Денис Синор урынына гыйльми тикшеренүче кирәк булды. Мин бу вакытта Ph.D. дәрәҗәсен яңа алган идем – шулай да кабул иттеләр. Азәрбайҗан, үзбәк телләрен укыттым, профессор ярдәмчесе буларак, аспирантлар өчен мәҗбүри дәресләр, үзбәк теле, Алтын Урда тарихы, алтаистика, уйгыр теле һәм борынгы төрки рун язмаларын да өйрәтә идем. Әмма ул Департамент бик катлаулы, проблемалы булып чыкты. Шуның өчен 1989 елда Висконсин-Мэдисон университетының тәкъдимен кабул итеп, Үзәк Азия төрки телләре буенча программа әзерли башладым.

***

Мин күп юнәлештә эшләргә күнеккән. АКШтагы университетларда да шулай: теләгән кеше күптөрле предметлар укыта ала. Бездә гуманитар фәннәр буенча төркемнәргә бүленмиләр: студент теләгән предметны үзе теләгән вакытта үзләштерә.

Университетта госманлы һәм гарәп филологиясен укыганга, ул телләрдәге чыганаклар хәзер дә минем өчен бик файдалы. Ләкин мин, чыганаклардан тыш, яңа теорияләргә таянып, анализ ясарга яратам. Бүгенге көндә күп хезмәтләремне дисциплинаара дип атарга була.

Аспирант вакытта минем беренче зур темам Алтын Урданың тарихы булды. Магистрлык рефераты XV-XVIII гасырлар арасындагы Кырым һәм Казан ханлыкларындагы карачы бәкләргә багышланды. Анда кыскача гына чыганакларда табылган мәгълүматларга күзәтү ясадым. Ул – 1984 елда басылган беренче ике мәкаләмнең берсе (икенчесе «бәҗәнәк» атамасына багышланды).

Карачы бәкләр системасының кайдан килеп чыкканлыгын иң беренче өйрәнүче булуымны әйтергә мөмкин, бу вакытта мин әлеге системаны аңлата торган бик мөһим яңалыклар ачтым. Соңрак булган ханлыкларда һәм иртәрәк – Алтын Урдада (ягъни Җучи Олысының көнбатыш өлешендә, аның тагын бер исеме – Ак Урда) Чыңгыз хан токымыннан булган хан янында тагын бер – 4 төп югары статуслы кабиләнең башлыкларыннан торган структура оешкан. Алар бергәләп ханлык белән идарә иткәннәр, хан чыгарган фәрман-боерыкларны мөһер сугып раслаганнар, хан сайлаганнар һәм аны күтәргәннәр, гаскәр тотканнар һәм чит дәүләтләр белән язышканнар. Хан начар булса, аны төшерү, хәтта үтерү хокукына ия булганнар. Шундый ук системадагы Казан ханлыгында булган вакыйгаларны һәм проблемаларны укучы яхшы белә...

Алтын Урдада да шулай булган, ләкин аталуы башкача. Гарәпчә чыганакларда ул әмир әл-олыс, ягъни олыс бәк дип исемләнә. Ул оешманың башлыгы XIII-XIV гасырда – бәкләр бәге булса, XV-XVIII гасырларда аңа карата олуг карачы һәм башка атамалар кулланганнар. Шуларны белми торып, Алтын Урданың тарихын аңлау авыр. Ялгышмасам, бу системаны шундый тирәннән тикшереп аңлаткан беренче кеше – мин. В.В. Вельяминов-Зернов Касыйм ханлыгы турында бик файдалы хезмәтләрен XIX гасырда язган булса да, системаны шул рәвешле тасвирламаган...

Диссертациямне тәгәлләгәннән соң, төп ике тема буенча эшләдем. Беренчесе – Алтын Урданың таркалуында вабаның роле. Мин бүгенге көнгә кадәр Евразия тарихында пандемияләр турында язуымны дәвам итәм. Башта XIV-XV гасырлар белән кызыксынсам, хәзер VI-VIII гасырлар, киләчәктә, насыйп булса, XIX гасыр ахырында чыккан пандемия турында да язарга ниятем бар. Бу, чыннан да, бик мөһим бер тема. Соңгы елларда генетиклар да Yersinia pestis исемле бактерияләрнең тарихын тикшерәләр һәм көтелмәгән нәтиҗәләргә киләләр. Мәсәлән, Болгарда табылган үрнәк XIV гасырда Европада таралган бактерияләрдән һич тә аерылмый. Димәк, пандемиягә

бәйле Болгар, Алтын Урда территориясендәге халык саны күпкә кимегән булырга тиеш. Алтын Урданың 1359 елдан соң таркалу сәбәпләренең берсе бу.

Алтын Урдага кагылышлы төрле темалар мине үзенә җәлеп итә: дәүләттәге каршылыклар, шәһәрләр, соңгы елларда чыганакларда табылган төрле күренешләр һ.б. Әйтик, Ибн Баттута Үзбәк хан мәҗлесләренең тост протоколлары, кемнең кем белән гаилә корганлыгы хакында кызыклы мәгълүматлар китергән. Хәразминең «Мәхәббәтнамә»сен өйрәнеп, аерым бер мәкалә әзерләдем, хәзер Мөгыйн үл-мөрид турында Алтын Урда тарихчысы күзлегеннән язам. Бу чор тарихыннан чыганаклар күп булмаса да, һәммәсен яңадан тикшерергә кирәк. Чөнки мин шәрехләгән структураларны белеп тә, тарихын аңлаткан кеше юк әле...

Икенче тема – Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» тарихы. Диссертациямне яклар өчен 1985 елның декабрь аенда Нью-Йоркка, Колумбия университетына кайтканда, ул хезмәтне «Нью-Йорк гаммәви китапханәсе»ннән табып алып, микрофильм ясаттым. Әлбәттә, татарча, фарсыча, гарәпчә катнаш телдәге бу китапны һәммә кеше укый алмый. Мин аның татар милли тарихына нигез салганлыгын аңладым: шул турыда махсус мәкаләм дә бар. Минемчә, төрки дөньяда аңардан элек милли тарих өчен нигез булырлык хезмәт язылмаган. Шул сәбәпле татарлар соңрак Россиядәге башка мөселман төркиләр белән уртак тел таба алмаганнар: чөнки башкаларда территория өстенә корылган бер милли үзаң алга куелмаган. Шуңа Россиядән качып, төркиягә хезмәт иткән татарлар Төркия тарихында мөһим роль уйнаганнар. Мәсәлән, Йосыф Акчура Мәрҗанине бик югары бәяләгән. Мостафа Кемаль Ататөрек аны Төрек тарих корумының (безнеңчә әйтсәк, Тарих академиясенең) башлыгы итеп билгели, Акчура «Төрек йорды» журналын нәшер итеп, төрек милләтчелегенең нинди булганын, нинди туфракларда урнашканын аңлатырга алына, аңа нигез салучылардан була...

Мин төрки филологияне укытырга яратсам да, үзем текстларны редакцияләп бастырмыйм. Шулай ук тел тарихы белән кызыксынсам да, бу юнәлештә махсус хезмәт язганым юк. Ләкин тарихчы, тюрколог һәм ваба тарихчысы буларак әдәби телләрнең югалып, кабат барлыкка килүен күп очракта пандемияләргә бәйлим. Мисал өчен, согъди теле урынына рун язмалары, алардан соң – уйгыр һәм тагы да башка әлифбалар белән дини текстлар иҗат ителә, XIV гасырда Несториан төрки кабер ташлары язылган Сурия әлифбасы югала, Урта Идел буенда болгар теле 1350 елларда бетә, 1360 елларда Алтын Урда теле юкка чыга, аларны гомумхалык теленә нигезләнгән яңа әдәби телләр алмаштыра.... Госманлы теле дә, чыгтай теле дә шулай барлыкка килгәннәр.

Табигый, Казакъстанда яшәгәнгә, күп мәкалә һәм серияләр казакъ теле, аның латинга күчүе, казакъ тарихы турында иҗат ителә. Соңгы елларда дөньяда адәмзатлар тарихының гыйльми нигезләрен өйрәнү яңа фәнгә әверелде: «Кешелек тарихы турындагы фән» («The Science of Human History») – бу да мине кызыксындыра. Назарбаев университетында, башка галимнәр белән бергәләшеп, борынгы ДНКларны тикшерү буенча лаборатория ачтык, проектлар ясарга тырышабыз. Күптән түгел диссертациямнең яңартылган вариантын Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының М.Госманов исемен йөртүче Алтын Урда һәм татар ханлыкларын тикшеренүләр үзәге бастырып чыгарган иде. Аны инглизчә дә нәшер итәргә кирәк. Киләчәктә Алтын Урда буенча дисциплинаара бер яңа китап бастырырга да телим. Аның эченә география, иҗтимагый төзелеш, экономика, шәһәрләр һәм ислам мәдәнияте, ваба, климат үзгәреше, һәм башка мәсьәләләр дә каралыр. Аңардан алдарак тормышка ашырасы бик күп хыялларым бар...

# БАКЫЙ УРМАНЧЕ ХАТИРӘЛӘРЕ

*Хатирәләр... Хатирә – ул кешенең үткәне, шәхси тарихы. Кеше – үзе үк хатирәләр тупланмасыннан торган кечкенә генә тарих. Ул бик бай һәм бик ярлы булырга да мөмкин. Кызганыч, без аларны еллар узу белән онытабыз, хатирәләр кеше белән юкка чыга, югала. Якыннарыңның да хәтерләре барлык истәлек-хатирәләрне саклап бетерә алмый. Аларны кәгазьдә теркәп калдырганда гына, ул киләчәк буыннарга барып ирешергә мөмкин. Ирешмәгәннәре дә шактый...*

*Хатирәләр дәфтәре әдәбиятта төрле формада, төрле вариантта яши. Кемдер аны мемуар, автобиографик әсәр, көндәлекләр, хатлар тупланмасы рәвешендә тәкъдим итә. Бакый Урманче аны тәрҗемәи хәл һәм хатирә итеп күзаллаган, 1960 еллардан башлап, үткән көннәренең хатирәләрен әкрен генә төрле кәгазь битләренә теркәп барырга тырышкан. Шактый еллар көндәлекләр язу белән дә шөгыльләнгән. Ләкин аларның күбесе сакланмаган, сакланганнары да тулы түгел, яисә кисәк-кисәк кенә. Шунысы кызык: үзе күргән, аралашкан кешеләре хакында исемлек төзи, шуның нигезендә истәлекләр итеп, хәтерен яңарта барган. Булачак, язылачак «Хатирәләр»енең керешенә Урманче түбәндә ният-сүзләрне язарга тиеш тапкан. Керешнең исеме «Хатирәләр – хатирәләр...» дип аталган. Хәзер керештәге сүзләргә игътибар итик: «Төрле үзгәрешләр белән кичергән гомеремдә байтак шәхесләрне очратырга, байтак вакыйга вә хәлләргә шаһид булырга, җәмгыятьтә күренекле урын тотып, дөньяда нинди булса да эз калдырган затлар белән сохбәт-әңгәмәдә булындым. Шуларны кәгазьдә индереп калуны күңелем теләде.*

*Монда исеме аталган шәхесләрнең күбесен күрдем, мәҗлестәш булдым. Кайберләре белән үзем күреп, таныш булмасам да, якын туганнары аркылы таныш булдым. Бу хатирәләрдә документ фәлән белән исбат ителүләр юк. Ләкин (ялгыз) фәкать озын колактан ишетелеп кенә язылган хакыйкый нигезе, риваясе булмаган сүзләрне теркәүдән саклandым.*

*Үзем күргән, үзем туры әңгәмәдә булып алынган хәбәрләр, вакыт-хисап даталары аз китерелде. Чөнки зиһенем цифрлар-рәкымнарга бик буйсынмас – саран булды.*

*Яшьләр вә урта яшьле зыялыларны югалтып сөйләшкәндә, күптән түгел генә узып киткән вакыйгаларны, күптән түгел генә дөнья куйган халкыбызның культурасына хезмәт иткән затларның исемнәрен дә белмиләр.*

*«Исә җилләр, / Күчә комнар, / Бетә эз...» /*

*Эз бетмәс дип яздым.*

*Бер үк архивларда казынып йөргәнем юк, булдыра да алмыйм. Ул миллионнарны туздырып, тәрбия итеп, соңыннан үзенең туфрагына әверелгән изге-мөкатдәс җирнең бавырында нинди генә аң вә тойгылар сеңмәгән! Йа Хода!..*

*Кайберләрнең исеме генә аталган, кайберләре хакында мәгълүматымның чынбарлык нигезенә, ышанычлы ташлардан саналган булуына нык инанып, киңрәк информация бирергә тырыштым. Вә Аллаһ игълам билсавап», – дип яза.*

*Б.Урманче үзенең хатирәләрен әдәби әсәр буларак күз алдына китермәгән, әлбәттә. Ул бары аерым-аерым шәхесләрне барлау, язмасында язганча, үзе белгән кадәрле вакыйгаларны әйтеп калдыруны максат иткән. Шул ягы белән башка төрле мемуарлардан аерыла да инде ул.*

*Мемуар әдәбият хакында сүз кузгалтканмын икән инде, азрак тарихына да тукталып үтү кирәктер. Татар әдәбиятында мемуар әдәбиятка, нигездә, ХХ гасырның 50-60 елларда игътибар ителә башлаган. С.Кудашның 1957 елда «Хәтердә калган минутлар» һәм 1964 елда «Яшьлек эзләре буйлап» мемуарлары татар һәм башкорт әдәбиятында тарихи вакыйга буларак кабул ителде, 60 нчы елларда З.Бәширинең «Замандашларым», 70-80 нче елларда Г.Тавлинның «Афәт», И.Салаховның «Колыма хикәяләре» һәм башкаларны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Ләкин болар, югарыда искә алынганча, әдәби әсәр жанрына карыйлар.*

*Мемуар әдәбият яисә теләсә нинди язмада вакыйга, шәхесләргә фәкать үзенең шәхси мөнәсәбәтен генә белдерә ала. Ул күп очраклар субъектив характерда була, вакыйгаларның тасвирланышы хакыйкатькә туры килсә дә, фактик яктан төгәллеккә дәгъва белдерә алмый. Шул сәбәпле, мемуар әдәбият, яисә мемуар стилендә язылган башка язмалар да аңа дәгъва кылмый. Б.Урманченың истәлек-хатирәләре дә шулар рәтендә каралырга тиеш.*

*Б.Урманченың шәхси архивында әлифба тәртибенә салынып, кулъязма хәлендә сакланган истәлек-хатирәләре бар. Аларның кайберләре акка күчерелгән, кайберләре каралама яки аерым кәгазь кисәкләрен уйланылган вариант, йә шәхес хакында берәр җөмлә белән язып кына үтелгән. Искә алынганча, иң элек ул шәхесләрне барлап, исемлек тә төзегән. Ул исемлек шактый зур һәм күләмле. Бу урында татар, рус һәм башка төрки мәдәниятка танышрак кайбер фамилияләрне генә атап үтәрмен. Исемлектә ХХ гасыр башы һәм 70-80 нче елларда танылган шәхесләр дә бар. Ш.Мөхәммәдьяров, Ф.Әмирхан, С.Сүнчәләй, Н.Гасрый, М.Солтангалиев, Г.Идриси, Г.Баттал, Л.Исхак, Ш.Әхмәдиев, соңрак дәвернең күренекле шәхесләре: Б.Әлминев, Х.Якупов, Л.Фәттах, Н.Җиһанов, Н.Рахлин, Л.Хәмиди, Д.Лопатников, М.Хомяков, А.Григорьев, А.Шевченко, төрекләрдән: Н.Хикмәт, М.Сөхби, Әнвәр паша, казакъ һәм үзбәкләрдән Д.Кунаев, Җ.Җабаев, Ә.Жобабаев, Сатпаев һ.б.*

*Болар кыскача гына атап үтелде. Шәхси архивтагы кулъязма истәлекләр ХХ гасырны иңли. Истәлек язмалар арасында күренекле шәхесләр белән янәшәдә Б.Урманченың язмышында, тормышында мөһим роль уйнаган кешеләрне дә күрергә мөмкин, әлбәттә. Туганнары, якын дуслары, якын-тирәдәге дин әһелләре, мәдрәсәдә бергә укыган шәкерттәшләре, очраклы рәвештә танышып киткән кешеләр дә хатирәләргә теркәлеп калган. Кыскасы, әгәр дә хатирәләрнең кулъязмасы китап итеп нәшер ителсә, ХХ гасыр, гомумән, рәссамның замандашлары хакында тагын да тулырак мәгълүмат белән танышу һәм аларга бөтенләй башка яктан ачылган, башкача якын килергә, яңача фикерләргә ярдәм иткән булыр иде.*

*Укучыга тәкъдим ителәчәк истәлек-хатирәләрне ике өлешкә бүлергә туры килде. Беренчесе, Б.Урманченың шәхесен, тәрҗемәи хәлен өстәмә чыганаклар белән тулыландыру максаты белән һәм рәссамның йөргән җирләре, тормышында мөһим роль уйнаган вакыйгалар, шәхси фаҗигасен ачарлык материалларны рәссам ничек язган булса, шул хәлдә, ягъни авторның стилен саклап, укучыга ирештерү. Дөрес, аларның кайберләре азрак үзгәртелеп, Б.Урманченың җәмәгате Ф.Әхмәтова тарафыннан төзеп бастырылган «Баки Урманче и татарская культура» исемле китапта «Гомернең беренче хатирәләре», «Мөхәммәдулла бабай», «Агыйдел», «Ак беретлы кыз» кебек язмалары һәм «Соловки һәм казакъ дуслар» исеме белән басылган әңгәмәсендә өлешчә чагылып үткәннәр. Мин ул чыганакларны тулырак бирүне максат итеп куйдым. Сәбәбе ачык: Урманче ХХ гасырның дәһшәтле вакыйгаларын үз күзләре белән күргән, шул фаҗигаләрне үз җилкәсендә татыган, шул гарасатлардан Аллаһның ярдәме белән исән кала алган, иҗатында югары үрләргә ирешә алган шәхес. Бу материаллар рәссамның тәрҗемәи хәлендәге мөһим детальләрен тулыландырыр дигән өметтәмен.*

*Хатирәләрнең икенче өлеше – Б.Урманче язмышында, яисә иҗтимагый тормышта азмы-күпме роль уйнаган аерым шәхесләр хакындагы истәлек-хатирәләрдән гыйбарәт. Алар да рәссамның шәхси язмышындагы аеруча әһәмиятле вакыйгаларны, XX гасырның олуг шәхесләре белән таныштырганда, Урманченың аралашу даирәсен, гасырның фаҗигале тарихын ачуда ярдәм итә алыр дигән уйдамын.*

*Кереш мәкалә авторы һәм кулъязма текстларны басмага әзерләүче* **Зөфәр МӨХӘММӘТШИН**

## Солдатка алыну. 1916 ел

Май аеның матур көннәренең берсендә Тәтештәге солдатка алу комиссиясе Габделбакый Идрисевне (призыв исемлегендә шулай язылган иде) гаскәрләргә алырга яраклы дип тапты һәм 3 көн эчендә озатачакларын, шунлыктан һаман китәргә хәзерләнеп торуны агяһландырды.

Әткәй мәрхүм бик кайгылы хәлдә, ләкин күз яшьсез, пароходка утырып, өйгә китте. Минем белән безнең авылдан янә берничә егет, шулар арасында Газиз Миңлегали угылы да бар иде. Газиз миннән өлкәнрәк булса да, минем белән бер елны каралды. Ул Казакъстанда балалар укытып, берничә ел каралырга кайтмыйча торган иде. Шулай Казакъстан даласында посып, гаскәрләргә бармый калган кешеләр булды бит. Бер-ике көннән соң, безне пароходка төяп, Самарага, аннан эшелон белән товар вагоннарында Оренбург ягына алып киттеләр.

Даланың иң матур, чибәр чагы иде. Язгы торым. Җир йөзе яшел утка һәм чәчәкләргә капланган. Казакъ даласы: төзлек, тигезлек, киңлек. Офык еракка-еракка киткән. Ара-тирә кечкенә генә берничә тирмәдән торган казакъ авыллары күренә. Төяләр, куй көтүләре, станцияләрдә бушлык. Чалкар, Казалы кебек станцияләр сирәк.

## Акмәсҗед-Перовскийга[1]. 1916.

Төркестан тимер юлының станцияләре үзләренең корылышы-төзелеше һәм буялышы белән аерым характерлы кыяфәттәләр. Алар хәзер дә әле һаман шул рәвештә Акмәсҗед-Перовский шәһәренең станциясендә шул рәвештә иде. Станциянең алгы ягында, гадәттәгечә, асфальтланган перрон-платформа. Станция бинасының арка ягында кечкенә генә баг сыман агачлык-куаклык, тир-ягында тузан. Поездда төшкәч, безне шул агачлар астына һәм станциянең ике ягындагы рәшәткә коймалар янында урнаштырдылар. Күбрәк татар егетләре булып чыкты. Казан һәм Сембер губернасы халкыннан иде. Бер-ике [көн] шундагы тузанда аунагач, безне кабул итә торган солдатлар һәм офицерлар килде. Алга музыка командасы булган хәлдә, дәртле маршлар тавышы белән гаскәри лагерьга киттек. Безнең аяк астыннан тузан күтәрелеп бара иде.

Шәһәр читенең түбән ягында Сырдәрья буенда өченче укчы Себер полкының (3-й Сибирский стрелковой полк) лагере урнашкан иде. Мине 4 нче батальонның 2 нче ротасына, 2 нче взвод, беренче бүлеккә урнаштырдылар. Юындыру булмады кебек. Гомумән, анда мунча керү минем хәтеремдә калмаган. Бераздан зур таслардан

[1] Акмәсҗед-Перовскига – Б.Урманче искә алган Акмәсҗед-Перовский шәһәре бүгенге көндә Казакъстан Республикасының Кызылорда өлкәсенең административ үзәге. Патша Россиясе Урта Азияне яулап алганга кадәр Ак Мәсҗед исеме белән атап йөртелгән. XIX гасырның 40 – 50 елларында Оренбург губернасы генерал-губернатор граф (1855) Василий Алексеевич Перовский (1795 – 1857) идарә иткәндә, аерым алганда, 1839 – 1840 елларда Хива ханлыгына уңышсыз һөҗүм ясый. 1853 елда Кокандка поход оештыра һәм шәһәрне штурм белән яулап ала. 1854 елда Коканд ханы белән Россия файдасына Россия империясе белән килешү төзелә. Перовский хөрмәтенә Ак Мәсҗед шәһәре Перовскийга алыштырыла, ул шул исем белән 1922 елга кадәр яши.

шти һәм карабодай боткасы белән сыйладылар. Лагерь саманнан[2] корылган бик күп бараклардан тора иде. Баракның ике башында ишек. Уртасында баштан башка ике якка да чыга торган. Ике катлы куш сәке-нар (нары) ясалган. Боларның такталары ышкыланмаган да *(гомернең урта чагында мондый сәкеләрдә янә ятарга туры килде бу фәкыйрьгә. Бусы Соловки лагеренда тиде)*. Һәр баракта бер рота. Идәне җир, түбәсе камыштан. Сырдарья белән бараклар арасында зур мәйдан: барлау һәм бүлек җыелышлары чагында шул мәйданда бөтен полк тезелә, иртәнге-кичке барлау чагында «Боже, Царя Храни»ны[3] җырлый идек. Полкның командиры полковник Норкевич, ротаның командиры Казанский, взвод командиры прапорщик Козловский иде. Аның ярдәмчесе һәм бүлек командирлары һәммәсе диярлек украиннар иде. Новосёлов һәм Рожков, берсенең фамилиясе исемдә калмаган. Өйрәтү яхшы ук тәртипле бара иде. Ашау-эчү дә вакытлы иде. Ләкин гаскәри киемнәрне безгә тиз бирмәделәр. Лагерьның батыш ягында бөтенләй чәнечкеле ут белән капланган дала иде. Шул далада практик уен ясала. «Тезлән!» дигәндә тезләнергә, «ят!» дигәндә ятарга туры килә. Бу рәхимсез үләннең чәнечкеләре шытырдап тезгә, ботка керәләр иде. Шул шартларда киемнәр тиз тузды, керселеп бетте[4]. Безгә иске, ямаулы солдат киемнәре бирә башладылар. Июнь аеның ахырында булса кирәк, безне урамга чыгарып, сафка куйдылар. Монда бер батальоннан артык кеше иде. Хәтта ике батальон булгандыр. Шалама киемнәрне салдырып, яңарак, бөтенләй яңа булмаса да, яхшы юылган, ямалган киемнәр, арка капчыгы һәм мылтык бирделәр. Без[не] сугышка җибәрәләр икән дип куркыштык, чөнки безгә бернәрсә әйтүче юк. Ләкин безне эчке фронка җибәргәннәр икән. Августта булса кирәк, Скоблев-Маргилан[5] шәһәрендә туктадык. Корбан гаете вакыты булса кирәк. Безнең бүлек гает вакытында гает укыла торган мәйданны әйләндереп алып, гает намазы вакытында саклап тордык.

Бу казакъ-кыргыз-үзбәк гыйсъянының[6] иң кызган вакыты иде. Безнең белән монда Урал казачийлары да бар иде. Алар да гает намазы укучыларны саклауда катнаштылар. Күңелдә авыр-авыр тойгылар. Бу шәһәрдән тиз киттек. Тукталдык Әндиҗанда. Анда борыннан калган землянка-казармалар бар икән. Шуларда урнаштык. Анда бик күп солдат бизгәк белән чирли башлады. Гаҗәп, мин Урал тайгасында алган иске бизгәгем булуына карамастан, монда ул чир яңармады. Иммунитет, ахры.

Казакъстан, Кыргызстан далаларына җибәрелгән бүлекләр дала халкын талап йөргәннәр, келәмнәр, ястыклар төяп кайттылар. Алардан бер үлгән кеше булмады.

Сентябрьнең 28 – 29лары булса кирәк, Әндиҗаннан безне бүлекләп, күпләрне казакъ далаларына гыйсъян басарга җибәрделәр. Без бер кечкенә бүлек Әндҗанның тимер юл станциясен сакларга калдык. Станция янында зур гына чәйханә бар иде. Анда тимер юл эшчеләре арасында татарлар да бар иде. Хәтта Күл Черкененнән дә бер егетне очраттым. Алар туган иле хакында сөйләшергә яраталар, сагыналар иде. Кавын-карбыз өлгергән вакыт, көзге айлар, һичбер вакыйг булмады[7] . Үзбәкләр гаҗәп тыныч яшиләр иде.

Кышын безне Акмәчеткә кайтардылар. Ноябрь-декабрь айлары бик суык булды. Декабрьдә ни өчендер Казалы[га][8] илтеп, анда берничә көн суык казармада яшәгәннән

---

2 Саманнан – саламнан.

3 «Боже, Царя храни» – патша Россиясенең Дәүләт Гимны. 1833 – 1917 елларда җырланган. 1833 елда рус патшасы Николай I әмере буенча язылган.

4 Керселеп бетте – керләнеп, каралып бетте.

5 Скоблев-Маргилан – Б.Урманче бу урында хәзерге Үзбәкстан республикасының Фирганә шәһәренең элеккеге исемен искә төшерә. Коканд ханлыгын патша Россиясе генералы М.Д. Скоблев гаскәре басып ала. Шәһәргә Иске Маргиланнан 12 чакрым ераклыкта төзелеп, Яңа Маргилан исеме белән беренче хәрби генерал губернатор Скоблев тарафыннан 1876 елда нигез салына. 1907 – 1924 елларда Яңа Маргилан шәһәре Скоблев исеме белән йөртелә. 1924 елдан шәһәр Фирганәгә үзгәртелә.

6 Гыйсъянының – баш күтәрүчеләрнең, каршылык күрсәтүчеләрнең.

7 Вакыйг булмады – очрак булмады.

8 Казалы[га] – Б.Урманче бу урында хәзерге Казакъстан республикасының Кызылорда өлкәсенең Казалы районы үзәге Казалы шәһәрен күздә тота. Шәһәргә 1853 елда нигез салынган, 1867 елдан шәһәр статусы алган. Тимер юл станциясе бар.

соң, Хукандка китереп төшерделәр. Бу декабрьдә булса кирәк, чөнки февраль революциясенә кадәр шәһәр белән яхшы танышкан идек инде. Безне афган багдагы казармаларга урнаштырдылар. Минемчә, безнең бүлек бер зурайтылган ротадан торса кирәк. Рота особого назначения, яисә «стрелковой» рота[9]. Хәзер хәтеремдә яхшы сакланмаган. Ротаның командиры бер яшь поручик иде. Бик гаскәри тәртип яраткан булып кылана, һәм ни өчендер сугыш вакытында һәрбер офицер гади хаки төстә[10] киенеп йөргәндә, ул купшыланып, татулык заманында киелә торган кызыл кырпулы картуз[11], соры драп шинель киеп йөри иде. Безнең вазифа шул ук афган багда[12] 7 – 8 казарма-баракка урнаштырылган немец офицерларын саклау булды. Болар чын алман түгел, Австрия гаскәрләреннән сугыш башлангач ук әсир төшкән чехлар, словаклар булды, ахры.

1917 елның февраль революциясе Хуканд дәверенең иң истә калырлык вакыйгасы булды. Бу вакыйга мине тәмам шаштырды. Хукандта тәмам җылы яз көннәре башланган иде. Революция алдыннан кызык бер вакыйга булды. Хукандка сугыш трафияләре поезды килгән иде. Монда төрле трафияләр, байраклар, штандартлар, кораллар бар иде. Без группалап, карарга бардык. Поезд тирәсендә байтак халык җыелган иде. Күбрәге, әлбәттә, тимер юл хезмәтчеләре булса кирәк. Шәһәр халкы да булгандыр. Бервакыт шәфкать туташы формасында бер ханым вагон алдына чыгып, берникадәр сөйләгәннән соң, халыкка «Боже, Царя храни!» гимнын җырларга тәкъдим итте. Һич җырлаучы булмады. Аннан соң ханым «поездда карт генерал сезнең патриотик тавышыгызны ишетәсе килеп утыра» дип җырларга кушты. Ләкин җырлаучы булмады. Ул вакыт без солдатлар группасы таралып киткән иде инде. Хәтеремдә дөрест калган булса, бу карт генералның фамилиясе Селиванов[13] иде.

Шул көннәрне патша төшерелгән дигән хәбәр килде. Бөтен гарнизонны Ходаяр хан сараеның курасына җыйдылар. Гарнизон башлыгы булса кирәк, бер йасавыл[14] сүз әйтте. Революциянең нинди революция икәнен аңлатырга тырышты. Законодательная власть[15] белән Исполнительная власть, монархия белән республика арасындагы аерманы аңлатырга тырышуы хәтеремдә калган.

Революция башланды: агитаторлар йөри башлады. Безнең бүлеккә социал-демократлар исеменнән Рубинштейн (ихтимал, башкачарак булгандыр, ләкин ...штейн), социал-революционерлардан (СР) Литвак атлы[16] бер кеше килде.

Комитетлар оештыру китте. Бер рота комитеты сайладык. Рәисе бер прапорщик, бик сөйкемле офицер, педагоглардан булса кирәк. Комитет секретаре итеп, мине сайладылар. Шәһәргә йөрергә ирек ачылды. Мин Хукандның татар мәктәбен табып алдым, анда җыелышлар да була. Шунда яшьләр белән таныштым, кайсылары белән яхшы ук дустлык та багланды. Революция хәйран күтәренке иде. Болар арасында ике гимназиядә укучы кыз да бар иде. Берсе Мәрьям Әхмәтҗанова, икенчесе Зөһрә (фамилиясе хәтеремдә калмаган), яшьләрдән төрле мәктәпләрдә укучылар һәм төрле фирмаларда хезмәт итүчеләр.

Мөхәммәтҗан Бисеров (Мәмәт)[17] бер зур (Вогау түгел микән) фирмада эшли иде. Аңарда мин берничә рәт кунакта булып, кунып та калган идем, арабызда дустлык хасил булган иде. Октябрь революциясеннән соң, бу кеше Төркестан революциясенең

[9] Рус сүзләре кирилл хәрефләрендә язылган.
[10] Хаки төстә – яшел төсле хәрби кием.
[11] Кызыл кырпулы картуз – кызыл юка картуз.
[12] Афган багда – ташланган бакчада.
[13] Селиванов – Андрей Николаевич Селиванов (1847 – 1917), рус армиясе генералы.
[14] Йасавыл – патша сараен караучы, патша кортежен атучы офицер. Бу урында бары «офицер» мәгънәсендә генә килә.
[15] Законодательная власть – рус сүзләре кирилл хәрефләрендә язылган.
[16] Литвак атлы – бу урында Моисей Ильич Литваков (1875 – 1938), яһүди революционеры, сәяси эшлекле, тарихчы, әдәби тәнкыйтьче күздә тотыла кебек.
[17] Мөхәммәтҗан Бисеров (Мәмәт) – Мөхәммәтҗан Гариф улы Бисеров (1898 – 1938), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. 1921 – 1937 елларда Үзбәкстанда җитәкче урыннарда эшли. Сталин репрессиясе корбаны.

президенты булды. Шул вакыт Ташкентка «Шәрык проезды» белән[18] Казаннан барган Маһирә Юнысова белән өйләнештеләр. 1921 ел Мәскәүдә каникулга барган чагымда Мөхәммәтҗан рабфакта укып йөри иде. Аннан соң ул югары белем алып, Үзбәкстан наркомы булып эшләде. Соңыннан Иранда консул булып эшләгән дип ишеттем. 1937 елларда юк ителә. Бер угыллары бар икән. Ул да авыр елларда вафат булып, Маһирә ялгыз кала. Кыен гомер сөреп, 1950 елларда абзасы Гали Юнысов өендә вафат. Мөхәммәтҗан Бисеров Әҗе авылында туган. Гаҗәп һәйбәт егет иде.

Кәрим Бакиров[19] – бу егет Казалының Бакировлардан. Әдип Кәбир Бәкер, артист, соңыннан Ташкент хокук профессоры Фатыйх Бәкерләрнең[20] туганы. Бер зур фирмада хезмәттә. Приказчик иде. Укымышлы, һәйбәт егет. Мин Тәтештә эшләгәндә һәм Глазовта аның белән языштык. Гомәр Әлмөхәммәтов[21] бар иде. Иске шәһәрдә яшиләр иде. Бу бик җитди, уйчан егет иде. Казанда булган. Казан сәнгать мәктәбенә керергә тырышкан. Якшәмбе курсларына йөргән сыман хәтердә калган. Дөрест хәтерләгән булсам «Ялт-йолт» журналына рәсемнәр ясаган. Аның нинди хезмәттә булганын белмим. Ул егерменче елларда ук вафат. Бу кешенең исемен дә, фамилиясен дә дөрест хәтеремдә калдырдым микән?

Бисеровларда коммерческое училищеда укчы бер егет бар иде.

Зур сәүдәгәрләрдән Газинның (?) угылы (исеме хәтеремнән чыккан) гимназиядә укый иде. Болар мәшһүр Юнә авылыннан (Мәскәү юлында Торбеево станциясеннән ерак түгел). Революциядән соң, ул егет МВД органнарында эшләгән дип ишеттем. Акыллы һәм сабыр егет иде.

Юныс (фамилиясен оныттым) Ташкентта мәшһүр миссионер нигезләгән «Учительская семинария»дә укый[22] иде. 1919 елны ул Казанда командирлар курсында укуда булды. Шуннан соң язмышын белмим.

[18] Ташкентка «Шәрык проезды» белән – Б.Урманче Мәскәүдә укый башлаган елында бер төркем студентлар белән Ташкентка сәяхәткә баруын искә ала кебек. Ул шул хакта кыска гына хатирәсен теркәп калдырган. Бу урында сәяхәтнең максатын аңлау өчен хатирәдән кыска гына өзек тә тәкъдим итәм «...Менә шушы оренбуглылар белән 1921 елның маенда без Ташкентка каникулга киттек. Ташкент, Төркестан революциясенең мәркәзе, анда барыр өчен Мәскәүдән аерым пропуск – чит илгә барган кебек алырга кирәк иде. Габделбарый Сөләйманов бармады. Димәк, юлга чыктык. [...] Мортазин, Гөлчәһрә Мортазина, Абләзин, Габделхәмид Беркутов, мин. Ләкин бишебездән дүртебез генә Ташкентка барып җиттек. Мортазин Орскка (?) барып җиткәндә, ваба йогыштырып чирләде. Гөлчәһрә үзе генә Ташкентка килеп, ул шулай итеп Ташкентта калды да. Ләкин заман шундый иде: һичбер вакытка артык тирән эз калдырмый җанда. Һәрбер көтелмәгән хәлгә күнегелгән заман иде. Авырлык өстенә авырлык килеп тора, яңа вакыйгалар, авырлык һәм хафалар үткәнен оныттырып баралар иде. Ташкентта янә бер төрле хафалар чыкты. Оренбурглар кайда барып төшкәннәрдер, хәзер хәтеремдә юк. Әмма мин Шәһид абзый Әхмәдиевне эзләп, Уратүбә күчәсенә Дом Советовка киттем. Юлда бераз чирләгән идем. Инде кич иде. Мин көчкә ул өйне табып, электән таныш булганлыктан Шәһид абзыйга юлыктым. Аның белән әшнәлек безнең әле 1919 елларда Казанда ук башланган иде. «Хәзергә урынлаш, ял ит, иртәгә сөйләшербез», – дип, ул мине Мәхмүд Бәдәйлегә тапшырды. Мәхмүд мине Гомәр Әлмөхәммәтов гаиләсенә кунак итеп урынлаштырды. Иртәгесен Шәһид ага белән мин мәгариф комиссариатында очраштым. Мин Мәскәүдә РСФСР мәгариф комиссариатының шәрык бүлегеннән кайбер йомышлар үтәр өчен командировка да алып килгән идем. Шунлыктан мин ул командировканы мәгариф комиссариатында теркәп, шуның буенча үземнең вазифамны да үтәргә тиеш идем. Шәһид Әхмәдиев миңа башка бер вазифа йөкләргә булды. Минем катгый рәвештә кабул итмәвемә дә карамастан, каһәрләп, мәгариф комиссариатының сәнгать бүлегенең башлыгына урынбасар итеп куйды. «Җирле халыктан анда эшләрлек кеше табып булмый, монда килгәч инде эшләргә, кулдан килгән хезмәтне кызганмаска кирәк...» – диде. Ул вакыт бу бүлекнең башлыгы Мордвинов иде. Мордвинов та әле өлкән кеше түгел. Вакытлы рәвештә укуын ташлаган студент иде. Соңыннан ул кеше Мәскәүгә кайтып, корылыш институтын тәмамлады һәм архитектура академиясенең президенты булды. Мәскәүдә аның проекты белән салынган берничә йорт-өй бар. Шуларның берсе Горький урамының мәркәзгә якын башындагы зур корпус».

[19] Кәрим Бакиров – Кәрим Бәкернең шәхесен ачарлык нинди дә булса мәгълүмат юк. Б.Урманченең шәхси архивында кечкенә генә истәлектә Бакировлар белән танышу хакында хәбәр бар. Хатирәләрдән аңлашылганча, Ул Кәбир Бәкер һәм Фатыйх Бакировларның туганы. Бу урында шул язманы тәкъдим итәм. «Бакировлар. 1921 елда таныштык Кәбир Бәкер белән. Фатыйхны күптән белә идем. Кәрим белән Хукандта 1917 елда таныштык».

[20] Хокук профессоры Фатыйх Бәкерләрнең – монда күренекле журналист, драматург Кәбир Бәкернең (1885 – 1944) бертуган энесе, Казанда артист буларак, Ташкентта яшәгәндә галим, хокук фәннәре докторы, профессор Фатыйх Бакировны (1889 – 1879) искә төшерә. 1967 елда Казанга килгәндә, график портретын ясаган. Ул «Альбом, 1982» һәм «Альбом, 1997»дә басылган.

[21] Гомәр Әлмөхәммәтов – Гомәр Камал улы Әлмөхәммәтов (1895 - 1937), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Сталин репрессиясе корбаны.

[22] Мәшһүр миссионер нигезләгән «Учительская семинария»дә укый – Ташкент укытучылар семинариясе 1879 елда ачыла. Монда күренекле рус ориенталисты, тарихчы һәм этнограф галиме, миссионер Николай Петрович Остроумов (1846 – 1930) күздә тотыла. Ул 1879 елд Төркестан укытучылар семинариясенең беренче директоры итеп билгеләнә.

Мәктәп мөгаллимнәре белән аралашырга туры килмәде. Җыелышлар мәктәп бинасында була иде. Мәктәп бер катлы, зур гына өй. Ходаяр хан сараеннан ерак түгел иде. Яңа шәһәрдә.

Май аенда булса кирәк, дамелла Галимҗан Баруди Хукандка килде. Мин күрештем. Мәктәпнең күршесендә Садыйк байның зур бакчалы өе бар иде. Ул багда мулла белән бер гайри рәсми очрашу булды. Яшь ханымнар да бар иде. Дамеллага кызык-кызык сораулар бирделәр. Барысына да бик оста җавап бирде. Янында сәркатибе Салих[23] – бу кеше миңа «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән таныш иде. Дамелланың (Барудиның) ятлау сәләте, ис-кодрәте икәнне сөйлиләр иде. Ләкин бу юлы мине тануына хәйран калдым. Күрешеп, кулын үптем. «Мулла Идрис угылымы?» – дип, сорау бирде. «Әйе», – дидем. Мин аның дәресләрендә бары өч-дүрт тапкыр гына булган идем. Бөтен сыйныф арасында, башка аның белән күрешкәнем юк иде. Казаннан еракта һич көтелмәгән шәриэттә, солдат киемендә күреп тануы мине таңга калдырды.

Мәрьям Әхмәтҗанова белән безнең арада бер дустлык тойгысы да нурланып киткән иде. Мин адрес та алган идем. Һәм берничә тапкыр хат та яздым. Соңгы хатында ул Назир Төрәкулов белән өйләнешкәннәрен язган иде. Аннан соң без Мәскәүдә 1921 елда күрештек. Ул вакыт Назир Мәскәүдә Шәрык халыклары уртак нәшриятының директоры булып билгеләнгән иде. Назир белән берничә тапкыр күрештек, арабызда бер дустлык та хасил булган иде. Ләкин болар торып китә алмадылар. Назир бик акыллы, киң белемле кеше иде. Мәрьям җиңел акыллы, тотнаксыз хатын булып чыкты, ахры.

Өлкәнрәк кешеләрдән Хөсәен Крымов[24] бар иде. Бу кеше Хукандтан Мәскәүдә уздырылган мөселманнар съездына делегат итеп җибәрелгән булуы хәтеремдә калган.

Бу юлларны язган чакта күңелем ул вакытта Хукандта сәяхәт итә. Шәһәр икегә бүленгән. Вокзалдан чыккач ук, яңа шәһәрнең төзек урамнарыннан барасы. Монда күбрәк иске Европа стилендә салынган өйләр, төрле банклар, Фирганә сәүдәсе тота торган бүлекләре. Шәһәр урамнары яхшы, ару. Урамда фәйтуннар (күбрәк пар ат җигелгән) еш очрый. Ходаяр ханның чиниләр белән бизәлгән,[25] Төркестан стилендә төзелгән сарае да яңа шәһәр эчендә калган. Анда ерак түгел «Урда» дигән елга иске шәһәр белән яңа шәһәрне аерып тора. Күперне кичкәч, иске шәһәргә аяк басасың. Шул елга тирәсен «урда» дип атыйлар. Моның сәбәпләре бардыр, әлегә төшенә алмадым.

Ул вакыт иске шәһәр белән яңа шәһәр арасында ерма бик зур иде. Иске шәһәрдә киң урамнар, проспектлар юк. Берничә киң мәйдан бар. Ул мәйданнар олуг мәсҗед, мәдрәсәләрнең каршында. Күчәләр[26] бик тар. Башка Төркестан шәһәрләрендәге кебек тәрәзәләр, ишекләр урамга чыкмый. Ялгыз саманнан ясалган диварлар һәм күчәдән хавлыга уздыра торган[27] капкалар. Күчәдән хавлыга кергәнче, нинди өйгә керәчәгегезне күз алдына китерә алмыйсыз.

Яңа шәһәрдән барганда, Урданы узгач, сул кулда бик олуг мәсҗед бар иде. Бизәксез һәм гөмбәзе бик мәһабәт. Ләкин керамик-чини юк. Соры саман төсе чи кирпечтән ясалган булса кирәк. Бу мәйданны кичкәч, син «Мең дә бер кичә»дә сурәтләнгән Багдад базарларын искә төшерә торган Хукандның дан тоткан базарларына керәсең. Бу җир тылсымлы бер хикәя кебек. Монда зур магазиннар юк. Аркалар агып торган күчәләр, аларның як-ягында кечкенә генә кибетләр. Шулар арасында ачык чәйханәләр

---

23 Сәркатибе Салих – Б.Урманче Салихтан соң фамилиясен язар өчен урын калдырган. Автор фамилиясен исенә төшерә алмаган, күрәсең.

24 Хөсәен Крымов – Х. Крымов хакында азмы-күпме мәгълүматны Б.Урманче хатирәләреннән алырга мөмкин. Ул аның хакында болай яза: «Хукандта зур игътибарлы кеше иде. Татар халкы аны Беренче корылтайга сайлап җибәрде. Коммерсант-маклер кеше булды, ахры. Хукандта танышканның соңында 1921 елда Мәскәүдә очраштык. Татар халкының зур җиңелүләрдән соң җәбер күреп, үзенең көнен кайгыртып, җәмгыятькә хезмәт итү вазифасында, онытылган сималарның берсе иде. Матур кыяфәтле, гади, ләкин килешле киенгән, салмак табигатьле. Ул вакыт 1917 ел. Хәзерге акылым булса, яхшырак танышкан булыр идем. 1921 елны ничек күрешкәнбездер, Мәскәүдә иде, мине чәйгә чакырды. Мин Казарменныйда тора торган заман... 1917 дә Февраль революциясе көннәрендә татар мәктәбендә булган татар әһлиясенең җыелышында булгандыр.

25 Чиниләр белән бизәлгән – чинаяк кирпечләр, кафельләр белән бизәлгән.

26 Күчәләр – урамнар.

27 Хавлыга уздыра торган – ишек алдына, койма белән әйләндереп алынган урынга уздыра торган.

һәм ашханәләр. Ачык мәйданга берничә сәке куелган. Келәмнәр, әлбәттә, өстәлләр юк. Бер якта учак, анда су кайный һәм аш пешә. Зур самоварлар монда Туладан килеп җиткәннәр. Самоварчының һәрбер хәрәкәте синең күз алдында. Чәйханәләрнең идәне җир. Ләкин пычрак һәм тузан юк. Һәрвакыт су сибеп, тузанны басып, һаваны тазартып торалар. Базарның күчәләрендә дә шулай су сибеп торалар. Шунлыктан җәй көннәрендә никадәр эссе һава булса да, һава һаман ярау булып тора. Базарның түбәсе әүсәлек кебек ябык булганлыктан, кояш көйдереп китми.

Бу базар хәзер юк. Бу кешеләр дә хәзер юк. Ни өчендер Мәрьям да юктыр дип беләм. Ләкин минем күңелемдә барысы да яши. Революциянең өмидле дәртләр белән рухландырган чакларында очрашкан иптәшләр шул хәлләрендә исемдә калганнар. Аларның һичберсен яманлык белән искә алу мөмкин түгел. Һәммәсе нурлы чырайлы, һәм шул нурлы чырайлы хәлләрендә сурәтләре күңелемдә уелып калган. Ул сурәтләрнең эзләре һич очмыйлар, шомармыйлар. Гүя мин кичә генә алар белән булган. Хәтта Мәрьямне дә соңгы хәлләрен белүемә карамастан, шул вакытта үсмер кыз вакытындагы чибәр һәм гафиф[28] кыяфәте белән күз алдыма китерәм.

Хукандтагы татар мәктәбе дә күз алдымда. Татар халкының бөтен культур тереклеге шул мәктәп тирәсендә йөргән. Гаҗәп, татар халкы борынгы мәктәп-мәдрәсәне бик хөрмәт иткән.

Хукандта тарихи әсәрләр, узмыш мәдәниятнең истәлекләре белән дә кызыксынырга мөмкин иде. Ләкин, ахрысы, анлык культурам да булмаган һәм революция әхвале бөтен башка интересларны бер якка селтәгән булса кирәк. Юкса, Ходаяр хан сарае[29], Төһмтән шаһан[30] һәм корылыш вә төзелеш әсәрләре белән кызыксынырга мөмкин иде. Кайчан монда татар сәүдәгәрләре килә башлаган? Базарда бер карт татар сәүдәгәрен, тартмачыны күрдем. Ул үзләренең хан заманыннан ук килгәннәрен сөйләде.

Майның икенче яртысында булса кирәк, безгә җыелырга дигән команда булды. Сафка тезеп, вокзалга алып киттеләр. Хуканд вокзалында поезд-вагон бирүләрен көтеп торган вакытта почтада эшли торган татар егетен очраттым. Якындагы чәйханәгә кереп, нан белән чәй эчтек, дусларга сәлам әйтүен үтендем. Бу Хукандтагы танышларымнан соңгы күрешкәнем һәм соңгы чәем булды.

Хуш, тылсымлы шәһәр! Җанымның бер парчасы синдә калды. Янә Акмәчеткә кайтып төштек. Монда да кояш нурлы, җылы җәй башы һәм монда да революциянең дәртле көннәре сизелә иде. Беренче майда бәйрәм сыман булып алды. Элекке «Боже, Царя храни» гимнын җырлый торган урынга биек трибуна тактадан ясап куелган. Шунда җыелышлар була. Солдатлар, офицерлар бергә катнашып, иҗади кичәләр ясадылар. Бүлек табибы бер капитан чинындагы кешенең виолончель уйнавы исемдә калган, шулай ук акробатика. Тәртип яхшы ук йомшарган иде. Казармаларга йөреп, дустлар белән әңгәмә корырга да вакыт табылды. Алма-Атадан байтак кеше бар иде. Капалдан әткәйнең дусты булган мөгаллим Фатыйх Садыйковның[31] шәкертләре бар

[28] Гафиф – саф, пакь, абруйлы, намуслы.

[29] Ходаяр хан сарае – монда 1845 – 1875 елларда Коканд ханлыгы белән идарә иткән Ходаяр тарафыннан 1863 – 1871 елларда төзелгән Ходаяр хан сарае истә тотыла.

[30] Төхммәте шаһан – көчле, батыр шаһ. Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәрендә тасвирланган Рөстәмнең эпитеты.

[31] Мөгаллим Фатыйх Садыйков – Фатыйх Садыйк улы Садыйков (1880 - ?), укытучы. Б.Урманче истәлекләре буенча 1905 – 1907 елгы революцион хәрәкәтендә катнашкан, социал-демократлар идеясенә якын торган. Урта Азиягә китә, Капал шәһәрендә укыта. Соңгы эш урыны Алма-Ата өлкәсендә Талдыкурганда укытучы булган. Сталин репрессиясе корбаны. Бу урында Ф.Садыйковның шәхесен киңрәк күзаллау өчен Б.Урманче хатирәләренә дә игътибар итү кирәктер. Истәлектә Урманче аны түбәндә болай тасвирлый. «Капал Фатыйх дип тә безнең якта шөһрәт тапты. Бакуда Нургали хәзрәт мәдрәсәсендә укыды. Журналист, язар Шакир Мөхәммәдевнең кардәше. Буа мәдрәсәсендә Һади Атласи, Бикколовлар, Зариф Бәшири, Сәгыйдевлар (Кәрим Сәгыйди), Шиһаб Әхмәровлар катнашкан сәяси, социал-демократлар түгәрәгендә күренекле әгъза булган кеше. Әткәй шулар арасында булган. Оренбургта (Каргалыда) Фатыйх Кәрими, Рәмиевлар оештырган мөгаллимнәр курсларында укый. Оренбургта кала һәм сәяси «ышанычсыз» кеше буларак, сөргенгә җибәрелеп, Капалда урнашып, шунда мөгаллимлек кыла. Язган әсәрләре бар. Революциядән соң Талдыкурганда зур сәүдә ширкәте корып йөрүе ишетелде. Әткәйнең сәяси сердәше булган. Күл Черкене янындагы Казма авылыннан. Бу Буа түгәрәге хакында язылган нәрсә күренми. Ләкин шул мәдрәсә аркылы әткәйнең кулына шапирограф белән басылган прокламацияләр килә иде. Бу минем хәтеремдә яхшы сакланган. Әткәйнең Черкеннән 1907 елда ашыгыч рәвештә Салтыкка күчеп китүе дә шул «түгәрәк» таралуыннан түгел микән?»

иде. Яхшы ук зыялы халык. Безнең казармада ук мәшһүр миллионер Габделвәлиев Исхак байның[32] угылы Йосыф[33] булды. Ул югары сәкедә ята иде. Скрипка уйный икән, скрипкасын да алып килгән. Кайвакыт аны тыңлап рәхәтләнә идек. Исхак байның приказчиклары һәм Мостиков дигән әйбәт укымышлы егет бар иде. Соңыннан аны 1919 елда Казанда күрдем. Ул сугыштан соң Сарытауга кайткан һәм шунда эшли икән. Кыскасы, һәрьяктан ирек булуы, революциянең нәтиҗәләре сизелә иде, рәхәтләндерә иде. Рамазан бәйрәменә дә, гает намазына да җибәрделәр. Безнең ротада татарлар күп иде. Аларны минем «командага» биреп, татарча җырлап барырга куштылар. Күнегеп карау булмаса да, без җырлап бардык. Шәһәргә бардык, мулла урта яшьләрдәге кеше иде. Казанда безнең «Мөхәммәдия»дә укыган икән. Тагын романтика! Акмәчеттә байтак татар яшәгән булса кирәк. Кайберләре белән күрешеп таныш булырга туры килде.

1927 елларда Казанда сәнгать техникумында эшләгәндә, Акмәчеттә туып үскән бер шәкертем дә булды: Солтан Борындыков[34]. Соңыннан бу егет Ташкентта сәнгать эшендә булган. 1957(?) елда Солтанның өендә кунакта да булдык. Акмәчеттә кызыл мал белән сәүдә итүче зур магазинлы байлар, базарда сәүдә итүче вак сәүдәгәрләр, ростовщиклар бар иде. Татар мәктәбе булган, яшьләрне яхшы гына тәрбия иткән мөгаллимнәр булган, ахры. Ләкин солдат булган чакта халык арасына кереп булмады. Ничек кенә булмасын, казарма-лагерь тормышы.

Июль ахырларында безне янә сәфәр хәленә куйдылар, фронтка озаталар икән дигән хәбәр таралды һәм шулай булып чыкты да. Безне бер эшелон ясап, көнбатышка озаттылар. «Хуш, Төркестан!» – дидек.

Безнең бүлекнең командиры, эшелон башлыгы бик симпатик бер поручик иде. Бу кеше яшь педагоглардан булгандыр, ихтимал. Аңарда гаскәри түрә булырга теләгән «замашкалар» юк иде. Чалкар станциясендә[35] туктап торган вакытта мин аңардан увольнение бирүен сорадым. Максатым пассажир поезды белән өйгә китеп, ата-анамны һәм кардәшләремне күреп чыгу иде. Эшелон бик акрын хәрәкәт иткәнлектән, Пенза тирәсендә эшелонны куып җитүем мөмкин иде. Рөхсәт алдым. Минем белән бергә янә безнең авылның (Кече Салтыкның) бер егете һәм күрше авыллардан берничә егет өйләренә кереп чыгарга рөхсәт алдылар. Самарага җитеп, аннан пароход белән Салтыкка кайтып җиттем. (Богородскоега кадәр пароход белән, аннан җәяү 10 чакрымны очып кына кайттым).

Көтмәгәндә, өйгә кайтып керүем нинди зур шатлык булуын чамаларга да мөмкин түгел. Әткәйнең шатлыгын ни белән булса да чагыштырырга мөмкинме?!

Инде туганнар белән күрешергә кайткач, әлбәттә, йөрәгемнең иң кадерле парәсе булган тәтәнкәйне-дәү әниемне күрмичә китү дә һич мөмкин түгел иде...

*(Ахыры киләсе санда.)*

[32] Габделвәлиев Исхак бай – тумышы белән хәзерге Кукмара районының Мәчкәрә авылыннан булган танылган сәүдәгәр Исхак Габделвәлиев (1841 - ?) Верный (хәзерге Алма-Ата) шәһәрендә яшәп, Урта Азиядә үзенең сәүдә челтәрләрен барлыкка китерә һәм күренекле байларыннан санала. Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймәнең атасы Хәмзә байның бертуган абыйсы. Яшәгән еллары хакында төгәл мәгълүмат юк. Язучы һәм галимә Фәүзия Бәйрәмова «Ана» әсәрендә «1858 елгы ревизия материалларыннан күренгәнчә, Исхак 1841 елгы булырга тиеш, күп хезмәтләрдә язылганча 1839 елгы түгел», – дип яза.

[33] Угылы Йосыф – Б.Урманче истәлекләре арасында Исхак бай улы Йосыф хакында да кыска гына мәгълүмат сакланган. Монда чыганакны тәкъдим итү урынлы булыр. «Исхак бай (Алма-Ата) Габделвәлиев. Йосыф аның углы белән таныш булдым Акмәчет-Перовскида. Солдатлыкта. Исемен оныттым. Бер баракта булдык, скрипка уйный иде. Бик мөлаем, сабыр егет иде. Революциядән соң болар кая китте икән? Кунаев Димәш, әлбәттә, белә торгандыр».

[34] Солтан Борындыков – Б.Урманченең Казан сәнгать мәктәбендә укыта башланган елларында беренче шәкертләреннән берсе. Тумышы белән Казакъстан Республикасының Кызыл-Орда шәһәреннән. Ташкентта Педагогия институтында эшләгән. Шигырьләр язу белән дә мавыккан. Яшьли вафат булган.

[35] Чалкар станциясендә – Б.Урманче искә алган Чалкар (Челкар) станциясе хәзерге кондә Шалкар исеме белән йөртелә, Казакъстан республикасының Актүбә өлкәсе Шалкар районы үзәге. 1901 – 1903 елларда Ташкент тимер юлы салынып, ул Челкар аша узган. 1905 елда тимер юл станциясе ачылган. 1928 елдан шәһәр статусын ала.

# АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ

## Алтын Урда дәүләте оешу

Алтын Урда дәүләте оешу Чыңгыз исемен алачак Тимучин яугирнең күчмәннәрне берләштереп һәм буйсындырып, 1206 – 1220 елларда күрше кабиләләргә һәм дәүләтләргә Монгол даласыннан яу чабуыннан, шул исәптән Төньяк Кытайны, Харәземшаһлар мәмләкәтен, Урта Азияне, Иранны, Кавказ арты төбәген буйсындыруыннан башлана. Кавказ тауларын кичеп, монгол гаскәре Кыпчак даласына чыга, бередә 1223 елның 31 маенда Калка суы буенда славян һәм кыпчак хәрби көчләре берлеген тар-мар итә. Ләкин Идел-Чулман төбәгенә таба хәрәкәт иткәндә, Болгар яугирләре корган тозакка эләгеп, җиңелә һәм чигенергә мәҗбүр була. Тарихи чыганакларда монголларның зур булмаган хәрби көчләре 1229 елда Җаек буенда болгар гаскәрен җиңүләре, ә 1232 елда бу төбәккә таба килүләре, ләкин Бүләр шәһәренә барып җитмәүләре хакында кайбер хәбәрләр бар.

Чыңгыз хан үзе төзегән империя җирләрен автоном өлкәләр рәвешендә улларына идарә итәргә бирә: үзәк олыс – Көньяк-Көнчыгыш Себер, Монголия һәм Төньяк Кытай үзендә кала (соңрак Үгәдәйгә бирелә. – *И.З.*), Иран биләмәләрен – дүртенче улы Тулуйга (соңрак улы Һөләгү идарә итә), Мавәраэннәһер (Амудәрья белән Сырдәрья арасы, Бохара һәм Сәмәрканд калалары) һәм Җидесу өлкәсен – Чагатайга; Харәзем һәм Иртеш елгасыннан көнбатышка таба җәелеп киткән Көнчыгыш Кыпчак даласын олы улы Жучига тапшыра (*Госманов М. Алтын Урда: тарих һәм мирас // Мирас. 1993. № 8. 39 б.*). Жучи Иртеш буена килеп төпләнә, әмма 1227 елда үлеп китә, алты айдан соң Чыңгыз хан да фани дөньяны калдыра. Идарә дилбегәсе, Чыңгыз хан фатихасы белән, аның улы Бату кулына күчә.

1236 – 1242 еллардагы Көнбатышка яу чабу нәтиҗәсендә Жучи Олысына яңа биләмәләр өстәлә. 1236 елда баскыннарга буйсынырга теләмәгән Идел буе Болгар дәүләте тар-мар ителә, шәһәрләре яндырыла, халкы кырыла. 1237-38 елларда Бату бер-бер артлы аерым-аерым яшәп ятучы славян кенәзлекләрен буйсындыра, 1240 елда Киевне ала, Венгрия, Польшага яу чаба. Каракорым каласында олуг хан Үгәдәй үлгәнен ишетеп, 1242 елда Идел-Чулман буйларына кайта.

Жучи Олысы аның 14 улы арасында бүленә, алар үзләренең беренче идарәчеләре дип Батуны таныйлар *(Сафаргалиев М.Г. Падение Золотой Орды. Саранск: Мордовск. кн. изд-во, 1960. С.43)*. Әйтергә кирәк, Бату беренче башкала итеп, 1243 елда гаскәре яндырган Болгарны сайлый һәм Идел елгасы буендагы бу шәһәрне тергезү өчен зур көч куя. Соңрак Бату Түбән Иделгә, хәзерге Әстерханнан ерак булмаган урында Сарай әл-Мәхрүсә (археологиядә – Селитренное шәһәрлеге) исемле яңа кала нигезли. Аны Алтын Урда башкаласы итеп, туганы Бәркә (1257 – 1266) төзеп бетерә. Үзбәк хан 1330 нчы елларда хәзерге Волгоградтан түбәнрәк урында Яңа шәһәр – Сарай әл-Җәдидне төзи (Царево шәһәрлеге).

Күчмәннәрдәге тәртип буенча, Жучи Олысы уң һәм сул «канат»ларга бүленә. Кайбер чыганаклар буенча Жучи олысындагы канатлар арасындагы географик чик Җаек елгасы буенча уза. Елганың көнчыгыш ярындагы җирләр Урда Иҗәннеке (Күк Урда), аның мәркәзе Балхаш күле янында урнаша (соңрак башкала Сырдәрья елгасы буендагы Сыгнак шәһәре була), ә көнбатыш яры ягы Бату биләмәләре итеп рәсмиләштерелә, бу җирләр Ак Урда (Алтын Урда) дип атала *(Трепавлов В.В. Степные*

*империи Евразии. Монголы и татары. М.: Квадрига, 2015. С. 203).* Дәүләтнең күпчелек халкы күчмә тормыш алып бара, күпчелек җирләре дала зонасына туры килә, шул сәбәпле гарәп һәм фарсы чыганакларында Дәшти Кыпчак дип тә исемләнә.

Чыңгыз хан улларының олыслары арасында Җучи Олысы иң зурысы санала. Ул көнчыгышта Иртеш елгасыннан көнбатышта Дунайга кадәр, Көньякта Кара һәм Каспий диңгезенең төньяк ярларыннан башлап, Себер ягыннан төньякта Арктикага кадәр сузыла дип әйтергә мөмкин *(Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск: Мордовск. кн. изд-во, 1960. С. 28)*[1].

Бату яулаган җирләр барысы да Бөек Монгол империясенеке санала. Җучи Олысы ханының олуг ханнан бәйлелеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: 1) аның кандидатурасын олуг хан раслый, 2) салымнарның зур өлеше Каракорымга озатыла, 3) хәрби походлар вакытында үзәккә гаскәр җибәрелә, 4) тәңкәләр олуг хан исеме белән суктырыла.

Тора-бара Евразиянең иксез-чиксез киңлекләренә җәелгән империя белән идарә итү кыенлаша, ә төбәктәге ханнар аерымлану юнәлешендә адымнар ясый башлыйлар. Бәркә якынча 1260 елдан Каракорымга салым түләүне туктата. Ул 1257 елда – Җучи йорты тамгасын куеп, 1259 елны – үз исемен, 1262 елда Җучи тамгасы белән, соңгы Багдад хәлифәсе ән-Насыйр ли-дини-Ллаһ исемен язып, тәңкәләр суктыра башлый *(Усманов М.А., Измайлов И.Л. Ислам в улусе Джучи // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.3. Казань, 2009. С. 604)* – бу гамәл ачыктан-ачык Монгол дәүләтенә буйсынмауны күрсәтә. Хәлифә исемен куеп, тәңкә суктыруны галимнәр Бәркәнең мәҗүси Монгол дәүләтенә каршы ислам дине идеологиясен куярга омтылышы дип бәялиләр (*Усманов М.А. Этапы исламизации Джучиева улуса и мусульманское духовенство в татарских ханствах XIII – XVI вв. // Духовенство и политическая жизнь на Ближнем и Среднем Востоке в период феодализма. М..: Изд-во «Наука», гл. ред. вост. лит-ры, 1985. С. 181).*

Бәркәдән соң Алтын Урда тәхетенә мәҗүси диндәге Мәнгү-Тимер (1266 – 1280) утыра. Ул тәңкәләрне үз исеменнән суктыра, Европа илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга сала, Үгәдәй һәм Чагатай олыслары белән Бәркә заманында бозылган мөнәсәбәтләрне яхшырта. Мәнгү-Тимер хан вакытында Алтын Урда мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыга. Ә 1269 елда хәзерге Кыргызстанның Талас үзәнлегендә узган монгол корылтаенда Чыңгыз уллары Җучи, Чагатай һәм Үгәдәйнең нәсел дәвамчылары үзләре идарә иткән олысларның чикләрен билгелиләр. Дөньяның сәяси картасында биш яңа дәүләт пәйда була: Җучи Олысы, Чагатай Олысы, Үгәдәй Олысы, Кобылай Олысы һәм Һөләгү Олысы, ягъни Илханнар дәүләте.

Төбәкләрнең чикләре Монгол дәүләтендәге хәрби идарә таләпләреннән, ягъни һәр урынның күпме гаскәр бирергә тиешлегеннән чыгып сызыла: төмәннәр меңнәргә, меңнәр йөзләргә бүленә. Салымнар һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләр хакимият уздырган җанисәп нәтиҗәләре нигезендә йорт башыннан җыела. Чыганакларда 1246 – 1259, 1273 һәм 1287 елларда булган халык санын алу турында мәгълүматлар сакланып калган.

Хан дәүләт белән диван – берничә кабилә җитәкчеләреннән, үзенең уллары, туганнарыннан торган дәүләт советы – ярдәмендә идарә итә. Хакимияттә төп рольне төрки-монгол кабиләләре вәкилләреннән торган гаскәрнең башлыгы – бәкләр бәге һәм гражданлык идарә җитәкчесе – вәзир башкара. Үзәк хакимият көчле чакта алар хан тарафыннан билгеләнә торган булганнар.

[1] Җучи Олысының «көнчыгыштагы чикләре Иртеш елгасының югары һәм урта агымыннан, Алтай таулары буеннан башланып, көньякта Балхаш күленең көнбатышына таба борылган, хәзерге Казакъстанның көньяк өлкәләре аша узып, Арал диңгезен урап һәм Үргәнеч-Харәземнәрне эченә алып, Каспий диңгезе янындагы Кара бугазга килеп терәлгән. Аннары чикләр, Дәрбәнд шәһәре тирәсеннән Кавказ таулары буйлап, Кара диңгезнең төньяк өлкәләрен эченә алып, Дунай елгасына кадәр сузылган. Моннан соң алар, кырт борылып дигәндәй, хәзерге Польша җирендәге Люблин шәһәре янынннан узып, өлешчә Белоруссия җирләре аркылы кичеп, Бөек Новгород биләмәләрен әйләнеп иңләп, Урал аша Себергә сузылган һәм Обь елгасы буендагы чикләрнең көнчыгышта калган очы белән ялгана», дип төгәлләштерә М. Госманов (Госманов М. Алтын Урда: тарих һәм мирас // Мирас. 1993. № 8. 46 б.)

Дәүләтнең хуҗалык нигезен монголлар яулап алган төбәкләрдә электән килгән кәсепләр дәвам итә. Алтын Урдада игенчелек, бакчачылык мәйданнары табигать (урман, урман катыш дала, дала) һәм климат зоналарына бәйле үсеш ала.

## Ислам дине белән танышу чоры

М.Госманов Алтын Урда дәүләтендә ислам таралуның өч этабын аерып чыгара. Беренче этап – монголларның ислам дине белән таныша башлаулары, икенче этап – исламны рәсми дәүләт дине дип игълан итү, Үзбәк һәм Җанибәкнең яңа динне актив тарату еллары һәм өченче этап – XIV гасыр ахырында Алтын Урда халкының исламлашу чоры (*Усманов М.А., Измайлов И.Л. Ислам в улусе Джучи.* ***Күрс.хезмәт.*** *С. 600).*

Алтын Урда дәүләтендә рәсми рәвештә ислам кабул итүнең алшартлары дип түбәндәге факторларны атарга мөмкин.

*Дин иреге.* Алтын Урдада төрле дин вәкилләре яши: мөселманнар, католиклар, несторианнар һәм православлау динен тотучылар, буддистлар, традицион дин тарафдарлары – мәҗүсиләр һ.б. Бу кавемнәргә һәм аларның элиталарына карата Чыңгыз хан керткән кагыйдә кулланыла: буйсыну, салымнарны вакытында түләү һәм җәмәгать тәртибен саклау хисабына үз диннәрен иректә тотарга рөхсәт ителә. Мөселманнарга карата дин иреге, бер яктан, хәнәфи мәзһәбе дәүләт дине булып танылгач та, башка мәзһәб тарафдарларына һәм голамәләргә хәерхаһлы мөнәсәбәт саклануда, икенче яктан, суфи тарикатьләренә карата түземле сәясәттә чагылыш таба.

*Монголларның төркиләшүе.* Монгол дәүләте рәсми язу өчен уйгыр алфавитын кабул итә. Чыңгыз Йорты вәкилләре канцелярияләрендә язу-сызу тулысынча диярлек укымышлы уйгырлар, бахшилар кулында була. Моңардан тыш, монголлар составларында төрки кабиләләре булган найманнар, кәрәитләр белән якыннан аралашып яшәгәннәр. Моңа дәлил итеп, М.Госманов Бәркәнең һәм аның сараендагы чиновникларның төркичә аралашуын китерә *(Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV – XVI вв. Казань: изд-во Казан. ун-та, 1979. С. 98, 100).*

1236 – 1242 еллардагы Көнбатыш походта катнашкан гаскәриләр Монголиягә кайтып киткәч, Җучи уллары үз карамагындагы аз санлы кабиләләр белән кала: дәүләттә сан ягыннан җирле төрки кабиләләр һәм халыклар өстенлек итә. Кыпчак даласыннан тыш, күп гасырлык утрак тормыш традицияләре булган һәм хуҗалык нигезен игенчелек яки бакчачылык тәшкил иткән Харәзем, элекке Идел буе Болгар дәүләте җирләре, Кырымның көньяк яр буйлары, Түбән Идел, Төньяк Кавказда Терек елгасының югары һәм урта агымы бассейны, Прут һәм Днестр арасындагы төбәк кебек, нигездә, төрки халыклар яшәгән урыннарның мәмләкәтнең төп икътисади төбәкләренә әверелүе, шул җирләрдә зур-зур шәһәрләр үсеп чыгу, аларның һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләренә әверелүе төркиләшү процессын тагын да тизләтә. Ярты гасырдан монгол телен куллану даирәсе тарая, йөз елдан соң ханнар һәм сарай хезмәткәрләре тулысы белән төркиләшәләр (*Госманов М. Алтын Урда: тарих һәм мирас. Күрс****.*** *хезмәт. 39 б.).* Кыпчаклашу, бер телдә аралашу, язма телнең бер булуы, менталитетның охшашлыгы һ.б. сәбәпләр ислам динен кабул итүгә уңай шартлар формалаштыра. Бер үк вакытта исламлашу монголларның төркиләшүен тагын да тизләтә.

*Югары шәһәр мәдәнияте формалашу.* Тарих фәнендә археологик табылдыкларга һәм язма чыганакларга нигезләнгән Алтын Урда мәдәниятен шәһәр мәдәнияте һәм күчмәннәр мәдәнияте симбиозы дигән фикер өстенлек итә. Шушы уңайдан, Җучи Олысында шәһәрләрнең үсеш этапларын барлап үтик:

XIII гасырның 40 нчы еллары – монгол гаскәре тарафыннан җимерелгән калаларның торгызылуы;

XIII йөзнең 50 нче елларының беренче яртысыннан – XIV йөзнең 20 нче елларына кадәр – яңа шәһәрләр нигезләү һәм аларның акрынлап үсүе;

XIV йөзнең 20-60 нчы еллары – Үзбәк һәм Җанибәк ханнар идарәсендә шәһәр төзелешенең чәчәк атуы;

XIV гасырның 60 нчы елларыннан башлап – шәһәр төзелеше туктаган заман. Биредә 1395 елда Аксак Тимернең Туктамыш гаскәрен җиңеп, шәһәрләрне җимергәнен аерым билгеләп үтү мәслихәт. *(Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII – XIV вв. М.: Наука, 1985. С.78).*

1236 елгы яудан соң элеккеге Идел буе Болгар дәүләте җирендәге күпчелек шәһәрләр торгызылмый, төбәк «шәһәрләр иле» булудан туктый. Алтын Урда чоры төбәк тарихында, нигездә, Болгар һәм Биләр калалары телгә алына. Урта гасырларда ислам мәркәзләре булып шәһәрләр саналганын исәпкә алганда, 1236 елда ислам институтларына көчле удар ясалганын таныргa тиеш булабыз.

Барлык заманнарда да шәһәр төзү дәүләт өчен бик кыйммәтле проект саналган. Ханнар яңа шәһәрләрне ялан кырда, ягъни элек калалар булмаган дала зонасында төзиләр. Шәһәр төзергә урын сайлаганда, төп критерий булып аның сәүдә юлында, алыш-биреш һәм яшәү өчен уңайлы җирдә урнашуы торган. Фәндә җәмгысе 110 Алтын Урда шәһәренең урыны билгеле. Яңа шәһәрләр төзү алар тирәсендә утрак тормыш алып баручы төркемнәрнең яшәү ареалы киңәюгә сәбәп булган.

Моңардан тыш, урта гасыр карталарында билгеләнгән, ләкин бүгенгәчә урыннары ачыкланмаган тагын өч дистә кала (нигездә, Идел, Дон елгалары, Каспий диңгезенең төньяк, көнчыгыш һәм көнбатыш ярлары, Кара диңгез һәм Арал диңгезе ярлары буенда урнашкан) була.

Тәңкәләр суккан шәһәрләр исемлегендә Сарай, Сарай әл-Җәдид, Харәзем (Үргәнеч), Гөлестан, Болгар, Бүләр, Алак, Кырым, Каф, Хаҗитархан, Урда Базар, Бәк Базар, Үкәк, Сарайчык, Мухшы, Шәһәр әл-Җәдид, Мажар каласы бар. Болар иң зур калалар һәм эре ислам дине үзәкләре саналган. Халыкара диңгез сәүдә үзәге булган Венеция шәһәре картографлары бертуган Францисск һәм Доминик Пицconfigurаниларның 1367 – 1373 елларда төзелгән картасында билгеләнгән Бинҗәмин, Төмән, Аккирмән дә шундый эре һөнәрчелек, сәүдә һәм идарә үзәкләре буларак танылган *(Егоров В.Л. Курс. хезмәт. С. 139).*

Ханнар Урта Азия һәм Гыйрак калаларында хөкем сөргән шәһәр тормышына йөз тоткан. Алтын Урда шәһәрләре, бер яктан, Урта Азиядәгегә охшаш мәчет-манаралары, мәдрәсәләре, югары катлам вәкилләренең бизәкле таш йортлары, полихром мозаика һәм майолика белән тышланган җәмәгать биналары, агач йортлар, икенче яктан, алар белән янәшә корылган күчмәннәрнең тирмәләре белән күзаллана. Шәһәр мәдәниятен буйсындырылган халыклар – Урта Азиядән, Ираннан, Мисырдан, Гыйрактан китертелгән төзүчеләр, галимнәр, астрономнар, дин белгечләре, шагыйрьләр – булдыра *(Фёдоров-Давыдов Г.С. Искусство кочевников и Золотой Орды. Очерки культуры и искусства народов Евразийских степей и золотоордынских городов). М.: «Искусство», 1876. С. 118, 119, 120, 121).*

Нәкъ менә шәһәрләр ислам динен тарату урыннары саналган, монгол элитасы тарафыннан ислам шәһәрләр дине дип кабул ителгән. Бу караш, үз чиратында, күчмәннәр вәкилләре булган монголларда шәһәрләр динен кабул итүгә тискәре караш формалаштырган *(Иванов В.А., Злыгостев В.А., Антонов И.В. Южный Урал в эпоху средневековья (XV – XVI века н.э.). Уфа: ВПО Башкирский гос. университет им. Акмуллы, 2013. С. 175).*

*Мөселман сәүдәгәрләр катламы формалашу*. Алтын Урда дәүләтенең иң зур керем чыганагы чит ил сәүдәгәрләреннән җыелган салым булу сәбәпле, мөһим сәүдә һәм транспорт артериясе саналган Идел елгасы ярларында ханнар яңа шәһәрләр коралар. Күчмәннәр сәүдә белән шөгыльләнми, шуңа күрә бу һөнәр утрак тормыш алып баручы мөселманнар һәм чит ил сәүдәгәрләре кулында туплана. Сәүдәгәрләр хан һәм дәүләт элитасы вәкилләре белән якыннан аралашкан, йогынтылы булганнар. Алар акчаларын, бигрәк тә, шәһәрләрдә мәчетләр, мәдрәсәләр төзүгә, гомумән, мөселман

инфраструктурасын булдыруга сарыф иткән. Ислам дине Алтын Урдада дәүләт диненә әйләнгәнче, шәһәрләрдә ислам институтлары, нигездә, сәүдәгәрләр иганәсе хисабына яшәгән. Әйтик, 1260 елда Болгар шәһәрендә җамигъ мәчете төзелеп бетә (*Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. 251 б.*). Аны төзүдә төп иганәчеләр сәүдәгәрләр булуы шик уятмый. Ислам дине дәүләт дине булгач, дәүләт эшлеклеләре дә ислам дине институтларын төзүгә һәм ныгытуга матди ярдәм иткәннәр.

*Мәмләкәт составында күптән исламлашкан өлкәләр булу*. Әйткәнебезчә, монголлар тарафыннан җимерелгән Урта Азия шәһәрләре Бату идарә итә башлаганда бер-ике дистә ел эчендә торгызылып, мәктәп-мәдрәсәләр аркылы яңа буын ислам руханиларны хәзерләүне җайга сала. Болгар шәһәре Алтын Урданың беренче башкаласына әверелгәч, Идел-Чулман төбәге дә күтәрелеш кичерә. Бату карамагында калган салымнарның зур өлеше шәһәрне үстерү һәм тирә-якта коммуникацияләр булдыруга тотылган булуына шик юк. Басып алу сугышлары барышында шәһәрләрне, мәчет-мәдрәсәләрне җимерү җирле мөселман халыкларын дин тирәсендә мобилизацияли, берләштерә, аларның тагын да исламлашуына йогынты ясый. Мәҗүси һәм христиан диненә симпатияләре булган монгол хакимнәре яулаган төрки кавемнәр үз шәһәрләрен кабат ислам дине үзәкләренә әверелдерә, ислам идеологиясен һәм дини практиканы таратуда, һичшиксез, җирле руханилар зур роль уйный. Утрак тормышлы һәм шәһәрләрдәге мөселманнар йогынтысында дала халкы да исламлаша башлый.

В.В. Бартольд Алтын Урданы исламлаштыруда, Идел буе болгарларына караганда, Урта Азия һәм Харәзем төркиләренең роле зуррак булган дип саный (*Бартольд В.В. Двенадцать лекций по истории турецких народов Средней Азии. Соч. М.: Наука, 1968. Т.V. С. 140).*

*Күрше илләрдәге ислам үзәкләренең интеллектуаль яктан һәм кадрлар белән ярдәме.* Урта гасырларда дини фактор, конфессиональ һәм мәдәни берләшүгә нигез булудан тыш, халыкара мөнәсәбәтләргә дә тәэсир иткән. Ислам илләре гарәпчә һәм фарсычаны китап укып өйрәнгән галәмәләр өчен бербөтен мөселман дөньясын тәшкил иткән, алар белем эстәп, укыту өчен яки хакимнәрнең чакырулары буенча бер илдән икенчесенә иркен күченеп йөргәннәр. Дөньядагы ислам үзәкләре төркиләр кулына күчкәч, гарәп, фарсы телләре белән янәшә Алтын Урда җирләрендә төрки тел һәм әдәбият ислам мәдәнияте буларак үсеп китә. Шул рәвешле, ислам динен төрки китап телендә таратырга мөмкинлек туа *(Бартольд В.В. Ислам // Бартольд В.В. Сочинения. В 6 т. Т. 6. М.: Наука, изд-во вост. лит-ры, 1966. С. 195).*

Шулай ук дәүләт башлыкларының үзара дус-тату мөнәсәбәтләре, илчеләр алмашу, мәчетләр төзергә ярдәм күрсәтү, галәмәләр чакыру мондый элемтәләрне ныгыткан һәм тотрыклы иткән. 1258 елда Габбасилар хәлифәте тар-мар ителгәч тә, Илханнар дәүләте белән көрәш барышында Мисыр, Каһирә белән эзлекле сәяси һәм мәдәни элемтәләр ныгый, күрше Бохара галәмәләренең дә тәэсирләре көчле була.

## Мөселман миссионерлары

Г.М. Дәүләтшин бик хаклы рәвештә Алтын Урдада ислам эчендә суфичылык рәсми статуска ия була дип яза *(Дәүләтшин Г.М. Күрс.хезмәт. 271 б).* Мәчетләрдә намаз белән җитәкчелек итүче руханилардан аермалы буларак, суфи дәрвишләр халыкка исламның эчтәлеген һәм рухын гади һәм үтемле итеп төшендерәләр. Аларның әхлакка нигезләнгән, байлыктан ваз кичкән тормышы ярлы-ябагайга якын-аңлаешлы булган, төгәлрәк әйтсәк, суфилар шул халыкның аерылгысыз өлеше кебек кабул ителгән. *(Тримингэм Дж. Суфийские ордены в исламе / Пер. А.А. Ставиской, под ред. и с предисл. О.Ф. Акимушкина. М.: Наука, Гл. ред. вост. лит-ры, 1989. С. 183, 184, 185).* Иң мөһиме – суфилар җирле мәҗүси традицияләрне үзләренә «сеңдереп»,

аларны халык массаларына мөселманча кодлаштырып кире кайтарып бирә алганнар *(Акимушкин О.Ф. Суфийские братства: сложный узел проблем // Тримингэм Дж. Суфийские ордены в исламе. М., 1989. С. 5).*

Хуҗа Әхмәд Ясәви (1166 елда үлә) тарафдарлары ислам динен күчмәннәр арасында таратуга зур көч куялар. Ясәви нигезләгән суфи тәгълимат фәкать төрки халыклар арасында барлыкка килгән дини-мәдәни күренеш була. Әхмәд Ясәви башта шәех Арслан-Бабадан өйрәнә, остазы вафатыннан соң, шәех Йосыф әл-Хәмәданидә (1140 елда үлә) белем туплау өчен, ул заманда китап теле фарсы булган Бохарага бара. Соңрак Төркестан шәһәренә кайта һәм төрки шәехләр һәм суфилар әзерли башлый *(Тримингэм Дж. Күрс. хезмәт. С. 25, 54).* Әхмәд Ясәви үзе аңлаган дин гыйлемен катлаулы трактатлар ярдәмендә түгел, ә «хикмәтләр» – ике яки дүртьюллык шигырьләр рәвешендә гади халыкка җиткерә, бу текстлар үзенә күрә дини дәреслек һәм бер үк вакытта әхлак кодексы вазифасын үти, патриархаль-ыруг мөнәсәбәтләре көчле булган төрки халыкларда буыннан-буынга тапшырылып килә. Риваятьләрдән күренгәнчә, Әхмәд Ясәви үзенең 990 ышанычлы укучысын төрки кавемнәр арасында ислам һәм тәсаувыф нигезләрен тарату өчен төрле тарафларга, шул исәптән Идел һәм Урал буйларына да җибәргән *(Сибгатуллина Ә. Илаһи гашыйклар юлыннан. (Суфичылык турында очерклар). Казан: «Кыйбла» нәшр., 1999. 28, 29 б.).*

Әхмәд Ясәвинең укучылары шәехләр Хәким Ата (1183 елда үлә) һәм Сәет Ата (1218 елда үлә) дингә дәшү эшчәнлеген Сырдәрья һәм Идел елгалары буйларында, Көнчыгыш Төркестанда җәелдерәләр. Шул рәвешле, Ясәвия тарикате тарафдарларының көчәюе һәм Урта Азия далаларында халыкны исламлаштыру янәшә бара *(Кныш А.Д. Мусульманский мистицизм: краткая история / пер. с англ. М.Г. Романов. СПб.: изд-во «ДИЛЯ», 2004. С. 312-313).* Ясәвинең дәвамчысы Хуҗа Бикташи, үз чиратында, йөзләрчә күченеп йөрүче дәрвишләргә остаз була.

Югарыда аталган Әхмәд Ясәви укыган Йосыф әл-Хәмәдани шәехнең дүртенче хәлифәсе Габделхалик Гыйҗдувани (1179 елда үлә) Хаҗиһания тарикатенә нигез салган.

XIV гасырда Ясәвия тарикате Урта Азиядә элекке көчле йогынтысын югалтып, беренче урынга Нәкышбәндия тарафдарлары чыга. Баһаветдин Нәкышбәндинең, дини догаларыннан һәм сакланып килгән сүзләреннән тыш, язма мирасы билгеле түгел. Бу тарикать тарафдарларының төп максаты – рухны чистартып, тазартып, илаһи сафлык дәрәҗәсенә ирешү һәм илаһиятка кушылу була (*Сибгатуллина Ә. Күрс.хезмәт. 91, 92 б.).* Нәкышбәнди фикерләренең утрак тормыш алып барган мөселманнар һәм күчмәннәр арасында киң таралуына суфиларның бердәмлеге һәм структурасының берләшүгә корылганлыгы сәбәп дип санала *(Бартольд В.В. Ислам // Бартольд В.В. Сочинения. В 6 т. Т. 6. М. Наука, изд-во вост. лит-ры, 1966. С. 119).* XV гасырда Төркестанда эре җир биләүче, чынлыкта төбәкнең идарәчесе булган суфи Хуҗа Әхрар (1404-1490) тарикатьнең эшчәнлеген мөселманнарны тираннардан саклау белән дә бәйли, шуңа күрә без хакимнәр белән аралаштык, аларга йогынты ясау юлы белән эшчәнлекләрен контрольдә тоттык дип әйтә. Ул Нәкышбәнди тарикатенең социаль-сәяси юнәлешен түбәндәге сүзләр белән билгели: «Дөньяда рухи миссияне үтәр өчен сәяси хакимияттән файдалану мәҗбүри» (*Хисматулин А. А. Суфийская ритуальная практика: (На примере братства Накшбандийа). СПб.: Центр «Петербургское Востоковедение», 1996. С. 27).*

Җучи Олысында мөселман дәгъватчыларының йогынты ясау һәм вәгазьләү объектлары дип, кемнәрне күрсәтеп була соң? Беренче төркем – шиксез, мәҗүси монгол ханнары һәм аларның туган-тумачалары, хатыннары һәм дәүләт чиновниклары: аларны исламлаштыру сәяси эчтәлектә булган – мөселманлыкны кабул иткән хан аркылы дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәтенә йогынты ясау, руханиларга һәм мөселманнарга ниндидер өстенлекләр алдыру мөмкинлеге ачылган. Икенче төркем – утрак тормыш алып баручы мөселман динендәге төрки һәм башка халыклар. Өченче төркем – Идел-

Чулман төбәгендә яшәгән фин халыклары һәм башка мәҗүси төркемнәр. Дүртенче һәм иң зур төркем – Жучи Олысының күпчелек халкын тәшкил иткән күчмәннәр – кыпчак кабиләләре. Аларның христиан дәүләтләре чигендә көн күргәннәре яки алар белән хезмәттәшлек иткәннәре берничә гасыр эчендә күршеләре йогынтысында яңа дин кабул итәләр һәм үзаңнарын алыштыралар. Әйтик, Грузия чикләрендә яшәгәннәре патша Давид IV (1125 елда үлә) үрнәгендә христианлаша. Икенче Болгар дәүләте (1185 – 1396) белән идарә иткән кыпчакларның славянлашуы яңа дин кабул итү белән үрелеп бара. Ә Византия гаскәренә хәрби хезмәткә кергән төркиләрне мәҗбүри чукындырып православ ясаганнар. Венгрия җирләрендә урнашкан кыпчаклар XIII гасырда католик динен кабул итә башлый, бирeдә Куман епископиясе оештырыла, шулай итеп, бу төркемдә XV гасырда мәҗүсилек элементлары юкка чыга һәм ассимиляцияләшә.

Алтын Урда дәүләте оешкан елларда Урта Азия төбәгендәге кыпчаклар беркадәр исламлашсалар, сахрада мал көтеп күченеп йөргәннәре несториан динендә була. Дөрес, аларның дини карашлары һәм практикасы электе мәҗүси гореф-гадәтләр белән үрелеп, синкретик характер алган. Әйтик, алар арасында яңгыр чакыртучы сихерчеләр популяр булган. XIII гасырда Сарай шәһәре халкы шуларның берсенә, яңгыр яудырсын өчен, җыеп акча түли торган булган *(Пилипчук Я.В. Выбор веры в Дешт-и-Кипчаке. Существовали ли альтернатива исламу?) // Ислам и власть в Золотой Орде. С. 203-231)*. Кыпчакларга ислам йогынтысы утрак тормышлы мөселманнар белән янәшә контакт зоналарда көчле булган. Далада динне нигездә күчмәннәргә ияреп йөреп, тирмәләрдә балаларны укытучы, ислам нигезләрен һәм шәригатьне аңлатучы Ясәвия тәрикате дәрвишләре тараткан *(Нуртазина Н.Д. Ислам в истории средневекового Казахстана (историко-культурологическое исследование): монография. Алматы: «Фараб», 2000. С. 229)*.

## Бәркәнең ислам динен кабул итүе

Батудан соң тәхеткә аның улы, несториан динен тотучы Сартак утыра, ләкин ул бик аз идарә итеп кала: үтерелә һәм дин өлкәсенә ниндидер үзгәрешләр кертергә өлгерми.

Шунысы да игътибарга лаек, әле тәхеттә Бату утырган заманда, 1242 елда мөселман булган Бәркә үзенең ислам динен кабул итүен җиткерү өчен имамга яки голәмә янына бармый, ә Бохара шәһәренә килеп, бу хакта Кубравия тарикатенә нигез салган Нәҗмеддин Кубраның укучысы Сәйфетдин Сәид әл Бәхәрзигә хәбәр итә *(Тримингэм Дж. Күрс. хезмәт. С.61,62)*. Шул елларда Бәркә Багдад хәлифе белән хат алыша башлый, хәлифтән кыйммәтле бүләкләр кабул итә. Тәхеткә утыргач, мөселман уку йортлары ача һәм дин галимнәренә һәрвакыт хәерхаһлы була.

1256 елда Иранга һөҗүм иткән Тулуй ханның улы Һөләгү 1258 елда Багдадны камый һәм хәлифәтнең башкаласын басып ала, хәлиф Мөкътәсимне үтерә. Бу кампаниядә элекрәк Бату җибәргән Алтын Урда гаскәрләре дә катнаша. Багдадны алу һәм анда мөселманнарга карата кулланылган җәза-үтерешләр кризиска кереп барган ислам цивилизациясен XIX йөз – XX гасыр башына кадәр диярлек дәвам иткән фикер торгынлыгы упкынына төшерә.

Чыңгызхан Йасасы буенча, басып алынган җирләр биш өлешкә бүленеп, аның ике өлеше олугъ монгол ханына, ике өлеше гаскәргә һәм бер өлеше Бату йортына бирелергә тиеш була. Ләкин Һөләгү Бәркәгә беркадәр бүләкләр җибәрү белән чикләнә. 1261 елда Бөек Монгол ханы Мәнгүдән соң тәхеткә утырган Кобылай Иран җирләрен яулаган Һөләгүне бу җирләрнең хакиме дип таный һәм «илхан» исеме бирә. 1262 елда Бәркә, Йасага сылтама ясап, хәрби ярдәм күрсәткәне өчен Һөләгүдән үзенә Азәрбайҗанны һәм Грузияне бирүен таләп итә. Бу низаг, ахыр чиктә, Бәркә һәм Һөләгү ханнар арасында, киләчәктә Алтын Урда һәм Һөләгүлеләр дәүләте – ягъни идарә башында бертуган чыңгызлылар торган илләр – арасында 100 ел чамасы дәвам итәчәк сугыш башлануга һәм канкойгыч бәрелешләргә сәбәп була. Башта ул дини эчтәлектәрәк кабул ителә:

мөселман Бәркә мәҗүси туганы белән сугыша. Соңрак Һөләгүнең дәвамчысы ислам динен кабул иткәч, мөселман чыңгызлылар арасында яңа биләмәләр өчен канкойгыч сугыш рәвешен ала *(Закиров С. Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом. М.: Наука, гл. ред. вост. лит-ры, 1966. С.10-17)*.

Бәркә тәхеткә утыргач та, башка диннәргә карата түземлелек сәясәте дәвам итә. Моның ачык мисалы булып 1261 елда Сарай шәһәрендә православ епархия оештырырга рөхсәт итү тора (*Закиров С. Күрс. хезмәт. С.56)*. Һөләгүлеләр белән көрәштә Бәркә һәм Мисыр солтаны мәмлүк Бәйбарс (1260 – 1277) союзникларга әйләнә. Соңгыларының ата-бабалары монгол яуларыннан соң Идел буеннан Мисырга коллар итеп китерелгән һәм башта сугышчылар, аннары хакимиятне үз кулларына алган мәмлүкләр исеме белән билгеле, 1517 елга кадәр Мисыр һәм Сүрия белән идарә итәләр. 1261 елда Мисыр солтаны кулына Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре күчә, шуңа күрә дә ислам дөньясында аның авторитеты арта. Бәркә1262 елда дин үзәге булып танылган Каһирәгә илчеләр җибәреп, исламның Җучи Олысында рәсми дингә әйләнгәнен хәбәр итә *(Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. С.431)*.

Гаскәре белән Һөләгүлеләргә каршы чираттагы сугыш белән Тифлис ягына барганда, Бәркә 1266 елда юлда үлә.

1270-71 елларда мөселман динен кабул иткән бәкләрбәге Иса-Нугай дәүләт эшләрендә мөһим урын тота. Ул яңа хан итеп Батуның оныгы Мәнгү- Тимерне (1282 – 1287) сайлата һәм аның исеменнән идарә итә. Шәехләр һәм суфилар белән аралашып, хан дин юлына кереп китә һәм дәүләт эшләреннән читләшә. Мәнгү-Тимернең балалары һәм туганнары, аның тормышы һәм фикер сөреше ислам йогынтысына буйсынуга ризасызлык йөзеннән, тәхеткә мәҗүси Теле-Буганы (1287 – 1291) утырталар.

Бәкләрбәге Иса-Нугай, моның белән килешмичә, тәхеткә Мәнгү-Тимернең алты улының берсе Туктаны (1291 – 1312) меңгерә. Соңгы елларда Тукманың ислам диненә уңай мөнәсәбәттә булуын раслаучы өстәмә дәлилләр табылды. Археологлар аның тарафыннан 1307–1308 елларда Үкәк шәһәрендә һәм 1310-11 елларда Сарай әл-Мәхрүсә каласында сугылган акчаларда «солтан» һәм «гыяс әд-дин» («динне коткаручы солтан») дип язылган тәңкәләргә юлыктылар. Шушы ачыш нигезендә тарих фәнендә Тукта якынча 1306-1308 елларда ислам динен кабул иткән дигән фикер урнашты. Моңарчы әл-Мофаззал исемле гарәп елъязмачысының 1304-05 елларга караган хәбәрендә Тукта ислам динен кабул итте дигән хәбәре бар иде. Хәзер бу текстның дөреслеге археологик табылдыклар белән дә расланды *(Исхаков Д.М. Проблема «окончательной» исламизации Улуса Джучи при хане Узбеке // Ислам и власть в Золотой Орде. Казань, 2012. С.134)*.


Алтын Урда оешкан дәвердә биредә калган монголларның күбесе мәҗүси яки христиан дине тәгълиматының бер агымы булган несториан дине тарафдарлары була. Ул, кыпчаклар арасында таралган несториан дине кебек үк, синкретик төстә, бик күп төрле мәҗүси күзаллауларга һәм гадәт-йолаларга нигезләнә *(Пилипчук Я.В. Күрс. хезмәт. С. 209)*.

Нәтиҗә ясап, монгол элитасында исламлашу Бату идарә иткән заманда ук башланганлыкны, Бәркәнең беренче мөселман идарәчесе булуын күрсәтергә кирәк. Ләкин ул елларда исламлашу Бәркәнең аралашкан даирәсе белән чикләнгән дип уйланыла. Бер үк вакытта Идел-Чулман һәм Урта Азия төбәкләрендә игенчеләр, һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр белән аралашкан һәм янәшә яшәгән күчмәннәр утрак тормышлы мөселманнарның икътисади һәм мәдәни йогынтысына эләккәннәр.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

*Галимҗан Ибраһимовның тууына – 135 ел*

# БЕЗНЕҢ КӨННӘРНЕ ДӘ ЯЗГАН ӘДИП



Татар халкының бөек әдибе, галим һәм дәүләт эшлеклесе, Хезмәт Батыры Галимҗан Ибраһимовның (1887-1938) юбилее матбугат, әдәбият-сәнгать оешмаларына язучының иҗатын халык күңелендә яңарту өчен матур бер форсатка әверелде. Ай дәвамында уку йортларында, китапханәләрдә, мәдәният сарайларында әдәби очрашулар, китап укучылар конференцияләре, кичәләр үткәрелә. Әлбәттә, бу чаралар әле дәвам итәчәк.

Татарстан радиосы исә әдипнең юбилее уңаеннан берничә юнәлештә эш алып барды. Беренчедән, Галимҗан Ибраһимовка кагылышлы архив язмалары хәрәкәткә китерелде. Алар биредә берничә дистә берәмлек тәшкил итә. Иң әүвәлге язмалар 1957 елга карый. Алар – «Тирән тамырлар» һәм «Татар хатыны ниләр күрми» романнары буенча эшләнгән радиотамашалар. Язмаларны тыңлаганда, без Галиәсгар Камал исемендәге театрның шул замандагы легендар артистларының тавышларын да ишетәбез. Шулай ук  режиссёр Әхтәм Зарипов тарафыннан инцинировкасы язылган һәм куелган «Без түбәннән күтәрелдек» дигән радиоспектакль (1966 ел), Ринат Таҗетдинов һәм Габдулла Фәтхуллин катнашындагы «Карт ялчы», Шәүкәт Биктимеров белән Вера Минкина башкарган «Көтүчеләр» радиотамашалары (1967 ел) эфир өчен әзерләнде. Юбилей елында тагын әле зур күләмле «Безнең көннәр» радиоспектакле, «Алмачуар», «Башкорт кызы Гөлбикә» (Ирек Баһманов язмасы), «Табигать балалары» (Айрат Арсланов язмасы), «Карак мулла» (Фирдүс Гыймалтдинов укый) хикәяләре, «Адәмнәр» повесте (Әзһәр Шакиров укый) тыңлаучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителәчәк. Әдипкә багышлап әзерләнгән тапшыруларда Сибгат Хәкимнең 1977 елда Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тулу уңаеннан ясаган чыгышы, Рафаэль Мостафинның әдипнең 100 еллыгында Гомәр Бәширов һәм Мөхәммәт Мәһдиев белән үткәргән әңгәмәләре файдаланылды.

Быел Татарстан радиосында тагын бер зур вакыйга көтелә. Бу көннәрдә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Галимҗан Ибраһимовны чын мәгънәсендәге әдип иткән әсәрләрнең берсе – «Казакъ кызы» романы нигезендә тулы метражлы радиоспектакль әзерләнә. Рольләр Г.Камал, К.Тинчурин исемендәге театрларның танылган актёрлары тарафыннан  башкарыла. Бу әсәр яз айларында эфирга чыгар һәм ул язучының юбилеена багышланган эшебезнең таҗы, әдәбият сөючеләргә олы бүләк булыр дип өмет ителә.

Хәзер исә Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары» дигән мәшһүр хикәясен Айрат Арсланов язмасында тыңларсыз.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

# МӘҢГЕ ТУЗМЫЙ ТОРГАН «БАШМАК»



*«Башмагым»нан күренеш.*

Татар театр сәнгатенең мәңге искерми, карап туеп булмый торган әсәрләре турында сүз чыкканда, «Башмагым» музыкаль комедиясе дә күз алдына килеп баса. Аның дөньяга ялау тарихы кызыклы һәм бу тарих Кайбыч районы басу-кырларыннан башланып китә. Бөек Ватан сугышының беренче кышында биредә оборона сызыгы төзү эшләре алып барыла. Казаннан бик күп халык, шул җөмләдән мәдәният-сәнгать хезмәткәрләре дә, окоп казырга җибәрелә. Танылган композитор Җәүдәт Фәйзи язучы Гадел Кутуй җитәкчелегендәге бригадага эләгә. Әнә шул авыр, катлаулы көннәрдә Кутуй аңа халык күңелендә якты хисләр уята, яшәү дәрте бирә торган шаян әсәр язарга тәкъдим итә. Татар театр сәнгатендәге беренче музыкаль комедия – «Башмагым»ның идеясе зәмһәрир суык көннәрдә көрәк, кәйлә, лом белән туң балчык чокыган чакта туа. Күренекле драматург Таҗи Гыйззәт булачак спектакльнең либреттосын язарга алына. Әсәр башкорт драматургы Хәбибулла Ибраһимовның шул исемдәге пьесасына нигезләнә. Җәүдәт Фәйзи аның музыкасын 3 ай эчендә язып өлгертә.

Премьера 1942 елның 1 мартында Казанда уза. Сугыш вакыты таләпләрен үтәп, тамашачылар энә күзеннән үткәрелеп тикшерелә, шуңа күрә спектакль 3 сәгатькә тоткарлык белән башлана. Беренче куелышта Галимҗан ролен – Фәхри Насретдинов, Сәрви ролен Галия Кайбицкая һәм Шәфика Котдусова башкара. Спектакльне атаклы режиссёр Сөләйман Вәлиев-Сульва сәхнәгә куя, оркестрга Ильяс Әүхәдиев дирижёрлык итә.

Әнә шул көнне «Башмагым» татар халкы күңеленә мәңге онытылмаслык булып кереп урнаша. Ул татар театрлары сәхнәләрендә генә дә 600 тапкыр күрсәтелә, тамашачы аны рус, украин, үзбәк, казакъ телләрендә дә ишетте.

Яңа гасырга атлап кергәч, Җәүдәт Фәйзинең тууына 100 ел тулу уңаеннан Казан Дәүләт консерваториясенең опера студиясе әсәргә яңа сулыш бирде. Спектакльдә консерваториянең Ринат Халитов җитәкчелегендәге «Татарика» оркестры, Казан музыка училищесының Венера Гәрәева җитәкчелегендәге татар хоры һәм бүгенге көндә инде танылган яшь җырчылар – Филүс Каһиров, Айгөл Хәйри, Артур Исламов, Илдар Әхмәтов, Руслан Абдрафиков кебек консерватория студентлары катнашты. Бу юлы да премьера республикабыз тормышында күтәреп алынган вакыйга булды. Спектакльдән соң сәнгать белгечләре билгеләп үткәнчә, ул «классик традицияләрдә эшләнгән, ләкин шул ук вакытта бик тә заманча яңгыраган, татар җәмәгатьчелегенең инде күптәннән уй-хыялында йөргән, зарыгып көтеп алынган чын татар музыкаль комедиясе булды». Киләчәктә дә «Башмагым»ның яңа куелышлары әле булыр дип өметләник, чөнки халык аны һәрвакыт көтеп алачак.

Мәкаләгә иллюстрация рәвешендә спектакльдән фрагментлар тәкъдим ителә.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# НӘФИС ЗАТНЫҢ КӨЧЛЕ ҖИЛКӘСЕ...



*Бүгенге көндә хатын-кызларның җитәкче урыннарда эшләве беркемне дә гаҗәпләндерми. Киресенчә дә әле. Дилбегәне үз кулларына алып, тормышның төрле өлкәләрендә уңышка ирешкән туташ-ханымнарга сокланып карыйбыз.*

Шундыйларның берсе – бүгенге героебыз Раилә Хисмәтуллина Теләче районындагы «Нәүрүз» авыл хуҗалыгы кооперативын җитәкли. Кукмара районының гүзәл табигатьле Югары Шәмәрдән авылында туып үскән Раилә Нәкыйп кызына сала тормышының бөтен яклары таныш. Әти-әнисенең алны-ялны белмичә колхозда тир түккәнен күреп үссә дә, язмышын авыл белән бәйләргә курыкмый ул. Мәктәпне тәмамлаганнан соң нинди һөнәр сайлыйм дигән сорау да тумый – республика һәм ил агросәнәгать комплексы өчен берничә дистә мең белгеч әзерләгән Лаеш авыл хуҗалыгы техникумына юл тота Раилә Нәкыйп кызы.

Бүгенге көнгә җитәкче ирешкән уңышларның иң зурысы дип, ул җитәкләгән «Нәүрүз» авыл хуҗалыгы кооперативын атарга була. Әлеге кооперативта сиксәнгә якын кеше эшли. Авыл җирлегендә шулкадәр эш урыны булдыру – үзе үк уңай күрсәткеч. Шуның өстенә җитәкче моннан берничә ел элек заманында район брендына әйләнгән май җитештереп, әмма банкротлыкка чыккан сөт-май комбинатын торгызырга алына.

– Предприятиене ачып җибәргән чакта дәүләт тарафыннан бирелгән грантлар нык ярдәм итте, – дип сөйли ул бүген. – Алар ярдәмендә ташландык заводны ремонтладык, алдынгы технологияләргә нигезләнгән, заманча җиһазлар сатып алдык, чистарту корылмасы төзедек, үз эшләренең осталары булган белгечләрдән, эшчеләрдән торган хезмәт коллективы туплადык. Элеккеге завод ябылгач, чит районнарга эш эзләп киткәннәр дә кире үзебезгә кайтты. Шунысы сөенечле: күбесе – яшьләр.

Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате тармагы белән сүздә генә түгел, гамәлдә таныш Раилә Хисмәтуллина сыр, май базарының бөтен нечкәлекләрен өйрәнә. Аның таркалган җитештерү объектларын эшләтеп җибәрү һәм аларга яңа җиһазлар алып, яңа технологияләр кертеп, аякка бастыру тәҗрибәсе дә бар. Авыл кызы булуы да файдага гына: бирердәге тормышны, сала кешеләрен, аларның психологиясен яхшы белә. Кечкенәдән авыл хезмәтен белеп, танып һәм яратып үскән, үз көченә, үз кулларына һәм белеменә ышана торган җитәкче белән эшләве кул астындагылар өчен дә ышанычлы күрсәткеч.

– Үз алдыбызга башкалар өчен үрнәк булу максатын куйдык. Шуңа күрә Польша, Испания, Белоруссиядә урнашкан заводларга барып, аларның эш тәҗрибәсен өйрәнеп кайттык. Шуның нәтиҗәсендә иң яхшы агрегатлар сатып алдык, алдынгы эш оештыру алымнарын гамәлгә керттек.

Уңышның тулы бер команда хезмәтенә бәйле булуына нык инанган кеше Раилә Нәкыйп кызы. Аның фикеренчә, коллективта аерым бер бригада гына аерылып, беренче урынга чыга, башкалардан яхшы булып күренә алмый. Шуңа күрә дә ул үз тирәсенә оста һәм җаваплы белгечләрне туплаган, алар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне җайга салган. Бу да үз нәтиҗәсен бирә – эшләрендә өзеклек туганы юк.

Социаль-икътисади үсеш ягыннан караганда, шундый зур җитештерү предприятиесе барлыкка килү – район өчен дә зур вакыйга. Бер яктан, район бюджетына өстәмә салым кертемнәре килсә, икенче яктан җирле халык үзендә җитештерелгән ризык белән туклана. Заводта тәүлеккә җиде тонна ярым каты сыр, бер тонна сыер мае

җитештерелә. Кулланучылар ихтыяҗын төрле яклап канәгатьләндерү йөзеннән күптән түгел эретелгән сыр цехы ачылган. Бу да – «Нәүрүз» кооперативы өчен тагын бер әһәмиятле адым. Беренчедән, әлеге цех калдыкларсыз эшләү мөмкинлеге тудырса, икенчедән, төрле тәмдәге сырларның ассортиментын киңәйтергә мөмкинлек биргән.

Теләчедә ясалган сыр сәүдә нокталарына барып җиткәнче яки кибет киштәсенә «менеп кунаклаганчы», сыйфат билгесе алу өчен берничә кат тикшерү уза. Иң әүвәл аны мастер тикшерә. Продукцияне сәүдә нокталарына һәм кибет киштәләренә җибәрү өчен машиналарга төягәндә май һәм дымлылык күләме билгеләнә, органолептик (төсе, исе, тәменә карап) бәяләмә бирелә.

– Барлык технологик этапларда да биредә җитештерелә торган сөт продукциясенең сыйфаты, санитар культура ныклы контроль астында. Бу исә, үз чиратында, кулланучыларга чын мәгънәсендә тәмле, файдалы, натураль продукт тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә, – ди җитәкче, горурланып.

Сыйфатлы сырның фәкать югары сыйфатлы сөттән генә ясалганын һәркем яхшы аңлый. Шуңа күрә дә кооператив ышанычлы җирле сөт җитештерүчеләр, шулай ук уткүршеләр – Кукмара, Саба һәм Арча районнары фермерлары белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Предприятиедә чималның сыйфатын ныклы контрольдә тотучы өч лаборатория эшләп килә. Сөтнең сыйфаты физик-химик күрсәткечләр буенча стандартларга туры килүе, майлылыгы, тыгызлыгы һәм башка төрле үзенчәлекләре аша билгеләнә. Сөтне кабул иткәндә, аның санитар микробиологик халәтенә зур игътибар бирелә. Биредә бер генә килограмм сөт тә ветеринария хезмәте белешмәсеннән башка кабул ителми. Төрле тәмләткеч өстәмәләр, майлар куллану турында сүз дә була алмый.

Теләче продукциясе Татарстан шәһәр һәм районнарына, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Түбән Новгородка һәм Россиянең башка бик күп төбәкләренә озатыла. Продукциянең сатып алучылар арасындагы популярлыгының сере исә алдынгы технологияләр белән беррәттән, биредә эшләүчеләрнең җан җылысы, эшне ярату хисләре кушылып җитештерелгән булуындадыр, мөгаен.

Уңышка омтылган, моның өчен бар тырышлыгын куеп эшли торган һәм соңгы нәтиҗәнең уңышлы булачагына нык ышанган Раилә Нәкыйп кызын яңа гына үз эшен башлап җибәрергә уйлаучыларга үрнәк итеп күрсәтәсе килә. Аның бетмәс-төкәнмәс энергиясенә, һәр яңалыкны җентекләп өйрәнеп, кирәк дип тапкан очракта үз эшенә кертеп җибәрергә омтылуына күпләр соклана.

– Хезмәткәрләрем, безнең продукцияне кулланучылар алдында җаваплылык тоям, – ди әңгәмәдәшем.

Шуңа күрә коллективта хезмәт хакына бәйле мәсьәлә күтәрелми дә. Ул төгәл билгеләнгән көнне бирелә. Шулай ук хезмәткәрләргә һәм район халкына уңайлы булсын өчен, үзләре җитештергән сөт ризыклары белән беррәттән, киштәләрендә Кукмара икмәге, кулинария ризыклары, печенье, кәнфит ише башка тәм-томнарны күрергә мөмкин булган фирма кибете дә ачканнар. Эштән соң әллә кая барып, азык-төлек эзләп йөрисе юк. Күптән түгел генә ашханәле дә булганнар. Монысы да хезмәткәрләрне кайгырту, ял вакытын дөрес итеп оештыруга кайтып кала.

Ял дигәннән, вакыты никадәр генә тыгыз булса да, героебыз китап укырга, үзен рухи һәм физик яктан формада тотарга тырыша. «Китап бит ул – тормыш көзгесе. Нинди генә сюжетлы әсәр укырга алынсаң да, тормыштагы хәлләр белән аваздаш була ул. Күпмедер вакыт борчып йөргән сорауларга геройлар сүзе аша җавап табу да файдага гына», – ди җитәкче.

Һәрдаим яңалыкка омтылу, авырлыкларга бирешмичә максатыңа тугры калу, ирешкән уңышның тәмен тоеп яшәү – болар барысы да Раилә Нәкыйп кызына хас сыйфатлар. «Татар эшмәкәре нинди була?» дип сораучыларга нәкъ Раилә Хисмәтуллинаны мисал итеп китерү урынлы булыр, мөгаен.

**Ландыш НӘСЫЙХОВА**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### «ТАТМЕДИА» ХИСАП ТОТТЫ

Казандагы IT-парк бинасында «ТАТМЕДИА» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының киңәйтелгән коллегия утырышы булып узды. Анда агентлык җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев доклад белән чыкты. Ул милли кадрларга ихтыяҗ, матбугат сәркатипләренең статусын көчәйтү һ.б. мәсьәләләрне күтәрде. Чарада шулай ук «Салават күпере» журналының баш мөхәррире Зилә Хөснетдинова, «Диалог» яңалыклар агентлыгының генераль директоры урынбасары Андрей Цепелев, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Әлфия Хәсәнова, Россия нәшриятлар Ассоциациясе президенты, «Ак шәһәр» сәүдә йорты генераль директоры Константин Чеченев, «Интернетны үстерү институты»ның пиар-директоры Александр Ляпин һ.б. чыгышлары тыңланды.

Киңәйтелгән утырышта Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты һәм чыгыш ясады. Ул медиакырга комплекслы анализ системасын булдыру, аудиториягә мәгълүматны аңа уңайлы каналлар аша җиткерү кирәклеген әйтте, кешеләр турында күбрәк язарга кушты.

2021 елда «ТАТМЕДИА» республикабыз тормышын яктырту бурычын лаеклы үтәде. Утырышта бер төркем журналистларга, медиабазарда хезмәт куючыларга мактаулы исемнәр бирү турында дипломнар, дәүләт бүләкләре, Рәхмәт хатлары тапшырылды.

Коллегиядә «Казан утлары» редакциясе журналның 100 еллык юбилеена багышланган күргәзмә белән катнашты.

### ҖӘЛИЛНЕ ИСКӘ АЛУ

15 февраль – Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең туган көнендә җәмәгатьчелек вәкилләре, язучылар, сәнгать әһелләре каһарман-шагыйрьнең Казандагы 1 Май мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр салды. Җәлилне искә алу тантанасы ТР Милли музеенда дәвам итте. Монда Моабит дәфтәрләренең төп нөсхәсе күрсәтелде. Әлеге чараларда ТР Дәүләт Советының Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов катнашты.

### «МӘҖМУГАИ АСАРЕ»

Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Габдулла Тукай. Мәҗмугаи асаре» китабын (төзүчесе, кереш сүз, искәрмәләр һәм аңлатмалар авторы – Г.Тукай әдәби музее мөдире, филология фәннәре кандидаты Гүзәл Төхвәтова) тәкъдим итү булды. Бу – 1914 һәм 1918 елларда Казанда нәшер ителгән, 1933 елда Токиода басылып чыккан китапның бүгенге татар алфавитындагы, ягъни кириллицадагы беренче басмасы. Г.Тукай әдәби музеенда узган бу кичәдә бер төркем язучылар һәм галимнәр чыгыш ясады.

### ТАНТАНА

Халыкара туган тел көнендә Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган ябык әдәби конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булып узды. Конкурсның жюри рәисе Ркаил Зәйдулла сүзләренә караганда, бәйгегә 1470 әсәр килгән. Җиңүчеләргә диплом һәм сертификатларны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла тапшырды. Тантанада төрле номинацияләрдә жюри әгъзалары Разил Вәлиев, Әлфәт Закирҗанов, Вакыйф Нуриев чыгыш ясады. Чара Рөстәм Насыйбуллин, Илүсә Хуҗина башкаруында җырлар белән үрелеп барды. Тантананы Зөлфия Вәлиева белән Илдар Кыямов алып барды. Фойеда Г.Камал театры оркестры уйнады.

Тантанада ТР Дәүләт Советының Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев, «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Илшат Әминов, ТР Дәүләт Советы депутаты Рамил Төхвәтуллин, ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды директоры Нурия Һашимова катнашты.

Менә алар – әдәби конкурста җиңүчеләр.

**Шигырь (балалар әдәбияты)**

I урын – Әнвәр Шәрипов (Шомырт) «Мин

бит – татар баласы»; II урын – Лилия Фәттахова (Л.Әхмәт) «Суалчан»; III урын – Г.Гаффарова (Назгөл) «Чыршылы аш».

**Хикәя (балалар әдәбияты)**

I урын – Лилия Фәттахова (Л.Әхмәт) «Телефон иясе»; II урын – Булат Ибраһимов (Китап сатучы) «Азалия язмалары»; III урын – Фатыйма Гыйльметдинова (Гомәрия) «Күзәй эзләп үткән җәй».

**Шигырь (үсмерләр әдәбияты)**

I урын – Хәбир Ибраһим (Музей) «Айфон-патефон»; II урын – Йолдыз Шәрәпова (∞) «Медальле эт»; III урын – Гөлүсә Батталова (Сабый акылы) «Җиләктә».

**Хикәя (үсмерләр әдәбияты)**

I урын – Гүзәл Шакирова (Су малае) «Африкада өрәңге үсәме?»; II урын – Гүзәл Шакирова (Бала күңеле) «Җиләк тәме»; III урын – Ләйсән Абдрахманова (Nisan) «I had a friend» (Минем дустым бар иде).

**Повесть (үсмерләр әдәбияты)**

I урын – Лилия Гыйбадуллина (Хамис Сафиуллин) «Бишенче гомер»; II урын – Алмаз Гыймадиев (Тимербулат) «Киләчәктән килгән малай»; III урын – Илдус Диндаров (Ризаэтдин) «Ак төннәрнең кара көннәре».

**Шигырь**

I урын – Лилия Гыйбадуллина (Нәүрүзбәк) «...көн коела уйчан тәрәзләргә»; II урын – Лилия Гыйбадуллина (Шоңкар) «Кош юлы»; III урын – Фәрсия Зиннурова (Кашкарый) «Туган телем».

**Поэма**

I урын – Лилия Гыйбадуллина (Әхмәр) «Гали Рәхим»; II урын – Рафис Корбанов (Бүре) «Казан»; III урын – Марат Кәбиров (КАФ) «Автомат һәм шигырь дәфтәре».

**Хикәя**

I урын – Рүзәл Мөхәммәтшин (Бохара мәчесе) «Лаләләр»; II урын – Ләйсән Низамова (Низам) «Тиле»; III урын – Илсөяр Иксанова (Ишмәк) «Матәм».

**Повесть**

I урын – Наилә Харисова (Үксез бала) «Үтте инде»; II урын – Марат Кәбиров (Марка) «Тик син генә...»; III урын – Хәбир Ибраһим (Бала) «Исемлек».

**Роман**

I урын – Зөлфәт Хәким (Әлиф Кирмән) «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?»; II урын – Фирдүс Гыймалтдинов (Сабирулла) «Урда ханы Үзбәк»; III урын – Равил Сабыр (Авыл-Мәркәз) «Фәхрине үтереп ташладылар».

## РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА – ТҮБӘН КАМА КУНАГЫ

«Кунакчыл Түбән Кама» проекты кысаларында Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист Ркаил Зәйдуллага 60 яшь тулу уңаеннан төрле чаралар үткәрелде. Ул көнне юбиляр Түбән Камага бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләре белән кайтты. Болар – язучылар Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Хәбир Ибраһимов, Вакыйф Нуриев, Илсөяр Иксанова, җырчылар Азат Тимершәех, Рөстәм Маликов. Аларга Чаллыдан Факил Сафин, Лилия Гыйбадуллина өстәлде. Кунакларны Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Рамил Муллин каршы алды. Башта Р.Зәйдулла Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәдә иҗтимагый оешмалар, мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре вәкилләре, укучылар белән очрашты. Аннары язучылар десантын 2 нче гимназиядә каршы алдылар. Монда каләм ияләре укучылар белән очрашты. Кунаклар сынчы-рәссам Бакый Урманче, рәссам Әхсән Фәтхетдинов музейларын карадылар. Р.Зәйдулланың юбилеена багышланган чаралар Т.Миңнуллин исемендәге Татар дәүләт драма театрында бәйрәмдарның иҗат кичәсе белән тәмамланды (чара башланыр алдыннан театрның Кече залын ачу тантанасында Ә.Фәтхетдиновның «Ияләр» циклы турында документаль фильм тәкъдим ителде). Театр директоры Рөстәм Вәлиевнең Ркаил Зәйдулла белән әңгәмәсе рәвешендә барган бу кичәдә шагыйрьнең шигырьләре, җырлары яңгырады. Зәйдулла пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде. Рамил Муллин баш кунакка үзенең котлавын ирештерде.

## СИГЕЗ ТОМЛЫК ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Татарстан китап нәшриятында (соңгы том Казандагы «Фолиант» нәшриятында) чыккан Татар әдәбияты тарихының сигез томын тәкъдим итү булды. Анда томнарны төзүчеләр, галимнәр, язучылар катнашты.

2022 елның 22 февралендә 86 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, публицист **Ягъсуф Долмаган улы Шәфыйков** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Чаллыда җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Буа», повесть Р.УСМАНОВОЙ «Счастье быть прощённым», рассказ Л.НИЗАМОВОЙ «Сумасшедший»; стихи Л.ГИБАДУЛЛИНОЙ, Ф.САФИНА, Э.ХУСАИНОВОЙ, И.КИЯМОВА.*
*Литературный конкурс «Майдан – для батыров!»: Документальная повесть Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Мастер».*
*«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья В.НУРИЕВА.*
*«Казан утлары» – в моей судьбе»: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА.*
*«Литературная критика»: статья Р.РАХМАНИ.*
*Фотоархив: Встречая юбилей.*
*«Наука»: статьи Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, Ю.ШАМИЛОГЛЫ.*
*«Бриллианты эпохи»: воспоминания Б.УРМАНЧЕ (вступительное слово З.МУХАМЕТШИНА).*
*«1100 лет со дня принятия ислама Волжской Булгарией»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 135-летию Г.Ибрагимова и 80-летию премьеры музыкальной комедии «Башмачки». Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*«XI Всероссийский сход предпринимателей татарских сёл»: статья Л.НАСИХОВОЙ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Казанская Ратуша. Фото И.АБРАМОВОЙ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by F.GIMALTDINOV «Bua», novel by R.USMANOVA «Happiness to be forgiven», story by L.NIZAMOVA «Crazy»; poems by L.GIBADULLINA, F.SAFIN, E.HUSAINOVA, I.KIYAMOV.*
*Literary contest «Maydan is for batyrs!»: documentary novel by N.GIMATDINOVA «Master».*
*«To the 100th anniversary of the magazine «Kazan Utlary»: article by V.NURIEV.*
*«Kazan Utlary is in my destiny»: article by T.GALIULLIN.*
*«Literary criticism»: article by R.RAKHMANI.*
*Photo archive: Meeting the anniversary.*
*«Science»: articles by D.ZAGIDULLINA, Y.SHAMILOGLY.*
*«Diamonds of the Epoch»: memoirs by B.URMANCHE (introductory speech by Z.MUKHAMETSHIN).*
*«1100 years since the adoption of Islam by Volga Bulgaria»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Priceless voices»: articles dedicated to the 135th anniversary of G.Ibragimov and the 80th anniversary of the premiere of the musical comedy «Bashmachki» («Slippers»). The column is led by N.AKMAL.*
*«XI All-Russian gathering of entrepreneurs of Tatar villages»: article by L.NASIKHOVA.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life. On our covers: Kazan City Hall. Photo by I.ABRAMOVA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан Ратушасы – Шәһәр мэриясенең вәкиллекле бинасы. *И.Абрамова фотосы.*

---

*Төзәтү: үткән санның («Казан утлары», 2022 ел, № 2) 133 нче битендә «Рәфкать Кәрамигә – 65 яшь» дигән җөмләне «Рәфкать Кәрамигә – 80 яшь» дип укырга.*